8(05)

# казан утлары

1
ЯНВАРЬ-1975



Х. ТУФАН



Ф. ЯРУЛЛИН



М. ХӨСНИМӘРДӘНОВ



М. ВӘЛИЕВ



Х. САРЬЯН

## Котлыйбыз!

«Казан утлары» журналы редколлегиясе инде менә берничә ел рәттән ел дәвамында журналда басылган кечкенә күләмле әсәрләрне — хикәяләрне, шигырьләрне, тәнкыйть мәкаләләрен һәм очеркларны бик җентекләп тикшереп, шуларның иң яхшыларын билгеләп килә. Редколлегиянең чираттагы утырышында 1974 елда журналда басылган иң яхшы һәм яхшы әсәрләр дә ачыкланды. Шигырьләр арасында Хәсән Туфанның журналның җиденче санында басылган шигырьләр циклы һәм Фәнис Яруллинның дүртенче, унберенче саннарда басылган шигырь бәйләмнәре; очерклар арасында Мирхәт Хөснимәрдәновның сигезенче санда басылган «Сиңа тартыла күңел» һәм унынчы санда басылган «Күңелең керсез булса» исемле очерклары иң яхшы дип табылды. Тәнкыйть мәкаләләреннән Мансур Вәлиевнең алтынчы санда басылган «Безгә ак болыт булырга язмаган шул» һәм Хәсән Сарьянның икенче санда басылган «Алай да була! — булмасын» исемле мәкаләләре яхшы дип табылды. Бу иптәшләрнең барысына да журналның бүләге тапшырылды.

Хикәяләр арасында узган ел алай аерып күрсәтерлек дәрәҗәдә үк яхшы әсәрләр булмаганлыгы билгеләп үтелде.

Әсәрләре иң яхшы һәм яхшы дип табылган әлеге иптәшләрне без — журнал редакциясе һәм редколлегиясе чын күңелебездән котлыйбыз, аларга яңа иҗади уңышлар телибез!

Журналыбызның күп санлы укучылары да безнең бу котлавыбызны уртаклашыр дип ышанабыз.

# Казан утлары

**АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ**
**ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ ОРГАНЫ**

1922 елның май аеннан башлап чыга

**1**

ЯНВАРЬ
1975


## Бу санда


М. ХӘСӘНОВ. Хәдичә. Романнан өзекләр . . . 3
Н. АРСЛАНОВ. Батырлык турында. Шигырьләр . 68
Г. МӨХӘММӘДОВА. Яшьлек көннәре. Повесть . 74
С. СӨЛӘЙМАНОВА. Соңгы патрон. Шигырьләр . 97
У. САТТАРОВ. Кызым хикәяләре . . . . . . . 102

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . . 106
К. ЛАТЫЙПОВ. Бүгенге Батыр . . . . . . . . 109

БӨЕК ҖИҢҮГӘ 30 ЕЛ

П. ПАВЛЕНКО. Якташым Юсупов . . . . . . . 116
С. ШАКИР. Империя канцеляриясен штурмлаганда . . . . . . . . . . . . . . . . . 120
ЯН ГРАНТ. Кечкенә инешнең башы . . . . . . 124

ПУБЛИЦИСТИКА

Г. КОНОВАЛОВ. Тарихи язмышлары ягыннан бертуганнар . . . . . . . . . . . . . . . 130

СӘНГАТЬ

Р. ХӘЙРЕТДИНОВ. Музыка профессоры Мансур Солтанов . . . . . . . . . . . . . . . 138

БЕРЕНЧЕ РУС РЕВОЛЮЦИЯСЕНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА

М. АБДУЛЛИН. Беренче рус революциясендә татарлар һәм хәзерге буржуаз историография . 141

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

В. ГАЛИЕВ. Тылмачлар, сәяхәтчеләр, дипломатлар . . . . . . . . . . . . . . . . 147

ИСТӘЛЕКЛӘР

Г. АГИШЕВА. Мәңгелек дуслык пык пык пык пык пык 152



КПССның
ТАТАРСТАН
өлкә
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА һәм
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ә. БАЯНОВ. Үсеш гармониясе . . . . . . . 157

КИТАП КҮЗӘТҮ

Р. МОСТАФИН. Эшче коллектив ничек туа . . 168
М. ГАЛИЕВ. Ачыктан-ачык . . . . . . . . . . 171

ТӨРЛЕСЕННӘН

С. АКБИЕВ. Мулланур Вахитов һәм Сәид Габиев . 174
Б. СӘМИГУЛЛИН. Әдипнең яңа табылган бер рәсеме . . . . . . . . . . . . . . . . 177

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

ӘХМӘТ ИСХАК. Үтенеч хаты. Шигырьләр . . . 178
Осетин мәзәкләре . . . . . . . . . . . . . 182

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

Х. ХАЛИКОВ. Зиләнең курчагы. Шигырьләр . . 186

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 12.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-69.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафаэль Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 2/X-1974 ел. Басарга кул куелды 22/XI-1974 ел. ПФ 09133. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 90.000 экз. Заказ Ю-275. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе, Казан, Декабристлар урамы, 12.

© «Казан утлары», 1974 ел.

Мәхмүт Хәсәнов

# ХӘДИЧӘ

«САФ ҖИЛЛӘР» РОМАНЫНЫҢ
ИКЕНЧЕ КИТАБЫННАН ӨЗЕКЛӘР



Хәдичә, өйалды ишеген ачып тышкы якка күз салу белән, баскан урынында туктап калырга мәҗбүр булды. Мондый да якты, мондый да тыныч төнне күргәне булдымы икән аның?! Ул, шулай бертын хәйран калып, як-ягына каранып торды.

Йа-а, төне лә!

Юк, бер ай яктысы гына түгел иде бу. Бөтен күк йөзен тутырып, гадәттәгедән эрерәк булып күренгән йолдызларның яктылыгы да өстәлгән. Шул сәер яктылык тирә-якны зәңгәрсу төскә манып, кар бөртекләрен берьюлы мең төрле төсләргә кертеп җемелдәтә.

Хәдичәне күңел күтәренкелеге биләп алды, ул, җәһәт кенә баскычтан төшеп, ишегалдыннан үтте дә урамга чыкты.

Авыл кар дөньясына чумган. Урамның буеннан-буена утыртылган агачларны да, скрипка кылларыдай берничә рәт булып сузылган телеграф чыбыкларын да мул булып йөнтәс бәс сарган. Үзе чатлама суык, ә һавада яз исе аңкый. Бу ис Хәдичәнең канын кузгатты, йөрәк тибешен ешайтты, күңелен җилкендереп җибәрде. Тагын язлар да җиттеме инде? Һай-й, бу гомер дигәнең!..

Хәдичә, тәнендә куәт тулылыгын тойган халәттә, урамны бер итеп авылның аргы башына, фермалар ягына таба китеп барды. Эшкә ул һәр вакыттагыча ашкынып, атлыгып атлый. Әмма бүген ул күңелендә ниндидер үзгәреш барлыгын тоя. Аның иң түрендәге иң яшерен кыллары ләззәтле бер киеренкелек белән тартылып чыңлый башларга әзер иделәр. Бу минутта Хәдичә үзен күптән зарыгып көткән кешесе белән күрешергә баргандай хис итте.

Сулыш алуларына кадәр рәхәт, иркен бит. Нәрсәгә юрарга икән күңеленең, йөрәгенең шулай пырдымсызлануын, сәер дулкынлануын?

Әллә Вазихның хаты күңелен шулай урыныннан кузгаттымы? И-и, Вазих, Вазих! Мескенем минем... «Сине бер күрергә зар-интизар булып, кавышачагыбызга өмет итеп яшим», дигәнсең. Мин дә бик сагындым сине, Вазих. Бик юксынам... Менә тагын язлар җитә... Син дә янымда булсаң соң! Юк, булмады. Язмыш күпсенде сине...

Хәдичә шундый хис-тойгыларга бирелеп авылны чыкканын да, ферма каралтылары урнашкан калкулыкка якынлашып килүен дә сизми калган. Әнә алар, солдат казармаларын хәтерләтеп, тигез рәтләргә тезелешеп, әллә кайларга хәтле сузылганнар. Үзе бер шәһәрчекне хәтерләткән бу тирәләр төннең-төн буена гөлт итеп балкып тора.

Хәдичә терлекчеләр йортына барып кергәндә, Гайния апа, өстәл-эскәмияләрне, тәрәзә төпләрен сөртештереп чыгып, идәннәрне юа башларга тора иде.

— Төн тынычлыгын алып кем йөри дисәң, шул син икәнсең әле,— дип каршылады ул Хәдичәне.

— Мин инде, мин, Гайния апа... Кая, чүпрәгеңне бирче. Кәвеш табаннарын сөртим әле...

Тегесе гадәттәгечә күтәренке тавыш белән элеп тә алды:

— Һәй-й, торган булмасана! Үт инде, үт. Чиста кардан гына ич. Ферма эченә кереп йөрмәдең бугай бит әле?

— Юк, кермәдем. Бераз тыныч кына ял итсеннәр, дидем.

— Әй-йе шул. Сине күрсәләр, таналарыңны әйтәм әле, тынычлыкларын тәмам җуялар, шунда ук урыннарыннан дәррәү кубып аяклана-лар. Мал-туарны шул кадәр ияләштерә алуыңа шаклар катам, Хәдичә. Әллә берәр әфсүн-төфсенең, телләрең беләсеңме шуларның?

Хәдичә дәшмәде. Киез итек өстеннән кигән кәвешләрен чак кына сөртештергәндәй итте дә элгечләр янына үтте. Сырмасын салды. Шәлен сырмасының җиңе эченә бөтереп тыкты. Бары тик шуннан соң гына түргә үтеп, киштәдән үзенең көндәлек эшләрен язып бара торган учет журналын алды, ут астында торган озын өстәл янына килде. Стена буендагы эскәмиягә утыру белән, шунда ук җәһәт кенә кире торды.

— Фу-у, билләһи, Гайния апа!..

— Нәрсә булды?

— Югач-югач, яхшырак корытып алсаң иде икән. Үзе юеш, үзе боз кебек салкын...

— Хәзер, хәзер корытам. Бу вакытта килерсең дип кем уйлаган сине.

Гайния апа чүпрәген чайкап алып һәйбәтләп сыкты да, җил-җил килеп, эскәмияне корыта башлады. Аннары, башын чак кына кыйшайта төшеп, Хәдичә ягына борылды. Итләч иреннәре, кысынкы күзләре белән берьюлы елмаеп, теленә салына башлады.

— И-и, Хәдичә, Хәдичә! Шул эскәмияне җылытырлык та кызуың калмадымыни инде?

— Юк инде, Гайния апа, юк. Инде беттек!..— Аннары үкенеченнән тирән көрсенгәндәй итеп өстәп куйды:— Кырыкның өстенә басарга торганда, каян килсен инде ул кызулык. Картаюлар шушыдыр инде. Эх-х, Гайния апакаем, бар иде заманнар! Ут та ут, мин дә ут идем. Суга керсәм, пар чыгар иде...

Хәдичәнең шулай ачылып китүе Гайния апаның да күңеленә бик хуш килде. Ул, белен язарга теләгәндәй, турайды да кеткелдәп көлә-көлә тезеп китте:

— Хак, хак, Хәдичә! Ул кадәресе һәркемгә дә мәгълүм иде.— Көлүдән туктап дәвам итте.— Тик алай тәмам бетешкән булып кыланмачы, зинһар. Кыланма! Көз көнен, моннан биш-алты ай элек булган

хәлләрне исенә төшер... Менә дигән, әүлия кебек кешене үзенә караттың. Ничек кенә әле!.. Үзенә җилбәзәк егет кебек гашыйк булган дип сөйләгәннәр иде.

— Кеше ни сөйләмәс...

Гайния түти Хәдичәне бөтенләй ишетмәгәндәй дәвам итте.

— Әгәр дә хак булса, әнә хәзер дә сине үз янына чакыра ди ич. Ниндирәк уйлар белән яшисең соң?..

— Нинди уй белән яшим ди инде, Гайния апакаем. Бәхетне аны читтә эзләргә кушмаганнар. Башымнан кичереп, сынап караганым бар... Шушы яшькә җиткәч, туган җирдән, сездән аерылдым юк инде.

Бу сүзләрдән соң Хәдичәнең йөзенә кинәт күләгә сарылды, тавышына кадәр үзгәрде.

— Юк инде, юк, Гайния апакаем. Гомерсез юаныч кына булачак ул... Барыбер тормыш булмаячак, тыныч кына яшәргә ирек бирмәячәкләр...

Гайния түти, бу ямен-тәмен югалта башлаган сөйләшүне читкәрәк этәрергә теләгәндәй, җайлап кына әйтеп куйды:

— Гелән алай кылана алмаслар иде әле...

Хәдичә аны шунда ук бүлде:

— Юк инде, Гайния апа, юк! Бәхет дигән нәрсә гомерем буена читләште миннән. Тәкъдиремә шулай язылган, күрәсең. Инде була, инде була дип өметләнеп көткәндә дә бәхет мине һаман әйләнеп үтә торды. Бәхетсезлек дигән нәрсә минем гомерлек юлдашыма әверелде, ахрысы. Җитмәсә тагын, шул бәхетсезлек, нәкъ йогышлы яман чир кебек... Үземә генә түгел, минем белән якынайган яки аралашкан кешегә дә тия, кагыла. Әнә, Вазих та, мескен, семьясыннан читтә яшәргә мәҗбүр...

— Кызлары бик зур урындагы кешеләр, ди шул...

Уен-көлке белән башланган сүзнең шундый кискен борылыш алуы Гайния апаны да сагайтты. Үз эченә бикләнгән Хәдичәнең шулай искәрмәстән генә күңелендәгеи чыгарып селкер дип ул да көтмәгән иде булса кирәк. Бәлки шуңа күрәдер, юк сүзне бар итеп, Хәдичәне юату ягын карады.

— Алай димә, Хәдичә. Син нишләп бәхетсез буласың ди. Типсәң тимер өзәрлек таза, сау-сәламәт хатынсың. Үзең матур, үзең уңган. Менә синең кебек хатыннар турында бит инде: кылны кырыкка ярыр, дип әйтәләр. Кеше алдында йөзең ак, исемең мактаулы, абруйлы. Синең бит өстәмә түләү, яки анда бүләк итеп алган акчаң да безнең кебекләрнең айлык хезмәт хакыннан артыграк...

— Хикмәт акчадамыни!

— Анысы шулай, әлбәттә. Хезмәтеңне дә бит әнә, башкаларга үрнәк итеп куялар. Эшчән бәхетен эшендә күрер ди. Сиңа тагын ни кирәк?

Хәдичә үзалдына сөйләнгәндәй әйтеп куйды:

— Әле дә ярый, шул эш бар... Ансыз кеше — сансыз кеше дигәндәй, кайгы-хәсрәтне шул эш белән куабыз, эш белән җиңәбез. Хет шуның белән онытылып яшисең.

Бу юлы Гайния апа дәшмәде. Нәрсә дисең соң? Аның бит үзен дә ялгызлык аз талкымады, үзенең дә күңеле гасабиланган чаклары күп булды. Яшьли ирсез калды. Барысына да, элеге дә баягы, шул сугыш афәте гаепле. Гомере буе фермада эшләде. Ул чорларда фермалары ферма идеме соң аның, муеннан тиң сазда чиләнәләр иде. Моннан берничә ел элек, чиргә уралып, озак вакыт авырып ятты. Башта ревматизм диделәр, соңрак инде кайгы-хәсрәтне дә, юклык-михнәтне дә күп күрүдән шактый таушалган йөрәге шаяргалый башлады. Хәзер әнә шул йөрәк өянәге интектерә. Бөтен яшьлеген, гомерен фермага биргән

Гайния апа мал-туар янынннан әллә кая китәргә теләмәде. Хәзерге вакытта ул терлекчеләр өен, кызыл почмакларны җыештыручы, бер үк вакытта төннәрен дежур торучы булып та санала. Хәзер инде савымчы булып аның кызы Зәйнәп эшли. Зәйнәбе бәхетле: тормышы тигез, балалар үстерә.

Гайния апа, идәннәрне юган чүпрәген сыгып, чиләк кырыена элде дә кабат турайды. Аннары, бик әһәмиятле сүз башларга җыенгандай, Хәдичә язып утырган өстәл янына якынайды. Тегесенең, эшен төгәлләгәндәй итеп, журналын ябып куюын күргәч, сүз кушты.

— Ишеттеңме икән, Хәдичә? Кичә председатель Маннур белән партком секретаре Нәҗипне, бюро диләрме әле, җилтерәтеп кенә шунда районга чакыртып алганнар, ди.

— Сөт өчендер инде?

— Шул инде, шул. Тәки илтеп терәделәр, китереп җиткерделәр мактаулы савымчыларыбыз. Алар да машина белән савалар, янәсе...

— И-и, Гайния апа. Илаһи уптым гына эшләнә торган эш түгел шул ул.

Колхозның товарлыклы-сөтчелек фермасында менә атна-ун көн инде механикалаштырылган савуга күчәбез дип мәш киләләр. Тавыш, шаушу, ызгыш анда. Ферма тирәсе тузгытылган умарта күче кебек гөжләп тора. Ул, мин сиңа әйтим, хатын-кызларның чыр-чуы дисеңме, ул сыерларның яман акырышулары, яки бәйләп куйган муенчакларын шартлатып өзеп, койрыкларын чәнчеп акыра-бакыра чыгып чабулары дисеңме — барысы да, барысы да булды. Аптыраш белән йөдәш анда. Хак булса, аппарат астында калдырып, бер сыерның имчәген өздереп чыгарганнар, ди. Эштән чыккан, саварга ярамас сыерлар да хәзер инде шактый, ди. Нәтиҗәдә колхозда сөт савып алу кимеп кенә калмаган, район газетасынын соңгы санындагы сводкасыннан күренгәнчә, иң соңгы урынга төшкән. Ләкин боларның берсе генә дә Хәдичә өчен сер түгел иде.

— Үч иткән кебек, Гөлнур гына да өйдә булмады, ичмаса,— дип куйды ул.

Гайния түтинең тагын бер яңалыгы булган икән.

— Гөлнур дигәннән, ишеттеңме икән әле, кызы бар, ди ич.

— Шулаймы? Менә анысы яраган. Ике малайлары бар иде бит инде...

Шул вакыт ишек артында хатын-кызларның чыркылдашкан тавышлары ишетелде.

— Әнә,— диде Гайния апа,— «уңганнарыбыз» килә дә башлады.

Шаулап-гөрләшеп, бер төркем савымчы килеп керде. Алар артыннан ишек ябылырга да өлгермәде, тагын берничә хатын-кыз күренде. Болары арасында теле авызына сыймас Зәмзәмбикә дә бар иде. Аның яшелле-күкле ачы тавышы үзеннән алда бүлмәгә бәреп үтте. Ул кerә-керешли үк ниндидер бик тә кызыклы, бик тә мәзәк сүз сөйләгәндәй шаркылдап көлә иде.

— Хатыннар! Хатыннар, дим, ишеттегезме әле?..— диде ул, һаман да әле көлүен дәвам итеп.— Председатель белән парткомга кичә выговор чәпәп кайтарганнар, ди ич... Ипидер менә, җир упсын әгәр.

Башка хатыннар да бака туе ясап алдылар. Гайния түтинең Зәйнәбе дә читтә калмады.

— Без дә ярышабыз, имеш! Җитмәсә тагын, уптым илаһи зурдан кубып, ярышыйк дип, үзебез үк барып, көрәшергә чакырып йөргән булган идек. Менә ярышның беренче җимешләрен күрдек тә...

— Сөйләмә дә!

— Ул кадәр зурдан купмасак, бу тикле зур көлкегә калмаган булыр идек.

— Хурлык, билләһи!

— Җикмәс борын куаларга яратабыз шул...— Бу сүзләрне савымчылар арасында «Район чемпионы» дигән мактаулы исемне яулап алган, хәзерге вакытта ферма мөдире вазифасын үтәүче Саттар Хәбирәсе әйтте.

— Әйтерең бармы!..

Чыннан да, моннан нәкъ ике ай элек, ел башында гына, күршедәге «Алга» колхозына үзара социалистик ярыш җәелдерү турында хезмәт договоры төзергә дип барганнар иде алар. Зәйнәп әйтмешли, зурдан кубып, бульдозерлар белән ике колхоз арасында юллар ачып, дүрт-биш җиңел автомобильгә төялеп бардылар. Кунакка, бәйрәмгәмени — киенеп-ясанып киттеләр. Иң алдагы машинада, колхоз «Волга»сында, изүләрен чишеп җибәреп, Саттар Хәбирәсе утыра иде. Күкрәгенә — моннан ике-өч ел элек кенә бирелгән Ленин ордены янына СССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсе медальләрен дә таккан. Хәбирәнең: «Булган алдынгы тәҗрибәләребез белән бик рәхәтләнеп уртаклашырбыз, күршеләрдән җәл түгел», дип чыгыш ясауларына кадәр сөйләгәннәр иде. Соңыннан, договорга куллар кую унае белән, делегатлар өчен мәҗлес кичәсе дә оештырган булганнар. Договорда һәр сыердан сөт савып алуны узган елга караганда 450 килограммга арттыру, осталыкны күтәрү, нәсел эшен яхшырту, терлекләрнең баш санын күбәйтү кебек пунктлар белән беррәттән, беренче кварталда ук сыер саву процессын тулысынча механикалаштыру бурычы да куелган иде.

Һәм менә беренче нәтиҗәләре...

Ә Зәмзәмбикә — теленә тилчә чыккыры — тыела алмыйча һаман чәпчи, теш агарта, нәрсәгәдер куангандай, башын артка ташлап, рәхәтләнеп бөгелә-сыгыла көлүен белә.

— Менәтерәк сиңа «Терлекчелектә югары культуралы колхоз!..» Менә сиңа районның Күчмә Кызыл байрагы! Уф-ф, үләм... Председатель белән парткомны әйтәм әле... Бик тә инде нык кыздырганнар ди үзләрен, тәмам йокыларын качырганнар ди... Районнан кайткач та әле аңнарына килә алмаганнар, төннәрен идарәдә генә уздырганнар ди...

Моңарчы дәшми-тынмый гына өстәл янында утырган Хәдичә түзмәде, азып узынган Зәмзәмбикәнең телен тыярга булды.

— Тукта әле, Зәмзәмбикә...— диде ул.— Нәрсә, тора салып, шатлыгы эченә сыймаган кешедәй кыланасың? Әллә җиңеләя башладыңмы?.. Әдәп йөзеннән генә булса да тыелыр идең...

Тегесе җәһәт кенә Хәдичә ягына борылды. «Син дә монда идеңмени әле?» дигән сыман, күзләрен тасрайтып бермәл текәлеп карап торды да элеп тә алды:

— Бәс, Чабата җанаш та монда булган ич!.. Тәгәрәпләр генә үлим, харап, бетте баш... Әйттем исә кайттым, тфю, тфю!..

Хәдичә, аның чәпчүенә карамыйча, әйтәсе фикерен әйтеп бетерергә булды:

— Әйтче, зинһар, сиңа нинди зыяннары тиде аларның? Алар бит житәкчеләр... Бөтен җаваплылык — шулар өстендә. Сөенечләр дә, көенечләр дә беренче чиратта алар йөрәге аша уза.

— Уф-ф, үләм!..— дип кабат зәһәрләнә башлады Зәмзәмбикә.— Ай-һай, жете кызылланды бу, Чабата җанаш. Үлешле хәзер аның белән. Билләһи газим, тәгәрәп үлим менә, әйткән иде диярсез... Тиздән партиягә кереп алып, нәчәлник кисәге булып, тәки җилкәбезгә менеп кунаклаячак бу. Күрегез дә торыгыз, менә...

Зәмзәмбикәнең теле бер язылса туктый алмаячагын яхшы белгәнгәме, Хәдичә бүтән сүз кераштереп тормады: «Бик кирәк иде ди синең жилкән...» дип, журналын урынына илтеп куйды да чыгып китте. Шулай да Зәмзәмбикәнең: «Путачка биреп утырган була бит әле, адәм тәганәсе! Тыгылмый, кысылмый калырмын дип курыккансыңдыр шул, ялагай. Шулай итеп ярыйсың да син...» дигән сүзләрен аермачык ишетеп калса да, Хәдичә кире борылмады. Теле тел булса иде икән көйсез мәхлукның. Бар белгәне шул чырылдау бит...

Сызылып кына таң беленеп килә. Бер якка авышырга өлгергән ай нәкъ баягыча якты, ялт итеп тора. Йолдызлар да әле бик җете җемелдәшәләр. Буйдан-буйга сузылган калкулык аермачык булып күренә. Аның сырынты ятудан киртләчләнеп торган итәгендә, катып калган дулкыннарны хәтерләтеп, кар өемнәре ята.

Хәдичә, пар бөркелеп торган ферма ишеген киң итеп ачып, эчкә үтте. Ул кинәт башка дөньяга эләкте: тирә-як дөбердәү, мөгрәү авазлары белән тулды.

— Хәзер, хәзер, җаныйларым!.. Хәзер!..— Хәдичә түргә үтешли юлы өстендә очраган һәрбер танасын иркәләп, сыйпап узды.— Хәзер, хәзер, җанкисәкләр...

Хәдичә, ферманың аргы башындагы шкаф янына килеп, өс-башын рәткә китерде дә онытылып эшкә керешге. Ә эш монда муеннан.

Иң элек азык хәзерләү цехына кереп чыгарга булды. Үзе бер кечерәк завод кадәрле ул: транспортерлар шыгырдый, моторлар гүли, бункерларда химик реакцияләр бара... Кальций исе аңкып тора. Цехта өч технологик линия: тупас азыклар эшкәртү, концентрат һәм тамыразыкларны чүпрәләү, ясалма сөт хәзерләү җайланмалары эшли.

Хәдичәнең беренче очраткан кешесе Озын Фәссах булды.

— Хәерле иртә, Фәссах абзый!

— Ә-ә, Хәдичә! Килдең дәмени?..

Төнге сменада эшләгән Фәссах агай тегермәнчегә охшап калган, кием-салымнарына гына түгел, кашларына кадәр көрпә-он кунган аның.

— Фәссах абзый, салам ни хәлдә? Машиналарың бүген киреләнмәделәрме?

— Все порядка, Хәдичә. Әнә, күр, урман печәнең бер якта торсын. Үз борыныңа бөтереп тыгарсың...

Хәдичә дә картның салпы ягына салам кыстырып куйды:

— Молодец! Яшерен-батырын түгел, Фәссах абзый, син дежурда чакта җан тыныч.

— Һе-һе! Шулай дигән бул инде...

Соңгы елларда эш катлауланды. Көн дә яңалык, көн дә белем таләп итә торган четерекле үзгәрешләр. Узган елдан бирле шактый кыю рәвештә химик өстәмәләр, микробиологик һәм ферментлы кушылмалар файдаланыла башлады. Аларның барысын да бел, үзләштер, бутый-нитә калсаң, башың бетәр.

Ул арада ферма тирәсе җанланганнан-җанлана барды. Терлек азыгы хәзерләү цехы ягыннан пульман вагоны кадәрле азык тараткыч таккан «Беларусь» тракторы күренде. Ул, ферманың буеннан-буена үтеп, таналар алдындагы улакларга парландырылган салам бушатып узды. Аннан соң нәкъ шундый ук икенче агрегат килеп керде. Монысы тозлаган алманың әчкелтем исен хәтерләткән силос түягәне.

Сәгать тә үтмәгәндер, мул итеп ашарларына салынган таналар, тәмам тынычланып, йонлач колакларын селкеткәләп, улаклары өстенә иелделәр. Аларның бары тик мыш-мыш килеп күшәүләре генә ишетелә иде.

Хәдичә ике җәпле агач сәнәккә охшашлы болгаткычы белән ин соңгы тана алдындагы салам катыш силосны һәйбәтләп аралаштырды да уф-ф! дип иркен сулады. Борчак-борчак булып тир бәреп чыккан маңгаен җиңе белән сыпырып алды. Менә хәзер чак кына хәл алырга да мөмкин. Ул, буш вакытыннан файдаланып, савымчылар янына кереп чыгарга ниятләнде: бүген нишлиләр, ниләр майтаралар икән?..

Бина эченә кергәнче үк, ачык ишек аша хатын-кызларның чәрелдек тавышларын ишетте Хәдичә. Чыннан да, хәйран-тамаша иде инде. Ул тавыш, ул ызгыш — бер дә харап. Баш зоотехник Гөлнур урынына калып торган ясалма орлыкландыру пункты техникы Миргасим кайсыдыр савымчыны эттән алып эткә салып сүгә. Ул, сыерын аппарат астында калдырып, терлек азыгы хәзерләү бүлегенә апара алырга киткән булган. Сыер имчәге тәмам эштән чыккан, кул белән саварлыгы да калмаган...

Миргасим сүзенә әллә ни колак салмыйлар. Хәер, яшь белгеч шул әле ул. Көз көне генә укуын тәмамлап кайтып, зоотехник-селекционер булып эшли башлады.

Ферманың икенче башында янә тавыш. Авырткан җирдә кул, кызык җирдә күз дигәндәй, анда да хатын-кызлар җыелган. Хәдичә дә шунда юнәлде. Савымчылар арасында, әлеге дә баягы, Зәмзәмбикә тавышы:

— Менә савып кара инде син аны!.. Тилебәрән орлыгы ашаган нәмәстәкәйне...

Хәдичә Зәмзәмбикәне урап алган хатын-кызлар янына килде. Зәмзәмбикә зарланган сыер быел беренче тапкыр бозаулаган, Хәдичә үзе караган «Чәчкә» кушаматлы тана иде. Күңеле әрнеп куйды Хәдичәнең. Тана арыккан, пычракка батып, мескенләнеп-моңаеп калган.

Ул арада Зәмзәмбикә, күз кырые белән генә, әле янарак кына килеп кергән Хәдичәне шәйләп алды. Әмма аны күрмәгәнгә салынып, янә зәһәрен чәчә башлады.

— Хәер, Чабата җанаштан кабул итеп ал да игелек тә күр ди...

Хәдичә бу юлы да дәшмәде, каны кайнавын тойса да, ачуын эчкә йотарга булды.

Зәмзәмбикә саву аппаратларын кабат алып, янарак кына чабыштан килгәндәй еш-еш сулап, тәмам ярсыган сыер янына якынлашты. Чылбыр муенчактагы сыер кабат әле бер якка, әле икенче якка атылыпбәрелә башлады. Ул да булмады, улаклар аша сикереп чыгып качарга теләгәндәй, куырылып килеп, автоэчергечләр өстенә ыргылды. Үз-үзен белешмәс дәрәҗәгә житеп дулаган сыер, әзерләп куелган саву аппаратларын гына түгел, Зәмзәмбикәнең үзен дә берничә тапкыр этеп-төеп җибәрде.

Бу хәл Зәмзәмбикәне чыгырыннан чыгарды, күзләре аларды аның. Һәм ул кинәт жикеренеп-очынып килде дә: «Мә сиңа, мә!..» дип, сыерның корсагына дөп-дөп итеп типкәли башлады.

Моңарчы тешен кысып булса да чыдаган Хәдичә бу кадәресенә инде түзмәде: «Кит әле... Кит!».. дип, Зәмзәмбикәне читкәрәк этәрде дә элеккеге танасы янына үзе килде.

Боларның барысын да кәмиткә әверелдереп күзәтеп торган хатынкызларга кызык, алар тагын да якыная төштеләр. Башкалары да эшләреннән бүленеп болар янына җыйналды һәм авызларын җыя алмыйча, күзләрен кысышып, бер-берсенең янтыкларына төрткәләшеп тамаша кыла башладылар. Ярсыган, тәмам эштән чыгарылган сыерны Хәдичә сава алырмы?

Баштарак тана Хәдичәдән дә читләште, бөрешеп килеп бер кырыйга тайпылды.

— Чү-ү, Чәчкә! Я-я, тынычлан. Җитте! Алай холыксызланма... Йә, тынычлан!..

Хәдичә улактагы башакны рәтләде, улак кырыйларыннан цемент тузаны сыман онны, көрпәләрне сыпырып төшерде. Төптә калган сусыл силосны өскәрәк чыгарды. Бары тик шунда гына бераз тынычлана башлаган сыер, ашарга омтылып, улак өстенә иелде.

Шунда Хәдичә саварга хәзерләнә башлады. Әмма аппарат стаканнарын кулына алу белән, бу уйдан кире кайтты. Зәмзәмбикә ягына борылып, тәмам хәйран булган кеше сыман башын селеккәләп алды да тегене битәрли башлады.

— Эх-х, Зәмзәмбикә, Зәмзәмбикә!.. Оятың да юк икән, билләһи... Шушы туң тимерләр белән сыердан сөт алмакчы идеңме? Шаккатам! Күрче, зинһар, төннең-төн буена салкында торып тач боз булганнар ич болар. Кулларны ябыштыра... Әйтәм, бичара сыер син стаканнарны куя башлау белән, керер тишек тапмый, куырылып килә. Эх-х, син дә йөрисең шунда мал-туар карыйм дип. Ул да җан иясе бит. Изүеңә ачып боз салсалар, нишләр идең икән үзең? Яки Хафизың иркәлисе урында эткәләп-төрткәләсә, җаның эрер идеме икән?..

Мондый чакта Зәмзәмбикәнең теле авызына сыямы соң!

— Анысы хак,— дигән булды ул.— Ир-ат белән эш итүнең нечкәлекләрен синнән өйрәнергә дә өйрәнергә кирәк әле безгә...

Хәдичә дә җавапсыз калмады.

— Анысы да теләсә кем булдыра алган эш түгел.

Хәдичә бүтән сүз куертып тормады. Иң элек җылы су белән сыерның җиленнәрен юды, коры һәм йомшак чүпрәк белән әйбәтләп сөртте. Аннары, күз иярмәслек хәрәкәтләр ясап, куш куллап массаж ясады. Бары тик шуннан соң гына чиләктәге кайнар суда җылытылган аппарат стаканнарын чиста чүпрәк белән сөртештереп, җаен-әмәлен белеп кенә имчәкләргә кидереп куйды. Шуннан соң, тәмам тынычланып улагында чемченгән танасы алдына чыгып, малның муен тирәләрен сыйпаштырды, иелә төшеп, хайванның колагына сер әйткәндәй итеп, үзалдына нәрсәдер сөйләнеп куйды. Бары тик шуннан соң шылт иттереп моторны җибәрде. Сыер, сискәнеп, җәһәт кенә башын калкытты, корсак тирәләрен дерелдәтеп алды. Әмма янында Хәдичәне күреп яңадан тынычланды һәм, ни булганын төшенгәндәй, башын янә улак өстенә иде. Ул арада инде елкылдап торган пыяла трубалар эченнән күбекле сөт шаулап ага да башлаган иде.

Бу хәлләрнең барысын да күзәтеп торучылар арасыннан кемдер түзмәде, әйтә салды:

— Билләһи, Хәдичә!.. Бу кадәр дә булырсың икән, берәр догасын, тылсымлы сүрәсен белә торгансыңдыр син малларның. Һич тә башкача булмас...

Тирә-яктагылар ихахайлап көлешеп алдылар. Бу инде Зәмзәмбикәнең җиңелүе, аның чама белмичә өскә чөелгән танавына нык кына итеп чиертү иде.

Әмма Зәмзәмбикә мондый чакта алай тиз генә килешә торганнардан түгел.

— Миргасим, үскәнем!..— дип кычкырган булды ул, яшь зоотехникның исемен атап.— Менә бу үләксәне дә заготскотка озатыласылар исемлегенә теркәп куй әле...

Бу, үзенә калганда, аның Хәдичәне үртәве, ирештерүе иде. Әмма Хәдичә монысын да йотты, тавыш чыгарасы килмәде. Ул белә, авызына шайтан төкергән Зәмзәмбикә теленә эләктеңме — рәтле сүз көтмә. Әмма сабырын күпме генә җыеп торса да, түзмәде: «Шаярма!.. Синең кебек тинтәкләргә карасаң, ферманың каккан казыгы калмас монда...» — дип әйтеп салды.

Шул вакытта Хәдичәгә бәлки чыгып үк китәргә булгандыр. Кыласы эш кылынган, Зәмзәмбикә хурлыклы рәвештә көлкегә калды. Тик нидер тоткарлады Хәдичәне. Һәм шул хәл тиресенә сыеша алмаган Зәмзәмбикәнең җәнҗал чыгаруына сәбәп булды да инде.

Әллә ни кырган сыман, буш бидоннарны дыңгырдатып, кайнап чыгарга әзер самавар кебек ут бөркеп калтырана башлаган Зәмзәмбикә яңадан Хәдичәгә бәйләнә калды.

— Бу Чабата җанаш һаман да мондамыни әле?.. Менә бит, әй! Берәүләргә җелеге, кемнәргәдер күбеге дигәндәй, бар әле бездә, эшлим дигән булып җил куып, уч тутырып акча алып ятучылар.— Шулай башлап, күзләрен тасрайтып, ул Хәдичә каршына килеп басты.— Нәрсә, җыен сорамаган җиргә кысылып йөрүдән кала бүтән эшең юкмы әллә синең? Ә?.. Бар әле, кит! Тар җирдә тана башы дигәндәй, йөрмә әле монда эч пошырып, эшләргә мишәйтләп...— дип, Хәдичәне этқәләп-төрткәләп тә алды.

Бу кадәресен инде Хәдичә күтәрә алмады. Менә шунда сырты сынса да сынатмас Хәдичә, ниһаять, сынатты. Кинәт күзләренә ут кабынды аның, йөзенә усал төс чыкты.

— Слушай... син!.. Телең белән агуыңны телисәң күпме чәч, әмма кулыңа ирек бирәсе булма. Матри аны! Бик тиз кыскартырмын...— диде ул яман да катгый, кырыс тавыш белән.

Тегесе аның саен зәһәрләнүен белде.

— Кит, кит, бар!.. Йөрмә әле монда кычытмаган җиреңне кашып...

Гарьләнү-үҗәтлек хисе акылын томаларлык чиккә җиткән иде инде. Һәм Хәдичә ничек, кай арада Зәмзәмбикәнең битенә чалтыратып сугып җибәргәнен сизмичә дә калды. Бары тик кулы яңгырап китүен генә тойды ул.

Зәмзәмбикә бермәлгә өнсез булып, торараш сыман катып калды. Аннары аңына килә башлаган сыман итеп, авыз-борын тирәләрен сыпырып куйды. Ә инде учында кан таплары күргәч, суелгандагы мал кебек, йөрәк яргыч тавыш белән акырып җибәрде.

— Ах-х... уйнашчы!.. Әле син шулаймы?!. Күзләреңне чукып алам бит хәзер... Бетерәм бит, Чабата җанаш... Җаныңны суырып алып кулыңа тоттырам бит,— дип котырынып һәм өзгәләп ташлардай булып Хәдичә өстенә килә башлады.

Хатыннар шунда ук араларына төштеләр. Тәмам чыгырыннан чыккан Зәмзәмбикәне эләктереп, боргычлап алдылар.

— Нишлисез сез, ә?!.
— Оятсызлар!..
— Башкасын булдырдык... Хәзер шушы гына җитмәгән иде ди...
— Җир битләр!.. Тапканнар үнәр...
— Әйтмә дә!

Ярсудан тәмам кешелеген җуйган Зәмзәмбикә, үзен чытырдатып тоткан хатын-кызлар кулыннан ычкынырга теләп, бер-ике тапкыр кабат талпынып-йолкынып карады. Ахыр чиктә үте сытылыр дәрәҗәгә җитеп, буыла-тыгыла такмаклап, гасабиланып җылый башлады.

— Уф-ф, үләм!.. Җибәрегез... җибәр... Измәсен изеп ташлыйм әле... Барыбер болай гына калдырмаячакмын мин аны... Авылда... Идарә тирәсендә, тиешкә дә, тиешсезгә дә гелән яклыйлар дип масая торгандыр... Ю-ук!.. Якламый торсыннар әле. Җиткәндер, ниһаять!.. Бүген үк, менә хәзер, милициягә барып җәвит итәм... Язу алып судка бирәм... Авылдан кудырачакмын мин ул Чабата җанашны...

Эт тә җыймаслык шундый сүзләрне тезде дә тезде Зәмзәмбикә. Ул арада Саттар Хәбирәсе килеп: «Бар!.. Сиңа да нечего йөрергә...» дип, Хәдичәне чыгарып җибәрде.

Бераздан Зәмзәмбикәнең: «Шул адәм тәганәсе Чабата җанашны авылдан кудырмасам, тудырган әниемнең күкрәк сөте тотсын», дип ду кубып, сыерларын да савып бетермичә кайтып киткәнлеге турында Хәдичәгә дә ишеттерделәр.

*
* *

Эше эш булмады Хәдичәнең. Тәмам ватылып, җеп өзәрлек тә хәле калмыйча кайтып егылды ул. Йөрәк сызуына, җаны әрнүенә тәкать тотарлык хәле юк. Нигә, нигә дип кенә телгә килде ул шул юньсез белән?!. Савымчылар яныннан ул бизгәк тоткандагы кебек дер-дер калтырап, әсәрләнеп чыкты. Чак кына тынычланып, ачуы басыла башлагач, өрлек баганасына капланып сабый баладай үксеп-үксеп елады. «Мине чәйнәмәсәләр, минем белән булышмасалар, эчләре күбә микән әллә?..» дип, гарьлек һәм ярсу белән илереп-үртәлеп елады.

Өенә кайткач та, кузгалырга да, кымшанырга да хәле калмаган кеше сыман, тезләре өстенә кулларын салып диванда утырды. Ашау-эчү дә, тормыш-көнкүреш мәшәкатьләре дә онытылды. Үкенү ачыгысы газаплый иде аны.

Шул вакытта капканың шапылдатып ачылып-ябылганы ишетелде. Хәдичә чәчрәп китте, йөрәге күкрәк читлегеннән атылып чыга дип тора.

Колхоз идарәсендә җыештыручы булып эшләүче Сабира апа килеп керде. Керүенә ук күгәрчен кебек гөрли дә башлады.

— Уф-ф! Әле дә ярый, өйдә туры килдең. Тәки фермага йөгерергә туры килер микәнни дип тора идем...

Хәдичә, күңеле белән нидер сизенеп, сорап куйды:

— Нәрсә булды, Сабира апа?

— Сине чакыралар...

— Кая?

— Идарәгә.

— Кайчан?

— Төп-төгәл бишкә, диделәр.

«Тәки барып җәвит иткән икән кәнтәй...» дигән уй чагылып китте Хәдичәнең башында. Уйлаган алга килә дигәндәй, тикмәгә генә көннең-көн буе җаны көеп йөрмәгән икән. Шулай да, сер бирергә теләмичә, тыныч кына кабат сорау бирде:

— Нәрсәгә икән, белмәдеңме?

— Белә алмадым,— диде Сабира апа һәм шунда ук нәрсәдер исенә төшергән сыман итеп өстәп куйды: — Һәрхәлдә, Хәдичә җаным, яхшыга булырга охшамаган... Кичәге-бүгенге хәлләрне үзең беләсең бит инде.

Сабира апа бары тик шунда гына, иркен сулыш алгандай, як-ягына күз төшерде. Өй эче тулы кояш һәм затлы җиһаз. «Яхшы, житенкә итеп, муллык белән яши, чукынмыш» дигән уй башына килсә дә, уендагын чыгарып селекмәде. Өйгә керү белән ычкындырып җибәргән шәл очын кабат муены тирәли урап, кире кыстырды да:

— Ярар, Хәдичә җаным, мин китим әле,— диде һәм шунда ук:— Зинһар, соңарып-нитеп мине кабат йөгертә күрмә инде,— дип, җил-җил атлап китеп тә барды.

Әллә нишләтеп җибәрде аны бу хәбәр. Әй-йе, яман хәбәр җирдә ятмый ди шул. «Милициягә җәвит итәм, кыйналуым турында язу алып судка куям»,— диде бит. Бәлки, чыннан да, эш зурга киткәндер...

Хәдичәнең күңел күгендә әнә шундый кара, кургашындай авыр уйлар болыты йөрде. Кемнең итәгенә төшә, шул яна, ди бит. Менә яңадан ничаклы үкенеч, әрнү, исәп... «Нишләтерләр?..»

Бәлки иптәшләр суды яки күптән түгел генә оештырылган эшче намусы советына куярлар? Әмма Зәмзәмбикә моңа үлгәндә дә риза булмаячак. Ул бит Хәдичәне кан дошманы күрә. «Шул Чабата җанашның үзен күргәндә түгел, күләгәсе чагылып киткәндә генә дә ләхетем кыса башлый...» дигән сүзләрен Хәдичәнең үз колаклары белән ишеткәне бар.

«Кәнсәгә чакыралар» яки «марш авыл советына!» дигән сүзләр Хәдичә өчен яңалык түгел түгелен, кайчандыр аңар мондыйларны шактый еш, хәтта бик еш ишетергә туры килгән иде.

Менә тагын: «Идарәгә чакыралар». Ай-һай, шыксыз яңгырый бу сүзләр Хәдичә өчен. Гади генә сүзләр түгел алар. Бу сүзләр аңа инде кайчандыр үлгән дип йөргән иң мәкерле, иң мәрхәмәтсез, иң явыз дошманының өрәге белән күзгә-күз очрашкандай тәэсир итте.

...Күнелләрен айкап-ботарлап, үткәннәре күз алдына килә башлады. Ә үтелгән юллар ифрат та яман, баштан кичергәннәре искә алгысыз. Ул көннәрен төштә күргәндә дә тәннәре чымырдап китә Хәдичәнең.

Бала чагы афәтле сугыш елларына, яшьлеге сугыштан соңгы авыр чорга туры килде аның. Бик тә кыен чаклар иде. Хәдичәнең туган әнисен алыштырган кешесе Васфикамал түти, хәзер инде гүр иясе, гомере буена ятим-ятимә булып яшәгән кеше иде. Шуның өстенә әле бик тә инде басынкы-юаш бер әлләзи зат иде, мәрхүмә. Белем арттыруга чут тимәде ул елларда. Җиде классны тәмамлау белән Хәдичә колхоз эшенә чыкты. Икесе ике яктан торып эшләсәләр дә, хезмәт көннәреннән башка һичбер килер җирләре юк иде. Тик шулай да рәнҗү-иңрәү авазы чыгармадылар алар. Төскә-биткә, буйга-сынга иң сылу, авыл гүзәле булып саналса да, Хәдичәнең аягыннан тула оек белән чабата төшмәде. Менә шул елларда ябышып калды да инде аңар «Чабата җанаш» дигән шыксыз кушамат.

Унҗиде яшь тулар-тулмас, Хәдичәгә дә мәхәббәт килде. Кенәлегә Казан педагогия институтыннан практика узарга кайткан Вәли атлы егет иде ул. Үзе яшь, буй-сынга да шәп, чибәр, өс-башы бөтен, беренче күренүдә үк авыл кызларын һуштан яздырды. Шуның өстенә әле яшь студент бик тә инде үҗәт, үтә үзсүзле кеше булып чыкты. Клубта танышкан кичне үк Хәдичәне озатып куярга теләге барлыгын белдерде. Әмма Хәдичә үзен караңгы тыкрык башына кадәр генә озаттырды. Кешеләрнең бакча артларындагы мунчалары рәтендә, каралты-курасыз, алачык сыман өйләрен кеше күрүдән курка иде ул. Әмма әрсез Вәли бу киртәне дә бик тиз җимерде, мәктәптән бирелгән бер олау утынны, кыз эштә чакта, аларның ихаталарына кертеп бушаттырды. Хәдичә, эштән кайтып, Вәлинең хәтта өйләренә дә кереп чыкканлыгы турында ишеткәч, оялуыннан ул көнне урамга да чыкмады.

Әмма яшьлек тормышның андый күләгәле якларына әллә ни игътибар итми. Алар яңадан очраштылар. Вәли кызны тыкрыкка кадәр дә, өенә кадәр дә озатты. Хәтта кемдер читән буена алып менеп каплап куйган көймә өстенә утырып таң аттырган чаклары да булгалады. Бәрәңге бакчаларына ук орынып яткан олы күл ягыннан саз үләннәре, камыш исләре аңкый. Һай-й, ул көннәр!.. Шунда алар гомергә бергә булырга вәгъдәләр бирештеләр, сүз куештылар. Ә инде практикасы тәмамланып, иртәгә китәсе дигән көнне егет, Васфикамал түти янына кереп, әни кешенең ризалыгын, хәер-фатихасын алып чыкты. Яшьләрнең бәхетләре хәттин ашкан иде.

Авыл җирендә кеше олы кибет витринасында яшәгән кебек: анда бернинди сер юк, һәрнәрсә ачык, бөтенесе билгеле. Хәдичәнең дә тиздән тормышка чыгачагы авыл халкына бик тиз мәгълүм булды. Берәүләре ак бәхетләр, тигез тормыш теләделәр, укуыңны дәвам итә алырсың, ичмаса, кеше булырсың, авылда чиләнеп ятмассың, диделәр. Билгеле инде, көнләшүчеләр дә табылды.

Вәли Казаннан: «Синнән башка, сине күрмичә яши алмыйм»,— дип, көн саен хатлар яудыра башлады. Хәер, Хәдичәнең дә егетне күрмичә түзәр тәкатьләре калмаган иде. Өч-дүрт көнгә генә сорап Казанга китеп барды. Искиткеч матур көннәр иде ул. Вәли белән Хәдичә кайларга гына бармадылар, кайларда гына булмадылар. Һәр көнне диярлек театрларда, циркта, могжизалы тавышларын бары тик радио аша яки пластинкалардан гына ишеткән мәшһүр артистларның үзләрен күрү бәхетенә дә ирештеләр. Вәли яшәгән фатир хуҗасының отпуск алып каядыр җылы якка ялга киткән чагы иде. Бу да ярап куйды. Яшьләр кайчан теләсәләр шунда чыгып киттеләр, үзләре теләгән вакытта кайтып керделәр. Шунда, Хәдичә Казанда вакытта, мәхәббәттән тәмам исергән ике гашыйк өйләнештеләр, ир белән хатын булдылар. Асылкош тоткан кеше сыман кайтып төште Хәдичә. Тиндәшсез куанычын әнисенә дә әйтте. Әмма Васфикамал түти кызының ул шатлыгын уртаклашмады, аның ул адымын хупламады. Алай гына да түгел: «Һай-й, сабырсызлангансың, балакай. Табын өстеннән ашатып, ашның ямен җибәргәнсең...» дип, хәтта чак кына битәрләп тә алган иде.

Әмма атна-ун көн дә үтмәде, Вәли үзе кайтып төште. Икенче көнне үк авыл советына барып никахны законлаштырдылар. Һәм шул зур вакыйгага хөрмәтенә мәҗлес кебек нәрсә дә үткәреп алдылар. Иң кадерле саналган он белән ит кебек нәрсәләрне колхоз биргәч, бу «кече туйга» әллә ни зур расход та чыкмады.

Соңгарак та Вәли җае чыккан саен кайта торды. Шундый кайтуларның берсендә Хәдичә җаныннан да артыграк күргән, алла урынына инанган иренә йөрәк серен ачты: ул тиздән ана булачак. Шунда алар дөньяга киләчәк мәхәббәт җимешләре өчен исемнәр дә сайлап куйганнар иде.

Вәли тагын китеп барды. Бу юлы ул, мәктәпләрдә укулар башлангачны, Свердловск өлкәсендәге әти-әниләре янына кайтып, киленне каршы алу хәстәрен күрә башларга тиеш иде. Әмма шул ук елның көзендә Вәли әле яңарак кына бөреләнеп килгән гаилә тормышын зәрзибәр итте дә ташлады. Станциягә килеп каршы алмадың, диде ул. Юри, юкны бар итеп, көнләшкән булып маташты. Менә шунда Хәдичә үз гомерендә беренче тапкыр хыянәт ачысын татыды да инде. Ай-һай, авыр кичерде Хәдичә ул хәлләрне, акылына зәгыйфьлек килә икән дип уйлады. Менә шул чакта Хәдичәнең канатлары салынып кына калмады, тәмам каерылды шикелле. Бигрәк тә ярата иде шул ул Вәлине. Вәли дә моны белә, сизә иде. Мәхәббәтенә артык ышанган кеше исә очына, узына, кирәксә-кирәкмәсә дә төрле сынаулар, тәҗрибәләр ясап карый башлый. Хәтәр нәрсә бу. Бичара Хәдичә: ул укымышлы, аңар гап-гади авыл кызы нәрсәгә? Тиң күрми, үз итми, шул гына, дип үзенчә нәтиҗә ясый торган иде.

Вәли, направлениесе Хәдичәләр районына булса да, Кенәлегә кайтмады, райүзәктә калды. Әмма Хәдичәне күздән яздырмады.

Кышын Хәдичә кыз бала тапты. Больницада район үзәгендә тудырды. Бәлки Вәли дә килер, хәлен белешер дип көткән иде, назлы сүз, нәзакәтле ишарә өмет иткән иде. Ул чакта Хәдичәнең җәрәхәтле йөрәге хаклыкка, гаделлеккә бик тә мохтаҗ иде бит. Әмма Вәли килмәде, табышын, корбанын сагалаган җанвар кебек, һаман нәрсәдер көтте. Ә Хәдичә өстенә бер-бер артлы бәхетсезлекләр ябырыла башлады. Иң элек, савыкмас борын эшкә чыгу сәбәпле, үзе өзлекте, урын өстенә ятты. Эш урынында, фермада да чатаклыклар чыгып кына торды. Күп тә үтмәде, тагын да яманрак бәла-казага юлыкты. Яз көне, җирләр кибә башлагач булды бу хәл. Бер караңгыдан икенче караңгыга тикле дуңгыз фермасында эшләп, шуның өстенә бала имезгән Хәдичә тәмам хәлдән тайды.

Тормышның ачысын-төчесен күп татыган, вакыты белән утә дә чыккан акыллы һәм зирәк була белгән Васфикамал түти дә үлеп китккәч, Хәдичәнең тормышы тагы да төрле яктан сүтелә башлагандай булды. Көннәрдән бер көнне Хәдичә өендә яман җәнҗал чыкты. Бер хатын шушы ихатада үзенең ирен кеше белән тотты. Тинтәк хатын буза чыгарып кына калмыйча, иң элек күсәк алып өйнең барлык тәрәзәләрен коеп чыга, аннары шешә белән сугып көндәшенең башын яра. Аның белән генә чикләнми: «Чабата җанаш үз өендә бардак оештырып ята», дип, авыл советына барып әйтә. Хәдичәне «кәнсә»гә чакыртып алалар. Ул үзенең бернәрсә дә белмәвен, тегеләрнең үзлекләреннән, аңардан сорап-нитеп тормыйча ишекне ачып керүләре турында сөйләвенә колак та салмыйлар. Авыз чайкарга, чышын-пышын сөйләшүләрнең тагын да күбәюенә шул бик житә калды. Шулай итеп Хәдичәнең исемен төрлечә селки-талкый башладылар.

Нәкъ шул көннәрдә Хәдичәнең ансыз да авыр тормышын астын-өскә китереп, пыран-заран итеп ташлаган вакыйгаларның иң зурысы, иң яманы булды. Нәни кызы Вәлидәне караучы Мәфтуха түти аны эштән кайтуга: «Ирең машина белән килеп, баланны алып китте», дип каршылады. Хәдичә шунда ук, төнгә каршы, район үзәгенә чыгып йөгерде. «Баласын алып Свердловск өлкәсенә очты», дигән хәбәр тәмам өнсезтелсез итте аны. Кеше-фәлән күрмәслек җиргә, ачык кырга чыккач Хәдичә: «Йа-а, гаделсез дөнья, шәфкатьсез язмыш!» дип җиргә авып, тәгәри-тәгәри елады. Шунда аның күңелендәге нечкә кыллар, зәгыйфь авазлар чыгарып, чыңлап өзелгәндәй булдылар. Тик нишләмәк кирәк, дөньяга үпкәләп, аны каргап кына яшәп булмый. Тормыш бу.

Атна-ун көн дә үтмәде, судка чакырдылар. Шунда Вәли вәхши кырыслык, яман да зәһәр катылык күрсәтте. «Бала тәрбияләргә мөмкинлеге дә, шартлары да юк. Гомумән, өендә бардак оештырып, җәнҗал чыгарып ятучы хатын ана була алмый», диде. Сүзен сүз итү өчен бернәрсәдән дә тартынмады. Баланы курчак кебек итеп киендереп, елмайтып, кулларына, яннарына берсеннән-берсе затлы уенчыклар тезеп куеп төшергән фотоларына кадәр алып килгән иде. Әтләнсә әтләнде Вәли, әмма үзенекен итте. «Баланы тәрбияләү вазифасын «вакытлыча» ата карамагына тапшырырга», дигән карар чыгарттырды.

Бу хәл тамырын корыткандай итте Хәдичәнең. Баласын алдырган кош кебек чапаланып, каңгырап-миңрәеп кенә калмады, чиргә сабышып аяктан ук егылды. Түшәктә узган шыксыз көннәр, газап-саташулы төннәр башланды. Йокысын, ашау-эчүен онытты Хәдичә. Атна-ун көн эчендә танырлыгы калмады: бит-йөзен кара тут басты, күзләре эчкә батты. Әмма, үзе кебек үк яшь тол хатын-кызлар килеп, хәлен белешеп тордылар. «Болай ярамый, Хәдичә. Каты кайгы әҗәл ирештерер, дигән борынгылар. Әллә эчеп карыйсыңмы?.. Андый чакта файдасы тиеп куя аның», дип, аракы тәкъдим итүләр дә булды. Менә шулай итеп йөгәннән дә ычкына язды Хәдичә. «Көфер почмагы» дигән сыман, Хәдичә яши торган тар аралык та соңрак «Чабата җанаш тыкрыгы» дип исемләнде.

Җиде төн уртасында Хәдичә ишеген килеп шакулар гадәти була башлады. Шуңа түзде-түзде дә ахырда чик куярга булды ул. Төннәрнең берендә янә килеп шакыдылар. Хатын-кыз тавышы, пәрә-пәрә килеп: «Ирем синдә генә... Яхшылык белән ачмасаң, ишегеңне җимерәм!..» дип чәрелдәде. Хәдичә башта яхшылык белән: «Миндә юк!» диде. Әмма теге тыңларга да теләмәде, берсеннән-берсе шакшы сүзләр белән Хәдичәне тиргәвен белде. Хәдичә исә башта ишеген ачып хатынны өенә кертте, тентеттерде, аннары: «Синең сасы көзәнең генә кирәк иде миңа», дип, чакырылмаган кунакны чәч толымнарыннан эләктереп алды да ишегалдына чыгарды һәм, бөтен авылга ишетелерлек итеп акыртып-бакыртып, күңеле булганчы тукмады. Бары тик шуннан соң

гына хатын-кызларның эзләре суынгандай булды, килми башладылар. Аның караны, Хәдичәне милициягә, прокуратурага чакырттылар.

Хәдичә: «Башны алып олагырга кирәк»,— дигән карарга килде һәм, беткән көе бар да бетсен дип, өенә керосин сибеп ут төртте. Шуны күмер өеменә әверелгәнче карап торып яндырды да авылдан чыгып китеп юк булды. Әллә ни ерак китә алмады, билгеле, район үзәгендәге такта яру заводына барып эшкә урнашты. Әмма анда да ул үзен икенче җирлеккә күчертеп утыртылган, тамыр җибәрә алмыйча газапланган гөл кебек хис итте. Шуңа күрә, расчет алып, яңадан каядыр китеп барды. Ә инде аннан соң булган хәл-әхвәлләрне, күргән мажараларны бер ходай белән Хәдичә үзе генә белә.

Кеше үз башыннан үткәннәрне бер селтәнүдә сызып ташлый алмаган кебек, узган юлына да күз төшермичә яши алмый. Хәдичә дә кеше-фәлән күрмәсен дип курка-курка артына борылып караштырып куйгалый... Әйе, үтелгән юл шактый сикәлтәле, хәсрәтсез көннәре аз булган, кыска гына итеп әйтсәң: заяга узган да киткән яшь гомер. Сәбәбе нәрсәдә? Беренче тапкыр кайда, кайчанрак сөрлекте соң ул? Хәзер инде Хәдичә бу сорауга бик теләгән тәкъдирдә дә тәгаен генә җавап бирә алмас иде. Андый вакытта ул үзенең тормышын рәешкә дип кенә саклаган өр-яңа аяк киеме киеп чыккан кеше халәтенә охшатып куйгалый... Андый кеше дә баштарак туфлиена кер дә кундырмыйча өф-өф итеп кенә саклап йөри. Тормыш булгач гелән яз, гелән аяз булып кына да тормый икән шул... Көтмәгән яктан кара болытлар чыгып, яшенле яңгыр ява башлый. Кеше кая керер урын тапмый. Атлаган саен болганчык су кулдәмәсе, сазлык-баткаклык, шаулап гөрләвекләр ага. Ә инде, бер-ике тапкыр пычракка батып, аяк киемен чумылдырып та алса, аннары гел бетте кеше: буласы булган инде дип, тездән тиң пычрак ера-ера турыдан гына юлын дәвам итә. Күмер корымга буялмый, ди бит. Кеше күңеле дә шулай, бер урыннан купмасын, какшамасын икән. Аннары инде оят та, хая да бетә, бары тик, үзенең барлыгын сиздереп, үзәк өзгеч эчкәртен бер сагышлы моң сыман нәрсә генә кала...

Олы, чын хис-тойгылар турында әйтеп торасы да юк, алар инде беткән, аяк астына салып тапталган гөл чәчәге кебек, тузан-пычрактан аерып алмаслык булып күренә шикелле. Ә күңел дигән нәрсә барыбер үз кирәген таләп итеп, даулап-бимазалап тора. Нәрсәгәдер өметләнә ул. Андый вакытта, бер дә булмый икән инде, һич югында, алдала аны, нәрсә белән булса да алыштыр... Тик игътибарсыз гына калдырма. Мәхәббәт дигән олы хис ялкынында бер тапкыр дөрләп янган хатын-кыз соңрак шуның көленә дә риза була.

Хәдичәгә дә үз башыннан нәкъ шуңар охшашлы мажараларны шактый кичерергә туры килде.

Күпмедер вакыт читтә болганып-тулганып йөргәннән соң, Хәдичә яңадан туган якларына кайтып төште. Ул чорда инде колхоз председателе булу дәрәҗәсенә күтәрелгән Мәдинә аны тимер юл вокзалы янында күреп алды һәм, көчләп диярлек, авылга алып кайтты. Нәкъ менә шул елларда башланды да инде Хәдичәнең намуслы хезмәт юлы. Нинди генә эшкә кушсалар да, карусыз алынды, җиренә җиткереп башкарды. Учларында ут уйнатты, кулыннан килмәгән эш булмады аның. Йөрәк парәсе — кызы белән күрешүнең иң туры, иң дөрес юлы намуслы хезмәт икәнлеген шулай төшенеп алды ул. Һәм бөтен тормышын, бөтен барлыгын хезмәткә багышлады, бар сагышын, бөтен кайгы-хәсрәтен эш белән басарга тырышты, авызыннан ялкын бөркелеп чыкканда да сиздермәде, эчтән генә сызып-янып яши башлады. Өенә дә бары тик бераз хәл җыеп, чак кына черем итеп алырга гына кайта торган иде. Кемгәдер, нәрсәдер исбат итәргә теләгәндәй, үҗәтләнеп: «Карыным белән кар ярырмын, борыным белән боз тишәрмен, әмма

маңгаемның кара тире белән юынып йөземне пакьлармын, исемемне акlargмын», дип, жан тирләре чыкканчы казганды ул. Шулай итеп көн артыннан көн, ел артыннан ел уза торды. Һәм, чыннан да, аның исеме макталып телгә керде, хезмәте башкаларга үрнәк итеп куела башлады. Күңеле утырган, йөрәк ярсулары чак кына басылып, тормышы бераз жайга салынган сыман булды. Әмма хезмәтенең ямен-тәмен чынлап торып белеп эшли башлагач та тәмам тынычлана алмады Хәдичә. Аны һаман да хакка да, нахакка да рәнжетәләр, я булмаса чит күрәләрдер сыман тоела иде. Үткән тормышы шулай шикчел иткән, күрәсең. Хәтта иң куанычлы, гомергә онытылмаслык истәлекле вакыйгаларга да, нинди дә булса шик-шөбһәгә бәйләп, килде-китте уй белән аз-маз күләгә төшерә торган иде. Ә бит башкалар белән бергә Хәдичәнең фидакарь хезмәте дә һичкайчан читләтеп үтелмәде. Җиде-сигез авылдашы белән бергә аңар да «Атказанган колхозчы» дигән мактаулы исем бирелде. Саттар Хәбирәләре Ленин ордены алган вакытта ул да өлешсез калмады: Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде. Тик ничектер шулай туры килде инде, орден алучыларны район үзәгенә чакыртып, зур тантаналар ясап, мәҗлесләр оештырып билгеләп үткәндә, Хәдичә янә кайдадыр, ниндидер семинарда булып калды. Билгеле инде, бу хәлне дә ул үзенчә: юри шулай эшләделәр, дип юрады. Аннары Мәдинә РСФСР Верховный Советы депутаты булып торганда ук Олы Кенәле авылы генераль план белән төзелә башлаган иде. Нәкъ шәһәрдәгечә итеп, бөтен шартлары тудырылып төзелгән искиткеч матур йорттан Хәдичәгә дә фатир бирделәр. Шул квартирны Шапырай карт белән бер түбә астыннан биргәч, янә: «Иш янына куш, ике чабата бер кием...» дип юри шулай эшләгәннәрдер инде, дигән уй туган иде Хәдичәдә. Әмма Шапырай абзый белән Хөпбениса түти күршелек өчен иллә дә мәгәр ипле кеше булып чыкты. Соңыннан Хәдичә алар белән күрше булуына сөенеп бетә алмады. Дәрья кебек киң күңелле Шапырай карт элекке, үзенең кырык тәрәүле өенә кеше чакырганда: «Ә-ә-нә, күрәсезме теге алпавыт утарыдай купшы йортны. Соң, әнә инде, теге калай түбәле, гөл-бакча эчендә утыра... Шуннан бер йорт аша гына минем өй булыр», дип әйтә торган иде. Хәзер исә аның тавышы чамадан тыш көр чыга. «Әнә, алма бакчалы йортны күрәсеңме?.. Өй почмагының иң күренеп торган җирендә, ак мәрмәргә алтын хәрефләр белән: «Атказанган колхозчы яшиң» дигән язу булыр. Шул түбә астында яшим инде мин. Тик икенче капкадан керергә...» дип өстәп куярга да онытмый иде.

Хәдичәнең ничектер төшенкеле ямансулавын һәр вакытта да иң беренчеләрдән булып Мәдинә сизеп-тоеп, күреп ала торган иде. Ахирәтенең боек-моңсу йөзен күрү белән, аулаграк җиргә чакырып ала да: «Я, нәрсә булды тагын. Ачып сал йөрәгеңне...» дип сораша башлый. Күңелен басып торган кара шомнарны чәчми-түкми чишә. Тегесе, гадәттәгечә, көлә генә, булмаган нәрсә белән башыңны катырма, юкка хафаланма, янәсе. Аннары: «Хәзер, Хәдичә, кешене кичәге халәтенә карап түгел, бүгенгесе белән бәялиләр. Син исә үзеңә теләсә кем кызыгырлык менә дигән яңа биография яздың», дип өстәп куярга да онытмый.

Яңа биография...

Хәдичә кинәт кенә аңына килгән кеше сыман сискәнеп китте. Яңа биография... Ничәмә-ничә еллар буена язылган шул яңа биографиясен бер селтәнүдә сызып ташлады түгелме соң ул?!.

Уйлар өермәсе яңа көч белән Хәдичәне ботарлый башлады. Ул да булмады, зиһенен яктырткандай, Вазих исенә төште. Әх-х, Вазих! Менә хәзер янымда син булсаң иде икән, дип уйлап куйды.

Тикмәгә генә килмәде ул Хәдичәнең уена. Узган елның көзендә Вазихның яман да усал кызы Хәдичәне кеше ганләсен җимерүдә гаеп-

ләп идарәгә чакыртты. Һәм аның соңгы тапкыр чакыртылуы булды бу. Менә шунда Вазих: «Синең бернинди дә гаебең юк, шунлыктан сиңа тел-теш тидерүләрен теләмим», дип идарәгә үзе киткән иде. Бәлки хәзер дә Хәдичәнең күңелендә: «Ничек тә шул Вазих ярдәм итәр иде әле...» дигән уй туган булгандыр.

Хәдичә, шулай уй иркенә бирелеп, өй эченә караңгылык иңүен дә сизмичә калган. Ул сәгать ягына җәһәт кенә күз салды, әмма күбып, комод янына килде дә бер көйгә генә текелдәп торган будильникны кулга алды. Биш тулып килә. Идарәгә барыр вакыт та җиткән ләбаса. Колхозда хәзер шундый закон: хәтта эшкә дә ике тапкыр әйтү юк. Шулай ук табынга утырту өчен дә кеше артыннан ялынып-ялварып йөрмиләр.

Хәдичә, ут та алмыйча, өс-башын аннан-моннан гына киенде дә бик үк күтәренке булмаган рух белән урамга чыкты. Анда инде, тирә-якны тоташтан томалап, котырынып буран чыгарга маташа иде. «Көненә кадәр чырай сытты бит...» дип уйлап куйды Хәдичә.

*

* *

Районда беренчеләрдән булып генераль план белән төзелә башлаган Кенәле үзәгенең бу тирәләре хәзер бер дә шәһәрдән ким түгел. Киң мәйданның як-ягында берсеннән-берсе олы, матур биналар. Менә тоташ пыяла тәрәзәләре гөлт итеп торган универмаг. Янында ук кафе-ашханә. Чак кына арырак, районның халыкка тормыш-көнкүреш хезмәте күрсәтү комбинатының филиалы.

Ә инде мәйданның каршы ягында, бу тирәләрнең күрке булып, авылның культура йорты тора. Аның янында ук тимер рәшәткә белән уратып алынган һәйкәл бар. Бөек Ватан сугышында һәлак булган авылдашларның исемнәрен мәңгеләштерү өчен салынган ул. Шуннан чак кына бирерәк — колхоз идарәсе. Нәкъ культура йорты кебек үк, һәркемнең игътибарын җәлеп итеп, әллә каян күренеп, күзгә ташланып тора. Фасадын ак кирпеч белән кызыл кирпечне аралаштырып, үзенчәлекле орнаментлар ясап, ике катлы итеп салынган ул. Идарәнең чак кына эчкә кереп торган алгы өлеше рәшәткә белән ураулы. Шунда ук рәт-рәт итеп алмагачлар, башка төрле җиләк-җимеш агачлары утыртылган, чәчәк клумбалары ясалган. Идарәгә керә торган капка челтәрләп-бизәкләп эшләнгән. Аның бер ягында Почет тактасы, икенче ягында «Маяк» колхозының перспектив планы. Боларның барысын да заманча итеп, зәвык белән каяндыр махсус чакырылган оста художниклар эшләгән.

Хәдичә биек капкадан үтте дә, бетон плитәләр җәелгән тротуар буйлап килеп, идарәгә керде. Беренче катта бухгалтерия, бригада бүлмәләре, өлкән зоотехник кабинеты, колхоз радиоузелы урнашкан. Председатель бүлмәсе белән партком кабинеты икенче катта.

Хәдичә икенче катка күтәрелде, «Кабул итү бүлмәсе» дип язылган ишекне ачып эчкә керде. Машинкада, тукран кебек шакы-шокы китереп, нәрсәдер басып утырган кыз, Хәдичәне күрү белән, сезне көтәләр, дигән кебек итеп, «Председатель» дип язылган ишеккә ым какты.

Хәдичә кара күн белән тышланган олы ишекне кыяр-кыймас кына ачты.

— Мөмкинме икән?..— диде ул, эчкә үтмичә генә.

— Кер, Хәдичә апа, кер,— диде Маннур, өстәле артыннан күтәрелә башлап.

Хәдичә керсә дә керде, кермәсә дә керде. Ишек катында туктап калып, кабинеттагыларны күздән кичерде. Әнә, өстәл янында Мәдинә утыра. Хәдичә керү белән: «Инде син төртеп екма», дип теләктәшлек эзләгәндәй, иң элек аның ягына күз салды. Әмма тегесе, аңардан йөз

чөергәндәй, партком секретаре Нәҗип ягына борылып, нәрсәдер исбат итә башлады. Аннары инде Хәдичә, ындыр табагыдай иркен кабинет буйлап үзенә таба якынлашып килгән Маннурга мөрәҗәгать итеп әйтте:

— Беләм... Нәрсәгә чакырганыгызны беләм,— диде ул, тонык-боек кына итеп.— Тиргәргә...

Маннур кинәт туктады. Хәдичәнең әрнү катыш шом тулы күзләрен күргәч, чын ихластан болай диде:

— И-и, Хәдичә апа! Нишләп ачуланыйк ди сине. Колхозның күзе өстендәге кашы икәнлегеңне үзең дә белми торгансыңдыр әле син. Билгеле, иртә якта фермада тавыш-буза, җәнҗал чыгаруың кирәкмәс иде... Дәрәҗә дә, мәртәбә дә өсти торган нәрсә түгел ул. Гомумән килешми... Без сине, Хәдичә апа, бөтенләй икенче мәсьәлә буенча чакырткан идек. Үзең күреп торасың, сөтчелек белән килеп терәлдек. Макталган килен туйда хур булган дигәндәй, районда гына түгел, бөтен республика күләмендә артта калдык. Шул эштә ярдәм итмәссеңме, эшкә МТФ га күчмәссеңме? дип сөйләшергә теләдек...

Хәдичәнең моңсу күзләренә яшь катыш нур тулды, йөзе кинәт, су өстенә төшкән кояш чагылышы сыман, ялтырап китте. Эченнән генә үз-үзенә: буеңны да төз тот, башыңны күтәр, сынатма! дип әмер биргәндәй итте. Шуның өстенә әле председательнең ифрат та үз итеп, тың итеп, киңәш-табыш сорагандай дусларча сөйләшүе Хәдичәгә тәмам җан өрде.

— Шул турыда баш ватып утыра идек,— дип дәвам итте Маннур. Аннары Хәдичәне түргә үтәргә, өстәл янына чакырды.— Утырып уйлый тор, аннары фикереңне тыңларбыз...

Колхоз председателе урынына барып утырды. Чәчен биш бармаклап аралап, артка сыпырып куйды да, Фирдәвес ягына борылып:

— Дәвам ит,— диде.

Хәдичә, керә-керешли, кабинетта утыручыларның әңгәмәсен бүлгән икән. Караса, яшел сукно җәелгән озын өстәлнең аргы башында Фирдәвес торып баскан. Алдында кәгазьләр. Ул шул кәгазьләрнең берсен алды да, карашын бер ноктага төбәгән хәлдә, иплән кенә, ашыкмыйча гына сөйләп китте. Әмма аның бу чыгышы сөйләүдән бигрәк кычкырып газета-журналлардан мәкалә укуны хәтерләтә иде.

Фирдәвес, озын чандыр гәүдәсен өстәл өстенә ия төшеп, алдында яткан кәгазьләрне бер читкәрәк этәреп куйды да тынып калды. Аның бу минуттагы бар рәвеш-кыяфәте: гүя МТФның шундый хәлдә калуында, терлек азыгы өчен җавап бирүче буларак, минем бернинди дә гаебем юк, дигәнне аңлата иде.

Хәдичә дә Фирдәвес ягынарак борылып утырды. Кызык егет ул. Яше утызга җитүгә дә карамастан, һаман да малай-шалай кебек беркатлы, кыз балалар кебек инсафлы, оялчан. Ә бит үзе авылда гына түгел, бөтен районда диярлек «кандидат» дигән гыйльми дәрәҗәсе булган бердәнбер кеше. Сугарыла торган культуралы көтүлекләр белән шулай дан казанды ул.

Фирдәвестән соң ук сүзне партком секретаре Нәҗип Низамов алды. Югары белемле, урта мәктәптә укытучы булып эшләгән кеше. Менә, икенче елы инде, колхоз коммунистлары үзләренең секретаре итеп сайлыйлар. Башта «аяк терәп каршы торган» дигән сүз йөрде. Әмма райкомда булып кайтканнан соң, риза булган дип сөйләделәр. Шулай да мәктәп белән элемтәсен өзми, һаман да шул тирәдә мәш килә. Узган көздә генә әле укучы балалар белән бергәләп музей ачтылар. Авыл музеенда агач сукадан тракторга, чыра яки сукыр лампадан электрга, землянка белән алачыклардан бөтен шартлары тудырылган, шәһәрчә салынган ташпулатларга ничек күчүләре бик ачык чагылдырылган. Бу музей турында өлкә газеталарында да язып чыкканнар иде.

Нәҗип әле яшь, янарак кына утызны тутырды. Үзе божыр кебек житез, хәрәкәтчән кеше. Сүзгә дә осталыгы зур. Трибунага-фәләнгә менеп басса, авызына карата да тота. Кәгазьгә карап сөйләүнең нәрсә икәнен белми. Менә хәзер дә ул фермалардагы партия группалары, аларның эше, тоткан урыны һәм җаваплылыгы турында сөйли башлады.

— Бу җәһәттән,— дип дәвам итте ул,— соңгы вакытларда партгруппаларның эше сизелерлек җанланды. Партгруппалар фермаларда эшләүчеләрнең производство активлыгын күтәрү, хезмәт дисциплинасын ныгыту, эчке тәртип кагыйдәләренең төгәл үтәлүе мәсьәләләрен даими игътибар үзәгендә тоталар.

— Һәм менә көтмәгәндә шундый ЧП,— дип дәвам итте партком секретаре.— Сәбәбе нәрсәдә? Бәлки хезмәтне оештыру тиешле югарылыкка куелмагандыр? Әйтмәс идем. Фермаларыбызның барысы да кадрлар белән тулысынча тәэмин ителгән. Савымчыларыбызның күбесе беренче һәм икенче класслы. Зооветеринария таләпләрен бозуга юл куелмый. Атнаның билгеле бер көнендә фермаларда коммунистик хезмәт мәктәпләренең дәресләре уза. Социалистик ярыш мәсьәләсе игътибар үзәгендә, ярышка кушылмаган һәм индивидуаль йөкләмәсе булмаган бер генә терлекчене дә тапмассың.

Партком секретаре сөйләгән арада Хәдичә кабинетта утыручыларны кабат күздән кичерде. Стена буена тезелеп куелган урындыкларда МТФ партгрупоргы Зәйнәп белән Саттар Хәбирәсе генә. Зәйнәп, тәрәзә ягына караган да, дөньядан ваз кичкән кебегрәк утыра; күз карашы еракка төбәлгән аның, уй-фикерләре белән әллә кайларда йөзә булса кирәк. Аларга каршы якта — зоотехник Миргасим. Күзләре ут аның: аңар бар нәрсә дә кызык, бар нәрсә дә кирәк.

Хәдичәнең карашы колхоз председателе Маннурга туктады. Күзе төшү белән хәйран булды да калды. Һай, бу узган гомерләрне генә әйт инде син, ә! Маннурны гына күр... Ул да хәзер өч бала атасы. Арслан ялыдай тузгып торган коңгырт-кара чәчләренең чигә тирәләрен бәс баскан. Бүлтәеп, чак кына алга чыгып торган киң маңгае тагын да ачыла, зурая төшкән. Йомры иякле, эре борынлы, беренче карашка чак кына тупасрак булып күренгән бу йөзне купорос ташы кебек яшел-зәңгәр күзләр бизәп тора. Әмма ул күз тирәләрендә инде пәрәвездәй вак җыерчыклар сузылган. Буй-сынга, гәүдәгә егетләрчә таза. Моны көч бөркеп торган киң җилкәләреннән үк күрергә була.

Ярата Хәдичә Маннурны, ихтирам итә. Яшь булса да өлкәннәр сабырлыгы бар аңарда. Хәер, гелән җитәкче булу, зур урыннарда эшләү сәбәпле, акыл утыртырга өлгергәндер шул инде, дип нәтиҗә ясагандай итә Хәдичә. Кеше күңеленә ачкыч таба белүен әйт әле син аның. Менә хәзер дә килеп керү белән, җанга рәхәт өстәрлек итеп бер генә елмайды, үз бәхетенә үзе исергән исәрдәй хис итә башлады Хәдичә шунда үзен. Күкрәгенә ташкын сыман шатлык хисләре бәреп кергәндәй булды. Ә бит Маннурга берьюлы меңләгән кеше белән эш итәргә туры килә.

Хәдичә күз карашын Мәдинәгә күчерде. Өстәл кырыена терсәге белән таянып, ияген учына куеп, башын чак кына кыңгыр салып утыра ул. Күз карашлары хәрәкәтсез, каядыр билгесез бер ноктага төбәлгәннәр. Мәдинәнең йөзе җитди. Шәлен дә, өс киемен дә салып элеп куйган. Ялан баш. Кайчандыр күпереп торган матур чәчләр хәзер инде чаларып, көл төсенә кергән. Нечкә, килешле кашлары астыннан өздереп караган соры күзләре бик моңсу. Бөтен халәтендә арыганлык сизелеп тора. Әмма йөзе матур да, мөлаем дә аның. Кояшта тигез булып янган маңгай, авыз кырыйларындагы җыерчыклар үзенә бик тә килешә. Борыны бик нәфис, чак кына өскә таба төртебрәк тора. Бу исә

аны бары тик бизи, чибәрлеген бары тик арттыра гына кебек. Күзләреннән, бөтен йөзеннән ниндидер жылылык бәрә, нур чәчелеп тора. «Эх-х, Мәдинә, Мәдинә! Шулай итеп син дә картаясыңмыни инде?!» дип уйлап куярга мәҗбүр булды Хәдичә.

Әңгәмә дәвам итте. Моңаю катыш ниндидер гаять борчылган кыяфәттә утырган Мәдинәгә дә чират житте. Ашыкмыйча гына урыныннан күтәрелде дә, сүзне дәвам итәргә җай чыкканга куанган шикелле, салмак кына элеп алып китте. Тора-бара аның күзләре жанлана-очкынлана башлады, тавышы да көррәк яңгырады. Ул фермадагы депутатлар постлары турында сөйләде. Үз вазифаларын жиренә житкереп башкаручыларның исем-фамилияләрен атады.

Шул чак, Мәдинәнең сүзен бүлеп, кабинет ишеге ачылып китте дә, «мөмкинме?..» дип, базык гәүдәле бер шофер егет керде.

— Маннур абый,— диде ул, башындагы күн тышлы бүреген сыдырып йолкып алып.— Сөтебезне тагын кире бордылар...

Маннур урыныннан торды.

— Берегезнекен дә кабул итмәделәрмени?

— Барыбызны да бордылар...

Бу хәлләрне күздән яздырмыйча күзәтеп торган Хәдичә председательнең күтәрелеп бәрелүен, бу яман хәбәрне китергән егетне элеп алып селкеп салыр дип көткән иде. Әмма Маннур гаять тыныч кына, хәтта дустанә бер кыяфәттә, сөтне дуңгызлар фермасына илтеп тапшырырга кушты, кайнатымпы яки анда әчетепме, терлекләргә бирү чарасын күрсеннәр, диде. Шулай да, егет чыгып киткәч, көрсенеп: «Менә кая оча ул чынлап торган хәләл тәңкәләр!..» дип әйтеп куйды.

Мәдинәдән соң чыгыш ясаучы булмады. Бары тик аңынчы авызына су алгандай тавыш-тынсыз гына утырган яшь белгеч Миргасим гына:

— Бөтен бәлабез, бөтен хатабыз бу эшкә Гөлнур апа югында керешүебездә...— дип тирән уфтангандай итеп әйтеп салды.

Бу фикергә барысы да берьюлы кушылган сыман булдылар. Маннур да соңгы сүзен әйтте:

— Әйе!.. Сүз дә юк, күрсәттек үзебезнең нәрсәгә сәләтле икәнлегебезне...

Бу сүзләрне Гөлнур урынына калып торган Саттар Хәбирәсе үз бакчасына таш ату дип кабул итте, ахрысы. Ул шунда ук чәчрәп сикереп торып, кырлы-мырлы сөйләнеп алды.

— Алайса, үзегез эшләп күрсәтер идегез...

Маннурның йөзенә күләгә кунды. Һәм ул, саксызлык белән күңелне кузгатырлык сүз ычкындырган Хәбирәне исенә китерергә теләгәндәй:

— Андый киңәш-миңәшләрнең башы-ахыры шул булыр дип уйлыйм,— диде дә: — Ярар, иптәшләр! Бу жыелыш, эшлекле киңәшмәдән бигрәк, тантаналы митинг төсен ала башлады...— дип, сүзен бетерде.

Чыннан да, производство киңәшмәсенә охшашлы бу утырыш үзәк мәсьәлә тирәсенә төпле фикер туплый, конкрет карар кабул итә алыр төсле түгел иде. Бәлки шуңадыр, Маннур: сүз болай да кирәгеннән артык күп булды, дигән кыяфәт белән туп-туры Хәдичәгә мөрәҗәгать итеп, баягы тәкъдим турында нәрсә әйтерсең дип сорап куйды.

Хәдичә нәрсә дип әйтсен соң? Монда инде ике төрле уйларга урын калмаган. Әнә бит аңар нинди зур ышаныч белән карыйлар. Яшеренбатырын түгел, бу минутта Хәдичәнең күңеле урыныннан купкан, куанычы канат яра иде. Димәк, туган колхозына ярдәме кирәк, аның хезмәте сорала. Тормышта шулай үзеңнең кешеләргә кирәклегеңне тоюдан да зуррак, бөегрәк шатлык бармы икән бу фани дөньяда!

— Мин риза...— диде ул ниндидер бер жилкенү белән.— Билгеле, кадәре хәлчә сез дә булышырсыз...

*
* *

Фирдәвеснең галим булуы шуны максат итеп куюдан яки анда гыйльми дәрәҗә, карьера артыннан куудан түгел, ничектер, үзеннән-үзе килеп чыкты. Барысы да шул сугарулы көтүлекләр турында уйлаудан башланды.

Бу эш белән Фирдәвес бик күптәннән, авыл хуҗалыгы институтында укыганда ук кызыксына башлаган иде. Диплом эше дә шул темага иде. Авылга җәйге каникулга кайткач, Фирдәвес тәҗрибә участогы булдыру өчен егерме гектар җир сорап колхоз идарәсенә гариза бирде. Бер дә: рәхим ит, дип тормадылар, моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән нәрсә дип, ниндидер чокырлар казып, баганалар утыртып, ата-бабалардан мирас булып калган болынлыкны «боздыруга» каршы чыгучылар да булды. Әмма Фирдәвеснең үз сүзендә тора торган егет икәнлеген искә алып, шуның өстенә диплом язу өчен кирәк булгач, егерме гектар урынына ун гектар чамасы җир бүлеп бирергә дигән карар кабул иттеләр. Әйдә, имеш, каян килеп кая китмәгән. Фирдәвес сораган үзәнлекнең соңгы елларда печәне дә әллә ни куандырырлык булмый иде.

Оны булгач, мае кирәк дигәндәй, көтүлекләрне кишәрлекләргә бүлү өчен баганалар, алар арасына сузарга тимер чыбыклар, сууткәргеч трубалар, сугару өчен насослар турында да кайгыртырга кирәк булды.

Председатель булып Мәдинә эшләгән еллар иде. Авылның да генплан белән салына башлаган чагы. Ансыз да төзелеш материалларына, башка кирәк-яракка кытлык зур булса да, Фирдәвес тә өлешсез калмады. Трубаларның бер өлеше үзләрендә табылды. Үзәк урам чатларына су колонкалары куюдан, торак йортларга су кертүдән калган трубалар иде алар. Алар гына җитмәгәч, ярдәм сорап, шефлык итүче заводка мөрәҗәгать иттеләр. Аның каравы, баганалар мәсьәләсе бик җиңел хәл ителде. Район үзәгендәге бетон заводына бардылар да тимер чыбыклар үткәрү өчен алкаларына кадәр куелган тимер-бетон баганаларны кирәк хәтле төяп кайттылар. Алар кайсыдыр төзелеш оешмасы кабул итмәгән перемычкалар булган.

Ул көннәрдә Фирдәвес ял итүнең нәрсә икәнлеген бөтенләй онытып эшләде. Иң элек бик нык тапталудан «кара җиргә» чыккан участокны буйдан-буйга дискылар белән культивация ясатып чыгарттылар, сайлап алып үлән орлыклары чәчтерде. Бары тик шуннан соң гына көтүлекне тимер чыбыклар белән кишәрлекләргә бүлдерде, насосларны көйләтте һәм, гүзәл Кенәледән су суыртып, «яңгыр яудыра» башлады...

Авыл халкы, бигрәк тә терлекчеләр, бүленеп алынган мәйдандагы үләннең чалгы кермәслек булып, кара-кучкылланып үсүен күреп хәйран калдылар. Кайчандыр аңар каршы чыгып маташучылар да, телләрен шартлаткалап, эчтән тынарга мәҗбүр булдылар.

Ниһаять, иген басуы кебек төрле төсләргә кереп, дулкынланып шау чәчәктә утырган кишәрлекләрне чабып алу вакыты җитте. Нәтиҗәләр исә көткәннән дә узып киттеләр. Фирдәвеснең культуралы көтүлегенең һәр гектары 470 центнер мена дигән печән бирде. Бу табигый болын уңышына караганда унбиш тапкырдан да артыграк дигән сүз иде.

Фирдәвес исә, кайчандыр бу яңалыкка каршы чыгучыларны үртәргә-үчекләргә теләгәндәй, мондый уңышны бер үк болыннан елына бишалты тапкыр җыеп алырга мөмкин дип, отыры гайрәт чәчте.

Хәер, гайрәтләнерлеге дә бар иде шул егетнең. Чөнки халык беләбелгәннән бирле Кенәле буе болынлыкларының печәнен июнь ае ахырларында бер тапкыр чабып алырлар иде дә, шуның белән вәссәлам. Бик сирәк елларда, яңгырлар мул явып, еллар үтә матур килгән җәйләрдә генә икенче катка чыккалыйлар иде.

Уныш җыелып алыну белән Фирдәвес яңадан эшкә кереште. Көтүлек мәйданнарына мул итеп ашлама кертеп, яңадан «яңгыр яудыра» башлады. Көннәр матур торгангамы, үлән яңадан күпереп-котырып үсеп китте. Ике атна үттеме икән, әлеге кишәрлекләрдә янә калын булып кәлшә үсеп чыкты. Бу юлы инде кишәрлекләргә чиратлап сыерлар керттеләр. Иң кызыгы шунда, бик борынгы булып саналган көтүче һөнәренең кирәге калмады, терәлеп торган җәйләүдән ут сузып, кишәрлекләрне уратып алган тимер чыбыкларга кирәк микъдарда ток җибәрелде...

Барыннан да бигрәк сыерлар рәхәткә тиенде. Хәзер алар, бер кишәрлектән икенчесенә күчеп, хуш исле үләнне теләгән кадәр ашап-утлап йөриләр. Суга да әллә кая барып йөрисе юк. «Беларусь» тракторлары сыерлар кергәнче үк кишәрлекләр эченә автоэчергечләрне алып килеп куя торган булдылар. Менә шунда күтәрелде дә инде «Маяк» колхозы савымчыларының даны. Урта кул саналган сыер савучылар да көненә һәр сыердан ким дигәндә берәр пот сөт ала башлады.

Билгеле инде, сыер алай бик нәзберек түгел. Әмма йомшагын, хуш ислесен, үзенә кирәген сайлап ашый. Сыерлар булып чыккан кишәрлектә шактый мул үлән утырып калганлыгы ачыкланды. Фирдәвес ул үләнне дә әрәм итмәде, сыерлар икенче кишәрлеккә күчерелү белән, утлап узылган көтүлекнең печәнен һәйбәтләп чаптырып алды һәм печән оны хәзерләү өчен моннан да яхшысы юк дип, ферма янына ташыттырып куйды.

Ул арада колхоз тормышында да зур үзгәрешләр булып алды. Колхоз председателе итеп элек партком секретаре булып эшләгән Маннурны сайлап куйдылар. Кайнар табигатьле, яңалыкка ике куллап чат ябышырга әзер торган Маннурга җитә калды, сугарулы культуралы көтүлекләр «җене» аңа да кагылды. Хәер, башкача булуы да мөмкин түгел иде. Терлекчелек — авыл хуҗалыгының иң авыр, иң катлаулы, барлык сарыф ителгән хезмәтнең өчтән береннән артыгын ала торган тармагы. Шуңа күрә дә бу өлкәдә фән-техника революциясенә кытлык үзен аеруча нык сиздерә. Механикалаштыру, электрлаштыру, химиялаштеру дип, терлекчелекне промышленность рельсларына кую, терлекчелек хезмәтенең культурасын күтәрү дип җан атып йөргән Маннур, председатель булган көннән башлап, Фирдәвеснең беренче хезмәттәшенә әверелде.

Фирдәвес диплом яклыйсы елны колхозның сугарулы культуралы көтүлекләре сиксән гектарга житте. Тагын ике елдан аның мәйданы ике йөз гектардан да артык иде. Ул елларда инде бу эш ил күләмендә таралган, полиэтилен трубалар, су сиптерү станцияләре һәм ясалма яңгыр яудыру өчен берничә төрле маркалы махсус машиналар чыгарыла башлаган иде.

Фирдәвеснең гыйльми дәрәҗә алуы исә болайрак булды. Иң элек районның авыл хуҗалыгы идарәсеннән вәкилләр килеп терлекчеләр янында ике-өч көн буена китмичә яттылар. Ул да булмады, өлкә газетасыннан берьюлы ике хәбәрче килеп, Фирдәвесне терлекчеләр йортына бикләп куеп диярлек, мәкалә яздырып алдылар. Эшне бик коры тоттылар, алар китеп ике-өч көн үтүгә газетада саннар белән шыплап тутырылган зур гына мәкалә басылып чыкты.

Нәшрият та әллә ни озак көттермәде. Китап чыгарабыз дип, зурдан кубып килеп җиттеләр.

Шуннан соң ай чамасы вакыт узгач, Фирдәвесне Казанга, Бөтенсоюз күләмендә үткәрелә торган зур конференциягә чакырып кәгазь килеп төште. Анда илнең төрле почмакларыннан колхоз, совхоз житәкчеләре, район, өлкә һәм край авыл хуҗалыгы идарәсе начальниклары, белгечләр, мелиораторлар, галимнәр, авыл хуҗалыгы белән

бәйле проект оешмалары вәкилләре, өлкә һәм союз масштабындагы партия аппаратларыннан авыл хуҗалыгы мөдирләре, авыл хуҗалыгы мәсьәләләре белән җитәкчелек итүче өлкә комитеты секретарьлары килгәннәр иде. Менә шунда Фирдәвес үзенең берьюлы русча һәм татарча бастырып чыгарылган брошюрасын күреп шаккатты. Ай-яй, тиз тотканнар дип, хәйран булды ул.

Аны бу гадәти булмаган форумга, әлеге дә баягы, Казан авыл хуҗалыгы институтының кафедра мөдире, профессор Таҗи ага Бариев чакырткан икән. Таҗи ага кайчандыр Фирдәвеснең диплом эшенең гыйльми җитәкчесе була. Бик тыйнак, аз сүзле, сабый балаларныкы кебек саф карашлы Фирдәвесне бик яратып калган иде ул. Аны хәтта аспирантурага калырга да өндәгән иде.

Күрешү белән, Таҗи агайның беренче сүзе шул булды:

— Кулында көн кадагына суга торган темага язылган менә дигән диссертация синең. Кичекмәстән эшкә алын. Үзем гыйльми җитәкче булам. Менә мин сиңа монда диссертациянең нигезен, җирлеген ныгыту, масштабын киңәйтү өчен бераз материаллар да туплап куйдым,— дип, Фирдәвескә шактый калын папка тоттырды. Һәм әмер-приказ биргәндәй катгый итеп өстәп тә куйды.— Тик бер шарт: бүген үк эшкә керешәсең...

Папкадагы материаллар белән шул ук көнне таныша башлады Фирдәвес. Әлбәттә, диссертация яклап тизрәк гыйльми дәрәҗә алыйм дип түгел, бары тик өлкән кешенең сүзен аяк астына салмыйм, дип керешә ул бу эшкә. Күндәм, сүз тыңлаучан булу аның инде канына сеңгән.

Папкада исә партия һәм хөкүмәтебезнең чәчү җирләрен киңәйтү һәм саклау турында карарлары, исемнәре бөтен дөньяга билгеле булган галимнәрнең җир-ана турында кайгыртып язган хезмәтләре, күп төрле брошюралар тупланган иде.

Шул ук папкада Фирдәвес безнең республикабыз турында гаять кызыклы мәгълүматлар тапты. Әмма алар һич кенә дә куанырлык түгелләр иде. Соңгы елларда Татарстан чәчүлек җирләрен бүтән теләсә кайсы республикаларга караганда күбрәк югалткан икән. Куйбышев дингезе астында гына, мәсәлән, 300 мең гектардан артыграк уңдырышлы җирләребез калган. Ә тиздән Түбән Кама гидростанциясе сусаклыгычы тагын шактый мәйданны басачак. Шулар янына тагын уннарча һәм уннарча мең гектар җирнең нефть промыселлары һәм Кама автозаводына бирелүен дә өстәсәк, хәлләрнең ничек торуына төшенү әллә ни авыр түгел. Демографларның исәпләвенә караганда, алдагы берничә елда гына да республикабызның халкы тагын бер миллион кешегә артырга тиеш икән.

Менә эшләр кай тирәдәрәк йөри икән дип уйланган иде Фирдәвес ул вакытта. Яшерен-батырын түгел, аның кинәт күзе ачылып киткән сыман булды. Һәм ул ирексездән бу мәсьәләнең үзләрендә ничегрәк торуы турында уйланып, чагыштырып карагандай иткән иде. Колхозда соңгы елларда чәчүлекләрне киңәйтү буенча күп төрле чаралар үткәрелүе аның өчен сер түгел иде, әлбәттә. Кечерәк ике поселок — Таллы Буләк белән Якты Аланлык Олы Кенәлегә күчерелде. Алар биләп торган урыннар, тигезләндерелеп, менә дигән уңдырышлы басуларга әйләндерелде. Аннары тагын сөзәгрәк тау битләре, әллә ни әһәмияте булмаган юллар, аланлыклар шулай ук сөрелделәр. Бу эшләрнең барысы белән дә авыл советы каршында төзелгән махсус комиссия шөгыльләнде. Әлеге дә баягы, тынгысыз Мәдинә апасы башлап йөрде.

Таҗи абзасы биргән папкада тарихи документлар да җитәрлек иде. Революциягә кадәр, мәсәлән, барлык сөрү җирләренең 96 проценты иген кырын тәшкил иткән булса, 1966 елда инде ул нибары 67 процентка гына калган. Моннан ярты гасыр элек терлек азыгы культуралары

гомуми мәйданның нибары 0,3 процентын гына тәшкил иткән икән, ә хәзер исә ул сан йөз тапкырга диярлек арткан инде.

Менә ни өчен сугарулы көтүлекләр турында шулай зурдан кубып, шулай игътибар үзәгенә куеп, Бөтенсоюз күләмендә семинарлар җыеп, форумнар үткәрәләр икән!..

Фирдәвеснең бу форумга катнашуы бик тә ярап куйды. Культуралы көтүлекләр, аларны сугаруга карата төрле фикерләр, төрле карашлар яшәп килүе билгеле булды. Шулай ук көтүлекләрне ничегрәк һәм күпме вакыт файдалануга карата да капма-каршы сүзләр булып алды. Хәтта үзенә күрә бәхәс сыман нәрсәләр дә чыкты. Академик Андреев, мәсәлән, үзенең докладында төп мәсьәләгә кагылып: сугарулы көтүлекләрне егерме-утыз елдан алып илле елга кадәр файдаланырга мөмкин, дип чыкты. Әмма Мәскәү янындагы «Красный луч» колхозы председателе, Социалистик Хезмәт Герое Кудряшов исә, көтүлекләрдән елына дүрт-биш кенә түгел, бәлки сигез-тугыз уңыш алып, нибары биш-алты ел дәвамында гына файдалану мәгъкульрәк дигән фикерне алга сөрде. Менә сиңа бер үк мәсьәләгә карата ике фикер: берсе — алдынгы фән сүзе, икенчесе — авторитетлы практика нәтиҗәсе.

Өч-дүрт көн дәвам итте бу зур сөйләшү. Фирдәвес тә үзе өчен бик файдалы, гаять дәрәҗәдә кирәкле, кыйммәтле мәгълүматлар туплады.

Кыскасы, шул: Тажи ага Фирдәвесне үзеннән бер генә адымга да читкә җибәрмәде, тимерне кызуында сугып калыйк дип, кулыннан тотып торып диярлек диссертацияне яздырды, үзе үк редакцияләп машинкага бирә барды. Ике-өч ай эчендә диссертация әзер булды. Яклавы да, ничектер, озакка сузылмады кебек.

Әмма Фирдәвескә бу эш шактый ук авырга туры килгән булса кирәк. Кандидат булып авылга кайтып төшкәндә, элек тә чандыр һәм озын гәүдәле, аксыл йөзле егетнең шәүлегән күләгәсе генә калган кебек иде.

*
* *

Теге вакытта Гайния түти: «Әүлия кебек кешене үзенә каратып, теләсә кем кызыгырлык итеп яши дә башлаган идегез» дип тикмәгә генә әйтмәде. Ул чагында чыннан да Хәдичәгә бәхет йолдызы елмаеп куя язган иде шул, аның күңел күгендә дә өмет нуры кабынган иде. Гайния түтинең: «Ил өстендә зурдан кубып туйлар ясап...» дигән сүзләрендә дә өлешчә булса да хаклык бар. Билгеле, теш агартырга яратучылар теленә генә «туй» булып кергән сүз иде ул. Вазых белән белешкәннән соң Хәдичә чыннан да сере сыярлык, дус күргән кешеләрен чакырып алып мәҗлес кебек нәрсә уздырды. Алай гына да түгел: «Кемнең теләге-дәрте бар, рәхим итсен... Картлар әйтмешли: ишек уйган, тәрәзәләр куйган». Иң элек, түр күрке син дип, Мәдинәне чакырды. Тегесенең: «Ниндирәк мәҗлес соң ул, туй түгелдер ич?» дигән соравына Хәдичә уенын-чынын бергә кушып: «Әйдә, күп соранып торма. Кияү кеше качмаса, туй булыр, ә инде китеп барса, чакырылган аш булыр. Барыбер бер җыелып аласы бар иде инде», дип кенә җавап бирде.

Уракка төшкән көннәр иде. Әлмәт нефть һәм газ чыгару идарәсеннән бер колонна машина килеп төште. Шоферларның сыйган кадәресен кунак өенә урнаштырдылар, калганнарын аерым йортларга тараттылар.

Хәдичәгә дә бер шофер керткәннәр иде. Бу турыда аңар, эштән кайтып килгәндә, ул вакытта инде авыл советы председателе булып эшли башлаган Мәдинә әйтте. Әле дә булса хәтерендә Хәдичәнең: бу хәбәр

аңар ошамады, аны куандырмады. Ул хәтта: «Кирәкмәс иде, мин бит көне-төне фермада...» дип мыгырданып, «казенный йорт булгач, рөхсәтфәлән сорап та тормаганнар» дип уйлап та куйган иде әле. Әмма Мәдинә аңар, юк-бар белән баш ватмаска киңәш итеп, шоферның өлкән яшьтәге кеше булуы, аларның да шулай ук көне-төне икмәк ташыячаклары турында әйтеп тынычландыргандай итте. «Ә инде ашау-эчү хәстәрен күрергә авырыксынсаң, әнә, ашханәсе. Әзерлим дисең икән инде, кирәкле азык-төлек складтан биреләчәк»,— диде.

Хәдичә кайтып кергәндә, капка төбендә тау кадәрле йөк машинасы тора. Күршесе Шапырай карт ишек ачып кунакны өйгә керткән. Шапырай карт һәм таныш булмаган бер кеше түрдәге сарай янында нәрсә турындадыр гәп салып мәйханә кыйлалар. Хәдичәне иң элек күрше карт күреп алды. Күреп алды да: «Менә безнең уңган-булган Хәдичәбез, тәк сказать, колхозыбызның горурлыгы шушы була инде», дип, теленә дә салына башлады.

Исәнләштеләр. Исемнәрен әйтешеп таныштылар. Шофер Вазих атлы икән. Ул инде чыннан да яшь түгел, чаларган чәчләренә, җыерчыклар баскан, җил кисеп тутланган йөзенә караганда, илле яшьләр тирәсендә булырга тиеш иде. Хәдичә аның колак артында чигәсенә кадәр сузылган яра эзе барлыгын да шәйләп алды. «Фронтовик икән. Шул яра эзен яшерү өчен чәчен җиткереп йөри торгандыр» дип уйлап куйган иде.

Ике-өч көн үттеме икән, Хәдичә тәмам ияләште Вазихка, баштагы тартыну-уңайсызланулар бетте. Искәрмәстән генә үзенә дус, гаҗәеп акыллы фикердәш тапкандай булды. Өйдә бергә туры килгән вакытларда алар сөйләшеп туймый торганнар иде.

Вазих үзе дә ифрат дәрәҗәдә тотнаклы, гаять тә сабыр, тыныч табигатьле кеше булып чыкты. Җаен туры китереп, Хәдичә аның кайда, кайчан яралануы турында да сорап куйды. Гомумән, сугышта булган, көн дә диярлек үлем белән күзгә-күз очрашып, илебез хакына кан койган кешеләргә тирән ихтирам белән карый иде ул. Вазих та унҗиде яшендә армиягә алынган, ә инде унсигез яшендә элемтәче булып сугышка кергән. Бер тапкыр шулай күрше частька пакет илткәндә урман эчендә минага эләгә ул. «Үлүем шушы икән» дип егылуын, егылганда бары тик агач башларының әйлән-бәйлән уйнагандай чайкалып китүен һәм шунда: «Үлгән хәбәремне алгач, минем өчен елаучы да булмас», дигән уй тууы турында әйтте Вазих. Аның әтисе фин сугышында һәлак булган, әнисе исә үзе армиягә алыныр алдыннан гына үлгән. Ә инде сугыш бетеп, госпитальдән чыккач, Вазих туган якларына кайтып төшкән. Менә шунда аны ире фронтта үлеп калган күрше хатыны йортка кертә. Шулай итеп башлы-күзле булган Вазих, Розалия белән Галия исемле ике кыз үстергәннәр. Алар да инде хәзер тормышка чыгып, аерым яшиләр икән.

Көн артыннан көн үтә торды. Кичләрен, кичектергесез эше көтеп торган сыман, өенә атлыгып кайта торган булды Хәдичә. Шулай итеп борчу-мәшәкать артты. Аш-суны җиренә җиткереп, мул итеп, шуның өстенә төрләндереп хәстәрләде. Әйдә, дөньялар имин, табыннар сыйлы чакта ашасын, рәхәтләнсен, кызгану юк. Вазихның кием-салымын юды, үтүкләде. Бу эшләрнең барысын да бернигә дә алыштыргысыз илаһи бер тойгы, рәхәт табып башкарды ул. Вазихның рейстан кайтуын зарыгып көтте. Тиздән, бик тиздән хис-тойгыларының нинди дә булса кискен борылыш ясаячагын күңеленең кай җире беләндер сизенә дә башлаган иде инде ул. Шул ук вакытта Хәдичә үзен тезгенләргә кирәклеге турында да онытмый иде. Тел озайтырга бернинди җай, бернинди сәбәп калдырмаслык итеп яшәүдә иде аның максаты. Үткәннәрне гомер чутыннан сызып, чигереп ташларга мөмкин булмаса да, кире кайту юк: ул арада үтә алмаслык киртә ята.

Яшерен-батырын түгел. Вазих та Хәдичәне беренче күрүдә үк үз итте, күңеле ятты. Үзен күргәнче үк, бусага аша атлап керү белән, бу өйдә уңган-булган хатын-кыз яшәвен абайлап алган иде ул. Өй эче кунак көткәндәй пөхтә итеп җыештырылган, ялт итеп тора. Гәрәбәдәй сап-сары итеп юылган идәннәрдән салкын-сафлык бөркелеп, агым су исе аңкып тора. Ә инде Хәдичәнең үзенә карап торгач тәмам хәйран булды, күңелен нәрсәдер тынгысызлый, бимазалый башлады. Абажур аша лампа яктылыгы сирпеп торган кебек, Хәдичәдән дә дәрт, дөрләп янарга сәләтле ялкын сирпелеп тора иде.

Ә инде Вазих китәргә атна-ун көн генә калды дигәндә, алар арасында шактый ук үтемле җитди сөйләшү булып алды. Башта, ничектер, ярым шаяру кебек кенә башланса да, соңрак шактый җитди төс алды ул әңгәмә. «Әх-х, Хәдичә!.. Шул кадәр ияләштем үзеңә... Онытa алмый газапланырмын инде»,— дип башлады Вазих. Мондый сүзләрне ишетергә бик зарыккан, бик тә мохтаҗ иде Хәдичә. Шулай да ул көлде генә. «И-и, Вазих, сөйләнгән буласың шунда. Өенә кайтып, карчыгың кочагына керү белән дөньяң түгәрәкләнер... Хәдичә ике ятып бер төшеңә дә кермәс әле...»

«Ярый ла, шулай булса...»

«Синә нәрсә, Вазих. Ул менә безгә, сагышлы-моңлы сыңар канат, ялгыз-йолгыз тол хатыннарга яман. Я-а, Вазих! Туйдыра икән ул ялгызлык адәм җанын...»

Алар шулай ут та кабызмыйча бер-берсенә йөрәкләрен ачтылар, күңелләре булганчы серләштеләр. Күбрәк Вазих сөйләде. Ул да үзенең назга-җылылыкка бик мохтаҗ икәнлеген аңлатырга теләде. «Сине күргәннән бирле, Хәдичә, үземне искәрмәстән генә бәхет тапкан кешедәй хис итә башладым. Моңарчы бер дә татымаган илаһи рәхәткә тап булдым кебек... Сүзгә осталыгым юк шул минем, күңелемдә булганнарны барыбер аңлата алмам...»

Хәдичә дә ачылып киткәндәй булды. Ияләшүен, аны юксынып көтеп алулары турында әйтте. Менә шунда Вазих, урындыгыннан күтәрелмичә генә, каршында, комод янында басып торган Хәдичәне йомшак кына итеп биленнән кочаклады һәм үзенең чал башын аның күкрәгенә салды. Хәдичә дә, онытылып китеп, Вазихның чәчләрен аралап сыйпаштырды. Бу минутта аның бөтен тәненә зарыгып көтелгән, гаять тә тансык бер наз, рәхәтлек таралды... Рәхәт тә, бер үк вакытта әчтән сызып, бәгырьләрне телгәли торган үзенә бер төрле сырхау да ул.

Әмма Хәдичә бик тиз үз-үзен кулга алды. «Кирәкми, Вазих...— дип йолкынып читкә тайпылды.— Кирәкмәс... Йоклаган арысланны уятмыйк... Ярамый!»

Ул бу сүзләрне юрамалай, шаярган кебек итеп әйтте. Шуннан соң Хәдичә, юк йомышын бар итеп, фермага дип чыгып китте.

Бу хәл икесенең дә күңелен иләс-миләсләндергән иде. Шул әңгер-меңгердә сөйләшүдән соң алар бер-берсеннән чак кына тартына торган булып калдылар. Вазих исә, юк эшне бар итеп, ишегалдында чуалды. Беркөн, иртәнге чәй вакытында, ындыр табагы чаклы ишегалдына күрсәтте дә: «Хәдичә, ник бакча утыртмыйсың? Никадәрле җирең әрәм булып буш тора»,— диде. Йорт хуҗасы көлде генә: кая аңар вакыт, кем аның белән шөгыльләнсен, янәсе. Вазих: «Ярар, алайса... Бакчалы итим әле үзеңне. Төсем булып калыр»,— дип, шул ук көнне кичен эшкә керешге. «Нәрсә, күрше, бәрәңге алыр вакыт җиткәч, син утыртырга гына җыенасыңмы әллә?» — дип, шул тирәдә чуалган Шапырайны да Вазих, картлык көнеңдә алма турап, карлыган вареньесе белән чәй эчәрсең дип, эшкә җикте. Беренче көнне җирне казып буйдан-буйга каналлар суздылар, агач утырту өчен оялар ясадылар. Иртәгесен ике машина белән кайтарылган тиресне тараттылар. Өченче көнне Вазих төшкә ашка да кайтмады, станциядән шактый еракта урнашкан питом-

никтан тулы бер машина җиләк-җимеш үсентеләре алып кайтып аударды. Иң элек, коймa буйлатып, кура җиләге, аннары карлыган, соңыннан инде алдан ук хәзерләп куелган ояларга ун төп алмагач утыртып чыкты. «Илләә дә мәгәр маһир, иллә дә мәгәр хирес кеше икәнсең!» дип, җае чыкканда такмазалар әйтеп алгалаган Шапырай карт та өлешсез калмады. Аларның тәрәзәләре каршына да өч-дүрт төп алмагач, шактый гына карлыган белән кура җиләге куаклары калкып чыкты. Аннары инде озын шлангны тәрәзә аша үткәреп кранга ялгадылар, бакча мәйданы күлдәмә булганчы төннең-төн буе су агыздылар.

Вазих китәргә өч-дүрт көн кала гына мәзәк сүз ишеттерделәр Хәдичәгә. Имештер, шоферлар элеваторга барып җиткәч, машиналарын чиратка куялар да, бергә җыелып гәп сатып, тәмәке көйрәтә башлыйлар. Шул вакыт авыл шоферы, әлеге дә баягы булдыксыз Садри, Вазихка: «Ну-у, малай! Арабызда фатирдан синең кебек унганы булмагандыр. Атаклы Чабата җанаш бит ул» дип теш агарта башлау белән Вазих тегене сугып та еккан, ди. Садриның: «Синең белән шаярырга ярамый икән» дип акланып маташуын ишеткәч: «Хатын-кызның яманатын сатуны кайчаннан бирле шаяруга саный башладылар әле?» дип әйтеп әйткән, ди. Һәм шунда ук яман да усалланып: «Тагын бер тапкыр ишетсәм, машинаң-ниең белән яр астына мәтәлдерәчәкмен», дип кисәтеп-янап та куйган, имеш. Шул юк кына сүз дә әллә нишләтеп җибәрде Хәдичәне. Кирәк чакта якларлык, таяныр кеше тапкандай хис итте үзен. Һәм шул кешегә карата күңел түрендә әйтеп бетерә алмаслык тирән ихтирам, олы хис уянуын тойды.

Ул көнне төшке ашка иртәрәк кайтты Вазих. Станция ресторанына кереп ике шешә шампан һәм, «эчүче булса» дип, ак аракы да алып кайткан.

— Бүген, Хәдичә, саубуллашу мәҗлесе уздырыйк,— диде ул.— Шапырай абзый белән карчыгын да чакыр... Гомумән, теләгән кешеләрең булса, чакыр. Үзем кунак итәм... Безне баеттылар бүген. Кесә тулы акча. Иртәгә иртән председателегез белән парткомыгыз җыелыш кебек нәрсә җыеп сөйләшәләр дә китеп барабыз...

Бу хәбәр икесенең берсен куандырмады. Вазих, сүз югында сүз булсын дигән кебек, кабат сөйләнеп алды. Хәдичәгә бирәр истәлекле бүләк алып бирергә теләге барлыгын әйтте ул.

— Юк, Вазих...— дип каршы төште Хәдичә.— Үзең күреп торасың ич, минем бар нәрсәм дә җитенке.

— Бик матур гына кул сәгате алсам?..

Хәдичә сүлпән генә елмайды.

— Кирәкмәс, Вазих. Миндә алар бишәү-алтау. Минем бит барлык нәрсәләрем дә бүләк итеп бирелгән диярлек. Телевизор да, менә бу радиоалгыч та, син йоклаган диван-карават та, әнә, стенага эленгән келәм белән идәнгә җәйгән паласка кадәр бүләк... Аннары, аласы килгән нәрсәм булса, акча да җитәрлек миндә. Менә, берничә ел инде, без акчаны кулга алмыйбыз, бары тик ведомостька имзабызны гына куябыз. Акча саклык кассасына җыела... Ярты елга берме шунда, уткасуга түләргә кергәндә, саклык кенәгәсенә яздырып кына чыгабыз. Шул тикле җайлы инде менә, кем уйлап чыгаргандыр, рәхмәт төшкере...

Ул кичне Хәдичә эштән иртәрәк китте. Өстәлгә яңа эскәтер җәйде, тирә-якны сөртештереп алды. Өй көлеп тора. Терлекчеләр өе каршындагы бакчадан бер бәйләм көзге чәчәкләр дә ала кайткан иде. Аларны, сулы вазага утыртып, өстәл уртасына куйды. Чак кына көзге каршында ясанып-бизәнгәндәй итте. Иң яраткан күлмәген киеп алды. Һәм түземсезлек белән Вазихның кайтканын көтә башлады.

Көнгә караңгылык капканда койма буена Вазих машинасы килеп туктады. Хәзер инде аны Хәдичә мотор гөрелтесеннән дә таный иде. Вазих, гадәттәгечә, тузанлы өске киемнәрен өй алдына салып калдырып, урамда, бакча рәшәткәсенә ныгытылган юынгыч астында пошкырына-пошкырына бил тиңентен юынды. Ул арада Хәдичә сөлге, юып өтеләгән майка-күлмәкләр чыгарды. Юынып, өс-башын алыштырып, чигә тирәләрен мул итеп чал суккан чәчләрен тарый-тарый, Вазих өйгә керде. Бер табынга, бер Хәдичәгә карап алганнан соң, түргә узарга кыймаган кеше сыман, ишек катында туктап калды.

— Я-я, ходай!..— диде ул, тирән көрсенеп.— Бу түбә астында соңгы кичем микәнни инде?..

Хәдичә дәшмәде. Мондый сүзгә җавап таба алмады. Үз хәле хәл иде аның.

— Авылыгызга кадәр яраткан идем, Хәдичә. Җил уйнатып, ашкынып кайта торган идем... Монда килеп аяк басканнан бирле, моңарчы таныш булмаган, моңарчы кичерелмәгән тойгылар белән яши башлаган идем мин. Бәлки инде әллә ни күп яшисе дә калмагандыр... Шулай да... һич югында, шул калган гомеремне менә шушындыйрак тормышта уздырасы иде дип хыялланам...

Бу кичне мул табын янында утырсалар да, тамакларыннан ризык узмады. Һаман да тормыш, яшәү мәгънәсе, язмыш дигән нәрсә турында сөйләшеп сүзләре бетмәде. Икесенең дә күңелләре урыннарыннан купкан иде. Күңелләрендәге телләрендә булды, берни дә яшереп-нитеп маташмадылар.

— Шулай итеп аерылышырбыз да микәнни?..

— Нишләмәк кирәк. Миңа да бик җиңел түгел, Вазих. Шулай язгандыр инде, күрәсең... яктылык булган җирдә күләгәсе дә булыр инде аның.

— Үзәкләрем өзелсә өзелер, Хәдичә... Әмма мин баеп китәм: моңарчы татымаган хис-тойгылар, якты истәлекләр алып китәм...

— Минем дә күңелемне кузгаттың, Вазих. Кайсы агачка арка сөяргә дә белмичә яшәгән бер чакта килдең дә чыктың...

Шунда Вазих, бу хәлләрдән чыгу юлын тапкан кеше сыман, тынгысыз бер җилкенү белән:

— Нишлибез соң?..— дип сорап куйды.

— Берни эшләр хәл дә юк, Вазих. Тәкъдиребезгә шулай язгандыр...

— Сагынуыма чыдый алмасам, нишләрмен?..

— Ярар, Вазих... Башыңны хафага салма. Сагынуы да, юксынуы да була торган хәл. Ул кадәресенә генә түзәргә туры килер.

Сөйләшеп сүзләре бетмәде аларның. Аннары иңнәрен-иңгә куеп, бер-берсенә елышып утырдылар, йөрәк түрләреннән чыккан иң изге, җылы-ягымлы сүзләр әйтештеләр.

Кеше күңеле бәхеткә комсыз, ди бит. Алар да вакытлыча гына булса да бергә булу бәхетеннән тәмам исергәннәр иде. Иртәгесен Хәдичә гадәттәгечә таң атар-атмас торып, аннан-моннан гына киенде дә эшкә чыгып йөгерде. Вазихны уятмады ул. Бүтән очрашып-күреп тормаска иде аның исәбе. Әмма эшкә барганда да, эштә дә уеннан Вазих чыкмады аның. Таң атты, мең төрле мәшәкатьләре белән яңа көн туды. Төш вакытлары да әллә ни озак көттермәде. Тик Хәдичә тешен кысып булса да түзде, өенә кайтмады. Бәлки инде китеп тә баргандыр, дип уйлады ул. Ә үзе чак кына бушау белән, ферма бинасы эченнән чыгып, авыл ягына күз салгалап кәрә торды.

Күңеле алдамаган Хәдичәне. Терлек караучы хатыннарның берсе, бик чытлыкланып: «Бар, Хәдичә, квартирантың килгән. Чыгып кәрә алмасмы икән дип көтеп тора»,— дигән булып ихахайлап узып китте.

Хәдичә йөгереп чыкканда, Вазих машинасы ферма каралтыларының җил капкасы янына килеп туктаган иде инде.

— Ник кайтмадың?..— дип каршы алды ул Хәдичәне.— Никадәр вакыт өйдә көтеп утырдым үзеңне...

Хәдичә үз чиратында, һич кенә эштән бушап булмады, дип аклангандай итте.

Икесе дә кинәт сүзләре беткән кебек кабат тынып калдылар. Сүзне янә Вазих башлады.

— Иртә якта митинг сыман нәрсә булды. Искиткеч кешеләр икән сезнең җитәкчеләр.— Билгеле, бу сүзләрне әйтергә дип килмәгән иде Вазих. Тик нишләсен? Башта әзерләп куйган сүзләр, җил тузгыткандай, кинәт кенә юк булдылар. Һәм ул: бер башлагач дәвам итим инде дигәндәй, өстәп куйды: — Председателегез дә, партком секретарегыз да менә дигән чын ир-егетләр икән. Эшләгән кешенең кадерен беләләр, ичмаса! Мина да менә Почет грамотасы белән «Агыйдел» дигән электр бритвасы бүләк иттеләр...

— Тәбриклим, Вазих!

— Рәхмәт...

Яңадан сүзләре бетте.

Шул вакыт фермадан берьюлы ике-өч хатын-кыз чыкты. Чыктылар да, шау-гөр килеп гәп сатып, алар басып торган капкага таба якынлаша башладылар. Билгеле инде, кыз белән егет кебек киртә аркылы гына сөйләшеп торган Вазих белән Хәдичә турысыннан да тыныч кына, серле елмаймыйча уза алмадылар.

— Сез нәрсә, бура аша бүре куган кебек кенә итеп, икегез ике яктан торып сөйләшәсез әле?..— дигән булды берсе.

— Сөйләмә дә!..— дип элеп алды икенчесе.— Өйдә, аулакта кирәк иде серләшергә, иеме?

— Әйтмә дә генә инде.

Хатын-кызлар, чыркылдашып, ихахайлап көлешә-көлешә, авыл ягына таба китеп барды. Вазих та, менә, минем аркада сүз ишетергә туры килә үзеңә дигән сыман, саубуллаша башлады.

— Ярар, Хәдичә җаным!.. Китим инде.

— Хәерле сәфәр сиңа, Вазих.

— Әгәр дә сагынып-саргая башласам, чыдар хәлләрем калмаса, килеп тә чыгармын әле.

— Эш өстендә алай йөри алмассың инде.

— Ярар, хуш! Сау бул, Хәдичә... Бир бишне!..

— Хуш, Вазих!

Вазих гөрләп торган машинасына сикереп менеп утырып китеп тә барды. Машина басу юлында күздән югалып тузаны басылганчы, Хәдичә киртә буенда сөялеп торды. Күңеле кабат тозакка эләккән кош кебек талпынып-җилпенә иде. Иркенләп сулыш алырга комачаулап, бугазына төер менеп утырды. Күз төпләрен әчеттереп, бит алмаларын көйдереп яшьләре тәгәрәде... Эх-х, ирең булсын иде икән дә, яшәсәң иде икән шулай чүкелдәшеп, киңәшеп! Ир-ат — имән, дип әйтмәсләр иде аны борынгылар: авыр чакта аңар ышыкланасың да, күләгәсендә назланасың да икән.

...Атна-ун көн үтүгә, тулы ай кебек балкып, Вазих яңадан килде дә чыкты. Әле дә булса хәтерендә Хәдичәнең: ул көнне эштән соңгарак калып кайткан иде. Тәрәзәләрендә ут күреп сәерсенде. Хөпбениса әби кергәндер... Керпе кебек шул кыштырдап йөри торгандыр. Почта калдырган газета-журналларны, юып элгән халатларны, керләрне җыеп алып кертеп куйгалый шулай. Хөпбениса түти еш кына: Хәдичә күрше, синдә һава җиңел, дип, ишек катындагы диван-караватка ятып та торгалый, кайвакытларда хәтта куна да кала иде. Шулдыр дип уйлады Хәдичә.

Әмма өйдә аны, кочакларын җәеп, Вазих каршы алды. Аннары, авызларын җыя алмыйча көлешә-көлешә, бер-берсен бүлдереп сорашулар, хәл-әхвәл белешүләр башланды.

— Я, сөйләп җибәр... Ничек килеп чыгарга иттең?

— Менә, тоттым да килдем...— Вазих, ишек катында торган чемоданына күрсәтеп, өстәде.— Әгәр дә куып чыгармасаң, бөтенләйгә дип килдем...

Өс-башын салып атырга өлгергән Хәдичә бу сүзләрдән соң кычкырып көлә башлады.

— Җүләрләнмә!..

— Ә ник?.. Чыны шул, Хәдичә...

— Ә семьяң?

— Хатын белән сөйләшенгән-килешкән, эш беткән.

— Ә кызларың?

— Нәрсә кызларым?.. Хәзер инде аларның үз тормышлары...

Ул арада Хәдичә, хәзер ашарга куеп җибәрим дип, иң элек җил-җил килеп юынып керде. Биленә алъяпкыч бәйләп алды. Аннары ашыга-ашыга плитә тирәсендә чуала башлады. Вазих та аның итәгенә тагылып йөрде, ярдәм итешим, диде. Ә үзе, әйтәсе сүзләрен әйтергә өлгерә алмаудан курыккан кеше сыман, һаман сөйләнде. «Курыкма, Хәдичә,— диде,— мин әле хәзергә, ходайга шөкер, сау-сәламәт, куәтемдә әле,— диде,— иждивенец булып ятмам»,— диде. Билгеле инде, сүз уңаенда үзенең класслы шофер гына булмыйча, менә дигән югары разрядлы механик булуы турында да мактанып алды. «Җәен машинада эшләсәм, кышын механика мастерскоена кучәрмен яки тракторга утырырмын»,— диде.

— Әмма җансыз, хиссез яшәр хәлем юк,— дип сүзен түгәрәкләде. Хәдичә, башын артка ташлап, янә көлә башлады.

— Нинди хисләр ди ул. Картаеп беткәчме?..

— Кем карт? Минме карт?..— дип әтәчләнгән булды Вазих.— Әгәр дә бик беләсең килсә, бел: мин хәзер унсигез яшьлек егетләрдән дә яшьрәк дип саныйм үземне.

— Дөньяга фаш ителүеңнән курыкмыйсыңмы соң?

— Минем инде куркыр чаклар узган.

— Кеше гаеп итәр бит, Вазих. Телгә керербез...

— Минем кешедә эшем юк. Миңа синең сүзең кирәк. Телгә керүдән курыкма: бер генә тәмсез сүз дә ишеттермәм...

— Кемем диярмен соң мин сине? Сөяркәм диярменме?

Вазих, һич тә исе китмичә, беркатлылык белән җавап кайтарды:

— Шулай диярсең. Ә ни булган? Сөяркә шул ук «сөю» сүзеннән алынгандыр бит инде. Ә мин сине, Хәдичә, чыннан да үлеп сөям...

Хәдичә кабат рәхәтләнеп көлде.

— Ул сүзнең бит, Вазих, хатын-кызны бик нык түбәнәйтә торган бик яман икенче бер мәгънәсе дә бар.

— Ничек дип атыйм соң?

Хәдичә көлүен белде.

— Ничек дип атасаң да аптыраган инде, Вазих. Кәләш булырга өлгермәдем, ә хатының булу... кая инде ул безгә, каткан тезгә...

Вазих тәки сүзендә торды. Ике-өч көн үттеме икән, эшкә дә алынды. Хәдичә өйдә көндезге аш хәзерләп йөргәндә, тау кадәрле итеп шикәр чөгендере төягән машинасын капка төбенә китереп тә туктатты.

— «Маяк» колхозының беренче класслы шоферына якты йөз күрсәтсәгез икән...— дигән булды ул көлеп-елмаеп.— Югыйсә, аны олы юл көтә...

Алар шулай көлешеп-шаярышып табын янына утырыштылар. Нәкъ шул вакытта капка төбенә тагын бер машинаның килеп туктаганы ишетелеп калды. Вазих ялт итеп тәрәзәгә барып капланды. Һәм кинәт

кенә үзгәреп, гаять тә яман хәбәр тапшыргандай: «Розалия!.. Өлкән кыз...» дип әйтә салды.

Ул арада ян тәрәзә яныннан озынчарак буйлы бер хатын-кызның кызу-кызу атлап кереп килгәнлеге күренде.

Бу хәбәр Хәдичәнең өнен алды. Ул, жинаять өстендә тотылган кеше сыман, өстәл яныннан сикереп үк торды.

Костюмы өстеннән аксыл төстәге плащ киеп, жилкәсенә зәңгәрсу косынка салган Розалия килеп керде. Бу бусаганы бик күп таптаган кеше кебек, бик жилле, бик кыю керде ул.

— Исәнме, эти!..— диде ул кырә-керешли.

— Саумы, Розалия.

Каушавыннан тәмам коелып төшкән Хәдичә дә, үз чиратында, исәнләшеп: «Утырыгыз!» дип урын тәкъдим итте. Әллә инде аның тавышы әкрен чыкты, әллә Розалия ишетмәмешкә салынды, һәрхәлдә, кунак аның сәламен кабул итмәде, урын тәкъдим итүенә дә игътибар бирмәде.

Розалия буйга-сынга да, төскә-биткә дә матур. Әмма ниндидер жансыз, коры матурлык иде бу. Моны Хәдичә кунакның йөзенә тәүге тапкыр күтәрелеп карау белән сизенеп алды. Чак кына «тереклек суы» бөркесә, бу йөз жанланып та, нурланып та китәр сыман иде.

Сәер тынлык урнашты. Шул вакыт кунак Хәдичә ягына борылды да ничектер өстән аска карап:

— Сезнең берничә генә минутка чыгып торуыгызны теләр идем,— диде. Тавышы да, әйтү рәвеше дә бик тә яман, бик тә мәкерле иде аның.

Хәдичә авыз ачарга да өлгерә алмыйча калды, сүзгә Вазих кушылды:

— Хужа кешене өеннән куып чыгару бик үк килешеп бетмәс, Розалия. Әдәпсезлек булыр ул. Шулай сер булырлык сүзең бар икән, әйдә, үзебез чыгыйк...

— Юк-юк, мин чыгам...— диде Хәдичә. Һәм рәхим итеп сөйләшегез дигән сыман йөгерә-чаба чыгып ка китте. Әмма баскыч болдырына чыгу белән, ачып куелган тәрәзә аша аермачык булып ишетелгән сүзләр колагына кергәч, туктап калырга мәжбүр булды. Розалия аның турында сөйли иде.

— ...Акылыңа кил, эти! Нәрсә булды сиңа? Башыма сыймый... Һич нәрсә аңламыйм. Бозыклыгы белән даны чыккан хатынга килеп юлыккансың бит. Шуның өчен аның беренче баласын да суд белән тартып алганнар икән ич. Аңыңа кил!..

— Тормыш булгач, ниләр генә булмас дисең, кызым...

— Ни сөйлисең син, эти?!. Аның алак-шалак икәне күренеп тора.

Хәдичә, кай жиредер түзә алмаслык булып сызган, үтереп әрнегән кеше кебек, башын иеп, иреннәрен тешләде.

— Гадел бул, Розалия,— дип башлады Вазих тыйнак-сабыр тавыш белән.— Үзең әйтмешли, объектив бул. Син бит үзеңне ике сүзнең берендә хаклыкны яклаучы, гаделлекне саклаучы дияргә яратасың...

— Әллә дөрес түгел дип әйтмәкче буласыңмы? Күзеңне ач, эти, дөнья бу. Әнә, аның тотнаксыз, бозыклыкның аръягына барып чыккан хатын икәнлеген бөтен халык әйтеп тора...

— Белмим, белмим,— диде Вазих, кызының сүзен бүлергә теләгәндәй итеп.— Мин, белгәнеңчә, гайбәт жыярга яратмыйм. Үземә калганда, мин аның турында бөтенләй башка, капма-каршы фикердә.

Әмма тәмам зәһәрләнә башлаган Розалия этисен шунда ук бүлде:

— Тилермә, зинһар! Кыяфәтеңне күр... Син бит инде карт... Чак кына оялыр идең, бер дә булмаса...

Вазих, сүзне уен-көлкегә борып жибәрергә теләгәндәй итеп:

— Сөя, сөелә алгач, димәк, ул кадәр үк карт түгелмендер әле...— диде.

Узынган кызы аны кырт кисте.

— Син дә, авызыңны күтәреп, «сөю» дип торган буласың тагын. Оялыр идең, һич югында. Кайчан да булса берәр тапкыр ул хисне татып караганың булдымы соң синең?!. Сөйләнеп торган була бит әле...

Шушы урынга җиткәч, Вазих, дөрләп кабынган кебек, элеп алып селкеп тә салды.

— Ай-һай, Розалия кызым, дөрес тә сүз әйттең бит. Рәхмәт сиңа! Бу сүзең белән бер түгел, мең тапкыр хаклы син. Әй-йе, андый хисләрнең нәрсә икәнлеген моңарчы белмәгән идем мин. Шулай язгандыр инде дип, берниндн хиссез, төссез тормышта әниеңне дә, үземне дә алдалап яшәдем... Булган барлык ялгышым шул иде минем. Яшәдек шунда... Аннары инде сез дип, сезнең хакка яшәдек. Бар куанычыбыз, карап торган шатлыгыбыз сез идегез. Бөтен барлыгымны сезгә бирдем, сезгә багышладым мин: үстердем, укыттым, кеше иттем. Ул яктан миңа үпкәләргә хакыгыз юктыр кебек...

— Хикмәт үпкәләүдәмени?!. Әхлак-мораль нормалары дигән нәрсәләр бар бит әле.

— Ул турыда да онытканым юк.

— Оныткансың шул. Ничек кенә оныткансың әле. Белмим, кеше күзенә ничек итеп күренергә тели торгансыңдыр син?

— Кеше дип күп яшәдем инде. Азмы-күпме калган гомеремнең соңгы өлешен булса да үземчә яшәп карарга кирәк.

— Шушы хатын беләнме? Белмим, нәрсәңә кызыкты икән ул синең? Бәлки акчаңадыр? Ә?..

— Между прочим, Розалия, ул алган хезмәт хакы синең белән миңа тәтеми...

— Бәлки син аның байлыгына кызыккансыңдыр?..

Бу урынсыз әйтелгән гаделсез сүз никадәр сабыр Вазихны да чыгырыннан чыгарды.

— Җитте!..— диде ул, сөйләшүнең шул урынында нокта куярга теләгәндәй итеп.— Җитте! Хәзер син түгел, синең зәһәрлегең, синең усаллыгың, ачуың сөйли. Туктатыйк бу мәгънәсез сүз көрәштерүне.

Шау-шу чак кына тынган сыман булды, соңгы аккордлары яңгырар вакыт җитте.

— Нәрсә, әти, соңгы сүзең шулмы?

— Әйе.

— Алайса, минем соңгы сүзләремне дә ишет. Бөтен җәмәгатьчелеккә аякка бастырачакмын, әмма сине бу баткаклыкта калдырмам. Юк, калдырмам! Газеталар, радиолар шаулар... Әмма ләкин...

— Алай итәргә хакың юк,— дип, Вазих каршы төшәргә теләп карады. Тик зәһәр хатын этисен ярты сүздә бүлде:

— Хакым да, хокукларым да үз кулымда минем. Ну-у, әти! Кара аны!.. Үкенерсең, әмма соң булыр.

— Ни күрсәм дә күрермен,— дип куйды Вазих, тирән көрсенгән кебек итеп.— Әмма мине бүтән борчып йөрмәгез... Шулай ук жалу белән йөрмәвегезне сорар идем. Ул эш кешесе...

— Беребез дә җил куып йөрми. Бүген үк, менә хәзер үк колхоз идарәсенә, парткомга, авыл советына керәм... Вакытым әрәм булса булыр, әмма сине бу баткаклыкта калдырмам. Ярар, мин киттем. Әйтмәдем түгел, әйттем. Соңыннан үпкәләштән булмасын. Хуш!..

— Сау бул! Хәерле юл, сиңа...

Өйдән атылып чыккан Розалия Хәдичә яныннан да йөгереп кенә үтте. Машинага да, каядыр соңга калудан курыккандай, очып кына кереп утырып китеп тә барды.

Тавыш-тынсыз гына кереп баскан Хәдичәнең боек, таный алмаслык дәрәҗәгә җитеп агарынган йөзен күргән Вазих пошаманга төште.

— Нәрсә?.. Нәрсә булды?..— дип сораштыра башлады.

Әмма Хәдичә кинәт кенә ачылып китә алмады. Ул, теше сызлаган кеше сыман, учы белән яңагын сыйпаштырып алды да ялынып-ялваргандай сөйләнә башлады.

— Кирәкми, Вазих... Кирәкми! Ялгышлык белән ясалган бу адымыбызны төзәтик. Хәзергә әле соң түгел, Вазих. Нишләмәк кирәк, хакыйкатьне, шулай, һәркем үз ялгышы, үз хатасы аша таба торгандыр инде... Кирәкми, Вазих, түгелгән тулы булмас дигәндәй, кеше тормышына күләгә төшереп табылган бәхет барыбер тулы булмаячак. Ташлама гаиләңне... Хатыныңны ялгыз итмә... Ир бирмәк — җан бирмәк, дип тикмәгә генә әйтмәгәннәрдер борынгылар. Кызың да хаклы: кая инде ул безгә бәхет турында хыяллану! Розалия әйтмешли, син дә яшь түгелсең инде...

Бу юлы Вазих та җавапсыз калмады.

— Балаларыбыз алдында без утыз яшьтә дә картбыз.

— Аннары минем үткән тормыш юлым да... шактый ук күләгәле. Язмыш тарафыннан бик нык кагылдым-сугылдым...

— Мине, Хәдичә, синең үткәнең кызыксындырмый. Безгә хәзер иртәге көн, киләчәк турында уйларга кирәк. Үз ягымнан бары тик шуны әйтә алам: иртәге көнеңне тагын да яктырак, бәхетлерәк итү өчен кулымнан килгәннәрнең барысын да эшләрмен...

Шул ук көнне Хәдичәне идарәгә чакырдылар. Бу хәбәр, искәрмәгән-көтмәгән яктан бәреп кергән өермә-давыл кебек, Розалиянең килү вакыйгасына караганда да ныграк тәэсир итте. Икесе дә бермәлгә телсез калды. Менә шунда Вазих: «Синең берниндә дә гаебең юк, урынсызга сиңа тел-теш тидерүләрен теләмим»,— дип, идарәгә үзе китте.

Гайния апаның: «Җилбәзәк егет кебек гашыйк булган...» дигән сүзләрендә өлешчә хаклык бар иде. Вазих идарәдә Маннур белән парторг Нәҗипкә үзенең хис-тойгыларын, йөрәген ачып салган дип сөйләделәр. Бу турыда Хәдичәгә түкми-чәчми җиткергәннәр иде. Әгәр дә мин гомеремнең соңгы чорында күңелемә ямь бирерлек җаныма якын кеше очратканмын икән, гаҗәпләнмәгез, егетләр, дип әйтеп әйткән ди Вазих. Чөнки мин моңарчы сөю-сөелү кебек нәрсәләрне белгән кеше түгел. Сезнеке кебек яшьлек, егетлек чоры безгә тәтемәде, читләтеп үтте. Малайлыктан солдат иттеләр безне. Ил язмышын тапшырдылар. Сугыштан соңгы авыр еллар турында әйтеп торасы да юк. Кайда анда ярты гарип көе хис-тойгылар белән санашып торулар. Хәтта киемсалымны да теләгәнне кимәдек без, тигәнне кидек. Мин бары тик Хәдичәне күреп белгәннән соң гына чын хисләрнең нәрсә икәнен татыдым. Менә шул, егетләр, мин сезгә авырлык китермәм, бүгеннән калмый китәрмен. Тик элеккеге гаиләмә түгел. Мин аннан кире кайтыр өчен китмәдем. Монда, сезнең авылга сыймаганмын икән инде, башка җиргә китәргә туры килер. Әмма минем бер шартым бар: теге зәһәр җылан сүзенә карап Хәдичәне чакыртып-нитеп борчымагыз. Ул ансыз да башыннан күпне кичергән кеше, дип өзеп әйткән, ди.

Аннары: ярар, егетләр, гаеп итмәгез. Исән-сау яшәгез! дип, башы авырта башлавы турында әйткән дә идарәдән чыгып киткән. Вазих чыгып киткәч, председатель белән парторг бер-берсенә күтәрелеп карарга да кыймаганнар, имеш.

Өйгә кайтып кергәндә Вазихның танырлыгы калмаган иде. Хәдичәнең йөзенә күтәрелеп-текәлеп елмаерга тырышып карады, әмма булдыра алмады. Аны ниндидер сызлану, әрнү борчыганын аңлау кыен түгел иде. Шул чак ул, куш кулы белән йөзен каплап беркавым тик

кенә утырды да, үзалдына гына сөйләнгән кебек итеп, бүген үк авылдан чыгып китәргә сүз биргәнлеге турында әйтте.

Ул төнне йокларга ятмадылар алар. Вазих караңгылы-яктыда Хәдичә белән саубуллаша башлады. Хәдичә аны басу капкасына кадәр озата барды.

— Эх-х, Хәдичә!.. Үкенечкә генә булган икән. Менә аерылышабыз да... Тик озакка түгел. Әгәр дә ризалыгың булса, барып урнашкач, барыбер чакыртам үзеңне.— Аннары бер мизгел генә уйланып торганнан соң кабат тезеп китте.— Риза булмасаң да үкенмим... Ичмаса, бәхетнең нәрсә икәнен белеп китәм. Шулай да җинел, шулай да рәхәт итеп көенеп-сөенеп яшәргә мөмкин икән дисәләр, элегрәк үтерсәләр дә ышанмас идем. Рәхмәт, Хәдичә! Бер түгел, мең рәхмәт сиңа. Әллә нишләттең син мине. Син, Хәдичә, үзеңдә... бу фани дөньяны җылытырлык җылылык барлыгын, бөтен галәмне сыйдырырлык киң күңелең барлыгын үзең бәлки әле белми дә торгансыңдыр. Хуш, Хәдичә!.. Хәзергә сау бул, җаным...

Вазих китте. Кызының кабат әтисен эзләп килүенә дә карамастан, Хәдичәне анда-монда чакыртучы булмый. Ул вакытта Вазих Лубян лесхозында фронтташ дусты янына барып эшкә урнашкан иде инде.

Вазих белән аерылышу Хәдичә күңеленә янә бер әйтеп бетергесез үкенечле һәм сагышлы яңа эз салды. Әмма әҗәл ирештерерлек киерешләр дә, вакыт үтү белән, көч-егәрен, гайрәтен югалта икән. Шуннан соң хис-тойгылар да, нәкъ кешеләрнең үзләре кебек үк, картаядыр, ахры, күрәсең, дигән фикергә килде Хәдичә.

*
* *

Гөлнур дөрес әйткән булган икән: сыерларны механик ысул белән саву бөтенләй көтелмәгән яклардан мең төрле мәшәкатьне тудырып кына торды. Җае килсә, җәбе килми, җәбе килсә, сабы килми дигәндәй, эшләр бер дә алга китәр төсле түгел иде. Бәласе дә аяк астында гына яткан икән.

Бу четерекле эш белән Гөлнур җитәкчелек итте. Әмма механик савуга керешү эше турыдан-туры Хәдичәгә йөкләтелде. Башта ук сөйләшенгәнчә, ул иң элек илле баш сыерны аерып алды. Сыерлар таныш, күпчелеге үзе тәрбияләгән таналар. Мал-туар комиссия тарафыннан бик җентекләп тикшерелде, имчәкләренең төзелешләренә карап группаларга бүленде. Һәм алар өчәүләп: Зәйнәп, Фәния һәм Хәдичә үзе, нәкъ башка савымчылар кебек үк, бу сыерларны кул белән савуны дәвам иттерделәр. Аерма тик шунда: һәр сыер янында аппарат тора һәм баш очларында вакуум моторлары тыкылдыйлар...

Тикшерә башлагач, саву агрегатларының тиешенчә монтажланмавы, ничек туры килде шулай көйләнүләре билгеле булды. Гөлнур гауга куптарды, башкарылган эшне бракка чыгарып, актлар төзеде. Шуннан соң башланды маҗаралар. Иң элек «Сельхозтехника»ның район берләшмәсеннән килеп җиттеләр. Килеп чыккан бәхәсле мәсьәләләрне хәл итү өчен «Татколхозстрой» берләшмәсеннән дә кешеләр чакыртып алырга туры килде. Тәки сүзен сүз итте Гөлнур: саву агрегатларын әр-яңадан монтажлау белән генә дә чикләнмәде, аппаратларның катлаулы системасына үзгәрешләр дә керттерде. Ике тактлыдан өч тактлыга көйләтте. Бары тик шуннан соң гына тынычлангандай булды.

Ләкин аңа, «инде булды» дип, кул кушырып утырырга иртәрәк иде әле. Ул шунда ук бу аппаратлар белән эш итәрлек махсус белеме булган кадрлар хәзерләү эшенә керешәе. МТФ каршында саву мастерлары хәзерләү курсы ачылды. Тик бер генә эш тә җиңел бармады.

Савымчыларның күпчелеге бу яңа ысулга ышанып бетмәделәр, һаман да шул ике куллап искегә ябышып яту ягын карадылар.

Хәдичә группасының эше дә тиз генә җайга килмәде. Сыерлар, эшләп торган аппаратлар белән үзләре генә калырга курыккандай, савымчыларны яннарыннан «җибәрмичә» иза чиктерделәр. Чак кына читкә борылдыңмы, шунда ук тынычсызлана, мазасызлана башлыйлар иде.

Әмма атна-ун көннән Хәдичә җитәкчелек иткән өч кешелек группа илле баш сыерны башта ике сәгать, соңрак бер, ә аннары инде нибары ярты сәгать эчендә савып бетерә торган булды.

Менә шундый көннәрнең берендә Хәдичә, башка савымчыларны үртәгән кебек итеп:

— Даешь, тагын илле баш сыер!..— дип, бөтен ферманы яңгыратып аваз салды.

*
* *

Бүген дә көн гадәттәгечә үтеп китте. Аерма тик шунда: бүрек кадәр генә булып бер болыт чыкты да, шифалы ләйсән яңгыр явып узды. Килүе дә, узуы да мәзәк кенә булды аның. Беренче тамчылары кояш нурында ялтырап, озын көмеш кадакларны хәтерләтеп, җиргә кереп югалгандай, күз алдыннан очып үтеп юк була бардылар. Алар ничектер шулай, биюче көйгә керә алмагандай, ничек туры килде шулай төштеләр. Әмма мизгел эчендә бар да җайга салынды: яңгыр тоташ шыбырдап коя башлады.

Ул да булмады, җәйләү-каралты араларында, куе томанны хәтерләтеп, пар күтәрелә башлады. Кичке савымга кардага якынлашкан сыерлар, су ерып килгәндәй, шул куе пар эченнән атлыйлар. Үзләре җиленнәре тулудан тынгысызланып мөгриләр, килеп җитү белән, берберсен кысрыклап, саву аппараты янында «чират» көтәләр.

Кулыннан эш төшмәс Хәдичә дә шунда. Көннәре мәшәкать белән тулып ташыган аның. Ничек арымый да, учларында ут биеткәндәй, тузып-җилләп эшләп ничек талмый ул! Менә шулай эш белән мавыгып, онытылып киткәндә, Хәдичә үзен дөньяның бөтен ваклыкларыннан югарырак, тормыш ыбыр-чыбырларыннан өстенрәк итеп хис итә башлый.

Кичке савым бара. Савымчылар ут өерәләр, куллары-кулга йокмый. Эш бик күп, шулай иткәндә дә бик таманга гына килә торган чак. Сыерлар, группаларга бүленеп, саву агрегатына кертелә торалар, икенче яктан ялт итеп килеп тә чыгалар.

Хәдичә бүген тагын бер нәрсәгә игътибар итте: сыерлар көтүе күзгә күренеп яхшыра бара. Нәселле терлек — зур байлык, дип белмичә әйтмиләр шул.

Нинди хикмәттер, бүген Хәдичә мал-туарларга гына түгел, кешеләргә, үзенең хезмәттәш дусларына карап та соклана, тәэсирләнә. Шул ук Фәниядән баядан бирле инде күзләрен ала алмый. Бигрәк тә тиз үсте, үзгәрде, карап туя алмаслык сылу кыз булды. Бу үзгәреш Хәдичә апасы янында эшли башлагач үзен аеруча нык сиздерде. Шифалы җирлеккә төшкән гөл орлыгыдай, шытым бирү белән генә дә чикләнмәде, шау чәчәккә күмелгән гөлгә охшап калды. Моңарчы аны бар дип тә белмәгән кешеләр: «Күр әле син моны! Тәмам җитлеккән, пешкән җиләк кебек кызга әверелгән ләбаса!..» — дип, үзләренең соклануларын яшерә алмый башладылар. Фәниянең төсе-бите, торыш-кыяфәте, үзен-үзе тотышы, сөйләшү рәвешләре, йөрүләренә кадәр үзгәрде. Адымнары нык, һәрбер хәрәкәтендә яшьлек дәрте, куәт һәм җитезлек сизелеп тора.

Өлкәнрәк кешеләр янында Фәния һәр вакытта да тыйнак-сабыр, сүзгә дә, аның үзенә туп-туры кагылмаса, кушылмый, акыл сатмый. Аның караве, үз тиңнәре, үз ишләре белән үзен иркен тота. Ни әйтсәң дә, исеме макталып телдән төшми башлаган, машина белән саву остасы бит ул хәзер. Яшьләр арасында уйный-көлә, әмма чытлыкланмый. Күз карашларында кызыксыну катыш чаялык та чагылып китькәли аның. Күзләре зур, дымланып торган эре карлыган төсле. Бу күз карашларында боеклык юк хәзер, һәр вакытта да нурланып, чәчрәп торган сүнмәс очкын булыр.

Ә инде эшкә килгәч, башына ак яулыгын бәйләп, өстенә зәңгәр халатын киеп алып, билләрен дә буып җибәрсә, анда инде бетте: килеш-килбәте, коеп куйгандай зифа буй-сыннары, җитлегеп килә торган күкрәкләре тагын да ачыграк булып күренә башлыйлар. Шул чак кулларын халат кесәләренә батырып, башын чак кына кыңгыр салып елмаеп та җибәрсә, аңардан күзләреңне алырмын димә, үзеңне әсиргә сана.

Хәдичә күңеленнән генә булса да бу уңган кызны алтын егет Фирдәвес белән якыннан таныштырып кына калмыйча, хәтта кавыштырып та куйгандай иткән иде инде. Әмма көн дә бергә мәйханә килүләренә карамастан, бер дә ул-бу булырга охшамаган. Нинди укымышлы, нинди башлы егет булса да, Фирдәвесе бераз мәмирәк шул. Үзе иртәнге чык кебек саф, кыз балалар сыман инсафлы, шуның өстенә әле сабыйлардай беркатлы. Бәлки шуңа күрәдер, аны, яше утызга җитүенә карамастан, егет дип тә, малай-шалай дип тә йөртәләр. Үзе үпкәләми дә, ачуланмый да тагын.

Савым төгәлләнде. Ат менгән көтүчеләр сыерларны төнгелеккә алып киттеләр. Сөтләр дә озатылды. Бер төркем кыз-киленчәкләр, чал җиңгәчәйләр, су кереп чыгабыз дип чыр-чу килеп, Кенәле буена йөгерештеләр. «Көтмибез, хәзер төяләбез дә кайтып китәбез», дип, алар артыннан кычкырып калучылар да булды.

Саву агрегатларын югалаганчы, чиләк-бетоннарны кабат чистартып, дезинфекцияләр ясаганчы, су керүчеләр дә менеп җитте. Ниһаять, шаярып-көлешеп, тирә-якны шаулатып машинага утырыша башладылар.

Шул вакыт Хәдичә янына, тыны-көне бетеп, Фәния йөгереп килеп җитте.

— Хәдичә апа!..— Кыз кинәт тотлыгып калып, йөзен аска иде.

— Әйт, нәрсә?

— Бүген мин дежур идем...

— Соң?

Кызның уңайсызлануы йөзенә чыккан. Ул күз карашларын яңадан туфлилары башына юнәлтте һәм җирдә яткан чуер ташын аяк очы белән тәгәрәткәли башлады.

— Соң, әйт инде!

— Хәдичә апа... Бүгенгә генә минем урынга берәрсен калдыра алмассынмы икән?

— Ә ник үзең сөйләшмәдең?

— Һәй-й, мине тыңлыймыни соң алар?!

Хәдичә тагын сорау бирер куйды:

— Нәрсә? Берәр кичергесез эшең бар идемени?..

— Бүген театр...— диде кыз. Бу юлы аның битләре ут капкандай кызарды.

— Һәм син кайтырмын дип вәгъдә биргән идең? Иеме?..

Фәния кабат гөлт кабынды.

— Ие, Хәдичә апа!..

Көлмичә булдыра алмады Хәдичә. Аннары, сөйгәндәй итеп, кызның җилкәсеннән каккалап алды да әйтте:

— Бар инде, бар!.. Үзем калам...

Кызның куанычы чәчрәп тышка бәреп чыкты.

— Рәхмәт, Хәдичә апа!..— Юк, әйтер сүзе бетмәгән икән әле аның.— Хәдичә апа... бер кочаклыйм әле үзеңне...— Хисләре тулып ташырга торган кыз кинәт кенә Хәдичәне кочагында кысып, чалт итеп бер үбеп алды да йөгереп китеп тә барды.

Баядан бирле: «Буласызмы инде?» дигәндәй, машинасын кычкыртып сигналлар биреп торган шофер егет, Фәния машинага очып менү белән, кузгалып та китте.

«Тәки гашыйк булган бу кызый, бер дә башка түгел...» дип уйлап куйды Хәдичә.

Тирә-як искәрмәстән генә тынып та, бушап та калган сыман булды. Бары тик сыерлар китеп барган яктан, печән күбәләрен хәтерләтеп оя-оя булып утырган таллыклар артыннан, көтүчеләрнең чыбыркы шартлатулары яки кычкырынгалап алулары гына ишетелеп куйгалый. Бераздан бу авазлар да әкренләп сүнде, гаҗәеп бер тынлык урнашты.

Әмма Хәдичәдә ялгызлыкны тою, моңаюның әсәре дә юк иде. Чыннан да, шушындый тымызык кичтә, ярларын куак-әрәмәлекләр каплаган гүзәл Кенәле буенда шәфәкъне таңга ялгап төн уздыруга ни җитә!

Иң элек ул үрчем алу бүлеге тирәсен әйләнеп килергә булды. Анда бүген бозауларга тиешле өч баш сыер көтүдән аерып алып калынды. Өсләре бөркәүле махсус абзарларда алар. Хәдичә якынлаша башлау белән мөгрәп, аның ягына борылдылар. Алларына яшел азык салынган, сулары да бар. Әмма сыерлар аларга борылып та карамый, үз хәлләре хәл.

Хәдичә аларны тынгысызламас өчен тизрәк ул тирәдән киту ягын карады. Елга буена килеп чыкты, су өстенә карап тора башлады. Кенәлекәй үзенең ишелә-ишелә аккан көмештәй саф суын бервзлексез каядыр коя да коя. Агымсуларга карап торулары үзе бер хозурлык. Бөтен барлыгыңны яулап алган уйлар да, нәкъ елга кебек, тыныч кына, бер көйгә агыла да агыла. Вазих турында аның: «Көт, Хәдичә җаным! Шушы көннәрдә расчет алам. Кавышу минутларын мин дә түземсезлек белән көтәм»,— дип язган соңгы хаты турында уйлап алды. Кинәт әйтеп бетергесез рәхәт булып китте Хәдичәгә. Аның да бит бу фани дөньяда терәк булырлык, таянырлык кешесе бар. Нишләп куанмасын ул! Мондый уйлар алҗытмый, бары тик тәнгә рәхәт, сихәт өстиләр.

Нәкъ шул вакытта Хәдичә күңеле түрендә моң сыман нәрсә чынлый башлавын тойгандай булды. Һәм ул шул көйгә күңеле белән генә кушылып, авыз эченнән генә җырлый башлавын үзе дә сизмичә калды.

Җилләрдә генә очыра көн, ай, тузанын, ай, тузанын;
Белми калдым яшь гомеремнең, ай, узганын, ай, узганын.
Өстә кием тузмый диләр, туза икән, туза икән;
Яшь гомерне узмый диләр, уза икән, уза икән...

Кояш баеган якта да янгын-шәфәкъ сүрелде, офык чистарып, яктырып калды. Хәдичә, яр буена ук килеп, елганың аскы ягына күз салды. Һай-й, матур да шушы Кенәле буйлары! Менә кайда ул дөнья җәннәте. Елганың бөтен буе бөдрә таллыклар, оя-оя булып утырган камышлар белән бизәлгән. Ә ачыграк урыннарда елга өсте, күк йөзенең бөтен яктылыгын үзендә чагылдырып, көмеш төскә кергән. Бары тик сайрак урыннарда, агым көчле булган шарламакларда гына бу яктылык ватыла, су өсте шадралана, чәлпәрәмә килгән көзге кисәкләренә охшап, көмеш тәңкәләр хасил булалар.

Бу кичнең тынычлыгына гына игътибар ит син: зирек-талларның бер генә яфрагы, камышларның бер генә кыягы селкенсенче! Тирә-яктан, җәй урталарында юкә агачы чәчәк аткандагы сыман, чак кына бал исен хәтерләтеп, үзенә бер төрле куе хуш ис аңкый. Дулкын-дулкын

килеп бәрелгән бу ис, талгын гына аккан салкынча су, мең төрле чәчкә, камыш һәм башка төрле су үсемлекләре исе белән аралашып, тагын да көчәя, байый, башларны әйләндерә башлый.

Җәйге кичнең галәмәтләре күп аның. Бермәлне, куе әрәмәлекләр арасында яшеренеп яткан күл буенда, каяндыр адашып килеп чыккан сыман, ак болыт пәйда була. Әллә күктән төшә ул, әллә тоташтан ак төнбоеклар белән бизәлгән күлләрдән чыгып үлән өстенә ял итәргә ята, күрмичә дә каласың. Шул чак болыт күзгә күренеп диярлек зурая, эрегәнгә охшап тарала башлый. Күп тә үтми, күл буе әрәмәлекләрен томалап, куе томанга әверелә. Бераздан инде томан бөтен үзән-болынлыкларны иңләп җәелә башлый. Хәтта су өстен дә ефәктәй юка ак томан баса.

Бу томан һәрнәрсәне яссырак итеп, гадәттәгедән зуррак итеп күрсәтә. Анда-санда калкып күренеп торган зирек агачлары да галәмәт зурлар — карт топольләргә охшап калганнар. Болынлык киңлегендә чәчелеп утырган куаклыклар да олы кибәннәр яки богылларны хәтерләтә. Бермәлгә тирә-як тәмам тынып калгандай була, гүя мул булып төшкән куе томан бар нәрсәне йоткан, үз иркенә буйсындырган.

Ләкин мондый хәл озакка бармый. Күп тә үтмәстән, тирә-як җанлана, су буйларында, болын киңлекләрендә үзенә бер төрле тормыш кайный башлый. Иң элек, кайдадыр якында гына, кыргый үрдәкнең сак кына тавыш биргәне ишетелә. Бу вакытта алар басу киңлекләренә, тыныч күлләргә, сай сулыкларга төнгелеккә таралалар. Ул да булмый, баш очында гына бу өлгер-җитез кошларның канат каккан тавышлары аермачык булып ишетелеп кала. Нәкъ шул вакытта су өсте чупырдап куя: я эрерәк балык чумгандыр, яисә берәр төнге кош төшеп кунаклаган булырга тиеш.

Ә инде беренче йолдызлар кабынгач, тирә-якта хәйран тамаша башлана. Якында гына, куе чытырманлыкта шау чәчәктә утырган гөләп куагы төбендә оялаган сандугач сайрап җибәрә. Шуны гына көтеп торган кебек, аңар бүтәннәр дә кушыла. Алардан бүтән кошлар да калышырга теләмиләр: һәркайсының үзенә генә хас моңы, аһәңе, көе бар. Болынлык киңлекләреннән такәрлекләр дә тавыш биреп куйгалый, бытбылдыклар да аваз сала. Шул авазларның барысын да басып китәргә теләгәндәй, елга аръягындагы калын урман ягыннан күкеләр кычкырган тавышлар ишетелә. Елның бу вакытында: «Күпме яшисем бар?» дип сорарга тартынма, бик юмартлар алар хәзер, санап кына өлгер...

Өстенә җиңел халат кына кигән Хәдичәгә салкынча булып китте. Ул тәрәзәләреннән мул ут балкып торган терлекчеләр йортына таба юнәлде. Берьюлы бөркәү астындагы сыерлар ягына да колак салып узды. Анда хәзергә тынлык, күшәүдән дә туктаган малларның бары тик авыр мышнаганнары гына аермачык булып ишетелә. Яннарына барып тынгысызлап йөрмәде, өйгә үтте.

Кызыл почмакка кергәч, түрге якка узып, эш югында эш булсын дигән сыман, радиоалгычны куйды. Аннан шау-гөр килеп кул чапкан тавышлар яңгырады. Ул да булмады, бер ир-атның яман да юан-калын тавыш белән җырлый башлаганы ишетелде. Юк, бу төн андый авазларны ишетү өчен түгел иде. Хәдичә җәһәт кенә килеп радиоалгычны сүндерде.

Әллә бераз черем итеп алыймммы икән? дип, Хәдичә, йомшак урыннарның берсе өстенә барып бераз утырып торды да, янадан олы якка чыкты. Юк, йокы качкан, күңелне нәрсәдер бимазалый, назлый иде.

Хәдичә кызыл почмакта да әллә ни озак утыра алмады, тәрәзәгә күз төшереп алганнан соң, кабат урамга чыкты.

Караңгылы-яктылы бер вакыт. Ярата, бик ярата Хәдичә «бер сапламлы» җәйге төннең менә шушындый чагын. Иң элек офык ягы

сыегая, әкренләп зәңгәр төс иңә башлый. Куе күләгәгә чумып, киртләчләнеп торган ярлар арасында тоташ кара чокыр сыман гына булып күренгән елга да күзгә күренеп диярлек киңәя бара. Әле бая гына кул белән сузылсаң буең җитәрлек булып тоелган теге як яр да, йөзеп киткән сыман, һаман ерагая бара. Бераздан бөтенләй сәер бер күренеш хасил була: теге як ярлар тирбәлеп-дулкынланып хәрәкәтләнгән аксыл томан эчендә кала. Аннары алар офыкка барып тоташкан сыман булып күренә башлый, гүя, анда иге-чиге күренмәгән диңгез киңлеге, тоташ су манзарасы ачылгандай була. Тот та, көймәгә утырып, шул очсыз-кырые күренмәгән диңгез киңлегенә чык та кит...

Ә инде таң беленгәндә әлеге куе томан, су өстенә генә сыеша алмыйча, язгы ташкын кебек булып, болынлык киңлекләренә дә ташып чыга. Шунда ул, таң җилләре белән хәрәкәткә китерелеп, сыегая, тарала башлый. Кояш чыгар алдыннан тирә-як кинәт ачылып, киңәеп киткән сыман була. Беренче алтын нурлар күренә башлагач исә, томан урынына, искитмәле матур, кояшлы аяз көн тууның беренче билгесе булып, сыек рәшә генә тирбәлеп кала.

Нәкъ шул вакытта Ќенәле елгасының аръягындагы нарат урманнары белән капланган тау-калкулыклар артыннан, бала кулыннан ычкынган утәдән-утә күренмәле кызыл шар кебек булып, кояш чыга башлый. Ул күзгә күренеп диярлек һаман өскә күтәрелә, күтәрелгән саен нурлары да көчәя. Шулай итеп, бөтен галәмне нурга коендырып, яңа көн туа... Һәрбер агач, куак, һәрбер үлән, чәчәк, иркен сулыш алгандай, селкенгәләп куя сыман. Куе яшел төстәге яссырак яфраклар мул булып энҗе-зөбәрҗәттәй эре чык бөртекләренә манчылгангамы, чак кына чаларып, уги ана яфрагының аскы ягына охшап, агарыбрак күренәләр. Чык бөртекләре берьюлы мең төрле төсләргә кереп җемелдиләр, нур чәчәләр...

Хәдичә бит-кулларын юарга су буена килде. Эрерәк ташлар өстенә басып чүгәләде. Кытыршы, бирчәйгән кулларын суга тыкты. Җилдә кара-кучкылланган, ярылган кулларына, буын тирәләре чак кына калынаеп киткән бармакларына карап торды.

Якында гына олы бер балык чупырдавына Хәдичә сискәнеп китте. Шул вакыт аңар сәер бер күренешнең шаһите булырга туры килде. Тельняжка кигән лоцманга охшаган бөкре сыртлы зур гына бер алабуга балыгы бармак кадәрле маймычны иң әлек сайлыкка, аннан инде яр буена ук куып чыгарды. Һәм саңакларын хәрәкәтләндереп, кымшанмыйча гына, корбанының суга кире төшкәнен сагалап тора башлады.

Хәдичә чыпчык йомыркасы чаклы гына чуер ташы алып, аны һаман да әле ут кебек янып торган кызгылт-сары канатларын селкеткәләп торган алабугага бәрде. Тегесе — ялт тирәнлеккә. Юлбарысныкына охшашлы сырлы яны белән кара-кучкыл яшел сырты гына чагылып калды. Аннары инде корыда ялт-йолт килеп чәбәләнеп яткан нәни чабакны алып суга җибәрде. Әмма маймыч суга төшкәч тә әле, яшен ташы кебек булып, яр буена атылып, сайлыктагы ике таш арасына килеп керде. Бары тик бераз аңына килгәч кенә кинәт, борылып, тирәнлеккә чумып юк булды.

Хәдичә өчен иртәнге як шактый ук мәшәкатьле булды. Өч сыерның икесе җиңел котылдылар. Әмма өченчесе белән кара тиргә батканчы газапланырга туры килде. Ничек итсә итте, бозауны саклап алып калды, сыерны да котылдырды. Менә шунда Хәдичә Фәния урынына үзе калуына сөенеп бетә алмады: кыз бала, һичшиксез, каушап, югалып калыр иде, дип уйлады ул.

Кояш шактый күтәрелде. Җәйләү тирәләре бермәлгә тыныч калгандай булды. Тирә-якта бары тик чикерткәләр туе. Ул да колак иярләшкәнче генә шулай, бераздан чикерткә тавышлары да ишетелмәс булды,

Иртәнге дүртләр тирәсендә машиналарга төялеп савымчылар килеп төште. Карда эче ыгы-зыгы, шау-шу белән тулды, янә мәшәкать белән тулы яңа көн башланды.

Соңгы вакытта сөтнең сыйфаты сизелеп күтәрелде. Билгеле булганча, ул үзенең куелыгына, әчелегенә, чисталыгына карап группаларга бүленеп кабул ителә. ГОСТ таләпләренә җавап бирерлек сөт саткан өчен генә колхоз кассасына шактый өстәмә табыш керде.

Әмма моның өчен күп тырышырга, зур көч куярга туры килде. Җәйләүдә үк кучмә лаборатория булдырылды. Анда һәр савым сөтнең майлылыгы тикшерелә башлады. Сөтнең бер өлеше махсус пунктта электр ярдәмендә, күбрәге исә карданың эчендә үк, йөз яшьлек карт тал төбеннән шаулап-ургып чыккан чишмә суында суытыла. Моның өчен чишмә авызын киңәйтеп, берьюлы утызлап бидон сыярлык махсус урын ясадылар. Як-ягы ишелмәсен өчен эре таш өеп менеп, өстенә басмаларга охшатып такта җәйделәр. Хәзер бидоннар күләгәдә боз кебек салкын су эчендә утыра, аларның бары тик тигез рәт булып көмеш капкачлары гына күренеп тора.

Җәйләү ягыннан, ут капкандай: «Хәдичә!.. Хәдичә апа!..» дигән тавышлар ишетелгәндә, ул суга батырылган шул бидоннарны барлап-санап йөри иде.

Әсәрләнеп, берсе-икенчесен уздырырга теләгәндәй кычкырынуларына караганда, тикмәгә генә түгеллеген, берәр хәл булганлыгын төшенү әллә ни авыр түгел иде. Әнә терлекчеләр йорты янына, ат җигеп, Түбән оч Мәйсәрәсе дә килеп туктаган. Ул нинди дә булса берәр хәбәр алып килгән булырга тиеш. «Вазих кайткан...» дигән уй чагылып китте Хәдичәнең башында.

Бер төркем булып җыелырга өлгергән хатын-кызлар Хәдичәнең якынаюын көтеп алдылар. Аларның кинәт тынып, хәтта чак кына сагайган сыман сәерсенеп карап торуларын күргәч, Хәдичәнең күңелендә шик-шом кебек нәрсә дә кузгалып куйды. Ләкин дилбегәсен тотып торган Мәйсәрә елмая, йөзе дә тулы ай кебек балкый иде.

Хәдичәнең тамагы кибеп киткәндәй булды. Һәм ул карлыккан тавыш белән:

— Нәрсә?.. Нәрсә бар?..— дип сорап куйды.

— Ну-у, Хәдичә малай! Зур шатлык китердем бит әле үзеңә. Сөенчегә нәрсә бирерсең икән?.. Бар, аттыр моннан ять кенә!.. Өеңә элдер... Кызың кайткан...

Өнсез калды Хәдичә. Кинәт тыны кысылгандай булды. Ул егылып китүдән курыкты, ахрысы, алпан-тилпән атлап, арба үрәчәсенә килеп ябышты. Бер тын югалып, аңына килә алмагандай торганнан соң ярым пышылдап:

— Булмас ла!..— диде.

Каядыр ашыккан Мәйсәрә, аягын камытка ирләр кебек терәп чөелдереген тарттырып бәйләде дә, тәртәләрне шыгырдатып аркалыкны күтәргәннән соң, янә сүзгә керешге:

— Ашык инде, ашык!.. Нәрсә терәлеп каттың? Эшнең бетәсе юк аның...— диде һәм нәкъ баягы кебек итеп елмаеп, кабат тезә башлады.— Ну-у, малай! Менә бәхет... Үзең кадәрле кызың бар икән ләбаса!..

Шулай диде дә арба үрәчәсенә егетләрчә җиңел генә сикереп менеп утырып: «Ну-у, малкай!..» дип, атын юыртып ерак болынга таба китеп тә барды.

Ул арада хатын-кызлар, берсе икенчесен бүлеп, шау-гөр килеп, базар ясап алдылар.

— Бар инде, Хәдичә апа... Иөгер тизрәк...

— Чыннан да, эш качмас ул.
— Җәяү йөгермәс бит инде?..
— Бәй! Машиналар кайда соң?
— Кара инде, кай арада юк булдылар соң әле алар?
— Су коенырга киткәннәрдер...
Берәве бик белдекле кыяфәт белән тезә башлады:
— Юк, коенырга түгел... озын күл эрәмәлеге артында бер язучы балык тотып ята. Бала-чагалары белән... Егетләр шуның янына йөриләр.
— Тозлы су сипмәгәннәрдер бит ул язучы янында...
— Азык-төлек, җимнәргә дип борчак-фәлән алып төшәләр аңар...
— Чакырып киләсе иде бит үзләрен...
Әле яңарак кына алынган хәбәрнең чын мәгънәсенә бары тик хәзер генә төшенгән кеше сыман, Хәдичә, кинәт хатын-кызлар ягына борылып:
— Ярар... Мин киттем, алайса...— диде дә, бөтен гәүдәсендә дәртле бер җиңеллек тоеп, авылга таба йөгерә-чаба китеп барды.
Савымчылар аның артыннан карап исләре китеп калдылар. Йөрәгендә кайнаган ашкынулы хисләренә буйсыныпмы, шактый ук җиңел элдертә иде ул. Азрак киткәч, машиналар йөри торган олы юлдан чыгып, турыдан гына авылга илткән тар сукмакка борылды.
Бераздан юл яфракларын лепердәтеп торган куе таллыкка керде. Бу тирәләр язгы ташу чорында су астында калалар. Тар сукмакта тояк эзләре. Хәзер инде алар, сукмакны тигезсезләп, аякларны яман авырттыра торган кантарга әверелгән. Хәдичә алны-артны, уңны-сулны белмичә йөгерә дә йөгерә. Куерак урыннарда, чумып-чумып алгандай, юл аркылы иелгән эре тал ботаклары астыннан иелеп кенә үтте.
Ишеткән хәбәре шашкан күңелен тәмам тилертте, йөрәген урыныннан кузгатты. «Иа-а, хода! Иа-а, тәкъдир... бу көннәрне дә күрәсе бар икән». Әйе, иртә якта таңнар атканын, офыклар алланганын күзәткәндә ул үзенең йөрәк парәсен, кызы Вәлидәне исенә төшергән иде. Күңелгә килгән алга килә дип, бер дә белмичә әйтмиләр икән бит. Нинди көн бу?!. Язмыш бүләк иткән иң бәхетле, үзенә бәһа белми торган көндер бу. Аның өчен дөнья кинәт киңәеп, берни белән дә чагыштыргысыз төс алган сыман булды. Хәдичәнең яшәешкә булган өмет нуры, өмет йолдызлары яңа көч белән кабынып китте. Күңеленә ташкын сыман, моңарчы һич кенә дә татып карамаган бәхет, әллә нинди шатлык хисләре бәреп керде.
Шулай йөгерә-чаба торгач, куелыкны үтеп, ачыклыкка килеп чыкты. Андагы үргә күтәрелде. Әмма шул вакыт Хәдичә ахыр чиккә җитеп хәлдән тайганлыгын тойды: сулуы кысылды, түзә алмаслык боргычлап чәнчер катуы чыкты, йөрәге күкрәк читлегеннән атылып чыгардай булып тыпырчына башлады. Аның кагуы, кайнап чыгар дәрәҗәгә җиткән канының чигәләрдә сулкылдавы Хәдичәнең үзенә дә аермачык булып ишетелә иде. Ул, тагын барлык көчен җыеп, кадала-каплана бераз йөгергәндәй итте дә, сөрлегеп китеп, үлән өстенә йөзтүбән барып егылды.
Бер тын иркенләп сулыш ала алмыйча газапланды ул. Тарткалапйолыккалап, күлмәк изүләрен ычкындыргандай итте. Шул чакны күңелдә үзен-үзе кызгану хисе туды. Нигәдер үксеп-үксеп бер рәхәтләнеп елыйсы килде. Ике кулы белән йөзен каплап, чәнчеп утырган тезләре өстенә иелеп төште. Әмма күз яшьләре чыкмады, алар инде күптән кипкәннәр, беткәннәр иде. Бу минутта аның бары тик җилкәләре генә калтырый иде.
Яшерен-батырын түгел, Хәдичәнең тормыштан тәмам суынган чаклары да булгалады. Әмма шундый минутта башына келт итеп бер уй килә, яшен кебек ялтырап, миен көйдереп ала иде. Чү-ү, аның бит әле бу фани дөньяда газиз баласы бар... Бар, бар!.. Язмыш кыерсыт-

кан, каккан-суккан һәр очракта газиз баласын һаман ешрак искә төшерә торган булып калды ул.

Шунысы гаҗәп, Хәдичә кызы белән очрашуына ышанып яшәде. Һәрхәлдә, йөрәк парәсе — кызы белән очрашырга, аның алдында тез чүгеп баш иярга, шулай бер-берсен күрергә зар һәм интизар булып яшәгәннәре өчен елап-ялварып аңардан гафу үтенергә тиешмен, дип уйлады ул. Аның үз тормышы газиз баласы — Вәлидәсе белән янәшә, гел бергә булыр сыман иде.

Шундый өметкә бәйле булган уйлар белән үз-үзен юатырга да өлгерми, икенчеләре баш күтәреп, йөрәкләргә шомлы тынгысызлык салып, аның хыял-максатларына балта чаба торды. Вәлидә бит кыз бала, дип уйлый иде ул. Ә кыз бала, билгеле булганча, туган нигезендә дә кунак кына. Хәдичәнең «үз» тормышына чират житкәләгәнче кызының бөтен уй-хисләрен белеп, бөтен барлыгын яулап мәхәббәт килсә?.. Андый вакытта бит ата-анага карата булган изге тойгыларның да икенче планга күчүе мөмкин.

Ә гомер дигән нәрсә, нәкъ сүтелә башлаган йомгак кебек, барыр юлны сапламлап кыскартканнан-кыскартып, үтә дә үтә. Хәдичә өчен аеруча яман уй иде бу. Ул инде бераз ашыгырга, кыен эш белән очрашу көннәрен якынайту чараларын күрә башларга да бик вакыт икәнлеген яхшы төшенә иде. Ул бит инде бер тапкыр үзенең бәләкәче белән элемтәгә кереп алды. Кызы Вәлидәнең хәтта: «Әнием!.. Син исән икән ич... Миңа бит сине үлгән дигәннәр иде. Минем сине бик тә, бик тә күрәсем килә» дигән сүзләр тулы хат та килде. Укучылар дәфтәре битенә эре, йомры хәрефләр белән язылган бердәнбер хат булды ул. Конвертына җавап язу адресы да куелмаган иде шул, бары тик «Свердловск өлкәсе» дигән штампы гына бар иде. Элемтә шуның белән өзелде. Шик тә юк, моның сәбәбе Вәли булгандыр. «Ана саналырга лаеклы кеше түгел ул» дигәндер. Беркатлы сабый бала әтисе сүзләренә ышангандыр да, күңеленнән бөтенесен чыгарып ташлагандыр... Ләкин бит хәзер аның Вәлидәсе җиткән кыз, узган кышта унҗиде яшь тулды үзенә. Хәзер инде тормышның ифрат та катлаулы, тормыш юлларының кайберәүләр өчен гаять тә сикәлтәле булуын төшенә башлагандыр... Әнә бит Мәйсәрә нәрсә ди: «Үзең кадәр кызың бар икән...» Әй-йе, бар! Әмма Хәдичә үзенең йөрәк парәсен бары тик бәләкәй итеп, имчәк баласы итеп кенә белә. Төшләренә дә гелән бәләкәй булып керә иде. Шуны юатырга, имезергә теләп саташып мәш килеп бетә торган иде. Ә хәзер әнә... Аның унсигезенче яше белән киткән кызы, аның бердәнбере кайткан...

Хәдичә күңелендә укмашып каткан кара төерләре эреп түгелгәнче елады. Бу елау газаплы да, рәхәт тә, әрнүле дә, татлы да иде. Күңеле бушап, авыр йөктән чак кына арынгандай булды. Сулышы да бераз тигезләнде сыман. Һәм ул яңадан торып авылга таба йөгерде...

Бу юлы да хәле бик тиз бетте аның. Аркасы дымланып, күлмәге тәненә ябышты. Йөрәге ярылыр дәрәҗәгә җитеп какты, тыны кабат тамагына күтәрелеп буа башлады.

Әмма түзде. Җан тирләре чыкса да түзде. Менә инде авыл да... Каз бәбкәсе үләне белән капланган тар тыкрык. Чишмә сукмагы бу. Аннан җил кебек элдереп кенә олы урамга чыгар... Анда инде аның өе.

Капка төбендә, ишегалдында шактый халык җыелып өлгергән: хатын-кызлар, карт-карчыклар, бала-чага.

Шул чак кемдер Хәдичәне күреп аваз салды:

— Әнә!.. Үзе дә кайтты...

Кешеләр, таралышкандай итеп, юл ачтылар. Шул чак Хәдичә баскыч болдырында басып торган кызын күреп алды. Алтын-саргылт чәчләрен толымлап үреп салган, буй җиткән Вәлидәне күрде дә аһ

итте: шул кадәр охшаса да охшар икән!.. Хәдичә үзенең яшьлеге белән күзгә-күз очрашкандай булды.

Ул баскычка якынлашты, кызы янына күтәрелде. Шушы көн бәрабәренә дип сайлап куелган, еллар буе күңел түрендә назлап йөртелгән иң үтемле сүзләре кинәт онытылдылар, хәтергә килмәделәр. Күңеле чуалды Хәдичәнең, күз аллары караңгылана башлады. Һәм ул, көзән җыергандай тартыша башлаган йөзен кызыннан яшерергә теләгәндәй, җәһәт кенә Вәлидәне кочагына алды да:

— Балам!.. Бәгърем минем!..— дип, кызының җилкәсенә капланды.

*

* *

Бәхетсезлекне аны күз белән каш арасыннан гына эзләргә кушканнар. Хәдичә белән дә шундыйрак хәл килеп чыкты.

Җәйләүгә инде ике-өч тапкыр шоферлык правасын алдырган, соңгы авариясендә колхоз машинасын тәмам җимереп эштән чыгарган әлеге дә баягы исерек баш Садрины билгеләделәр. Бөтенләй эштән азат итеп булмый бит аны. Беренчедән, өч баласы бар. Шуның өстенә әле тагын, машина җимергән өчен, өлешчә генә булса да түләргә ясадылар — айлык хезмәт хакыннан егерме биш процентын тотып калалар.

Гомумән, Садри эшләп бик куандыра торганнардан түгел. Җитмәсә, үзенең бер дә серкәсе су күтәрми, әйткәнне яратмый. Савымчылар үзләренең ризасызлыкларын белдерә башлауга бер сүзгә бише белән җавап кайтара. «Ярар, ярар!.. Саву аппараты самолет түгел... Һавага күтәреләсегез юк. Ул кадәр төпченмәсәгезче!» — дип кенә җибәрә.

Күрәсе булгандыр инде, ул көнне Хәдичә иртә торгач та күңелендә әллә нинди тынгысызлыкмы, сөенечме сизенгәндәй булды. Һәрхәлдә, аның күңеле үз урынында түгел иде.

Савымчылар, гадәттәгечә, сөйләшенгән вакытка, сөйләшенгән урынга җыелып, машинага төялеп җәйләүгә төшеп киттеләр. Ничектер шулай чыкты, Садриның юклыгына беркем дә игътибар итмәде. Чөнки мастер-наладчик кешенең үз транспорты белән иртәрәк төшеп китүе бик ихтимал иде. Андый хәлләр моңарчы да булгалады.

Савымчылар җәйләүгә, гадәттәгечә, бөтен су буен тутырып, якынлашып килгән сыерлар көтүе белән бергә төшеп җитә. Машинадан сикерешеп төшү белән эшкә дә керешәләр. Бу юлы да шулай булды. Савымчылар тыз-быз килеп халатларын киеп алдылар, кулларын юып, үзләренең агрегатлары тирәсенә таралышып та беттеләр.

Фәния белән Хәдичә дә, саву агрегатының үзләре эшли торган секциясе янына килеп, аппаратларны караштыра, детальләрне барлый башлады.

— И-и, Хәдичә апа!..— диде Фәния, махсус флягаларны секция буенча таратып чыгып.— Борчылып төшеп йөрисегез калмаган...

— Юк белән башыңны катырма,— дип кырт кисте Хәдичә.— Кара син аларны... үзе бер көтү бит.

Чыннан да, Хәдичә бүген төштән соң икенче сменага гына чыгарга тиеш иде. Әмма элеккеге илле сыер янына тагын егерме ике баш килеп өстәлде. Шуны әйтте дә инде ул, «үзе бер көтү бит» дип.

— Алайса, кичкә мин дә төшәм,— диде бөҗыр кебек бөтерелгән Фәния.— Югыйсә, сезгә авырга туры килер...

— Анда күз күрер әле...

Ниһаять, аппаратлар әзер, сава башларга да мөмкин.

— Кертә башлыйммы, Хәдичә апа?

— Давай!..

Җиленнәре тулудан тынгысызлана башлаган сыерларның ин түземсезләрен унысын берьюлы стойкалар арасына кертеп бастырдылар.

Эшне кызурак тоту нияте белән моторларны җибәрделәр. Әмма күпме генә тырышып карасалар да, эшләрен дәвам итә алмадылар. Ун насосның берсе дә эшләми иде.

— Нишләптер суырмый, Хәдичә апа...

— Минекеләр дә киреләнә...

«Ни булыр бу?» дигәндәй, аптыраешта калдылар. Алай иттеләр, болай иттеләр, моторларны туктатып кабат ходка җибәреп карадылар, тик бернәрсә дә ярдәм итмәде. Тәмам аптырагач, агрегатны яңабаштан карап, һәр детален җентекләп күздән уздырырга булдылар. Бары тик шунда гына насосларны эшләтә торган редукторның пульсаторы үз урынында юклыгы билгеле булды.

Менә сиңа мә! Үч иткән кебек, мастер-наладчик Садри да юк. Ахыр чиктә Хәдичә белән Фәния, терлекчеләр өе янына барып, Садриның инструментлары, запас частьлары саклана торган әрҗәне каерып ачтылар. Тимер-томырның астын-өскә китереп актардылар, тик үзләренә кирәк пульсаторны таба алмадылар.

Ул арада савымчылар: «Малларыгызны карагыз әле... Эшләргә комачаулыйлар»,— дип, чынлап торып гауга куптардылар.

Шул чак Хәдичәнең күңелендә: «әллә берәрсе юри алып үз агрегатына куйдымы икән?» дигән уй туды. Бу турыда ул Фәниягә дә әйтте: өлгер-житез кызга житә калды, әллә кая кадәр сузылган агрегатның буеннан-буена йөгереп үтеп, барлык секцияләрнең пульсаторларын күздән кичерү белән генә дә чикләнмәде, хәтта капшап карап чыкты.

— Юк, Хәдичә апа... Безнеке күренми. Үзебезнекенә мин игәү белән бер сырлы тамга салган идем,— диде Фәния, озак йөгерүдән еш-еш сулыш алып.

«Тамга салу»ның үзенә күрә хикмәте дә бар. Садри аппаратларның иң кирәкле ваграк детальләрен я ватылды, я стройдан чыкты дип ала да: «Теләгән тәкъдирдә табып була... Тик бит, Хәдичә апай, җаныкаем, үзең беләсең, майламый... купмый диләрме әле? Заманы шундый бит аның...» дигән булып, уң кулының баш бармагы белән имән бармагын ышкып күрсәтә, ягъни «тамак чылатырга кирәк» дигәнне аңлата торган ишарәләр ясап куя.

Чараң юк, теләсәң-теләмәсәң дә, бирергә туры килгәли. Сер түгел, запас частьлар җитенкерәми, теләгәндә кирәклесен кайчак чыннан табар хәл юк. Тик менә шул кадәресе бар: ватык, тузган яисә коелып төшәргә торган детальләр, кагыйдә буларак, Хәдичә аппаратында табыла торган иде.

Бу хәлне беренче булып Фәния сизенде һәм үз детальләренә сизелер-сизелмәс кенә «тамгалар суга» башлады. Гаҗәп хәл! Икенче көнне үк бер детальне Садридан икенчеме, өченчеме тапкыр «сатып» алганлыклары билгеле булды. Фәния бу турыда шунда ук Хәдичә апасына житкерде. Комсомолка Фәниянең бу нәрсә белән һич кенә дә килешәсе килми иде. Ул тамга салуын дәвам итте. Җае туры килгәндә Садриның йөзенә бәреп әйткәләде дә. Ник әйтмәсен ди! Оятын җуеп, күзгә карап алдаша бит. Юмарт дигәч тә, Хәдичә апасында да Әндри казнасы юктыр...

— Менә бит, ә! Хәзер нишләп карыйбыз инде?..— дип хафаланды Хәдичә.— Башкалар савып бетергәнче көтәргә туры килер микәнни?.. Аппаратлары бушау белән без керешербез...

— Ләкин бит алар безне көтеп тормаячаклар...

— Көтмәсәләр көтмәсләр инде.

— Ә көтүчеләр?..

— Алар да бераз сабыр итәрләр.

Ләкин бу уен эш түгел иде. Бәлки шуңа күрәдер Хәдичә:

— Әллә кул белән сава торабызмы? — дигән тәкъдим ясады.

— Алай да ярый, Хәдичә апа...,

Ачуыннан кайнап чыгу дәрәҗәсенә җиткән Хәдичә: «Ну-у, адәм тәганәсе! Күзгә генә күренсен. Минме, мин аңардан моңарчы биргән акчаларымны да костырачакмын...» дип, чынлап торып янап та куйды.

Алар яңадан терлекчеләр йортына кереп чиләкләр алып чыктылар да, бидон-флягалар хәзерләп, кул белән саварга җыена башладылар. Тәмам тәкатьләре беткән сыерлар, агрегат тирәсенә өелеп, бер-берсен кысрыклап, яман үкерешәләр. Бу хәл башка савымчыларның да эчен пошыра иде, билгеле.

Нәкъ менә шул вакытта килеп чыкты да инде мастер-наладчик Садри. Мотоцикл рулен бер яшүсмер малай тоткан, ә аның артына ин беренчеләрдән эш урынына килергә тиеш булган әзмәвир кадәр гәүдәле мастер-наладчик менеп кунаклаган. Уенчык кебек кенә мотоцикл ничек күтәргән диген әле син аны!

Хәдичә, ярсып, Садрины алып килгән мотоцикл янына ташланды. Ачуыннан күзләре аларган, йөзе усал иде аның.

Әмма тегесе, башларын да күтәрмичә эшләүче хатын-кызлар янына житәр-житмәс, бер кулын өскә күтәреп:

— Салют новаторларга!..— дип сәлам биргән булды.

Хәдичә аны мотоциклдан җилтерәтеп төшерде.

— Тизрәк бул, хасис!.. Җан көеге... Хәзер үк пульсаторны урынына куй!..— дип якалый да башлады.

Мондый көтелмәгән хәлне күргән яшь егет, мотоциклын тиз генә борды да, син күр дә мин күр, авылга таба җил уйнатып китеп тә барды.

— Тизрәк кыймылда, явыз җан!..— дип кабат җикеренде Хәдичә.

Тегесенең анда-монда кайгысы юк. Хәдичәнең сүзләрен гаменә дә алмый. Ул исерек. Аягында көч-хәл белән басып тора. Чәчләре әвәләнеп, киезләнеп беткән. Мотоциклдан төшкәндә, җил кисү сәбәпледер инде, күзләреннән яшь агып төшкән.

Хәдичә Садрины җилтерәтүен белде:

— Пульсатор кайда дип сорыйм мин синнән? Ишетәсеңме, юкмы?..

Тегесе күзләрен челт-челт йомгалап алды да:

— Нинди пульсатор ул, Хәдичә апай, җаныкаем?..— дип, үз чиратында сорау бирде.

— Редуктор пульсаторы... Чак кына шуны аңларлык хәлең бармы синең, әтрәк-әләм!..

Садри, кинәт нәрсәнедер исенә төшергәндәй, имән бармагы белән чигәсе тирәләренә кагылгалап алды.

— Ә-ә!.. Әй-йе, әй-йе... Менә хәзер аңлашылды... Искә төште. Башта ук шулай диярге кирәк иде аны, Хәдичә апай, җаныкаем...

Хәдичәнең чыдар хәле калмады.

— Пульсаторның кайдалыгын әйтәсеңме син, юкмы, ниһаять?!.

Бу минутта Садри бары тик бер мизгелгә айнып киткән сыман булды. Үзенең шактый ук житди хата ясавына төшенде, ахрысы. Әйе, төшенде. Моңарчы бит ул: «туздый» яки «кирәгеннән артык шакылдый» дип, бары тик бер генә аппаратны «аксата» иде. Бу юлы исә ул кызган баштан, үзе дә сизмәстән, ун аппараттан торган тулы бер секцияне, агрегатны «ремонтка куйган» булган икән...

— Пульсатор кайда? — дип кабат кычкырды Хәдичә.

Бу катгый сораудан шактый ук шүрли башлаган Садри, күзен дә йоммыйча, алдашырга керешге.

— Бәй!.. Ватылды бит ул, Хәдичә апай, җаныкаем...

Хәдичәнең ачу оеткысы бу юлы кабарып кына калмады, күәсенә сыеша алмаган камыр кебек бүселеп үк чыкты.

— Нинди җаный булыйм ди мин сиңа, шакшы! — дип җикеренде ул, ярсыганнан-ярсый барып.— Хәзер үк... Менә хәзер үк урынына китереп куй пульсаторны...

— Юк ул...
— Ничек юк?
— Ташладым мин аны.
— Кая ташладың?

Мондый конкрет куелган сораудан башына эзлекле фикер, теленә кирәкле сүз килми гаҗизләнде Садри. Аннары инде юмакайлангандай, бер үк вакытта мыскыл да иткән кебек, тезә башлады:

— Ватык нәрсәне кая ташлыйлар ди инде?.. Син дә сорау биреп торган буласың, Хәдичә апай, җаныкаем...— Әйе, кичә лыкынганчы чөмергән булган бу адәм рисвае. Теле көрмәкләнә, үзе һаман да чайкалгалап куя иде әле ул.— Кая ташладың дип сорыйсың син... Кая ташлансын инде ул?.. Чүплеккә ташлана инде, билгеле. Яраксызга чыктыңмы, марш, чыгаралар да ташлыйлар. Шундый ул тормыш дигән нәрсә...

Хәдичәнең бүтән чыдар чамасы калмады.

— Пульсаторны табып китер дим мин сиңа!.. Синең аркада никадәр вакыт эшсез тордык, кабахәт җан!.. Шушы сәгатькә чаклы бер сыер савылмаган... Яхшылык белән бирәсеңме син пульсаторны, юкмы?..

— Чү-чү, Хәдичә апай, җаныкаем!.. Алай бик чәпчемә әле син... Мин сиңа менә дигән, җылкылдап торган... тузуны белми торган пульсатор табып куйдым. Рәхмәтләр әйтеп туя алмассың, тегеләй... Тик бит аның өчен... үзең беләсең...— Садри, әлеге дә баягы, таныш ишарә ясаган кулын Хәдичә танавына якынайтты.

— Бирәм, бирәм!..— дип өтәләнде Хәдичә.— Ун сум кирәкме, егермеме?.. Бирәм! Тик, зинһар, агрегатны кына тизрәк ходка җибәр...

Савымчының моңарчы күрелмәгән юмартлыгыннан тәмам илереп китте Садри. Һәм ул яңадан, нидер әйтергә хәстәрләнгән кебек, имән бармагын кабат чигә тирәләрендә кыймылдаткалап алды. Аннары әйтәсе сүзен кинәт кенә исенә төшергәндәй итеп:

— Егерме тәңкә дидеңме әле?..— дип сорап куйды.

— Әйе, әйе!.. Тик, зинһар, тизрәк кыймылдачы... Кайда соң ул?.. Яңа пульсаторың дип соравым...

Садри, чак кына айнып, эзлекле фикер йөртмәкче булып азапланды.

— Чыннан да... Кайда соң ул?.. Кичә кичен алгач... кая гына куйдым соң әле мин аны?..— Ул хәтта буш кесәләренә шапылдатып суккалап та алды.— Тю-тю-ю, шайтан алгыры! Өйдә калган ич ул, Хәдичә апай, җаныкаем!.. Билләһи, өйдә калган...

Садриның бу кыланышлары Хәдичәне тәмам чыгырыннан чыгарды. Ул бөтен тәненең җиңелчә генә калтырый башлавын тойгандай булды. Тавышына кадәр үзгәрде аның.

— Син нәрсә дип шамакайланасың әле монда, ә?! Цирк дип беләсеңме әллә?.. Куй хәзер үк пульсаторны урынына...

Тегесе, үз хатасын таныган кеше сыман, җилкәләрен сикертеп, кулларын җәеп җибәргән булды. Аннары: тәки җиндең, Хәдичә апай, җаныкаем! дигән кебек итеп, иреннәрен чалшайтып елмаеп та алды. Ахырда инде соңгы сүзен әйтте.

— Куям, куям, Хәдичә апай, җаныкаем!.. Әбәзательно, куям. Син дигәндә аяк идәндә. Икенче төшүеңә үк пульсатор үз урынында булыр. Ә хәзергә... теге әйткән суманның яртысын гына булса да...— Таныш бармаклар, күнегелгән ишарәләр яңадан Хәдичә битенә якынайды.

— Миңа пульсатор хәзер үк кирәк,— диде тегесе.

— Хәзергә юк ул, Хәдичә апай, җаныкаем... Өйдә онытылып калган...

Түземлегенең соңгы чигенә җиткерелгән Хәдичә дә ахырда өч бармактан ясалган нәмәстәкәен: «Менә сиңа егерме тәңкә!» дип, тегенең борын төбенә китереп куйды.

— Алайса, сиңа да пульсатор... менә, тот!..— диде Садри, бармакларыннан җәһәт кенә Хәдичәнекенә охшашлы рәвеш ясап.

Аның соңгы сүзләре, сүзләреннән дә бигрәк кыланышлары, кукиш ясап борын төбенә төртүләре әллә нишләтеп җибәрде Хәдичәне. Нәрсә эшләгәнен абайламас дәрәҗәгә килде. Менә шунда ул: «Менә сиңа егерме тәңкә!» дип, кулындагы буш чиләге белән Садриның башына кундырды да инде.

Бу кадәресен Садри да көтмәгән булса кирәк. Әле төшкән шәпкә генә чиертсәң кан чәчрәп чыгардай кызарынган-бүртенгән йөзе кинәт әллә нишләп китте, йөзеннән кан качкан сыман булды. Ә инде уң як күз турысыннан сузылып кан агып төшүен дә тойгач, тәмам агарынды. Күзен томалап агып төшкән канны учы белән сыпырып алганнан соң, Хәдичәнең йөзенә туп-туры карап: «Эх-х, син!..» диде дә якында гына торган озын өстәл янына китеп тә барды. Эскәмиясенә утырмады, ни өчендер аркасын өстәл аягына биреп, җиргә чүмкәйде.

Хәдичә үзе дә өнсез-телсез булып, баскан җирендә тораташтай катып калды. Колаклары томаланып, күз аллары караңгыланып китте. Аягы астында җир чайкалып куйган сыман булды. Шул чак ул, бары тик калын пәрдә аша ишетелгән сыман, аерым җөмләләр, өзек-өзек сүзләр абайлады. «Хатыннар!.. Ниткән эш инде бу, ә?!. Күрәләтә торып кеше үтертәбез түгелме соң?..» Зәмзәмбикәнең колакка ятышсыз черелдек тавышы иде бу.

Бераздан Хәдичә күз алдында Зәмзәмбикә үзе дә пәйда булды. Ул, Хәдичәгә бармагы белән янап, нәрсәдер кычкырды... ыгы-зыгы купты. Башка хатыннар да шул тирәгә килде. Кемдер: «Аптечканы алып чыгыгыз... Тиз булыгыз!..» дип әмер бирде. Барысы да тыз-быз килеп, тезләре өстенә капланып утырган Садри тирәсендә чуала. Кемдер, көчләп диярлек, ак бинт белән аның башын бәйләргә кереште. Аның янында иң бөтерелгәне, иң куштанланганы, әлбәттә, әлеге дә баягы Зәмзәмбикә иде.

Зәйтүнә дә килеп җитте.

— Нишләдең син, Хәдичә апа?!.— дип өзгәләнеп күрсенде парторг.— Эх-х, сине!.. Акылыңдамы син, юкмы? Шулай итәргә ярый димени?.. Сыерларыгыз савылмыйча калыр дип курыккан идеңме әллә? Хәзер савабыз аларны... Эх-х, нишләдең син?! Торып-торып шаккатам, Хәдичә апа. Тымызык күлне корт баса дигәндәй, Садрины, ул соры кортны, яман гадәткә акча биреп үзең өйрәттең. Нишләп соң әнә безнең агрегатлар, аппаратларыбыз стройдан чыкмый... Кагылып кына карасын минем агрегатка. Мин аны, колхоз производствосына аяк чалучы корткыч дип, җыелыш алдына чыгарып бастырачакмын... Эх-х, син!.. Тәмам аптыраган синең белән. Бер караганда сокланып туймаслык кеше үзең, икенче караганда... шайтан белсен, нәрсә...

Ул арада инде эшләрен бетерергә өлгергән савымчылар, каядыр соңга калудан курыккандай, Садрины машина кабинасына утырта башладылар. Ул эшләрнең барысы белән дә Зәмзәмбикә идарә итә.

Чак кына зиһенен җыя башлаган Хәдичә ут өере уйнатып йөргән Зәмзәмбикәнең соңгы сүзләрен ишетү хәленә килә башлады.

— Ю-юк-к!.. Бу юлы инде йомып кала алмаслар. Җиткәндер, ниһаять! Болай да күп мәтәштерделәр. Чәчрәп китим әгәр, җирләр йотсын дип әйтәм, үз башына дип кылана бу Чабата җанаш. Менә әйткән иде диярсез, бу юлы аның кулын кыскартачаклар... Ничек кенә кыскартырлар әле, үзе дә шакай булыр...

Ул да булмады. Зәмзәмбикә шофер егетне, кузгалырга дип, кыбырсыта-ашыктыра башлады. Шактый җыелырга өлгергән хатын-кызларның күпчелеге аның бу әмер-приказына каршы килеп маташтылар. Бераз көтик, янәсе, эшләрен бетерсеннәр. Аларга да кайтырга кирәк бит.

— Әнә, Зәйтүнә дә яңадан эшкә алынды...
— Күтәргә кирәк, билгеле...
— Ничу монда суфиланырга!..— дип, бер генә җикеренде Зәмзәмбикә.— Күрмисезмени... монда яралы кеше бар. Тизрәк кайтырга кирәк. Заражение круви булуы бар... Кешене үтерергә телисезме әллә? Бик кирәксә, машина кабат төшәр. Беркем дә аның алдына киртә тотарга җыенмый...
Машина китеп барды.
Өлгер-җитез Фәния, Зәйтүнә, тагын берничә савымчы агрегат тирәсендә мәш килеп эшләп яталар. Барлык сыерлар да, стойкаларга кертелеп, саву аппаратларына куелганнар.
Тик Хәдичәнең генә эшкә кулы күтәрелмәде. Тәмам хәлдән тайган кебек, өстәлнең күләгә эчендә калган өлешенә барып утырды. Күңелен сүз белән әйтеп аңлатып булмаслык газаплы хисләр, ифрат дәрәҗәдә яман уйлар өермәсе биләп алды аны. Бу минутта аның искәрмәс яктан ыргып бәреп кергән зәмһәрир җил барлык өметләрен өзеп, хыялмаксатларын чәлпәрәмә китереп ташлагандай итте. Нишләде ул, нишләде?.. Күр инде, ә?!. Бүгенге көннәрне ходай бер үк күпсенә күрмәсен дип куанып кына яшисе урында, тагын нишләп ташлады бит, ә!.. Тыныч кына яшәргә язмаган микәнни соң миңа дип, лаф орды Хәдичә. Бу турыда кызы Вәлидәсе белән Вазих ишетә-нитә калса, җир тишегенә кер дә кит... Һәй-й, тиле, ишетмиләрме соң?! Зәмзәмбикә күптән инде урам буенча сибеп йөри торгандыр. Әнә, Зәйтүнә дә нәрсә ди бит: бер караганда сокланып туймаслык кеше үзең, ә икенче караганда... Кызы Вәлидәнең дә: моңарчы синнән башка яшәгән идем әле, моннан соң да, шәт, яши алырмын, дип китеп баруы бар... Мескен Вазих та, минем янга дип кайтып та,ниндидер бер килмешәк кебек, олы башларын кече итеп, гелән чит-ят кешеләрдә яши алмас. Түзәр-түзәр дә, китеп тә барыр. Нишләргә?.. Инде нишләп карарга?..

Хәдичә ут та кабызмыйча өендә утыра. Җәйләүдән кайтышлый парткомда булган сөйләшүне ничәмә-ничә тапкыр күңеле аша уздырды инде. Барысы да бер авыз сүзгә кайта да кала: «Берниндн дә шәфкать көтмәгез...» Юк, ул хәзер үз-үзен аяусыз тиргәп утыру белән генә чикләнми. Тиргәсәң-тиргәмәсәң дә, күңелдә, йөрәк үзәгендә һаман да бер үк хисләр: үкенечле уфтану, әрнү, әчтән сызу.
Бүлмәгә караңгылык инде. Ә Хәдичә, селкенергә дә курыккандай, утыра да утыра. Күңелендә бушлык, салкынлык, рәнҗү, каһәрлек. Күбрәк уйлаган, уе тирәнәя барган саен, йөрәге меңгә телгәләнә башлый. Бу хәбәрне агитбригада белән күрше авылларга чыгып киткән Вәлидәсе дә ишеткәндер инде. Әле дә ярый, Вазих өйдә юк, дип уйлап куйды Хәдичә. Вазих бүген таң белән Казанга полиэтилен трубалар, ясалма яңгыр яудыру өчен яңа насослар алырга дип киткән иде. Кайгының иң зурысы, хәсрәтнең иң ачысы шул иде Хәдичә өчен: бу хәлләрне кызы белән Вазихның ишетүе, аларның белүе. Әлбәттә, ишетерләр, әлбәттә, белерләр... Ишетмиләрме соң?!. Баягынак эштән кайтып идарәгә кергәндә генә дә күпләр аңар, ничектер, сәерсенеп карап калды сыман.
Хәдичәнең күз алдына яңадан партком кабинеты килеп басты. Иң каты бәрелгәне, әлбәттә, Нәҗип булды. Ләкин Хәдичә гаепләми дә, үпкәләми дә. Аның урынында башка берәү булса да нәкъ шул үк сүзләрне әйтер иде. Авызыннан ялкын бөркелсә дә, Нәҗип турында Хәдичә начар уйламады, гадел, миһербанлы егет, дигән фикердә калды. «Җинаять эшләгән икәнсең, җәзасын ала да бел». Дөрес әйтте. Ә дөрес сүзгә җавап юк. Бәлки шуңа күрәдер дә Хәдичә: ә дип тә, җә дип тә тел тибрәтә алмады.

Шул вакыт капка keləce шалтырап куйды. Ул да булмады, кемнеңдер бик җиңел, җил-җил атлап тәрәзә яныннан үтеп киткәне чагылып калды. «Вәлидә кайтты, ахрысы...» дигән шомлы уй Хәдичәнең зиһенен өтәләп үтте.

Ялт итеп ачылып киткән ишектә Фәния күренде. Бүлмәнең караңгылыгыннан икеләнеп булса кирәк, бусага төбендә туктап калды. Һәм шунда ук, рөхсәт-фәлән сорап-нитеп тормыйча, утны кабызды.

— Бәй, Хәдичә апа! Нишләп караңгыда утырасың әле?..

— Утыра идем шунда...

Фәния җәһәт кенә өй хуҗасы янына килде.

— Авырыйсыңмы әллә, Хәдичә апа? Бәлки урын җәеп бирергәдер үзеңә?..

— Хафаланма... Үзем җәярмен.

Яңадан сүзләре бетте. Сизелеп тора, төп сүзгә керешергә икесе дә тартына, икесе дә уңайсызлана.

— Вәлидә һаман да кайтмадымыни әле?

Хәдичә апасының җавабы кыска:

— Юк...

Фәниянең бу турыда шатлыклы хәбәре булган икән.

— Укыдыңмы әле, Хәдичә апа?.. Район газетасында безнең авыл агитбригадасын мактап язып чыкканнар. Ә Вәлидәне менә инде күкләргә чөйгәннәр...

Фәния бу хәбәр белән дә Хәдичә апасын әллә ни куандыра алмады. Ул арада өй хуҗасы үзе сорау биреп куйды:

— Үзеңә генә авыр булмадымы соң?..

Әңгәмәнең яңадан ялганып китүенә сөенгәндәй, Фәния йотлыга-йотлыга тезә дә башлады.

— И-и, Хәдичә апа!.. Агрегат гөрләп эшләп торганда нәрсәсе авыр булсын ди аның. Барысы белән бер үк вакытта саудым да бетердем. Бер генә минутка да соңгармадым, ичмаса.— Кызып китеп, киңәшмиңәш иткәндәй, сорау да биреп куйды.— Әллә, мин әйтәм, Хәдичә апа, сыерлар санын йөз башка җиткереп карыйкмы икән? Барысы да шаккатсыннар иде бер... Билләһи, Хәдичә апа, без синең белән йөз башны да сава алачакбыз төсле...

— Уйлап карарбыз,— диде тегесе бик тә инде тыныч кына.

Яңадан сүзләре бетте. Яңадан тынлык урнашты. Шул вакыт Хәдичә искәрмәстән генә:

— Я-ә, тагын нинди яңалыклар бар?..— дип сорап куйды.

Моны төп сүзгә, төп мәсьәләгә күчү икәнлеген кыз өлкән хезмәттәшенең күз карашыннан ук тойды. Саф күңелле, самими кыз бала бернинди хәзерлексез-нисез сүзгә дә керешге.

— Синнән соң, Хәдичә апа... идарәгә мин дә кердем. Теге мөртәт Садри да шунда иде. Үзенә дә бирдем кирәген... Ялгышлык белән елап та җибәргәнмен... Берсен дә калдырмадым, күрсәттем күрмәгәнен. Хәдичә апа урынында мин булсам башыңны ярып кына калмас идем... Үтерер идем, дидем. Җир битләнеп үзебезнең пульсаторыбызга егерме тәңкә соравын да әйттем. Ә бит пульсатор чыннан да безнеке булып, тамгалы булып чыкты. Кеше җибәреп, жилтерәтеп кенә өеннән китерттеләр. Маннур абый да ну бирде соң тегенең кирәген. Тетмәсен тетте. «Әле син шулай, сыйнфый дошман кебек, колхоз производствосына аяк чала башладыңмы? Корткычлык юлына бастыңмыни әле?..» — дип стенага терәде. Синең үзеңне фәлән-фәлән статьялар нигезендә тотып судка бирәм. Эшеңнән куам, диде. Теге исерек килеш җимерткән машинаны да тулысынча түләргә ясатам дип, уттан алып утка салды. Шундый күтәрелеп бәрелде. Маннур абыйның болай усаллануын моңарчы һич тә күргәнем юк иде. Сафура бураннары уйнап тора анда, Хәдичә апа, жаным!.. Кәмитнең кәмите анда...— Фәния кинәт кенә тук-

тап калды. Як-ягына карангалап алды. Аннары нәрсәнедер исенә төшергәндәй:

— Хәдичә апа... Син ашадыңмы соң әле?..— дип сорап куйды.

— Ашармын әле.

— Үзем генә берәр нәрсә хәзерләп бирмимме?

— Юк, кирәкми. Борчылма, Фәния...

Тегесе этәләнеп тора.

— Нинди борчылу ди ул!

Хәдичә елмайгандай итте.

— Син бар кайт, Фәния... Бар. Сине көтәләрдер...

— Көтмәсә тагын!

— Бар, үзем карармын...

Кыз искәрмәстән генә очынып килеп Хәдичәне кочаклап алды.

— Хәдичә апа, җаным!.. Борчылма да, хафаланма да... Әллә ни булмас әле... Монда без дә бар бит. Безме?.. Без...— Фәния кемгәдер янагандай, хәтта йодрыгын селеккәләп алды.

Хәдичәнең дә күңеле кинәт йомшап киткән сыман булды. Җанын авыр кара таш кебек басып торган хәсрәте дә чак кына басылганга охшашлы тойгы тууын сизде. Фәниянең аркасыннан сөеп елмайгандай итте.

Бары тик шуннан соң гына кыз, ничек кергән булса шулай ук җилләнеп, чыгып та йөгерде. Җаны-тәне белән теләктәшлек күрсәтергә атлыгып торучы изге җан Фәниянең кереп чыгуы Хәдичәнең тилмергән, иңрәгән, яраланган йөрәгенә бер шифа булды кебек.

Әмма аның бу халәте озакка бармады, яңадан мең төрле уйлар туып аның җанын кыйный башладылар. Уйлары да әллә ниндиләр: очлары-очкы ялганмый, капма-каршы фикерләр уята торганнар. Кереп килүче Фәнияне кызы Вәлидә дип уйлап, өне-коты алынуын гына күр инде!

«Нилектән шулай соң бу?» дигән сорау, йөрәгенең нәкъ үзәгенә кадалган кылчык кебек, өзлексез бимазалап торды. Вәлидә бит аның бердәнбере, газиз баласы, булган кайгы-хәсрәтен дә, шатлык-куанычын да ана кеше иң элек үзенең газиз кешесе, йөрәк парәсе белән уртаклашырга, үзен газаплаган күңел серләрен беренче чиратта аңар ачарга тиеш иде ләбаса! Әле кайчан гына Хәдичә: газиз балакаемны бары тик бер күреп кочагыма ала алсам, миннән дә бәхетлерәк кеше булыр идеме икән? дип уйлый иде. Әгәр дә мәгәр аның шул хыяллары тормышка аша-итә калса, Хәдичә бар нәрсә белән риза-канәгать булып, булган кадәресенә шөкерана кылып, килде-китте тормыш ыбыр-чыбырларыннан тәмам азат булып яшь башлар сыман иде. Аның янында күреп сөенер-куаныр, сөяр-иркәләр өчен бары тик кызы гына калыр төсле иде. Кая ул бүгенге кебек сөртенү, шундый юләрлек ясаулар! Андый нәрсәләрдән күп өстен торачак сыман булып тоела иде.

Юк икән! Тормыш ул уйлаганча ук тади түгел икән. Кызы да кайтты, Вазихы да янында. Әмма Хәдичәнең күңеле һаман да үз урынында түгел, тормышының һаман да әле кайсыдыр чите китек икәнлеге үзен сиздереп тора кебек. Башында һаман бетмәс-төкәнмәс уйлар өермәсе. Иң хикмәтлесе шунда: аның бөтен барлыгын яулап алган бу тойгы-хисләре бары тик кызына, Вазихына бәйле, бары тик алар турында гына түгелләр икән ләбаса! Күпчелек уйларының очлары эшенә, көндәлек хезмәтенә баралар да ялганалар. Соңгы вакытта, әнә, сыерларның баш саны артты. Бу исә үзе генә дә күпме мәшәкать өстәде. Алар да җан иияләре бит: берсенең кичә сөте кимеде, икенчесе, әнә, алдына салган бардага әйләнеп тә карамады. Әллә берәр кирәкмәгән нәрсә йоттымы икән? дигән шик туа Хәдичәнең күңелендә. Менә сиңа өстәмә хафа, мәшәкать. Иртәгә дә шулай итенсә, Гөлнурга хәбәр итәргә кирәк булыр, карасыннар, тикшерсеннәр, сәбәбен белеп тиешле

чарасын күрсеннәр. Беренче тапкыр бозаулаган яшь танасының кичә кич җилене кирәгеннән артык кайнар иде. Димәк, малның температурасы бар. Бу да нормаль хәл түгел. «Майка» аксый. Бер дә бәрелеп сугылуга охшамаган, чөнки аксавы көннән-көн көчәя бара. Аяк чиренә юлыккан булса кирәк. Аны да ачыкларга, сырхау икән, кичекмәстән дәваларга куярга кирәк...

Менә шунда Хәдичә үзе өчен гаять тә зур, искитмәле бер хакыйкать ачкан сыман булды. Тирәнтенрәк, төптәнрәк уйлый калса, аның бар тормышы, яшәү мәгънәсе шул хезмәтендә, эшендә дә икән бит! Күр инде, ә... Чыннан да шулай икән ич! Әгәр дә шулай булмаса, эш дип җанып-көеп, яшәү мәгънәсе, тормыш тоткасы булган хезмәте белән яшәмәсә, тормышның кызыгы булыр идемени соң? Юк, әлбәттә.

Шул вакыт кабат капка келәсе шалтырап куйды. Бу юлы Хәдичә: шәт, Вәлидә кайткандыр дип уйласа да, баягы кебек җан газабы кичермәде. Кайтсын, сөйләшербез, аңлашырбыз. Ул бит миңа җиде ят түгел, канса канис, ә газиз балам. Күңелсезлек чыкты дияр, аңлатыр, андый хәлләр, китек-чатаклыклар булмый калмый ул, шуңар күрә эш, хезмәт диләр аны дип аңлатыр, төшендерер.

Ул шулай күңеле белән булачак сөйләшүгә хәзерләнеп, әйтәсе фикерләрен күңеле аша үткәреп утырганда, башы ак бинт белән уралган Садрины күреп аптырап калды.

— Ярармы икән?..— диде тегесе, бөтенләй ят тавыш белән.

— Әйдә... килгәч кер инде...

Хәдичә, һич тә көтелмәгән бу кичке кунакны күргәч, чак кына шүрли калды. Күзләрендә дә бермәлгә шикләнү галәмәтләре чагылып киткәндәй булды. Исерек башның нинди уй белән йөргәнен кем белгән? Әмма Садри ап-айнык иде.

— Бу мин әле...— диде ул, башын тагын да аскарак иеп.

— Соң... Түргә уз, алайса...

— Юк, узып тормам...— Юк, яман нийт белән килмәгән ул. Хәтта үпкә, ризасызлык белдерергә дә килмәгән. Алайса, нишләп йөри соң?..

Әмма алар рәтләп сүзгә дә керешә алмый калдылар, бик эшлекле кыяфәт белән Шапырай карт килеп керде. Кулына шактый ук җилле кусәк тә эләктереп алган.

Бу хәлне шәйләп өлгергән Хәдичә, иң элек күршесенә мөрәҗәгать итеп, нинди йомыш белән керүе турында сорап куйды.

— Менә бу ләгыйньнең синең өйгә кереп китүен күргәч... Ярдәмемнием кирәк булмасмы дип уйлаган идем...— Ул шулай искәрмәстән басып керүенең төп сәбәбен аңлатырга теләгәндәй, кусәгенә ымлап, аңлаган кешегә бик аңларлык ишарәләр ясап куйды: исерек зобаниның арт сабагын укытырга кергән, янәсе.

Шул чак Садри да телгә килде, үзенең Хәдичә белән күзгә-күз карашып кына сөйләшәсе сүзе барлыгын әйтте.

Шапырай карт аның сүзләрен колагына да элмәде.

— Ничу монда бәгырь талап йөрергә!..— дип кенә җибәрде ул. Аннары Садри каршына килеп басты да кусәгенә кушкуллап таянган килеш элеп тә алды.

— Ну-у, малай! Зрә дә булдыксыз, зрә дә никчемушный бәндә булып чыктың бит әле син. Нәкъ теге, тоткасыз бакыр комган кебек: эшкә дә ярамыйсың, чыгарып ташларга да жәл.— Бу әле картның кереш сүзләре генә иде булса кирәк. Аның әйтергә теләгән сүзе бармак башы хәтле булса, кереш сүзе, гадәттә, ботаклы бәрәңге чаклы булыр. Менә ул Садрига таба тагын да якыная төште һәм күзгә керергә чамалаган черки сыман сүзләр тагын безелди башлады.— Хет алдың, хет артың, иллә мәгәр бу сүзләрне әйтмичә булдыра алмыйм. Зобани так зобани икәнсең, тәки кеше була алмадың. Һаман да шул шешә иркәләп гомер үткәрешме?.. Аракы өчен иманыңны гына сатып калмассың

син, жанынны да закладка салырсын. Билләһи газим дип әйтәм, бер артың кызып алса, аракы түгел, кайнап торган сумала чөмерергә дә әзерсеңдер син...

Бу юлы инде Хәдичә түзмәде, күршесенең сүзен бүләргә, Садриның йомыш белән кергәнлеге турында картның исенә төшерергә мәҗбүр булды.

— Әнә, сүзем бар ди бит...

Тегесенең үз тугызы тугыз.

— Ничу монда!.. Исерекбашлар белән тел талдырып сөйләнеп торасы юк. Аның нәрсәгә кергәне көн кебек ачык: акча сораргадыр. Юмарт кулга күп керер, ди мәкаль. Әмма ләкин, Хәдичә күрше, сиңа да житкәндер, күп узындырдың бу зобанины. Мин үзем, мәсәлән, изгелек, яхшылык эшләгән кешеңә артын куйган бәндәне, гомумән, өнәп бетермим...

— Шапырай абзый...— диде Садри, күзләрен яшереп, чак кына читкә борылып.— Беразга гына чыгып тора алмассыңмы, ә?.. Бер-ике генә авыз сүзем бар иде.

— Ничу монда командовать итәргә!..— дип кычкырып, тагын да чәчәләнебрәк сүзгә кереште карт.— Син инде әйтәсе сүзеңне әйткән... Хәтта су буе итеп жалу да язып биргәнсең ди, жир бит!..

Садри башын тагын да аскарак иде, телен аркылы тешләп тынып калырга мәҗбүр булды.

— Сорамагыз да, нитмәгез дә... Барыбер чыкмыйм. Сүзегез бар икән — сөйләшегез, мин мишәйт итмәм.— Шунда ул башын як-якка боргалап, чайкаштырып алды да чак кына тынычлана башлаган сыман өстәп куйды:— Әйтәсе сүзеңне әйт!.. Миннән бернинди дә сере юк Хәдичәнең. Тәк-кәк, мин аның бер түбә астында диярлек яхшымы-яманмы күршесе. Дальше дә шул: без аны беркемгә дә обижать итәргә бирмәбез. Асубунный хәзер... Шуны бел: ул инде ялгыз түгел.

Бары тик шуннан соң гына Шапырай карт, бүтән бер сүзем юк дигәндәй, стена буендагы диван-карават кырыена барып утырды. Садри да, бу бәйләнчек карттан барыбер котылып булмаячагына төшенептер инде, сүзгә керешге.

— Хәдичә апа...— диде ул, акка чорналган башын тагын да аскарак ия төшеп.— Минем килүем шул иде. Бу низагыны... бу тәмсезләнүне булмаганга саныйк. Эшләр харап минем... Председатель эштән алды... Ә өйдә балалар... Алар хакына кичерсәң иде икән мине...— Садри елый ук башлады, сиздермәскә теләгәндәй, кулы аркасы белән генә күзләрен сөртештереп алды.— Сез нәрсә дисәгез... шулай булачак... «Бүтән эш тәкъдим итә алмыйм... бигайбә!» — диде Маннур. Сез генә алып калсагыз алып кала аласыз...

Хәдичә тетрәнеп куйды. Хәтта Садрины кызгану хисе туды аның күңелендә. Кайчандыр элеватор янында аны Вазих сугып еккан булуына кадәр искә төшеп узды. Хәдичә гомер-гомергә төчеләнә белмәде, күңелендә нәрсә булса, телендә дә шул иде. Әмма хәзер әллә нәрсә булды, күңеле кинәт кенә йомшап китте. Жан җәфасы, кылган хатасы өчен тагын да ныграк үкенү-әрнү дулкыны ярсып алды.

— Син үзең мине кичер, Садри...— диде Хәдичә, булдыра алган кадәрле ягымлы булырга тырышып.— Әллә нәрсә булды шунда... Нервылар беткән... Миңа бит, Садри, акча жәл түгел иде. Әйбәт кенә килеп сорасаң, мин сиңа болай да биреп тора ала идем бит...

Сүзгә кушылмыйча утырган карт:

— Ә теге язулар?..— дип ычкындырып куйды.

Садри, исенә бик әһәмиятле нәрсә төшергәндәй, җәһәт кенә кесәсенә тыгылып, йомарланган кәгазь кисәкләре чыгарды.

— Менә, алар... Язарга кушканнар иде. Котырттылар...

Шапырай картның теле бу юлы да авызына сыймады:

— Куштылар, котырттылар, имеш! Өс-өс дигән саен котырырга этме әллә син? Вәт мать якасына! Ачуың бер килмәгәе, кеше ни әйтмәс. Кеше үгете үт сытар дигән борынгылар.

Садри кулындагы кәгазьләрне вак кисәкләргә теткәләп ертты да, кая куярга белмичә бераз аптырап торганнан соң, мич алдына илтеп ташлады.

Соңгы сүзне дә Шапырай карт әйтте.

— Чүштеки, син ул кадәрле үк өметсез түгелсең икән әле... Чыкмаган җанда өмет бар дигәндәй, белмәссең, бәлки әле кеше булып та китәрсең...

*
* *

Кеше тормышында еш кына булгалый торган истәлекле зур вакыйгалар, гадәттән тыш хәлләр, күпмедер вакыт үткәч, яңадан кабатланган сыман булып тоела башлый. Мондый халәт, гадәттә, күпне күргән, озын гомер кичергән кешеләр белән булгалый.

Район үзәгенә килеп төшеп, Кенәлегә бара торган олы юлга чыккач, Вәли дә шундыйрак тойгы кичерде. Әйе, моннан егерме ел чамасы элек аңар инде бу юлдан бер түгел, уннарча һәм уннарча тапкырлар үтәргә туры килгәләгән иде. Уйлый калсаң, хәйран булырлык. Егерме елга якын вакыт үтеп тә киткән. Егерме ел! Аңлы-айнык кеше гомереңең яртысы дигән сүз бит бу.

Бу якларга беренче тапкыр аяк басканда да, нәкъ менә хәзерге кебек, көз көне иде. Тирә-якта изрәгән балчык, дымланудан черегән әрем, башка төрле үләннәр исе аңкып тора. Аерма тик шунда, ул вакытта аны озын гомер көтә, яшьлеге дә мәңгелек булыр сыман тоелә иде.

Ул вакытта да Вәли: нинди әк авыл икән? Нинди әк укытучылар коллективына туры килермен икән? Һәм, ниһаять, нинди әк балалар белән эш итәрмен икән? дип хафалану катыш борчылып юлга чыккан иде.

Менә ул яңадан юлда. Шул ук Кенәле юлында. Хәзер дә ул үзен сәер-шомлы тынлыкка чумган кара урман авызына килеп туктаган ялгыз мөсафир сыман хис итте, каушап-югалып калды. Аяклары атламас булды. Юлга чыгар алдыннан гына: шунда калган яшьлек эзләре буенча хыялга бирелеп бер йөрисе иде, күңелләре тулыланып, хыялмаксатлары бөтенәеп китмәсме дип, юкка гына батырайган икән.

Район үзәге урамыннан чыгып, карт тирәкләр шаулап утырган зират турысына җиткәч, Вәли юлдан читкә борылды. Ике ташка эскәмия сыман итеп аркылы куйган такта өстенә килеп утырды. Бу урынны машина-фәлән көтеп торучы юлчылар ясап куйган булсалар кирәк, аяк асты кара җиргә әверелгән, тирә-як тәмәке төпчекләре, көнбагыш кабыклары белән тулы.

Вәли, төрелгән плащын чемоданы өстенә аркылы куеп, аякларын язырга теләгәндәй сузып җибәрде, аркасын зират коймасына терәде. Һәм кинәт... бу якларга кабат кайтып төшүенә чынлап торып үкенә башлады. Әйе, үкенерлеге дә бар иде шул. Егерме ел буена ачыну, әрнү-уфтануларга бәйле истәлекләр яңа көч белән кабат күңел түрендә калыктылар... Хәер, ул истәлекләр болай да гомер буена онытылмыйча, үзәкләрне меңгә телгәләп, һаман искә төшеп тордылар. Бу минутта Вәли үзен иң якын кешесенә карата этлек эшләгән, юк, этлек кенә дә түгел, ә чын мәгънәсендә җинаять, хыянәт эшләгән кеше сыман хис итә башлады. Бермәлгә бу халәт аның бөтен барлыгын яулап алды. Һай-й, бу тиле яшьлек! Алды-арты уйланмаган шул. Һәм аны яңа көч белән өермәдәй бөтәрләп алган уйлары моннан әллә кайчан булып узган вакыйгаларга илтеп тоташтырды...

Ул чакта Вәли дөньяны буйсындырырлык көче-дәрте ташып торган егерме ике яшьлек егет иде. Кенәледә аны көткәннән дә әйбәтрәк каршыладылар. Менә дигән фатирга урнашты. Ул һәр яктан канәгать, жаны тыныч иде. Сугыштан соңгы авыр еллар булуга да карамастан, ул житмәүчелекнең нәрсә икәнен белмәде. Тигез-таза тормышта яшәүче әти-әнисе, Вәли дип жаннарын бирергә әзер торган туган-тумачалары бар иде аның.

Авыл беренче күрүдә үк ошады. Халкы да һәйбәт. Аларның тырышлыгы булсын, тормышыбыз тагын да алга китсен дип, Жир-анага ябышып ятулары булсын Вәлине чын-чыннан сокландырган иде. Янында гына чишмәнеке кебек саф, мул суы белән дан тоткан, куе әрәмәлекләр каплаган ярлары, күз күреме житмәслек киң болынлыклары белән жырларда назлап жырланган гүзәл Кенәлекәй елгасы жәйрәп ята...

Кенәлекәй буе яшел сазлык,
Сазлыгында үсә андызлык.
Сагынмамын диеп киткән идем,
Сагындыра икән ялгызлык...

Шунда ук ярларын камыш-төнбоеклар, бөдрә таллыклар каплаган күлләр... Хозурланып туя алмассың инде менә!

Вәлине тагын бер нәрсә гажәпләндерде: авылда яшьләр күп иде. Әллә ни шәптән булмаса да, клубы бар. Кич життеме, яшь-жилбәзәк шунда жыелып төрле уеннар оештыралар, бәйрәм-фәләнгә дип концерт программалары хәзерлиләр, спектакльләр куялар. Андый эшләрне гадәттәгечә укытучылар башлап йөри.

Менә шунда күрде дә инде Вәли унжиде яшьлек авыл гүзәле Хәдичәне. Күрде дә хәйран булды. Килешле зифа буй-сынлы, ак чырайлы, артка шуышып төшкән шәле астыннан сыпылган алтын-саргылт чәчләре. Зур зәңгәр күзләреннән, йөзеннән ниндидер нур, мөлаемлек сибелә сыман. Коеп куйган төз борын. Ияге чак кына алга төртебрәк торган төсле. Әмма бу — кызның матурлыгын бары тик тулыландыра гына иде. Юк, кыз бите-төсе, буе-сыны белән генә түгел, тагын бик күп яклары белән дә башка кызлардан аерылып тора. Беренче күрүдә үк ул аңа күгәрченнәр арасына ялгышлык белән килеп кушылган акчарлак сыман булып тоелды. Аның һәрбер хәрәкәтеннән тыйнак әдәплелек, ниндидер садәлек бөркелеп тора иде. Шул чак: әллә шәһәр тирәсеннән кайттымы икән? дигән уй да туып куйган иде Вәлинең башында. Әмма кызның клубка чыгып та, өстендә нибары эшкә кия торган сырма гына икәнлеген күргәч, ул бу уйдан кире кайтырга мәжбүр булды.

Вәли ул кичне кызны күздән яздырмады. Үзе өчен бик тә, бик тә кирәкле, кадерле кешесен югалтудан курыккандай, яшьләр арасыннан ерып үтеп, ишеккә таба, бер төркем дус кызлары белән торган Хәдичә ягына таба юнәлде.

— Гафу итегез,— диде ул, кыз каршысына барып басып.— Минем сезне кайдадыр... кайчандыр күргәнем бар кебек...

Вәли алдаламады. Бая кызны беренче тапкыр күргәч тә туган иде ул уй.

Билгеле, шулай искәрмәстән генә әрсезләнеп сүз катуының бераз иртәрәк, иртәрәк булуыннан да бигрәк, хәзерлексез булуын егет үзе үк сизенгән иде. Тик, нишләмәк кирәк, әйткән сүз — аткан ук, ди бит, кире кайтарып алып булмый.

Кыз башта сәерсенеп: танышыр өчен берәр яңарак, акыллырак нәрсә уйлап таба алмадыгызмы? дигән кебек, чак кына житдиләнгән булды. Әмма озакка түгел, шунда ук ирен кырыйлары белән генә нурланып елмайды да: «Белмим шул... бәлки ялгышасыздыр»,— дип жавап кайтарды.

Тавышы да нәкъ үзе кебек үк мөлаем, күңелгә ятышлы иде аның. Күр инде, ә! Шундый гап-гади гына сүзне дә шулай матур итеп, йөрәккә үтеп керерлек итеп әйтеп булыр икән. «Белмим шул... бәлки ялгышасыздыр...» «О-о, күктән иңгән фәрештәкәй, ялгышаммы соң!..» дип уйлап куйды Вәли. Кызның әйтү рәвешенә, тавышына, күзләре белән генә елмаюына караганда, бу сүзләр, ничектер, үз итеп, хәтта чак кына иркәләп тә әйткән кебек булып яңгырадылар. Хәер, Вәлигә генә шулай тоелуы да бар иде. Әмма, ул уйлаганча иркәләп үк әйтмәсә дә, кыз дорфа кыланмады. «Бәйләнмәгезче, зинһар!..» дип кырт киссә дә, берни дә эшли алмас идең.

Хәер, алай дорфа-тупас кылану да бик үк килешеп бетмәс иде. Вәли бит Казаннан, югары уку йортыннан кайткан яшь укытучы. Ә укытучылар, билгеле, абруйлы, иң ихтирам ителә торган кешеләрдән саналалар. Барыбер кайчан да булса бер танышырга, сөйләшергә туры киләчәген кыз үзе дә яхшы белә иде.

Вәли кызның тагын үзенчәлекле бер ягын күреп өлгерде. Кыз чак кына уңайсызланса яки оялса, шунда ук йөзенә мул булып алсулык бәреп чыга. Мондый халәт, гадәттә, пакь йөрәкле, тотнаклы, әдәпле хатын-кызларга хас. Егет кызны якыннан күргәч тәмам әсәрләнде, сүзен дәвам итә алмаслык бер хәлгә килде. Хәдичәнең нечкә, кыйгач кашлары астыннан, күз төпләренә кулэгәләр яткырып торган озын керфекләре арасыннан, дөньяның бар зәңгәрлеген үзенә җыйган сыман, күкбаш чәчәгенә охшашлы күзләре җемелдиләр. Бу күзләр кирәк чагында иркәләп-назлап та, шулай ук шактый кырыс, зәһәр итеп өздереп тә карый белә торганнардыр...

Бернәрсә белән дә санашмады Вәли, шул ук кичне авыл гүзәлен озата да барды. Әмма кызның нибары үзләре яшәгән тыкрык башына кадәр генә озаттыруы аны бераз сәерсендерде. Моның сәбәбен Вәли бары тик соңыннан гына белде...

Билгеле, сылу Хәдичә дип авылда җан атып, авыз суларын корытып йөргән егетләр дә булмаган түгел, булгандыр. Әмма Вәли юлына аркылы төшеп, тавыш-гауга чыгарып йөрүчеләр табылмады. Укытучы егетнең барыбер кызны үзеннән арттырмас дигән фикер белән килешкәннәрдер бәлки.

Алар очраша башладылар. Һәм Вәлинең ике айлык практикасы уяулы-саташулы татлы төш сыман үтте дә китте.

Саубуллашу көннәре җиткәндә инде егет белән кыз гашыйк булып кына калмыйча, бер-берсеннән башка яши алмау дәрәҗәсенә җиткәннәр иде.

Вәли Казанга китеп барды. Менә шунда ул Хәдичәдән башка яши алмаячагына төшенгәндәй булды. Көн дә сагыну-сагыш белән тулы хатлар язды. Кыздан да «бер күрергә зар һәм интизар» дип җырлар белән чуарланган хатлар килеп тордылар.

Мәхәббәтеннән һәм бәхетеннән тәмам исергән Вәли үзенең тиздән башлы-күзле булырга җыенуы турында әти-әнисенә дә хәбәр итте. «Улым, без, әлбәттә, синең өйләнүеңә каршы булмабыз. Әмма тормыш иптәше сайлау ул кием-салым алу гына түгел, берүк җиде тапкыр үлчәп, уйлап эш итә күр, соңыннан үкенерлек тә, шулай ук кеше баласының күз яшен коярлык та булмасын» дигән җавап алды. Әмма шунда ук: «Хәзердән үк семьяга уралырсың микәнни?» дип, чак кына уфтангандай итеп әйтелгән сүзләр дә бар иде.

Вәли әти-әнисенең «өйлән» дип атлыгып тормауларына әллә ни игътибар итмәде. «Картлар ризалар» дип, Хәдичәне Казанга кунакка чакырып телеграмма сукты.

Хәдичә килде. Мәхәббәтләреннән тәмам иләс-миләсләнгән яшьләр шунда кавыштылар. Авылга кайтып никахны законлаштырдылар. Шулай итеп, алар ир белән хатын булдылар...

Бераздан диплом яклау һәм имтиханнар бирү дигән мәшәкатьләр дә узды. Вәли башта Свердловск өлкәсендә яшәүче әти-әнисе янына кайтып, шактый гына торып килде. Һәм, ниһаять, аның: «фәлән-фәлән көнне каршы ал, авылдан китәргә хәзерлән» дигән телеграммасы килеп төште.

Әле дә булса хәтерендә Вәлинең, көз ифрат дәрәҗәдә явым-төшемле иде. Басуларда урылып, егып салынган игеннәр җирдән йолкып ала алмаслык булып яшелләнеп үрделәр. Халыкның: кадерләп, тир түгеп үстергән игенкәйләребез шулай харап булыр микәнни? дип ут йоткан ел иде ул.

Менә шундый көзге көннәрнең берендә Вәли поездддан төште. Берничә тәүлек рәттән койган яңгыр туктарга һич уйламыйча сибәләпмесибәли. Бу хәлне күреп, Вәли «каршы ал» дип телеграмма сугуына хәтта үкенеп тә куйган иде. Аның белән бергә поездддан төшеп калган пассажирлар, җил тузгыткандай, кайсы кая таралышып та бетте. Су күлдәмәләре җәелгән перронда ул гына берүзе басып калды. Як-ягына каранталады, ник бер генә җан иясе күренсенче. Хәдичәсе юк иде...

Искәрмәстән генә нәрсәдер буласын сизенгәндәй, Вәлинең күңелен газаплы тынгысызлык биләп алды. Берьюлы мең төрле уй туды башында. Әллә чирләдеме икән? Авырлы көе җәяүләп юлга чыгып, берәр җирдә егылып кала күрмәсен тагын. Һәрхәлдә, тикмәгә генә, бөтенләй сәбәпсез килмичә калмас. Бәлки әшеннән җибәрмәгәннәрдер? Андый хәлләр дә булгалый бит...

Машина-фәлән очрата алуына тәмам өметен җуеп, Вәли олы юлга чыкты. Таш җәелгән, ярым җимерелгән юл. Кая карама шунда болганчык күлдәмәләр дә яңгыр сулары ярган ерганаклар.

Караңгы төшеп килә. Унҗиде километр араны җәяүләп үтәсе бар. Авыр, салмак болытлар, барлык нәрсәне җиргә иңдерергә теләгәндәй, түбәнләп кенә, җир өстенә елышып ук диярлек агылалар да агылалар. Ә яңгыр бер көйгә сибәли дә сибәли. Көзге ачы җил юешләнеп тәмам эштән чыккан киемнәр аша үзәкләргә үтеп керә. Вәли, чемоданын бер кулыннан икенчесенә күчергәләп, җил-җил атлавын белде.

Берсеннән-берсе шомлырак, шөбһәлерәк уйлар белән уралып унҗиде километр араны йөгереп диярлек үтүен сизми дә калды ул. Авыл өстендә инде күптән төн хакимлек итә. Күп кенә өйләрдә утларны да сүндерергә өлгергәннәр. Вәли тездән пычрак ерып урам буйлап бара. Менә, ниһаять, тыкрык башы... Менә алачык сыман өй. Вәлинең йөрәге күкрәктән атылып чыгардай булып тибә. Җил капка ачык. Вәли ишегалдына керде. Шул вакыт ул яктылыгын көмеш сукмак итеп юлына аркылы салган ян тәрәзәгә күз төшерде... Кинәт әллә нәрсә булды үзендә. Күз аллары караңгыланып, башлары әйләнеп китте. Тәрәзә буендагы нигез казыгына тотынырга мәҗбүр булды...

Тәрәзә каршында ук аның Хәдичәсе утыра. Нииндидер чиксез зур куаныч кичергән кеше сыман, рәхәтләнеп көлә-елмая. Кулында рюмка. Бер ягында алтын погонлы яшь кенә офицер, икенче ягында янә яшь кенә егет. Икесе дә күзләрен майландырып, кулларындагы рюмкаларын Хәдичәгә таба сузганнар. Гөрләшеп көлешкән, шаулашып сөйләшкән тавышлары аермачык ишетелеп тора. Нәкъ шул вакыт яшьләр утырган табын янында Васфикамал түти дә күренде. Ул берьюлы ике тәлинкә белән төрле ризыклар китерде. Ул да, куанычы эченә сыймаган кеше кебек, көлә-елмая, шунда ук егетләргә шаярып бармак янап алырга да өлгерә.

Вәлинең күзләре Хәдичәдә. Шаян холыклы, үткен-чая табигатьле, көр тавышлы, гомергә күңелгә кереп урнашып кала торган сөйкемле, искитмәле сылу Хәдичәсе каршысында гына утыра лабаса!.. Әнә, көлмәгәндә дә күзләреннән шатлык нурлары атылырга, алсу иреннәреннән елмаю түгелергә тора...

Вэли баскан җирендә шулай өнсез булып катып калды. Йөрәге ярсый, йөрәге өзгәләнә. Чигә тамырларының сулкылдап тибүен үзе ук аермачык ишетеп тора. Үләр чиккә җитеп көнләшү галәмәте иде бу. Үз гомерендә беренче тапкыр буларак татый иде ул яман да шыксыз бу хисне.

Эх-х, Хәдичә! дип өзгәләнде Вәли. Шушы булдымы мине көтеп алуларың? Кайда синең биргән вәгъдәләрең? Димәк, мине яратуың шул чаклы гына булган. Кемдер мәхәббәтне аерым торып, вакыт дигән мәрхәмәтсез нәрсә белән сынап карарга кушкан. Вакыт, нәкъ кискен искән җил кебек, пыскып, шәм кебек кенә булып янган зәгыйфь, көч-сез-куәтсез утны шунда ук сүндерә, юк итә. Ә инде сыналган чын хисне, олы тойгыларны, киресенчә, дөрләп янган ялкынга, хәтәр көчкә әверелдерә, имеш.

Шунда, тәрәзә каршында торган минутларында, йөрәгенең сызып сулкылдавына тәкатьләр тотар хәле калмады Вәлинең. Тәгәрәпләр генә үләсеңмени! Ул хәтта Васфикамал карчыкны да эченнән тиргәп, әрнү катыш каргап алды. Күр инде син аны, ә! Димәк, аның: «Һай-й, кияү!.. Ходай тәгалә кушып, менә нәниегез генә тусын, кулыгызга да тидермәс идем, үзем багар идем. Бигрәк тә якын күрәм үзеңне», дигән сүзләре чеп-чи ялган булган икән.

Вәли үз-үзен белешмәс хәлдә иде. Гүя аның тормышының асты-өскә килгән, чәнчелеп киткән, бер генә яме дә калмаган. Шул чак нинди-дер көч аның күкрәгенә бәреп, тәрәзә каршыннан чөелдереп җибәрде. Һәм ул ничек очынып, ярсып атлыгып килгән булса, нәкъ шулай ук җил-җил атлап, ишегалдыннан кире станциягә таба китеп тә барды. Бу минутта гарьләнү хисе аның акылын томалаган иде шул. Хыял күгендә, күңел түрендә назлап йөрткән, бөтен киләчәгеңне, бөтен барлыгыңны бәйләп йөрткән кешең шулай итсен әле!

Зәһәр җил белән аралашып яуган салкын яңгыр һаман коя да коя. Шулай итеп, барлык хыял-өметләрем чәлпәрәмә килде микәнни? дип өзгәләнде Вәли. Йөрәге сызуына һәм әрнүенә чыдар чамасы юк. Кинәт башы катып китте, эзлекле фикер йөртә алмавына гаҗиз булды. Андый да шыксыз, андый да җан кайтаргыч бүтән көнне үз гомерендә татыганын хәтерләми иде Вәли. Дөнья бушап, үзе нәүмизләнеп калган кебек булып тоелды. Кайда, кайда сез, тәнгә сихәт, җанга рәхәт бирә торган изге уй-хыяллар, ләззәтле тойгылар?!.

Тоташтан кара уйлар эчендә янып, тирләп-пешеп, вакыты белән дер-дер калтырап атлый-йөгерә торгач, станциягә килеп тә җиткән. Казан ягына барасы поездга билет алды. Аннары бары тик зәһәр җилләр генә хакимлек иткән буш перронда әрле-бирле йөренә башлады. Ниһаять, прожекторлары белән күзгә төн караңгылыгын ярып, юеш рельсларның көмеш җепсәләрен ялтыратып, поезд да килеп җитте. Вәли вагон янына йөгереп килсә дә, баскычка күтәрелә алмады. Шул чак аңа нинди-дер, гомер буена үкенерлек, уфтанырлык ялгыш адым ясый сыман булып тоелды. Берьюлы берничә төрле уй-фикер аның миен көйдереп узды. Кем белә, бәлки Хәдичәнең гаебе дә юктыр. Чыннан да, кемнәрнеңдер кереп утыруыннан ни булган, ди. Бәлки алар, Вәлинең кайту хәбәрен ишетеп, аны үз итеп, дус итеп тәбрикләргә кергәннәрдер. Шунда ук икенче бер сорау башын калкытып куйды. Ә ни өчен Хәдичә аны каршы алмады? Җавап та әзер: бәлки Хәдичә аның телеграммасын да ала алмагандыр. Авыл җирен белмәссең.

Шулай икеләнеп, үз-үзенә сорау артыннан сорау биреп, шунда ук җавабын да кайтарып, ике ут эчендә торган арада поезд китеп тә барды. Вәли шулай мең төрле уйларга бирелеп перрон тирәсендә болганды-тулганды да, кичекмәстән, бүген үк, хәзер үк Хәдичә белән аңлашырга кирәк дигән катгый карарга килеп, яңадан йөгерә-чаба Кенәле авылына чыкты. Үзе дер-дер калтырый, теше-тешкә тими. Үзе

һаман: башка берни дә түгел, Хәдичә телеграмманы алмагандыр, югыйсә, каршыламас идеме соң?! дигән уй белән юангандай итә. Яшерен-батырын түгел, авылга да нәкъ менә шул мәсьәләне ачыкларга дип кире борылды бит ул.

Кабат авылга барып кергәндә әтәчләр яңа көн тууы турында хәбәр сала башлаганнар иде инде. Ә яңгыр өзлексез коепмы-коя. Таң атуын шәйләве дә кыен.

Бәхеткә каршы, почта таратучы Камәр апаның өе авылны кергәч тә иде. Вәли аны яхшы белә. Еш кына Камәр аны очратып: «Вәли апаем, тиз бул, сиңа хат!» — дип, әллә каян күреп чакырып ала торган иде. Менә ул йорт. Тәрәзәләрдә ут. Вәли капка келәсен әллә ни шалтыратмаска тырышып, ишегалдына керде. Өй алды болдырына кадәр җәелгән таш басма буйлап ян тәрәзә янына килде, шуңа бер-ике чиертте. Камәр апа үзе чыкты. Вәлинең нинди йомыш белән йөргәнен белгәч, тезә дә башлады. «И-и, апаем,— диде ул чак кына каушап калуын яшерергә теләгәндәй.— Телеграмманы алган көнне үк җылы кулдан тапшырдым. Хәдичәнең үзенә тоттырдым. Әгәренки ышанмасагыз, почта ачылу белән, рәхим итегез, имзасын да күрсәтә алам. Телеграмманы алгач ничек куануларын күрсәң иде икән!..» Вәли: «Ничек куанганын кичә кич тәрәзә аша үз күзләрем белән күреп тордым», дип әйтмәкче иде дә тыелып калды. Ул бүтән сүз куертып тормады. Таң аткалаганчы, кеше-фәлән күргәләгәнче дип, Хәдичәләр өенә таба китеп барды. Берсеннән-берсе шыксызрак уйлар өермәсе яңадан йөрәк итен кимерә башлады. Бу минутта ул Хәдичәне туйга хәтле, язылышканчы ук хатыны булырга ризалык биргәненә кадәр гаепли иде. «Андыйдан җан нинди игелек күрмәк кирәк...»

Менә яңадан Хәдичәләр өе. Тәрәзәләрендә ут күренми. Шул вакыт «Бәлки әле берәрсе куна да калгандыр...» дигән яман уй туып, кабат җанын көйдереп алды Вәлинең. Туп-туры ишеккә юнәлде. Һәм, киләкилешли үк, йодрыгы белән бер-ике тапкыр каты итеп сугып алды. Бер мизгел үттеме икән, Хәдичәнең: «Кем ул?» дигән тавышы ишетелде. «Мин...» — диде Вәли. Гаҗәп, үз тавышын үзе танымады ул. Аның каравы, Хәдичә таныды, шунда ук күгәрчен кебек гөрли-гөрли ишекне ачып та җибәрде. «Вәли, җаным!.. Ни булды?.. Ник болай соңардың?..»

Шунда Вәли күңеле кушмаган, ихтыярына каршы килә торган эш эшләде. Юк, сукмады да, сүкмәде дә, әшәке сүзләр дә әйтмәде. Бары тик эчке күлмәкчән генә чыгып, муенына килеп сарылган Хәдичәне, «Кит янымнан!..» дип, шактый тупас рәвештә этәреп җибәрде. Бер ни дә аңламаган, тәмам аптырашта калган Хәдичә: «Нәрсә булды, Вәли?..» — дип хафаланып сорап куйды. «Мин дә синнән нәкъ шул турыда сорамакчы идем»,— диде Вәли. Аннары инде яман да авыр, яман да шыксыз сүзләрне тезде дә тезде. «Рәхмәт сиңа, булдырдың... Шулай каршылавың өчен бер түгел, мең рәхмәт... Хәер, алтын погонлы нәзакәтле офицерлар, тәти егетләр барында Вәли нигә ди. Әйдә, типтерегез... мин комачауламам...»

Ул арада торып өйдә ут кабызган Васфикамал әби дә ишектә күренде. Вәлинең соңгы сүзләрен ул да ишетеп калган булса кирәк. «Һай-й, кияү балакай!..— диде ул үз чиратында.— Зинһар гөнаһлы була күрмә. Безгә бер генә чит-ят кешенең дә аяк басканы булмады. Берсе орынып торган күршебез, хәрендәш тиешле кешебез Мәфтуханың кече улы Заһит. Өченче көн генә кайтты... Бер атнага дип кенә җибәргәннәр. Икенчесе, камсамул дисезме әле, шуның башлыгы... Сине күрергә дип, Хәдичәне озату турында сөйләшергә дип кергәннәр...»

Әмма Вәли кеше сүзен тыңларлык та, аңларлык та хәлттә түгел иде. «Акланмагыз, зинһар...» дип, бер җикеренеп алды да: «Ярар,

хушыгыз! Бәхетле булыгыз!..» диеп җәһәт кенә борылып ачык калган ишектән чыгып та китте.

Җилкәсенә шәл кисәге салып өлгергән Хәдичә аны капка артында куып тотты. Аягына да киеп өлгермәгән иде ул. «Тукта әле, Вәли, җаным!.. Нишләвең бу?..— дип өзгәләнде ул.— Һич югында, аңлашыйк... Болай булмый бит инде. Әйтче, зинһар, нәрсә булды?.. Әллә берәр җүнсез яманатымны саттымы? Кеше сүзе кеше үтерер, ди бит...» Вәли янә күтәрелеп бәрелде. «Син нәрсә?.. Җыен тузга язмаган гайбәт җыеп йөрергә... мине яулык бәйләгән дип уйладыңмы әллә?.. Кәеф-сафа кылып утыруыгызны үз күзем белән күрдем... Менә шул!..» Бу сүзләрне ишеткәч, бичара Хәдичә: менә хәзер барысы да ачыкланды дигәндәй куанып, янә күгәрчен кебек гөрли башлады. «И-и, Вәли!.. Тилем минем... Җаным-бәгырем минем!.. Көлдермә, ичмасам. Алтын погонлы булса да, борын асты кипмәгән малай гына ич ул. Ә комсорг Гарифны: «Хәдичәнең колхозыбызга файдасы күп тиде, тиешенчә озату чарасын да күрергә кирәк»,— дип яшьләр җибәргәннәр. Озату кичәсе сыман нәрсә оештырырга телиләр, ахры.— Аннары, хата гына түгел, гафу ителмәслек җинаять эшләгән кеше сыман, дәвам итте:— Бу сүзләрне акланыр өчен әйтә дип уйлый күрмә, Вәли җаным! Гаепле мин... Бик, бик нык гаепле. Хәзер барысын да аңладым... Яңгыр түгел, таш яуса да мин сине каршы алырга тиеш идем. Тиеш идем... Гаеплемен, җаным! Җәяүләп чыгып китәргә эни ризалык бирмәде. «Йөкле көе барып-кайтуы кырык чакрымга җыелган юлга чыгып китеп, харап булырга телисеңме әллә?» диде. Ә ат булмады... Сорап бер түгел, ике төштем идарәгә. Әмма Борһан абыйның үзен күрү белән йомышымны йомышлаудан баш тарттым. Бик ачулы, ярсыган чагы иде. Аны аңлавы кыен түгел иде. Басуларда иген череп харап була... Аннары инде, һич югында, авыл башына чыгып каршы алыйм дип, киенә генә башлаган идем, Гариф белән Заһит килеп керделәр. Өлешчә алар да гаепле... «Мондый көндә каршы алам дип йөрмә. Вәли үпкәләмәс... Сөйләшүне үз өстебезгә алабыз», дип телләренә салынган булып, юлыма аркылы төштеләр. Кунаклар кергәч эни чәй куйды. Бер шешә вино да ачтылар...»

Вәли, күңеле белән Хәдичәсен күптән кичерсә дә, теле белән башка сүзләрне такылдады. «Ярар, хуш... Сау бул! Оныта алсаң, оныт мине. Бәхетле бул!..» дигән булды ул кабат китә башлап. Хәдичә янадан аның җиңенә килеп ябышты. «Тукта, Вәли!.. Нишләвең бу?.. Тукта!..— Үзе дер-дер калтырый иде Хәдичә. Тавышына кадәр чатнап, дереләп чыга иде аның.— Сабыр ит... Тыңла! Әгәр дә мине ташларга телисең икән, анысы синең ихтыярда. Тик бел, синең алда катрә бөртеге кадәр дә гаебем юк минем. Намусым пакь, вөҗданым саф минем...» Хәдичәнең шулай түбәнсенүен күрү Вәлинең күңеленә хуш килде булса кирәк. Ни әйтсән дә, эт йөрмәслек төндә әле анда, әле монда сугылып, тездән тиң пычрак ерып йөрүенең үчен алды бит. Юк, моның белән генә дә чикләнмәде Вәли. Шунда ул сүз түгел, ук та тишеп үтә алмаслык калкан кигән кеше сыман кыланды. Хәдичә ябышып-таянып торган кулын йолкып алды да яңадан тыкрык башына таба китә башлады. Бу минутта ул Хәдичә барыбер аны туктатыр, кабат ялынып-ялварыр дип уйлады. Хәдичәнең яңадан дәшүен өмет итеп булса кирәк, олы урамга чыгып җитәр алдыннан ул яңадан артына борылып карады. Хәдичә якты шәүлә булып һаман да әле читән буенда тора иде.

Менә шунда Вәли үз гомерендә беренче тапкыр кеше әйтеп кеше ышанмаслык тинтәклек, вак җанлылык, тар күңеллелек күрсәтте. Ә бит егет кешенең күңеленә җигүле ат та сыярга тиеш дигән халык. Вәлинең этисе дә: егет була алмаган — ир була алмас, ир була алмаган — кеше була алмас, ди торган иде. Дөрес әйтелгән. Нәкъ Вәлигә атап, аның кебекләргә карата әйтелгән сүзләр иде, күрәсең, алар.

Вәли Хәдичәне ташлау белән генә дә чикләнмәде бит, намусын җуйган, вак җанлы вөҗдансызларга гына хас гадәтне: төрлечә эзәрлекләүне, кеше тормышын агулауны максат итеп куйды. Шул ук районга направление алып райүзәктә укытучы булып урнашты. Хәдичәнең мең төрле авырлыкларга, кыенлыкларга, җәбер-кыерсытуларга кайчан да булса бер дучар буласы көн кебек ачык иде. Авыр еллар. Белеме чамалы. Әни карчыгы да бетешкән. Йорт-җирләре коелып төшәргә тора. Ялгыз калды. Шуның өстенә бала көтә. Ә ир ташлаганны мир ташлар ди. Куллар булып куллар да чиста, пакь булу өчен бер-берсенә мохтаҗлар ич.

Күп тә үтмәде, Хәдичәне бәла-казалар эзәрлекли дә башладылар. Иң элек эшендә чатаклыклар чыкты: фермада ниндидер чирдән дуңгыз балалары кырылды. Аннан гына котылган иде, үзе авырып больницага керде. Яңа ел алдыннан исә Хәдичәнең кыз бала табуы турында хәбәр килеп җитте Вәлигә. Менә хәзер баш ияр, тез чүгәр дип уйлады Вәли. Бала белән кая барсын ди, кемгә кирәк ул?.. Больницадан чыгышлый ук күтәренеп килеп керер әле... Әмма Хәдичә кермәде. Ну-у, тәкәббер кыз, барыбер бөгелерсең, дөнья бу! дип күңеле белән әрепләшеп, янап яшәде Вәли.

Бер килсә килә бит ул: табигатьнең иң матур бер чагында Васфикамал түти дөнья куйды. Хатыны өстенә төшкән бу бәхетсезлекне дә үз файдасына юрады Вәли: менә хәзер әллә ни тыпырчына алмас, килеп тез чүгәр, һич тә булмаса, алимент сорар дип уйлады ул. Юк, Хәдичә бу юлы да баш имәде. Судка чакыручы да булмады Вәлине. Алай гына да түгел, Хәдичәнең нәкъ ул теләгәнчә итеп баланы «Вәлидә» дип атаганлыгы турында ишетте. Бу хәл аны тәмам чыгырыннан чыгарды. Шул вакыт Вәли иң соңгы чараны кулланырга — Хәдичәдән баланы алырга кирәк дигән карарга килде. Иң элек судья янына кереп консультация алды. Аннары, Хәдичә тирәсендә йөргән җыен тузга язмаган гайбәтләрне чәчми-түкми туплап, берсен биш итеп күпертеп һәйбәтләп теркәп, гариза язып тапшырды. Бары тик шуннан соң гына, РОНО машинасына утырып, Кенәлегә чыгып китте. Мәфтуха түтиләрнең капка төбенә килеп туктау белән, өзгәләнеп бала елаган тавышны ишетеп алды Вәли. Өйгә атылып керде. Бер әрҗә сыман нәрсәдә пычрак аяклары белән тыпырчынып, тешсез авызларын ачып, сыны катар дәрәҗәгә җитешеп елап яткан баласын күрде ул. Гүя бала: «Нишләдегез сез, юньсезләр?.. Шушы хәлләргә төшерерлек булгач, нигә дип таптыгыз мине?..» дип, бөтен дөньясын каргый иде. Әти кешенең бугазына төер менеп утырып, буа башлады. Күз төпләрен яман әчеттереп, яшьләр бәреп чыкты. «Кичер, кичер... балакай...» дип нарасый өстенә иелеп төште ул. Һәм шунда ук, үз-үзен белешмәгән кеше сыман, баланы кулына алды. Аннан-моннан чүпрәк-чапраклар йолыккалап баланы төрде дә, тәрәзә төбендәге сөтле шешәне кесәсенә тыгып, ишегалдына алып чыкты. Шул вакыт бер көтү тавык-чебиләрен ияртеп лапас астыннан чыгып килүче Мәфтуха түти күренде. «Баланы алай тәрбияләмиләр аны!.. Хәдичәгә әйтерсең, Мәфтуха түти... Кызны мин алам. Законлаштырып алам... Суд аша», дип тузынды Вәли. Мондый шомлы сүзләрдән өне алынган күрше карчыгының кулыннан җим тутырылган коштабагы төшеп китте. Тавык-чебешләр әүмәкләшеп, берсен-берсе тапташып җим чүпли калдылар, ә Вәли машинасы белән китеп барды...

Бу юлы Вәли җиңде. Хәдичәнең тормышы чыннан да пыран-заран килде. Әмма бу җиңү куаныч та, канәгатьләнү хисе дә бирмәде Вәлигә. Судтан соң ук ул үз-үзенә урын таба алмады. Расчет алып районнан ук китеп барды. Әти-әнисе янына кайтып, тормышының бердәнбер шатлыгы, куанычы булып калган Вәлидәне тәрбияләде. Өйләнде. Мәрхүмә Гөлсем, яхшы тормыш иптәше булу белән бергә, менә дигән ана да була белде. Тик Вәли генә үзенең беренче мәхәббәтен — Хәдичәне

оныта алмыйча иза чикте. Хәдичә һәр вакытта да аның күз алдына йөзен әрнүгә охшашлы күләгә сарган булып, я ерып үтә алмаслык күе-кара көзге төндә эчке күлмәкчән генә читән буенда баскан килеш яки тагын да яманы — суд залындагы кыяфәте белән килеп басар иде. Бу күренешләр аңар тынгылык бирмәделәр, егерме ел буена яман чир, күңелгә шом сала торган шыксыз төш кебек һаман да эзәрлекләделәр. Иөрәге шулай урыныннан кузгалган чакларда ул тизрәк икенче бер күренешне күз алдына китерергә тырыша... Ә ул күренешне соңгы сулышына кадәр дә онытасы юк Вәлинең. Яктылык сирпеп торган бәләкәй генә тәрәзә. Шунда ук нигез казыгы. Өйнең салам түбәсенә, бик-бик нечкә иләктән сибелгән кебек, пыскып кына яңгыр коя. Тәрәзә артында, алтын погонлы яшь офицер белән тагын бер сылу егет арасында аның Хәдичәсе утыра... Гәрәбә кебек шәраб салынган рюмка аның йөзе турысына күтәрелгән. Алтын йөгертелгән сыман йомшак ефәк чәчләре бик пөхтә итеп бөтереп артка җыелып куелган. Өстендә, бик күп тапкырлар күргәндәге кебек, челтәр якалы кофтасы. Күзләре күлә үзенең, йөзләреннән нур балкый. Менә генә ул... Ә нитә! Кулыңны гына суз... Еллар үтеп, шактый күп сулар акса да, Вәли ул күренешләрне оныта алмады. Андый-мондый мәҗлесләрдә, тантаналы кичәләрдә, кунакта булганда, кулларына фужер тоткан хатын-кызларны күрү белән, күз алдына Хәдичәсе килеп баса торган булып калды.

Яшьлегендә ясаган хатасы, дөресрәге — җинаяте өчен шулай гомере буе җаны әрнеп, вөҗданы газапланды Вәлинең. Ә бит ул яшьнәп торган яшьлегендә зур максатлар, изге уйлар белән хыялланган иде. Соңга таба иң гаҗәпләндергәне, хәйран иткәне шул булды: җаныңнан артык сөйгән, өзелеп яраткан якын кешеңә карата да этлек эшләп була икән. Эх-х, вакыты белән киң күңеллелек, кешелеклек җитмәүләр суя ла! Чын кеше икәнсең, кеше абынса — иңеңне куй, сөртенә-егыла икән — күтәрелергә ярдәм ит, дип тукыган булабыз. Моралебез шундый. Әмма Вәли алай итә алмады. Начар күпер авыр йөкне күтәрә алмаган кебек, ул да андый адымны ясый алмады, егетлеге җитмәде.

Ә бит Хәдичәнең тормышы бөтенләй башкача корылырга, икенче төрле булырга тиеш иде. Вәлинең әти-әниләре булачак киленнәренең җиде генә класс тәмамлаган кыз икәнлеге турында ишеткәч, улларына хәер-фатиха биргәндә: «Алайса, улым, аның укуын дәвам иттерү чарасын да күрергә кирәк булыр. Укусыз булмый хәзер. Заманы шундый. Безнең өчен борчылмагыз. Кирәксә, үзебезнең сезгә ярдәм кулы сузарлыгыбыз бар», дип калганнар иде.

...Башын артка ташлап, аркасын зират коймасына терәп, байтак вакыт уй иркенә бирелеп утырды Вәли. Аннары, кеше күзенә күренергә курыккан сыман, бары тик караңгы төшә башлагач кына чемоданын алып олы юлга чыкты.

Ә алда, заманында дәртле-ялкынлы хисләр, олы мәхәббәт, зур омтылышлар белән тулы булган яшьлек юлы... Әйе, кайчангыдыр яшьлек юлы...

*

* *

Ярата Маннур менә шулай рульне үзе тотып, «газигы» белән җил уйнатып алга ыргылырга.

Район үзәген артта калдырып асфальт юлга чыккач, тизлекне арттыра төште. Нәкъ шул вакытта зират коймасы яныннан күтәрелгән бер кешенең юлга якынлашып килүен күреп алды ул. Ялгыз юлчының кул күтәреп, утыртуын сорар дип көткән иде. Әмма теге кеше якынлашып килгән машинага игътибар да итмәде, алга-артка, уңга-сулга карамыйча, бер кулына җыйнак кына чемодан тоткан, икенчесенә

плащын салган килеш тигез адымнар белән алга таба атлавын белде. Бу хәл сәерсендерде Маннурны, мөсафир турысына житү белән ул, кинәт тормоз салып, машинасын туктатты.

— Исәнмесез, абзый кеше!

— Саумысез!..

Теге кешенең машина туктавын күреп тә утырырга дип бер дә атлыгып тормавын күргәч, Маннур кабат сорау бирде.

— Кая таба юл тотыш?

— Кенәлегә...

— Алайса, юлдашлар икәнбез.

— Шулаймы?..

— Утырыгыз, әйдә.

— Рәхмәт.

Маннур машина ишеген ачып җибәрде. Бу сәер юлчы гәүдәсе, бөтен йөзе белән аның ягына борылгач кына Маннур төсмерләп алды аны.

— Вәли абый түгелме соң сез?..

Көтелмәгән очрашу юлчыны гаҗәпләндерде булса кирәк, ул кабат рульгә утырган егетнең йөзенә текәлеп карап торды. Бары тик шуннан соң гына:

— Әйе, мин...— диде.

Маннур машинадан атылып ук төште.

— Алайса, күрешик, Вәли абый! Исән-сау гынамы?..

— Рәхмәт.

— Димәк, Кенәлегә?

— Әйе. Бер күрим, дидем...

— Бик һәйбәт, Вәли абый!

Ул арада Вәли үзе сорау бирде:

— Ә менә мин, гафу итәсез, сезне төсмерли алмыйм...

Маннур көлде генә.

— Гаҗәп тә түгел, Вәли абый. Кая инде ул безне хәтерләү?!. Сез дәрес бирергә класска кергәндә, безнең әле качып-посып, урлашып тәмәке көйрәткән малай-шалай чак кына иде.

— Шулайдыр, шулайдыр,— диде Вәли һәм сүлпән генә елмайгандай итте.— Гомер дигәнең сорап тормый икән ул, үтә икән...

— Үтмәгән кая, Вәли абый!

Егетнең шулай үз иткәндәй, якын күргәндәй, һәрбер сүзне җөпләп торуы Вәлигә ошады, хәтта чак кына кыюлык та өстәде.

— Бәлки әти-әниләрегезне белгәнмендер? — дип сорап куйды ул.

— Юктыр, Вәли абый. Әти Сталинград фронтында калды... Әнием гап-гади бер колхозчы иде. Җәмилә апа дип йөртәләр. Гомере буе яшелчәчелектә эшләде. Хәзер инде пенсиядә, оныклар үстерә...

Вәли янә сорау бирде:

— Үзең дә шунда, Кенәледәме?

— Әйе.

— Шунда эшлисеңме?

— Шунда.

— Нинди эштә?

— Председатель мин.

Вәли чын-чынлап гаҗәпләнде һәм гаҗәпләнүен яшермәде дә. Хәйран булган кеше сыман, сузып әйтә салды:

— Ал-лаймыни!..— Шунда ук өстәде.— Үзең болай карап торырга бик яшь күренәсең?

— Дүртенче елым инде,— диде Маннур. Бу сүзләр, ничектер, мактану сыманрак булып яңгырадылар. Моны ул үзе дә сизенде, шуңа чак кына уңайсызланды да. Һәм, акланырга теләгәндәй, сүзне тизрәк икенчегә борды.— Вәли абый, әйдәгез, машинага рәхим итегез! Юлда сөйләшербез... Кая, чемоданыгызны алыйм...

— Борчылмагыз, үзем генә...

— Нинди борчылу ди ул! — Маннур җилтерәтеп алган чемоданны арткы урындыклар янына утыртты.— Ә үзегез минә монда, минем янга...

— Кайда да ярар.

Маннур, алга кайтарылган беренче креслоны турайтып, укытучысына җайлабрак урнашырга ярдәм итте. Аннары үрелеп ишекне япты да машинасын олы юл уртасына чыгарды. Бераздан инде «газик» тигез юлда җил уйнатып, яңадан томырылып элдерә башлады.

Күршесе, бая башлаган сүзне дәвам иткәндәй, икскәрмәстән сорап куйды:

— Председатель дигәннән, Борһан абый ничек соң? Исән-саумы?..

Юлдашының шундый сорау бирәсен Маннур күңеле белән сизенгән иде инде.

— Юк,— диде ул көрсенгән тавыш белән.— Үлгәненә биш-алты ел инде. Йөрәк белән китеп барды. Басудан, буразна арасыннан табып алып кайттык үзен...— Янә тынлык урнашты. Моторның көр гөрелтесе аермачык булып ишетелә башлады. Маннур, сүзне очлап куяргамы, әллә инде ачыклык кертергәме теләгәндәй, дәвам итте:— Соңгы елларда башка эштә иде... Борһан абзый исән чакта да, аннан соң да күп еллар буе колхоз председателе булып Мәдинә апа торды. Бәлки әле белгәнсездер дә. Зимагур Зиннәт Мәдинәсе дип йөртәләр иде үзен... РСФСР Верховный Советы депутаты булып та, район советларына да сайланды...

Юк, Вәли Мәдинәне дә белмәгән икән. Ул, бик җилле кайту сәбәпле, кирәкле, үзен кызыксындырган нәрсәләр турында сорашырга өлгерә алмаудан курыккан сыман, кабат сорау бирде:

— Кызым Вәлидә андамы?.. Авылдамы?

— Бездә! — дип элеп алды Маннур бик тә хәбәрдар кеше кебек итеп.— Вәлидә хәзер бөтенләй авыл кызы булып китте. Кулы эшкә ябышуын әйтәм... Без бит, Вәли абый, бала чактан ук хезмәтне китаплардагы рәсемнәргә карап, фермаларга, иген кырларына экскурсияләргә йөреп кенә өйрәнмәдек, без анда эшләп үстек.

— Әйе!..

— Вәлидә дә шунда кул арасына кереп мәйханә кылә.

— Тик минә укуын дәвам итә алмады.— Вәли ага бу сүзләрен ничектер уфтанган кеше сыманрак, чынлап торып хафаланып әйтте.

Маннур җәһәт аның ягына борылды.

— Нишләп?..— диде ул.— Сезгә хәбәр итмәделәр микәнни? Укырга керде ич ул. Казан культура институты студенткасы ул хәзер. Колхоздан җибәрдек. Яхшы гына стипендия дә билгеләдек үзенә. Чакыру кәгазе дә алган, бүген-иртәгә китәргә тиеш бугай инде...

Бу хәбәр Вәлине куандырдымы, юкмы — сиземләве кыен иде. Шулай да: «Рәхмәт инде сезгә», диде ул.

— Так что, Вәли абый, Вәлидәне Кенәледән җибәрдем юк хәзер. Сер булса да әйтим инде: егете дә бар. Авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты. Үз егетебез...

Вәли бу юлы да дәшмәде. Йөзе җитди иде аның. Кайчан да булса бер шулай япа-ялгыз каласына ул инде әзер иде. Авызына су капкан кебек дәшми баруына уңайсызлангандай, бары тик сүз югында сүз булсын дигән кебек итеп, кабат сорау бирде ул.

— Колхоз зурдыр инде хәзер... Кенәле дә үзгәргәндер?

— Колхоз да зур, Кенәлене дә таный алмассыз, Вәли абый.— Тавышы отыры көчәя барды аның.— Без бит районда иң беренчеләрдән булып авылны генплан белән төзи башладык.

Маннурны баядан бирле берничә төрле сорау борчый: кая барам дип бара икән инде бу бичара? Хәдичәнең тормышка чыгып, менә дигән гаилә корып җибәрүе турында беләме икән, юк микән? Хәзер Хәдичә апаларының бакчалары ягына ачып куелган тәрәзәләреннән, үткән-сүткән кешеләрнең игътибарын җәлеп итеп, катлаулы аккордлар, ялкынлы-ашкынулы гамма авазлары озатып кала. Бая колхоз турында, авыл турында сүз чыккач та Маннур, Хәдичә апасының да суы, газы кертелгән, бөтен шартлары булдырылган яңа йортта тора, дип өстәргә теле бик кычытса да, тыелып калды. Хәдичә турында сүзне Вәли абыйсы үзе башламасмы дип көтә иде ул. Яхшымы, яманмы, ир белән хатын булган кешеләр ич. Әнә, кызлары да бар...

Машина алга чаба. Сүз дә һаман шул колхоз турында, андагы үзгәрешләр, хәл ителәсе эшләр турында бара.

— Әйе, Вәли абый. Эш тә күп, җаваплылык та зур хәзер. Аннары бит вакыт, заман таләбе «җаваплылык» дигән нәрсәнең мәгънәсенә, аның эчтәлегенә бик нык үзгәрешләр кертте. Бүгенге авылда механикалаштыру, автоматлаштыру кебек төшенчәләр янына тагын телемеханика, кибернетика кебек яңалыклар да өстәлергә тора. Фәнни-техник революция, культура-техника революциясе һәр җирдә бара. Шуларның барысын да күр, үзләштер. Ике авыз сүз белән әйтсәк, бүгенге көннең динамикасын тоеп яшәү таләп ителә бүген.— Маннур сизеп тора, янәшәсендә утырган кеше өчен бу сүзләрнең әллә ни кызыгы юк. Әйе, дип уйлап куйды ул, тормыш бу кешегә яңа кайгы-хәсрәтләр биргән, күзгә бәрелеп торырлык билгеләрен салган. Кайчандыр кабарып, дулкынланып торган чәчләре чаларган, йөзен җыерчык баскан. Кыскасы, аның янында шактый ук йончыган ир урталарындагы кеше утыра. Сизелеп тора, күңеле тыныч түгел бу адәмнең, нәрсәдер кимерә, нәрсәдер борчый аны. Ахыр чиктә Маннур түзмәде, күршесенең телен ачарга тырышып, яңадан сорау артыннан сорау яудыра башлады.

— Безнең хәлләр, туган, хәзер бер тирәдәрәк инде. Нәрсә дип әйтергә дә аптыраган...— Чыннан да нәрсә дисен соң ул? Эх-х, егет!.. Башың яшь шул әле синең, барыбер аңламассың. Юктан юаныч, бардан куаныч табып, тыныч кына бер яшәсәң иде икән дип, күңелеңдә булганның барысын да чыгарып салып булмый бит инде.

— Эшегез нинди?

— Эше бар ла аның. Аңа мохтаҗлык юк ул хәзер...

— Һаман да шул укытумы?

— Шул инде.

Авылның мәктәп коллективы, укытучылар турында сүз куертып алдылар. Берме, икеме өлкән яшьтәге укытучыны Вәли дә белә икән. Маннур да, форсаттан файдаланып, авылда өр-яңа, спорт залларына кадәр булдырып, ике-өч катлы итеп таштан мәктәп салдырырга җыенулары турында сөйләп алды. Урыны билгеләнгән, проекты расланган, сметасы төзелгән булуын да өстәп куярга онытмады.

— Әйе,— дип куйды Вәли,— колхозларның мөмкинлекләре зур хәзер.— Аннары, сүзне икенчегә борырга теләп, аның каян кайтып килүе белән кызыксынды.

— Бюродан кайтып килеш,— диде Маннур. Шунда ук елмаеп, көр тавыш белән дәвам итте.— Соң булса да уң булсын дигәндәй, куанып кайтып киләм...

— Шулаймы?

— Кыш көне выговор чәпәгәннәр иде, шуны снимать иттеләр...

Вәли ялт кына аның ягына борылды.

— Нәрсә, андый хәлләр әле дә булгалыймыни?

— Булмаган кая!..— Бу сүзләрне чын күңелдән елмаеп әйтте Маннур.

— Нәрсә өчен «янган» идегез соң?..— Вәли ага үзенең урынсызрак сорау бирүен сизенепме, тизрәк төзәтенде.— Шәхси тормышыгызга бәйле булса, әйтмәсәгез дә ярый.

— Юк, андый мәсьәлә түгел. Кыш көне, сыерларны механикалаштырылган ысул белән савуга күчкәндә, шактый гына мал-туарны эштән чыгарган идек...— Менә тагын Хәдичә апасы турында сүз кузгатырга сәбәп чыкты лабаса! Бу юлы инде, җае туры килгәч, Маннур түзмәде, тәвәккәлләп, аны да кыстырып куйды.— Әле дә ярый, Хәдичә апага рәхмәт. Эшне ул җайга салып җибәрде. Хәдичә апа булмаса шактый чиләнәсе идек...

Маннур күз кырые белән генә күршесенә карап алды. Әмма тегесенең йөзендә һичнинди үзгәреш күрмәде. Бер генә мускулы селкенсенче! Вәли абыйның бу халәте ошамады аңар һәм ул, ишетмәсәң ишет дигән сыман, Хәдичә апасын авыз тутырып, күкләргә чөеп мактый башлады.

— Колхозыбызның күз өстендәге кашы ул, уңганның да уңганы, ә уңган — үзе уңга тора...

Шул вакыт Вәли, бары тик Маннурның сүзен бүлергә теләгән сыман итеп: «Бик картаймадымы?» дип сорап куйды. Берьюлы: тормыш бит аңар гелән елмаеп кына тормады дип тә өстәмәкче иде дә, тыелып калды.

— И-и, картаямы соң?!.— диде Маннур ниндидер бер җилкенү белән.— Хәдичә апа, Мәдинә апа кебекләрне без картайганнары өчен түгел, ә картая белмәүләре өчен яратабыз, ихтирам итәбез. Яшьлек дигән нәрсә яши-яши килә диярсең инде менә үзләренә!..

Шунда Маннур: бу мөсафир Хәдичә апаның тормышка чыкканын белми икән дигән карарга килде. Янә тынлык урнашты. Машина күңелле генә гөрелти, фара утлары белән асфальт юлны камчылап һаман алга әлдерә. Ә юл кырыйларындагы чуер һәм вакланган ташлар фара яктысында, эзәрлекләүдән качкан чабак балыклар кебек, ялтырап чагылып калалар. Маннур сүзне үзе үк ялгап алып китте.— Үзегезгә тагын бер сер ачыйм инде, Вәли абый... Тик хәзергә үзара гына калып торсын. Минем әни әйтмешли, эрләмәгән-сукмаган, менә сиңа ыштанлык дигәндәй, алдан ук телгә кертергә ярый торган сүз түгел ул. Бюродан соң райкомның беренче секретаре Абрар Гайнетдинович безгә, колхозның партком секретаре белән икебезгә, калып торырга кушты. Ну-у, мировой да кеше инде! Соң шул, кабинетына чакырып алып каршысына утыртты да, башта выговордан котылуыбыз белән тәбрикләде. Соңыннан инде йомышын әйтте. Районыбызда Социалистик Хезмәт Герое исеме бирерлек бернечә кеше бар икән. Шуларның берсе безнең колхоздан... иң лаекле кеше дип бертавыштан Хәдичә апа исемен әйттек. Үзе орденлы. Күргәзмә медальләре бар. Терлекчеләребез арасында иң беренче коммунистик хезмәт ударнигы. Гомуми җыелыш карары белән атказанган колхозчы дигән мактаулы исем бирелеп, өенә истәлекле такта куелды. Менә шул... Партком секретаре шушы мәсьәлә буенча иртәгә кадәр районда калды.

Вәли дә телгә килде.

— Ул булдырыр...— Юк, бу сүзләрне әдәп саклау йөзеннән генә әйтмәде ул, тавышы, ничектер, карлыгып, чатнаган сыманрак булып чыкты.

Машина тизләгән дә киметеп тормыйча үргә күтәрелә башлады. Алда, үр арръягында, таң атуны хәтерләтеп, якты офык сыман булып бөтен күкне иңләп аязлык күренде. Күп тә үтмәде, ялт итеп электр утларына күмелгән Олы Кенәле үзе дә пәйда булды.

— Менә ул безнең гүзәл Кенәлекәй!..— Маннур тавышы бу юлы аеруча көчле яңгырады.

Машина авыл урамына килеп кергәч, Вәли, әңгәмәдәше ягына борыла төшеп: «Гостиница-фәлән бармы?», дип сорап куйды.

— Бар! Кунак өебез менә дигән,— дип, беркатлылык белән җавап кайтарды Маннур. Һәм шунда ук юлдашының бу соравы колхозның байлыгын белү өчен генә бирелмәвен төшенеп алды. Аннан инде аклаучы кеше сыман, тезә дә башлады.— Юк сүз сөйләмәгез, Вәли абый. Сезнең кебек могътәбәр кунакны гостиницага урнаштыраммы соң! Сез бит минем укытучым да... Телисез икән, хәзер үк, туп-туры миңа кайтабыз...

— Яхшы сүзең өчен рәхмәт, туган. Шулай да мин башта кызым янына... аны күрермен инде...

Шул сүзне генә көтеп торган сыман, Маннур машинасын кинәт кенә сулга борып олы юлдан чыгарды да, гөлбакчага күмелеп утырган йорт янына туктатты.

— Алайса, менә, Вәли абый. Хәдичә апаның өе шушы була инде,— дип, мул булып яктылык бөркелеп торган тәрәзәләргә күрсәтте.— Әнә, үзләре дә өйдә, ахрысы...

Юлдашының чемоданын кулына тоттыргач, кабат сөйләнеп алды Маннур.

— Безнең өй, Вәли абый, идарә тыкрыгында гына. Борылу белән чардаклы алты почмаклы йорт булыр...

— Рәхмәт, туган...— Хәзергә хушыгыз...

— Что сез! Саубуллашмыйбыз әле, Вәли абый...

— Ярый, алайса, рәхмәт!..

Вәли ишегалдына узды. Салмак кына атлап өйалды баскычына житте. Керергәме, кермәскәме дигән сыман, бермәлгә икеләнеп торды. Бары тик шуннан соң гына ишек артында юк булды.

Маннур, рәшәткә буенарак килеп, пәрдәләре төшерелмәгән ян тәрәзәләргә күз салгач, өстәл кырыенда утырган Вазихны күреп алды. Һәм ирексездән: «Йа-а, катлаулы да соң син, тормыш!..» дип уйлап куйды. Нәкъ шул вакытта, ишектән кергән Вәли абые да күренде. Ул да булмады, өермә кебек очып килгән Вәлидәнең әтисенең муенына барып сарылганы чагылып китте...

Маннур, күңеленең урыныннан кубуын тоеп, җәһәт кенә машинасына утырды да колхоз идарәсенә таба китеп барды.

Икенче көнне таң белән берәүнең авылдан чыгып, станциягә таба япа-ялгыз китеп баруын күреп калганнар.

Азнакай, 1972—1974.

## Нури Арсланов

### Батырлык турында

Шартлар тудыра батыр, ә батырны — шартлар!
Чынлап әйтәм, язмышыма юк бер үпкәм:
Дан-батырлык эзләп үтми егет чаклар,
Чын батыр шул — ватан өчен поход үткән!

Боермады гизү киң фронтлар буйлап...
Курку белмәсәм дә, батыр түгел идем:
Ләкин ул чактагы дәһшәтләрне уйлап
Хәзер үрә тора чал чәчләрем минем!

Мин бер дәрвиш идем язмышыннан көлгән,
Башка «башың сакла!» дигән уй кермәде.
Сугыш корбаннары, терелгәндәй көлдән,
Миңа мәдәт бирде, каушау китермәде.

Яшен суккан кебек яткан егетләрнең
Гәүдәләрен күреп туа иде аңда
Яшәү фәлсәфәсе: «Юк, юк, минем хәлем
Була алмас болай, яшәү әле алда!»

Боермады миңа фронтларны гизү,
Шәһәрләр алмадым, батыр саналмадым.
Тик булмаган курку, каушауларны сизү,
Дәһшәтләрне фәкать хәзер мин аңладым...

Шуңа, ялгыз калып кай чак, шыпырт кына,
Элек ис тә китмәс хәлләрне бер уйлап,
Хәзер тетрәп китәм, чәчләр үрә тора,
Кан чымырдап төшә кинәт арка буйлап...

### Давыл

Давыл килә, давыл килә,
Давыл белән явым килә:
Авам, диеп, өстегезгә!
Кара болыт тавы килә,
Дию-гаскәрләрен тезгән
Дәһшәтле Каф явы килә!

Давыл әллә ниләр кыла:
Җилдән җимерер җилкән кора,
Тузаннарны пыр туздырып,
Өермәләр билен бора...
Тузан басмак булгач болыт, —
Үпкәли дә давыл тына.

Кара болыт түгә яшен:
Давыл дигән дәү юлдашын
Югалтканга кара кигән,
Җиргә кадәр игән башын...
Шук давылны эзли микән? —
Көндез утлар яга яшен!..

Ие, шундый чакларым бар,
Давылланып чатнавым бар!
Табылмасны табар кебек
Көндез чыраг якканым бар,
Давылдан соң тынгы китеп,
Кабат давыл тапканым бар!

## Котлау сезгә

Португаллар, виват! Котлау сезгә!
Капкаларын ачып төрмәнең,
Чыгардыгыз кояш илегезгә,
Фашизмның үчереп өннәрен.

Португалия! Гыйбрәтләнеп синнән,
Испания дә — синең игзәгең
Алып атар бер көн җилкәсеннән
Ярты гасыр изгән имгәген.

Көрәшләрдә коелмаган булган
Корбаннарның каны бикәргә! —
Мин ышандым илле елдан соң да
Ирек яулап була икәнгә.

## Сезне сөйгәнгә

Бар җырларым сезгә — аналарга!
Мине дә үз итә алдыгыз:
Ир-ат белән тиңләп караганда
Рәхимлерәк сезнең җаныгыз.

Кагылдым да-сугылдым да тиккә,
Гамьнәр белән булдым бергә мин...
Какмадыгыз тик сез генә читкә,
Җик булмадым сезгә бер дә мин.

Җылы, нечкә хисләрегез белән
Шигъри хисләр туры килүгә,
Ратканга сезне чын күңелдән
Яраттыгыз, ахры, мине дә.

Әнкәемнең сөтен имгән чактан,
Картайганчы дөнья ләззәтен
Мин татыдым сезнең шат кочакта,
Сездә таптым мин җир җәннәтен!

Алиһәләр күп Юнанда, Римда, —
Бер-бер артлы тезеп китәрлек!
Тик бездә юк хәтта берәү имгә,
Ә күпмегез һәйкәл итәрлек!

«Чал чәчләре төшкән иңнәренә,
Безне мактый үзе, дивана!» —
Дияр кайбер нечкә билләр генә...
Шагыйрь күңелен нәрсә тыяла?! —

Җырда сезнең белән уңдым-уңсам,
Сезнең аша сөйдем илемне!
«Мактый!» дисез, оста җырчы булсам,
Болай гына мактар идемме?!

«Һәр яшьтә дә бәндә мәхәббәткә
Буйсынучан була...» [1] дигәнгә
Мин баш иям, бирелеп хискә, дәрткә,
Җырлыйм, дуслар, сезне сөйгәнгә.

## Мәхәббәт сагышы

Күренде дә китте... Калды гомергә!
Күңел сараемның түрендә хәзер.
Ятсам да гел бергә, торсам да бергә, —
Гаҗәп гүзәл сынын иркәли хәтер.

Көнем болыт иде, яшендәй балкып
Бер ялтырап үтте, — күзем чагылды...
Вөҗүдемне тагын нурыңда яктырт,
Кайтар, кайтар кабат бер шул чагымны!

Керфек кагар кыска илаһи балкыш
Атты ләззәт угын — мин яра алдым.
Им-том белән, дөнья, кагылма ялгыш,
Миңа рәхәт шулай — мәҗнүнгә калдым.

Мин мәҗнүнгә калдым... күзем алалмыйм,
«Ул микән?..» дип карыйм узган-барганны:
Ни гомерләр инде... эзлим, табалмыйм,
Йөзләремә кунды юл тузаннары.

Юып ташлар өчен юл эзен биттән
Әллә күз яшьләре, әллә тир ага...
Мең омтылып, тик бер теләккә җиткән
Көнем булды микән минем дөньяда?!.

[1] Любви все возрасты покорны...» — А. С. Пушкин сүзләре.

## Язмыш турында

Кара елан туз башлы ла,
Йөри камыш буенча;
Ялгыз башым, юк ярдәмчем,
Йөрим язмыш буенча.

Халык җыры.

Үз язмышын кеше үзе кора,
Үз кулында, диләр, — һич түгел:
Һәркем туса батыр булып кына,
Тормыш булыр иде ал да гөл.

«Батыр» сүзе үзе булмас иде,
Әгәр батыр булса бар кеше.
Әлмисактан бирле килә инде
Кара һәм ак язмыш тартышы...

«Язмыш» әгәр чыннан да бар дисәк,
Нинди язмыш көтми бәндәне! —
Бирәүдә бар терәк, төгәл исәп,
Берәүнең бик мөшкел хәлләре...

Берәү ача куркып-каушап кына
Тылсымлы бу тормыш ишеген,
Берәү кереп китә ансат кына
Канатында дусы-ишенең.

Ялгыз батыр чыккан ирләр дә күп.
Күмәклектә ләкин җиңүләр!
Иң дөресе — бергә михнәт күреп,
Бергәләшеп рәхәт чигүләр.

Гадел язмыш өчен юл сапканда
Тик бер генә ысул яраклы:
Барың өчен берең җан атканда,
Берең өчен барың җаваплы!

## Мин җырлармын

Җитсә-җиткән җик күренер чаклар,
Өмет кошы кайтыр яз үткән, —
Амурымда ләкин шат канатлар,
Мин чигенмим әле «язынтан!»

Хәят диңгезендә күмелгәнче
Моңлы сазым сыкрар кулымда:
Мин уйнармын кыллар өзелгәнче,
Мин җырлармын гыйшкым турында!

## Уйлата

Һава, Ослан тавы, Идел... зәп-зәңгәр.
Күңел сәрхуш — миндә гаҗәп шәп хәлләр,

Тәмам риза, рәхәт табам тирәмнән, —
Табигатем ризалыкка өйрәнгән...

Кинәт серле бер өн килә Иделдән:
Әй, Арслан, син батырлар иленнән!

Бат тирәнгә, төш суларым астына,
Ту яңадан — кайт яңадан аслыңа!

И хыяллар! — туа кая карама.
Син үзеңне күпме азат санама,

Кол итә аң,— үз кулында уйната,
Фәлсәфәле төрле уйлар уйлата:

Болытларда, күктә генә йөрмә, ди,
Төшкәлә, шагыйрь, кай чакта җиргә! ди.

Бер өн килә әнә зәңгәр Иделдән:
Әй, хыялый, син батырлар иленнән!

Бат тирәнгә, төш тә дулкын астына,
Җир улы бул, кайт яңадан аслыңа!

## Кара болыт

Кара болыт итәкләре
Манчылган төшеп суга:
Суда болыт! Су да — болыт,
Бар дөнья чумган шуңа...

Күк белән җир кавышканнар,
Тоташып Иделләрдә.
Каушаудан я чирканудан
Дерелдәү иреннәрдә...

Томан дисәң — томан түгел,
Яңгыр дисәң — яшенсез.
Без дә шулай кай чагында
Бик күңелсез яшибез:

Еласаң — яшьләр түгелми,
Көлсәң — юк бер көлкесе...
Кара болыт төсле чытык
Була күрмәсен кеше.

## Сары яфрак белән сөйләшкәндә

Мәңге яшел калырмын дип белдең,
Сары яфрак, яшел чагыңда...
Бер чара юк — чиге бар гомернең!
Дөрес, язлар килер тагын да,

Тик булмабыз инде без ул чакта,
Гомер үткән яшьнәп, ялтырап:
Мин аерылам дип каерылам артка,
Син торасың тетрәп, калтырап...

## Шәддад җәннәте

Шәддад патша җирдә җәннәт корган:
Алмаларын койган алтыннан... —
Бар дөньяны шаккатырмак булган,
Атым калсын, дигән, артымнан!

Аты калган калуын, ләкин җәннәт
Мирас булып безгә күчмәгән:
Җимеш калдырмаган җирдә Шәддад,
Багында чын алма үсмәгән.

Зәмруд агачларда алтын алма, —
Ул бер алҗу гына, төш кенә.
Ачышларың белән, я, замана,
Мифлар килде асты-өстенә!

Киң дөньяга акыл күзе белән
Каравыма — иман какшады:
Инде йөртмим аңда үзем белән
Шәддад төзгән җансыз бакчаны.

## Этюд

Алсу күлмәкләре белән,
Юеш күкрәкләре белән,
Караңгыда кинәт балкып
Елмайды сылу:
Коенып кайтып килә икән,
Юл уңае кергән икән,
Мин карап калдым шаккатып...
Илаһи сын бу!

Тудырса-тудыра дөньясы, —
Бу — Рафаэль мадоннасы!
Мин телдән калдым, дивана,
Шигыремнән айнып,
Каләм төшеп китте кулдан,
Кузгалмадым урынымнан...
Ә сылуга нәрсә аңа! —
Тора елмаеп...

## ...гә

Арабызда елга, иске күпер.
Мин үткән, ә сиңа үтәсе.
Сиңа куып җитү, миңа көтү
Мөмкин түгел... ни хәл итәсе?!.

Тартып кына алыйм дисәм ярдан —
Кулым җитми елга аркылы...
Юлларыңа төшсен якты булып,
Һич булмаса җырым ялкыны.

1974

Гөлсем Мөхәммәдова

# ЯШЬЛЕК КӨННӘРЕ

ПОВЕСТЬ

АВТОРДАН

Бу әсәрне язганда, Галимҗан Ибраһимов турында матбугатта төрле вакытларда басылып чыккан мәгълүматлардан башка, аның якын туганнары һәм хәзерге көндә исән булган шәрикләре белән күп тапкырлар очрашу, язышу нәтиҗәсендә туган материаллардан, шулай ук үземнең исемдә калганнардан файдаланылды.

Повестьтагы барлык уңай типлар үз исемнәре белән алынды. Заһидулла хәзрәт һәм һинди Минһаждан башка кире типларның исем-фамилияләре үзгәртеп бирелде.

Үзләренең истәлекләре, кулларындагы материаллары, киңәшләре белән ярдәм иткән иптәшләргә чын күңелемнән рәхмәт белдерәм.

## Аургазы буйларында

### I

Унбер яшьлек Галимҗанның тынчу һавалы тар мәдрәсәдән кайтуына өч айлап вакыт үтте инде. Шулай да авылның сокландыргыч матур табигатен ул әле һаман да күреп туя алмый. Анда, Оренбурда чакта, туган йортын бик сагынган иде шул ул. Менә хәзер дә малай йокысыннан тору белән урамга чыкты.

Төнлә яңгыр явып узган. Табигать гүя ки юынып-чистарынып, яшәреп киткән. Иртәнге кояш җылысында җир өстеннән җиңелчә пар күтәрелә. Галимҗан дымлы җир һәм үлән исләре аңкып торган саф һаваны йотлыгып сулады да тирә-ягына каранды. Табигатьнең хозурлыгын беренче тапкыр күргән кебек хәйран калды. Бөтен тәнендә әйтеп бетергесез җиңеллек сизде. Бу рухландыргыч һаваны тагы да тирәнрәк суласа, кулларын җәеп җибәрсә, үзлегеннән аяз күккә хәтле очып китәр төсле тоелды аңа.

Чыннан да, шулай очып китә алса, нинди булыр иде! Башта ул әнә тегендә, күпер артында калкып торган Кинҗәгол тавы тарафына юнәлер иде. Аның көньягындагы текә яры өстендә кул-канатларын какмыйча гына һавада йөзә-йөзә, яр астында җәелеп яткан яшел болынга,

болын уртасыннан боргаланып аккан Аургазы елгасына карап сокланыр иде. Аннан соң ул, яшел имәнлек өстеннән үтеп, төньяктагы Яманташ ягына очып китәр иде. Анда, киң яфраклы куаклар, куе үләннәр белән капланган тарлавыкта, таш кыя астына яшеренгән тирән бер тау куышы бар. Аны да барып күрәсе иде...

Галимҗан хыялларына шул чаклы чумган иде ки — капканы шыгырдатып әнисе Хәсәнә остабикәнең урамга чыкканын да сизми калды. Әнисе бераз вакыт эндәшмичә торды. Аннары йомшак кына тавыш белән:

— Галимҗан, ашарга кер, балам! — диде.

Малай сискәнеп артына әйләнеп карады. Ихтыярсыз, әнисенә таба омтылып, аның җылы күкрәгенә сыенды.

Тыштан бик сиздермәсә дә, остабикә аны башка балаларына караганда яратарак төшә иде. Галимҗан Шакирҗан абыйсы кебек артык юаш һәм басынкы түгел. Аны һәрнәрсә кызыксындыра, ул бөтен нәрсәне белергә тырыша, уенга да, башкасына да, үзе теләгән һәр эшкә җаны-тәне белән дәртләнеп керешә... Хәсәнә остабикә Галимҗанны башкалардан артыграк кызгана да иде.

Улының капка янында шулай япа-ялгыз басып торуы остабикәнең йөрәген әрнетте. «Баланың сәламәтлеге бик үк әйбәт түгел шул. Гел авырый... Шуңа күрә кайбер усал малайлар аны «чирләшкә» дип үртиләр. Шуңадыр, ахрысы: ул башка малайлар белән аралашырга, алар белән уйнарга атлыгып тормый... «Авыру» дип, аны абыйсы Шакирҗан укый торган «Хөсәения» мәдрәсәсенә дә алмаганнар. Баланы Вәли мулланың кадим мәдрәсәсенә биреп калдырырга туры килгән...» Хәсәнә остабикә, шуларны уйлап, тирән итеп сулап куйды да:

— Әйдә, кер инде, балакаем. Сумсалар суынмасын! Син бит кайнар килеш ашарга ратасың, — дип, улын бакчага алып кереп китте.

Бакча эчендә, яшь сәрби агачы күләгәсенә, сәке ясап куелган. Өстенә кулдан суккан палас җәелгән. Сәке уртасындагы шакмаклы ашъяулыкка, тәлинкәләргә өеп, кызарып пешкән сумсалар, коймаклар куелган, бер савытта Галимҗанның иң яраткан ризыгы — каймак та бар. Ашъяулыкның бер читендә, көзгедәй ялтырап, җиз самавар пар чыгарып утыра.

Остабикә, гадәтенчә, сәке читенә, самавар каршына утырып, болай да елкылдап торган чынаякларны сөртә башлады.

Төпчек малай — өч яшьлек Габделхәким — сәкегә менәм дип үрмәләп маташса да, булдыра алмый газаплана иде. Моны күреп, Галимҗан урыныннан торды да энесен күтәреп сәкегә утыртты. Габделхәким, ашъяулык янына якынлашу белән, кара күзләрен елтыратып каймакка сузылды. Әнисе аны шелтәләп алды:

— Күрмәдеңме? Абыйларың табын янына кулларын юып килеп утырдылар, ә син юмаган кулыңны каймакка сузасың. Алай ярамый, балам! — дип, тезләре өстендә яткан тастымалның бер очын юешләп, нәнинең кулларын сөртте һәм, чынаяк тәлинкәсенә берничә кашык каймак салып, малайның алдына куйды.

— Коймакны маныып-маныып ашасаң бик тәмле була! — диде төпчегенә, ул арада чынаякларга чәй ясап, балаларына бирде.

— Ашагыз, балалар! Исәнлеккә-саулыкка булсын! — дип сөйләнде һәм «бисмилласын» әйткәннән соң, авызына нәни генә шикәр кисәге кабып, чынаяк тәлинкәсеннән чәен эчә башлады.

Шакирҗан, әнисенә карап:

— Әтине көтмибезмени? Әллә ул, чәйгә кайтмам, дигән идеме? — дип сорады.

— Намаз вакыты күптән үтеп китте инде. Күрәсең, картлар белән әңгәмә корып калгандыр, я берәрсенә җомга чәенә кергәннәрдер... — диде әнисе.

Хәсәнә остабикә сүзен дә әйтеп бетермәде, урам ягыннан аяк тавышы ишетелде, һәм капкадан Гыйрфан мулла кайтып керде. Гаилә башы бакчага, табын янына килмичә, туры өйгә юнәлде. Чалмасы белән җиләнен салганнан соң, ул янә бусагада күренде.

Шакирҗан сәкедән атылып төште. Юл уңаеннан агач ботагына эленгән сөлгене алып, шул ук агач төбендә торган комганны эләктерде дә этисе янына ашыкты, аның кулына су салып тора башлады. Гыйрфан мулла ашыкмый гына кулларын юды, тамак кыргалап, көмешләнә башлаган кара сакалын сыйпаштырды, башындагы кәләпүшен төзәтебрәк киде һәм шуннан соң гына сәке янына килеп, балаларын күздән кичерде:

— Сез инде ашый-эчә дә башлагансыз икән, — диде.

Остабикә уңайсызланыбрак:

— Син бүген үзең кичегебрәк кайттың, этисе. Балалар ачыгышып беттеләр... — дип куйды.

Гыйрфан мулла көлемсерәде дә, әле картаюның ни икәнен белмәгән ап-ак йөзле, сызылып торган кара кашлы, зур коңгырт күзле остабикәсенә карап:

— Яхшы иткәнсең, анасы! — диде. — Бик ябыкканнар шул бичаралар. Ашат, симерт үзләрен. Минем үземнең дә карыным ачты, — дип сөйләнә-сөйләнә, сәкегә менеп, аяк бөкләп утырды.

Габделхәкимгә бу юлы тиешенчә илтифат күрсәтмәделәр кебек тоелды. Ул ярым аптыраган, ярым үпкәләгән кыяфәт белән бер этисенә, бер әнисенә карады. Ләкин алар малайга күз дә салмыйлар иде. Габделхәким этисен үзенә каратыр өчен ике куллап аның тезенә төрткәли башлады. Тик шуннан соң гына Гыйрфан мулла төпчегенә таба борылды:

— Чү, нишләвең бу, балам?! — диде.

Малай, этисен үзенә карата алуына сөенеп, «р» хәрефен йота-йота:

— Мин дә мәдләсәгә балылмын әле, мин дә ябыгып кайтылмын әле. Ә бит, эти? — диде.

Этисе елмаймаска тырышты:

— Шулай, шулай, улым! Дәү булгач, син дә, абыйларың төсле, мәдрәсәгә барырсың, шәкерт булып йөрерсең, — дип, йомшак кына итеп малайның аркасыннан какты.

Габделхәким, куанычыннан масаеп, абыйларына карады. Ләкин Шакирҗан аның шатлыгын бозып ташлады:

— Адым саен җылакланып, мине кулыңа күтәр дип әнине йөдәтүең дә җиткән инде. Син бит хәзер кечкенә түгел, дүртенче яшеңдә!..

Габделхәким үпкәләвеннән чак кына елап җибәрмәде. Абыйсының бу төртмәле сүзләренә каршы шундый ук җавап табарга тырышты, тик теленә бөртөрле дә юньле сүз килмәде:

— Ә син... Ә син үзең... — дип, йөзен чытып, еларга хәзерләнде.

Әниләре аларны тынычландырган булды.

— Житәр, көйсезләнмә, Габделхәким! Табын янында тавыш чыгарып утырма! Шакирҗан абыең бик дөрес әйтте. Җылакланганчы, әнә, каймакка манып коймак аша!..

Шул вакыт урам капкасыннан Галимҗанның дусты Мохтар килеп керде. Бакча ишеге янына җиткәч, ул кулын күкрәгенә куеп сәлам бирде. Гыйрфан мулла, табындагыларның барчасы йөзеннән:

— Вәгаләйкем әссәлам! — дип җавап кайтарды.

Кунакчыл остабикә исә:

— Кил, Мохтар, чәйгә утыр! — дип, аны табынга чакырды.

— Рәхмәт, җиңги, без инде чәй эчтек,— диде Мохтар. Үзе күз чите белән генә мәгънәле итеп Галимҗанга карап куйды. Мохтар Галимҗанның туганнан туган абыйсы икәнне белмәгән кеше аларны игез балалар дип уйлар иде. Икесе дә балаларча бүлтәебрәк торган иренле, киң маң-

гайлы, куе коңгырт кашлы, коңгырт күзле. Дөрес, Мохтарның бите бераз кинрәк, тулырак, гәүдәгә дә тазарак.

Мохтар хәзер килеп чыкмаган булса, чәйдән соң Галимҗан дусты янына үзе йөгергән булыр иде. Ни дисәң дә, аның белән күңеллерәк. Башка малайлар шундук я әрләшергә, я сугышырга, я үчекләшергә тотыналар. Әлбәттә, аларга кирәгенчә җавап бирергә, әйбәт итеп арт сабакларын да укытырга мөмкин. Тик андый бәрелешүләрдән соң артык уйныйсы килми башлый. Мохтар исә, яшьтәшләренә караганда тазарак булса да, сугышырга яратмый. Бер-ике яшькә олырак булгангамы, ул Галимҗанга юл куя. Шуңа күрә Галимҗан аның белән уйнарга ярата. Менә әле дә, дустын күрү белән, ул ашап утырган сумсасын тәлинкәгә куйды да:

— Әнкәй, мин туйдым инде. Мохтар белән уйнарга чыгыйммы? — дип әнисенә дәште.

Әнисе кырт кисте:

— Ичмасам, башлаган сумсаңны ашап бетер, уйнарга өлгерерсең әле! Мохтарың беркая да китмәс!

Галимҗан ялвара башлады:

— Валлаһи, мин туйдым инде, әнкәй! Башка ашыйсым килми!

— Нигә аны туктатасаң? Уйныйсы килә икән, барсын, уйнасын! — диде әтисе.

Әтисенең яклавына шатланып, Галимҗан сәкедән сикереп төште.

Капкадан чыгу белән, Мохтар:

— Нәрсә уйныйбыз? Хәзинәбезне казып чыгарып, чичәкәй уйныйбызмы? — дип сорады.

— Кем инде хәзинәне көпә-көндез казый?! — диде Галимҗан.— Ничек вәгъдәләшүебезне оныттыңмы әллә? Төн уртасында, һичкем күрмәгән вакытта казырга барабыз дип килешкән идек бит. Төнлә казу кызыклырак та булыр!

Мохтар уйланып торды да:

— Алай булгач нәрсә уйныйбыз соң? — дип сорады.

— Балык каптырырга барыйк! Бүген җил дә юк, яхшы чиртер.

Чичәкәйләрне — аллы-гөлле чынаяк ватыкларын — күмгән җирләреннән казып чыгарырга бик теләсә дә, Мохтар балыккка барырга риза булды.

— Ярар, алайса,— диде ул. «Миннән кечерәк ич ул, әйдә аның сүзе сүз булсын», — дип уйлады.

Бу тәти чичәкәйләрне алар кайда тапсалар, шуннан бик тырышып җыялар, юалар, кырыйларын пөхтәләп кырып шомарталар. Шуларны җиргә тезеп әллә нинди искиткеч нәрсәләр ясыйлар. Учларына алып, чәчеп җибәрәләр дә, ничек төшкән булсалар, шул көенчә әкрен генә бер-берсенә янәшә шудыралар. Менә сиңа әйтеп бетергесез муенса, я бик матур чәчәк, яки карап туймаслык, ут кебек янып торган тагын әллә нәрсә килеп чыга! Галимҗанның чичәкәйләрне казып алырга ашыкмавы Мохтарны гаҗәпләндерә дә төшкән иде, чөнки ул дустының бу чынаяк ватыкларын күңел биреп җыюын, алардан бормалы-сырмалы бизәкләр төзештереп утыруын күп күргән иде. Хәер, балык каптыру да күңелле ич!

Балалар, кирәк-яракларын алып, Кондызлы күл ягына китеп бардылар.

2

Урау юл булса да, дуслар Ишекле тау яныннан үтәргә уйладылар. Алар чичәкәйләрен шушындагы тау куышына күмеп куйганнар иде. Ап-ак тауның ачык капкага охшаган табигый ишегендәге бер баганасы җимерелгәнлеген Галимҗан ерактан ук күреп алды. Аның кәефе китте.

— Кара әле, безнең тау ишегенең бер баганасын сындырганнар ич! Хәзер инде аңар Ишекле тау дип тә әйтеп булмый, — диде ул, кемгәдер үпкәләгән сыман.

Мохтар аңлатып бирде:

— Аны ташчылар җимерде. Гыйсмәт байга өй салганда нигез ташы кирәк булган...

Моны ишеткәч, Галимҗанның ачуы килде:

— Ташны башка җирдән алсалар да була иде бит. Әнә, бөтен җире ак таш, теләгән җиреннән ал! Кара инде бөтен ямен бозганнар бит тауның!

— Ишек баганасын җимерүе җиңелрәк ич, ә тауның үзен ничек итеп ярасың? Ул бит таш тау! — диде Мохтар, аны тынычландырырга тырышкан сыман.

Галимҗан дустына кырыс кына күз ташлап алды. Чыннан да, бит бу ишек ак тауга аеруча бер матурлык бирә, әкиятләрдә сөйләнә торган тылсымлы сарайларны хәтерләтә иде. Менә шул ишеге өчен дә тауга «Ишекле тау» дип исем кушканнар! Ишеге җимерелгәч, тауның матурлыгы бик кимегән төсле күренә шул! Ләкин Галимҗан үзенең бу тойгыларын сүз белән әйтеп аңлата алмады. Бары тик:

— Син бернәрсә дә аңламыйсың! — дип кенә куйды.

Бераз эндәшми барганнан соң, тау янына килеп җиткәч, ул:

— Әйдә әле, куышка төшеп карыйк. Безнең чичәкәйләргә тимәгәннәрме икән? — диде.

— Әйдә! — диде Мохтар бик шатланып. Ул иптәшеннән калышмаска тырышты, чөнки Галимҗан түзмәс тә чичәкәйләрне үзе генә казый башлар, дип уйлады.

Хәзинә күмелгән урынга барып җитү ансат түгел. Иң элек, куыш башланган урынны ышыклап торган ташлар өстенә үрмәләп менәсе бар. Аннан соң, алга чыгып торган ташларга, таш ярыкларында үскән чирләшкә куакларга тотына-тотына түбәнгә, куышка төшәргә, шуннан соң гына эчкә кереп, асылынып торган кыя астындагы йомры ташны бер читкә этәргә кирәк. Менә шул таш астына чичәкәйләр күмелгән.

Хәзинә Галимҗанның уенда да юк иде. Киресенчә, ул йомры таш өстенә менеп үк утырды да:

— Әйдә, бераз ял итик әле, — диде.

Монда салкынча икән. Яктылык та бик аз төшә. Тып-тын... Җир йөзендә ак кыядан башка бер нәрсә дә юктыр кебек.

— Сабирҗан абзыйның улы Кәрим әйтә, бу куыш эчендә төнлә утлар яна, ди!..

Мохтарның басынкы гына тавыш белән әйткән бу сүзен ишеткәч, Галимҗан ялт итеп аңа карады.

— Төнлә ни эшләп йөргән ул монда?

— Белмим. Сорамадым... Бәлки монда дөрестән дә төнлә җеннәр уйный торгандыр, ә? — Мохтар Галимҗанга якынрак сыенды да пышылдап кына: — Галимҗан, әйдә, хәзер үк чичәкәйләрне казып алыйк,— диде.

Галимҗан, иптәшенең сүзләрен ишетмәгән шикелле, куыш авызындагы таш өемнәренә дикъкать белән карап тора башлады.

Төн уртасында монда килеп, шушы таш өемнәре аша үрмәләячәкләрен уйлагач, Галимҗанның йөрәгенә курку йөгерде. Чыннан да, монда җеннәр оясы булса, ни эшләрсең? Куркыныч шул!.. Ләкин куркуын сиздерәсе килми иде аның.

Байтак вакыт эндәшми торганнан соң, Мохтар тагын Галимҗанга карап куйды. Ләкин дустының йөзендә икеләнү, курку дигән нәрсәләрнең әсәрен дә күрмәде. Ул, Галимҗанның үз ниятеннән кире чигенмәячәген аңлап, тирән сулап куйды.

— Төнлә бик куркыныч шул, — диде Галимҗан. — Тик эти әйтә: әйткән сүз — каккан казык, ди. Егет кеше әйткән сүзендә нык торырга тиеш, ди. Алдан шулай сүз куешкач, төнлә килергә кирәк инде... Шушы сүзләрне әйткәч, Галимҗанның җилкәсеннән авыр бер йөк төшкән төсле булып, күзләре нурланып китте.— Беләсеңме, Мохтар, кичен югга чыкканда шырпы белән шәм алырга кирәк. Берәрсе төнлә куыш эчендә ут яктысы күрсә, җеннәр икән дип белер...— Галимҗан шулай диде дә көлеп җибәрде.

Аның дәртләнеп китүе Мохтарга да тәэсир итте. Алар, көлешеп, утырган урыннарыннан сикереп тордылар.

Су тамчыларыннан куыш түренә күл җыела, кыш көннәрендә ул боз булып ката, җәй көннәрендә дә эреми. Шуның өчен куыш эченнән суык бәреп тора. Малайларның эченә салкын кереп өлгергән иде инде. Алар, калтырана-калтырана, югарыга үрмәләделәр.



## 3

Күл янында беркем юк. Тик сөзәк яр буйларында, куе үлән арасында, бәбкәләрен ияртеп, казлар гына масаеп йөриләр.

Бормалы-сырмалы чокырлыкта күл җәелеп ята. Бу күлгә бер елганың да суы килеп кушылмый һәм күлдән инеш тә агып чыкмый. Шулай булгач, кайчан да булса ул кибеп бетәргә тиеш иде бит, ә аның суы артмый да, кимеми дә. Күлнең көньягында куе камышлар, таллар үскән бер урын бар. Әнә шунда су җир астына кереп китә дә авылдан читтәрәк чишмә булып бәреп чыга. Авыл халкы су ала торган чишмәне менә шушы Кондызлы күлнең суы диләр. Күлнең бу урыны турында әллә нинди имеш-мимеш сүзләр дә сөйлиләр. Имеш, шул төштә кешене җир йота икән! Шуның өчен иң батыр йөрәкле егетләр дә ул урынга йөзеп бармыйлар. Яз башында, карлар эрегән чакта, чылтырап, таштан ташка сикереп, күлгә гөрләвекләр агып төшә. Ә җәйге челләдә су каян килә икән? Бу сорау Галимҗанны бик кызыксындыра. Кармагын салганчы шул хакта бераз баш ватып торды. Аннары гына:

— Күл төбендә җир астыннан бәреп торган берәр чишмә бардыр, — дигән карарга килде.

Башта, үч иткән кебек, балык һич чиртмәде. Инде бөтенләй өмет юк дигәндә, Мохтарның калкавычы кинәт сикереп куйды да суга батып китте. Яңадан өскә калкып, су өстендә бии башлады. Көтелмәгәнлектән малай үзе дә утырган урынында сикереп куйды, чак кына күлгә егылып төшмәде. Аннары, исенә килеп, кабалана-кабалана кармагын тартуга, судан тыпырдый-тыпырдый бәләкәй генә балык килеп чыкты!

— Инде эшләр хутка китәр! — дип әйтеп өлгермәде Галимҗан, үзенең дә калкавычы калтырана башлады. Бик җитди кыяфәт белән, дулкынлануын сиздермәскә тырышып, Галимҗан кармак сабын тиз генә югары күтәрде. Ләкин... Эх, кармак буп-буш, җимне өзеп калганнар!

Галимҗан үкенечле тавыш белән:

— Их, малай, калкавыч батып китүгә үк кармакны тартырга кирәк булган... — дип куйды.

— Ә син кармагыңа симезрәк суалчан каптыр! — дип киңәш итте Мохтар.

— Мин үзем дә шулай итәм ич! — диде Галимҗан аңа каршы. Күзләрен калкавычларыннан алмыйча байтак утырдылар алар. Балык озак вакыт чиртми торды. Малайлар инде йокымсырый ук башлаганнар иде. Кинәт Галимҗанның калкавычы калтыранып куйды да суга батты. Балыкны ычкындырмаска тырышып... Балыкны ыграк эләктерим дип Галимҗан кармак сабын кисәк тартып куйды һәм шуннан соң кармагын әкренләп судан чыгара башлады. Мох-

тар бөтен гәүдәсе белән иптәшенә таба борылды. Ул түземсезләнеп: «Ни чыгар икән?» — дип көтә иде.

Ниһаять, судан карасу-яшькелт сыртлы, кызыл канатлы зур гына алабуга күренде.

— Эләктеңме?! — дип кычкырып җибәрде Галимҗан, шатлыгын яшерә алмыйча. Аннары балыкны кармактан ычкындыра-ычкындыра: — Белеп тордым ич! Бая җимне ашап качкан балыкның нәкъ үзе бу! Авырлыгы бер кадактан да ким булмастыр, ә? — дип сөйләнде.

— Нинди зур! Озынлыгы да бер карыштан ким түгелдер! — дип, Мохтар күзен алмыйча, дусты балыкны чиләккә салганчы карап торды.

Галимҗан, үз эше белән генә мәшгуль кебек күренсә дә, Мохтарга:

— Син әнә үз калкавычыңны кара, балык бөтенләй кармагыңны сөйрәп китмәсен! — дип шаяртып алды.

Мохтар тиз генә иелеп кармак сабын кулына алды. Менә сиңа кирәк булса! Әйбәт кенә кызыл канат эләккән бит. Галимҗанның алабугасыннан бер дә ким түгел!..

Инде чиртә башлады! Рухланып киткән малайлар тынып калдылар. Ләкин иманлек ягыннан ниндидер тавышлар ишетелде. Озак та үтмәде, кояшта янган бер көтү яшьләр күл янына килеп чыктылар. Алар шунда ук күлмәкләрен сала башлаганнар иде инде. — Кая инде хәзер монда балык каптыру?! Малайларның кәефе китте. Ләкин егетләрнең коенырга хәзерләнгәннәрен күреп, боларның да су керәселәре килде. Кирәк-яракларын, чиләктәге балыкларын читкәрәк алып куйдылар. Циндер күлмәк-ыштаннарын салдылар. Ул арада яшьләрнең берсе:

— Әйдәгез, егетләр, ярышабыз! Кем кемне узар икән, — дип кычкырды.

— Эш ярышуга калса, әйдә, болай булсын: кем дә кем мине суда тота, шул җиңгән булып чыга,— диде икенчесе, Габдулла дигән егет.

Арада иң яхшы йөзүче саналган Нурмөхәммәт үзенчә шарт куйды:

— Алай булгач, болай итик: Габдулланы уртага бастырабыз. Суга бөтенебез берьюлы сикерәбез.

Габдулланы бик тиз тотачагына ышана иде ул. Башкалар да шикләнми иде.

Галимҗан белән Мохтар, суга кермичә, ярышны күзәтеп кенә утырырга булдылар, ялангач килеш читкәрәк китеп, яр читенә чүгәләделәр.

Уртага Габдулланы бастырып, яшьләр яр буена тезелеште, эле генә малайлар балык каптырып утырган урыннан берьюлы суга сикерделәр. Менә егетләр берсе артыннан берсе су өстенә калкып чыга башладылар. Калыккан бере аптырап тирә-ягына карана, ләкин Габдулла күренми иде. Бу ни хәл? Галимҗан аның иң ерактагы егеттән дә ике сажин чамасы арырак су өстенә килеп чыкканын күреп алды. Аның шундый житезлегенә сөенеп, Мохтарның кабыргасына төртте:

— Кара, кара әле! Чыннан да егет икән бу! — дип, бармагы белән Габдуллага таба күрсәтте.

Иптәшләре дә аны күреп алдылар. Габдулланы тотар өчен ярым божра рәвешендә тезелешеп, аңа таба йөзеп киттеләр. Галимҗан бөтен гәүдәсе белән ярышучылар ягына борылып, күзләрен зур ачып Габдуллага текәлде. Аңа кая китәргә дә юл юк бит! Аны уратып алдылар! Артында исә камышлар, таллар. Анда китмәс ул! Ул якка берәү дә йөзеп бармый! Ләкин ни өчен соң әле Габдулла бер дә исе китмичә, тыныч кына тора бирә? Әллә: «Башка чарам юк, барыбер тотачаклар», дип уйлый микән?

Мохтар түзмәде, Галимҗанның җилкәсенә тотынды. Тыны кысылып:

— Менә хәзер инде Габдулла абыйны тоталар! — дип пышылдады.

Галимҗан, аның сүзен ишетмәгән кебек, эндәшмәде. Күп тә үтмәде, ул иркенләп сулап куйды. Иптәшенә таба әйләнеп карады. Шатлыгыннан көлеп үк җибәрде.

— Тотарлар ди! Күрдеңме?!

Егетләрнең берсе Габдулланы инде тотам дигәндә генә, ул:

— Әйдә, тот! — диде дә суга чумды. Аның чумган урынын уратып алыр өчен, иптәшләре читкәрәк йөзеп киттеләр, ләкин бер ялгышлык ясадылар! Габдулланың чумган урыныннан әллә ни ераклашмадылар. Габдулла исә күлнең нәкъ кырыена ук килеп чыкты. Күкрәген киереп бер сулады да ашыкмыйча ярга менеп киенә башлады. Егетләр дә бер-бер артлы судан чыктылар. Алар җиңелүләреннән оялган төсле күренәләр иде.

Беренче булып ярышырга өндәгән егет:

— Ничек итеп син шулай бездән качып котыла алдың? — дип гаҗәпләнеп сораган булды.

Габдулла хәйләле генә елмаеп җавап кайтарды:

— Ансат кына. Тик шунысы бар, серне ачаргамы сезгә, әллә юкмы?..

— Әйт инде! Берәүгә дә сөйләмәбез! Үзебез генә белербез, — дип үтенә башлады иптәшләре.

— Әйтмәссез бик! Бер сәгать тә үтмәс, бөтен авылга таралыр, — дигән булды Габдулла.

— Валлаһи дим, һичкемгә әйтмәбез!

— Ярар инде, әйтсәм әйтим, ачыйм серне, — диде Габдулла көлеп.— Сез чумгач та күзләрегезне йомасыз, шунлыктан суда бернәрсә дә күрмисез. Ә мин чуму белән күзләремне ачам да бар нәрсәне күрәм. Сезнең яныгыздан ук йөзеп үтәм. Бөтен сере менә шул...

Егетләр шаулашып көлештеләр:

— Мин әллә нинди зур хәйләме икән дисәм!..

— Искитәрлек берни дә юк икән!

Габдулла тагын көлеп куйды:

— Әйттем ич мин сезгә, бик ансат ул дип!

Шул вакыт арттан кинәт Гыйрфан мулла тавышы ишетелде:

— Ә, менә кайда икәнсез! Анагыз сезне эзләп аптырады. Төшке аш вакыты күптән үтте инде, ә сезнең өйгә кайтырга исегездә дә юк...

Ул инде өйлә намазыннан чыккан икән: өстендә һәр көн өйдә кия торган, ап-ак итеп юылган киндер күлмәк, җиңсез кара камзул, ычкырлы алача ыштан, башында кара түбәтәй иде.

Аны күрү белән, егетләр, читкәрәк китеп, кабаланып киенә башладылар.

Гыйрфан мулла — ачык, шат күңелле кеше. Ул муллалыгы белән тәкәллефләнми. Намаз вакытларыннан тыш үзен гади крестьян кебек тота. Ялчысы Әхми белән бергәләп кырда җиң сызганып эшли. Башка руханилар төсле комсызланып, садака артыннан да кумый. Тирә-юньдә ул чабышкы атлар асравы белән дан казанган иде. Аның атлары ел саен сабан туенда чабышалар... Киенеп беткәч, яшьләр Гыйрфан мулла алдына килеп сәлам бирделәр. Мулла аларның сәламенә каршы:

— Вәгаләйкем сәлам! — дип җавап кайтарды да, яр читендә ялангач килеш олыларның сүзләрен кызыксынып тыңлап утырган Галимҗан белән Мохтарга таба борылды: — Ә сез коеныгыз да тизрәк өйгә кайтыгыз! Әниләрегез анда ут йотып тора!..

Шулай дигәч ул, җиргә нык-нык басып, авылга таба китеп барды.

## 4

Авылда көннең ничек үткәнен сизми дә каласың. Мәдрәсәдәге кебек түгел шул! Анда көнне уздырып булмый торган иде. Менә кич тә җитте. Янәшә бүлмәдә Галимҗанның әтисе, балаларны уятмас өчен, басынкы бер тавыш белән остабикәсенә ни турындадыр сөйли. Галимҗан, йокысын җиңәргә тырышып, әтисенең сүзләренә колак сала. Салих дигән

кешенең аты югалган икән. Ул аны чишмә янындагы болынга җибәргән булган. Анасы борчыла:

— Алла сакласын андый бәладән! Ничек инде ул вакытында карамаган? Әллә атын тышауламаган булды микән?

Әтисе:

— Аты тышавын өзгәндер дә китеп баргандыр, — дип җавап кайтара.

Хәсәнә остабикә һаман тынычлана алмый:

— Аның бердәнбер аты бит! Бәла-казага очрамагае, атын бүре бумагае дим! Яхшырак эзләргә кирәк иде!

Гыйрфан мулла аны тынычландырырга тырыша:

— Төнлә берүзе аны кайдан эзләп йөрсен? Таң аткач, яшьләр тирәякка чыгып эзләрләр. Бу турыда кешеләргә әйттем инде... мин,— ди.

Сәгать суга башлады. Галимҗан, сәгатьнең һәр сугуына бармакларын бөгә-бөгә, унга кадәр санады. Тагын бер сәгатьтән Мохтарны уятырга була. «Кара син аны, ничек мышный бит!» — дип уйлады ул.

Иң читтә, аерым юрган астына кереп, абыйсы Шакирҗан яткан. Әткәсе белән әнкәсе дә йоклап киттеләр бугай: әтисенең ара-тирә гырлап куйганы ишетелә.

Галимҗан юрганын өстеннән алып ташлады да торып утырды. Их, рәхәтләнеп түшәккә сузылып ятасы иде! Ләкин — ярамый. Мохтарга ышаныч юк: йоклап калуың мөмкин. Күр, ничек мышный! Гаҗәп тә түгел: алар бүген көн буе уйнадылар, шаярдылар, чабыштылар... Анны абзар тазарттылар — әйбәтләп эшләп алдылар. Алмачуарның өстен чистарттылар. Тәннәре язылсын дип чыгарып йөрттеләр.

Алмачуар исенә төшү белән Галимҗанның йокысы очты да китте! Шәп тә соң ул Алмачуар! Аркасы буйлап әйтерсең кара тасма сузып салганнар! Ә бөтен гәүдәсе алма-алма чуар бит. Бәкәлләре нинди зифа үзенең! Ялы, койрыгы шундый матур булып дулкынланып тора, муены чын-чыннан дуга инде менә! Башы да бик нәфис, бик килбәтле! Күзләре искиткеч: шундый зур, шундый саф, йомшак карашлы! Тиресе хәтфә кебек елкылдап тора! Бу сылу айгырны саф токымлы дип әйтеп әйтә әтисе. Ул бөтен губернада дан тоткан чабышкы «Алмаз» токымыннан икән!

Үткән кыш башында Гыйрфан мулла аны рус алпавытының Агыйдел буендагы утарыннан барып алган иде. Галимҗанның әтисе атны беркемгә ышанмый, аны үзе карый, үзе ашата. Киләсе сабан туйга әзерли. «Безнең Алмачуар, һичшиксез, беренче булып килер!» — дип уйлый Галимҗан.

Алмачуар турында уйлана-уйлана, сәгатьнең яртыны сукканын ишетми дә калган икән. Унберне суга башлагач кына Галимҗан айнып китте дә Мохтарны төрткәли башлады. Тегесе исә икенче ягына гына әйләнеп ятты. Ниһаять, сабыры бетеп, Галимҗан аны чеметеп алды. Шуннан соң гына Мохтар мөгрәп, көч-хәл белән күзләрен ачты. Галимҗан аның колыннан тарткалап:

— Тор инде! Уян! Китәргә вакыт җитте!..— дип пышылдады.

Мохтар, күзләрен бер ачып, бер йомып, түшәк өстенә торып утырды. Ул әле дә ни өчен төн уртасында торырга, каядыр барырга кирәклеген исенә төшерә алмый иде. Янадан түшәккә аумасын дип, Галимҗан аны тарткалавын белде. Тагын пышылдады:

— Беләсеңме, сәгать күптән унберне сукты инде. Без Ишекле тауга барып җиткәнче унике булыр. Әйдә, тор!..

Мохтарның җылы түшәктән һич тә аерыласы килми иде. Галимҗанның үз сүзле икәнен белсә дә:

— Бармасак та була бит, — дип әйтеп карады.

— Әйттем ич мин сиңа: чичәкәйләрне күмгән чакта ни уйладың? Сүзеңдә тормаска исәбең бармы әллә?

Мохтар сүзендә тормаслык малай түгел ул. Торды. Шакирҗанны уятмас өчен, сәкедән әкрен генә төштеләр дә кичтән әзерләп куйган чикмәннәрен, түбәтәйләрен киеп, шыпырт кына ишегалдына чыктылар.
Җылы түшәктән соң тышта шактый суык кебек тоелды. Җилкәләрен җыерып, баскычта бераз басып тордылар. Аннары келәткә барып, кичтән әзерләп куйган шырпы, шәм, бау һәм пычакларын алып урамга чыктылар.
Күктә тулган ай йөзә. Әле болытлар артына качып, әле чыгып тирә-якны яктырта. Урам гадәттән тыш тын. Һичкем юк. Шуңа күрәдер, урам киңрәк, ниндидер тылсымлы булып күренә иде.
Дуслар туры юлдан китмәскә булдылар, чөнки, ай яктыртып торса да, төнлә турыга гына китү уңайсыз булыр шикелле тоелды аларга. Көнбатыш якка карап болын аркылы чишмә юлына кадәр барырга да, шуннан туп-туры Ишекле тау ягына борылып китәргә булдылар. Тауның ишеге ягыннан куышка керүе дә ансатрак.
Бөтен дөнья сагаеп, нидер тыңлаган сыман тынып калган... Малайлар, үз аяк тавышларыннан да курка-курка, тирә-якларына каранып баралар.
Инде ярты юлга җиттек дигәндә генә кайдадыр ат кешнәгән кебек булды. Бу аваз ничектер җир астыннан чыккан төсле тонык ишетелде. Малайларның котлары очып, баскан урыннарында катып калдылар, бер-берсенең кулына ябыштылар.
— Әйттем бит мин сиңа, төнлә йөрмик, дип! Хәзер инде җен безне ат булып алдарга уйлый!..
Мохтарның бу сүзенә Галимҗанның ачуы килде. Йөрәгенең дөп-дөп итеп типкәнен дә онытты ул. Атларны бик яраткангамы, убырлар ат кыяфәтенә керер дип башына да китерә алмады.
— Җен бервакытта да ат була алмас! Ат ул яхшы мал! Кешеләрне ярата торган хайван! Җен хәйләкәр төлкегә, ерткыч бүрегә, кара каргага әверелгән дисәң ышаныр идем!
Галимҗанның бу сүзеннән соң Мохтар тынычлана төште. Шулай да алар бер-берсенә якынрак елышып, алга таба атладылар. Басынкы гына кешнәгән ат тавышы тагын да якынрак ишетелде. Малайлар тагын туктадылар. Муеннарын алга сузып, үзләрен куркыткан хайванны күрергә тырыштылар, ләкин аның күләгәсен дә күрмәделәр. Югыйсә бит инде, ай яктысында алар аны күрергә тиешләр иде! Вак кына атлап тагын алга таба кузгалдылар. Ун адым да узмаганнардыр, чак кына чокырга төшеп китмәделәр. Яңадан ат кешнәгәне ишетелде. Бу юлы инде тавыш боларның нәкъ аяк астыннан, чокыр эченнән ишетелгән сыман булды. Малайларның исләре китте.
Мохтар чокыр кырыеннан читкәрәк тайпылды. Куркынган тавыш белән:
— Монда чокыр юк иде ич! Каян килеп чыккан бу? Ат та каян килеп монда төшкән? — диде.
Галимҗанның күңелендә туып та әле һаман ачыкланып җитмәгән бер сизенү инде тәмам ачыкланды. Шатлыгыннан аның тавышы яңгырап китте:
— Беләсеңме, бу — Салих абзый атыдыр. Әтинең әнигә сөйләгәнен ишеттем мин. Салих абзый атын тышаулап чишмә янында калдырган булган. Караңгы төшә башлагач барса, аты юк! Эзләп-эзләп тә таба алмаган. Ат чокырга төшеп киткән дә чыга алмый, күрәсең. Шәмне яндырып карыйк әле. Бурлы ат булса, Салих абзыйның байталы була инде ул!
Алар чокыр кырыена ятып шәм кабыздылар. Чыннан да, чокыр эчендә ат тора иде! Янында кеше барлыгын сизептер инде, ара-тирә башын чайкап, әкрен генә кешнәп тә куя.
Мохтар, куркуын бөтенләй онытып:

— Кара әле, дөрестән дә бурлы ат бит бу! — дип кычкырды.

Галимҗан бераз тыңланып ятты да:

— Ишетәсеңме? Чокырда су чылтырый! — диде.

Малайлар янә тавышка колак салдылар. Шулай шул! Суның чылтыразы аермачык булып ишетелә. Ат таптанганда су чайпалып китә. Малайлар, хәйран калып, эндәшмичә чокыр читендә беравык уйланып утырдылар. Аннары Галимҗан, тынлыкны бозып:

— Беләсеңме, Мохтар? Кондызлы күлнең суы җир астыннан нәкъ менә шушы турыда инеш булып та torгандыр, ә түбәнрәк ул без эчәргә су ала торган чишмә булып җир өстенә бәреп чыгадыр. Кызык бит, ә? — диде.

Мохтар, үзенең олырак икәнлеген күрсәтергә тырышып, каршы бер фикер әйтеп куйды:

— Алай булгач ни өчен соң бу җир моңарчы ишелмәгән? Моннан бит һәр вакыт атлар да, йөкле арбалар да узып тора.

Галимҗан тагын уйга калды. Чыннан да шулай ич. Чишмә әүвәләүвәлдән бар, әмма җир бервакытта да ишелми иде. Ә менә хәзер ишелгән! Гаҗәп хәл!.. Ничек болай булды икән?

Уйлана торгач, ул тагын бер фикергә килде:

— Беләсеңме, Мохтар? Бәлки башка җирләр Ишекле тау төсле ташлыктыр, туфрагы тик өстә генәдер. Ә менә бу җирдә таш юктыр. Шуның өчен су аны елдан-ел әкренләп юа-юа агызып алып китә торгандыр...

Бу сүзгә каршы Мохтар җанланып җавап кайтарды:

— Дөрес әйтәсең! Быел яз буе тәүлекләп яңгыр яуды. Бу да шуңа сәбәп булгандыр!

Малайлар тагын беравык тынып тордылар.

Мохтарның башына яңа бер уй килде:

— Кара әле, Галимҗан, әйдә, хәзер үк авылга чаптык! Салих абзыйны атың табылды дип сөендерик!

Галимҗан атны бик кызгана, аны тизрәк чокырдан коткарасы килә. Икенчедән, чичәкәйләрне дә казып аласы бар иде. Әтисе белән әнисенең сөйләшүләре тагын аның исенә төште. «Барыбер ат хуҗасы берүзе генә хайванны таба алмас»,— диде ич әтисе. «Аннары ул яшьләргә таң белән торып, Салих абзыйга булышырга кушкан»,— дип уйлады. Хәзер авылга кайтып, кешеләрне уятып йөрсә, әтисенең сүзенә каршы чыгу булыр кебек тоелды. Шуның өчен ул Мохтарга:

— Юк! Ат турында кайткач ук әткәйгә әйтербез. Хәзер, әйдә, эшне озакка сузмыйк, Ишекле тауга чаптык! — диде.

## 5

Артык маҗарага очрамыйча, малайлар Ишекле тауга барып життеләр дә күмелгән чичәкәйләрне казып алдылар. Кайтышлый тагын чокыр кырыенда бурлы атка карап бераз утырдылар. Аннары авылга кайтып киттеләр. Ай инде төн белән саубуллашып күңелсезләнгән, тоныкланган. Һава тагы да салкыная төшкән. Бөтнек, мәтрүшкә исләре аңкый. Таң алды суыгына калтыранып, малайлар житезрәк атладылар. Ниһаять, авылга да кайтып життеләр. Урамда бер җан иясе күренми. Ай да болыт астына кереп яшеренде. Тирә-юнь караңгылана төште. Аның каравы, йолдызлар яктырак яна башладылар. Алар күбәйгән, зурайган төсле күренәләр иде.

Авыл урамына керү белән малайлар кулга-кул тотынышып киттеләр. Бик саклык белән ян капканы ачып, ишегалдына керделәр. Капканың келәсен төшерделәр. Галимҗан әтисе белән әнисе йоклый торган зур бүлмәнең ишеген шыгырдатмаска тырышып кына ачты.

Мена сиңа кирәк булса! Бусага аркылы атлыйм гына дигәндә, чичәкәйләр тутырылган кап ишек бавына эләкмәсенме?! Кап Галимҗанның кулыннан ычкынып китте дә баскыч басмалары буйлап шалтыр-шылтыр тәгәрәде.

Өй эченнән Гыйрфан мулланың тавышы ишетелде:

— Кем бар анда?..

Балалар, баскан урыннарыннан кузгалырга куркып, тын калдылар. Җавап ишетелмәгәч, мулла дәһшәтлерәк тавыш белән:

— Кем йөри анда? — дип кычкырды. Ул урыныннан калкынуга, Хәсәнә остабикә дә уянды. Көтмәгәндә шау-шу куптаруына аптыраган Галимҗан, ниһаять, телгә килде:

— Бу — без, әткәй. Мохтар белән мин...

Әтисе, карават читенә утырган хәлдә, аларны ачуланырга кереште.

— Ни пычагыма төн уртасында сукбайланып йөрисез? Ни булды?

Шунда арага әнисе керде:

— Кычкырынма инде, әтисе. Габделхәкимне уятасың. Балаларның эчләре авырткандыр да тышка чыкканнардыр.

Алдашып өйрәнмәгән Галимҗан:

— Безнең бер җиребез дә авыртмый... — диде дә, төнлә йөрүләрен ничек аңлатырга белмичә, шып туктап калды.

Әтисенең ачуы басыла төшкән иде инде.

— Алай булгач, ни дип төн уртасында йөрисез?

Мохтар түзмәде:

— Ә без, Гыйрфан бабай, Салих абзыйның югалган атын таптык! — дип ычкындырды. Мулла Мохтарның әтисе белән бертуган булса да, малай аны «бабай» дип эндәшә иде.

Гыйрфан мулла малайның сүзенә ышанмады:

— Әллә төшегездә күрдегезме? Бикле капка аркылы ул ат безнең ишегалдына ничек килеп кергән?!

— Без аны ишегалдында түгел, Ишекле тауга барганда күрдек.

— Анда ни эшләп йөрдегез?..

Әтисенең тавышы Галимҗан көткән дәрәҗәдә үк ачулы түгел иде. Малайга җан керде. Ишекле тауга ни өчен барганнарын һәм анда чокырга төшкән атны күргәннәрен җентекләп сөйләп бирде.

Гыйрфан мулла урыныннан торып киенә башлады. Остабикәсенә:

— Инде дүртенче сәгать икән, анасы. Барыбер артык йоклап булмас. Атларны карап чыгыйм да Салихка барып килим. Атын уйлап бичараның күзенә йокы кермәгәндер. Яхшы хәбәр ятып калмасын,— диде. Аннары, балаларга таба әйләнеп, йомшак кына итеп әрләп алды: — Ә сез, көш-көш! Ятыгыз! Бүтән болай йөрисе булмагыз! Башыгыз бармы? Төн буена капка ачык калсын, имеш! Әгәр Алмачуарны караклар алып киткән булса, ни эшләр идегез?!

Әтисенең бу сүзен ишеткәч, Галимҗанның бөтен тәне чымырдап китте. Чыннан да бит! Ничек ул бу турыда уйламады икән? Андый хәлнең булуы бик мөмкин. Алмачуар бит ул теләсә кем кызыгырлык, карап туймаслык айгыр!

Галимҗан әтисенә ияреп ишегалдына чыкты. Сөекле Алмачуары беркая да китмәгәнен үз күзе белән күргәч кенә күңеле тынычланды.

### 6

Җәй дә килеп җитте. Ул үзе белән төрле кызыклар, уеннар гына түгел, эш һәм мәшәкатьләр дә алып килде.

Яз башында коеп яуган яңгырлар тугайларны туйганчы сугарган икән: үлән бик яхшы уңган, ир кешенең биленнән булган. Димәк, әтисе быел да өмә ясар. Әтисе генә түгел, авылның хәллерәкләреннән тагын

бер-ике кеше өмә ясамыйча булмас. Менә кайчан кызык ул, менә кайда уен-көлке!

Син иртүк, һавада таң сандугачларының сайраулары әле яңгырап бетмәгән чакта ук, йокыдан уянасың. Әнисе, булышырга дип килгән Хәтимә җиңги белән бергә, өмәгә җыелган кешеләрне кайнар белен, кабартмалар, шикәрле-сөтле чәй белән сыйлый башлаган инде.

Кешеләр ашап-эчеп алганчы ялчы Әхми белән бер-ике егет атларны арбаларга җигеп өлгертәләр. Арбаларга төялеп тугайга барып җиткәнче, таулар артында күк йөзе инде алсулана башлый. Күп тә үтми, дөньяга якты нурларын чәчеп, ашыкмый гына кояш калка. Аның нурлары үлән яфракларында мөлдерәп торган чык тамчыларына күз ачып йомганчы килеп орыналар да киң болын өстенә җем-җем иткән энҗеләр сибеп уйный башлыйлар. Ә һавасы! Һава шундый саф, шундый хуш исле, шундый рәхәт! Уен-көлке, бер-береңне үртәшү, шаяртып-төртеп җырлаулар, ярышу-әйтешүләр!..

Төш вакыты җитүгә, авыл ягыннан арба күренә. Арбага, як-ягына ике зур төргәк куеп, аларны юрган белән каплап, Хәтимә җиңги утырган. Бер төргәктә капкачын бик ныклап каплаган казан, казанда исә симез сарык итен мул итеп салып пешергән куе, тәмле өйрә. Икенче юрганны ачып җибәрсәң, мичтән яңа чыккан кайнар, йомшак күмәчләр! Ашап-эчкәч, су кергәннән соң күләнкә ясап, арба астына кереп ятулары да искиткеч рәхәт!

Галимҗан өчен иң күңеллесе кибән салу иде. Арбаны кендегеннән чыгарып, ике тәгәрмәчле алгы күчәрен арткы ягыннан аерып аласың. Хуш ис аңкып торган чүмәләне бау белән чалдырып, шул алгы күчәргә бәйләүләре белән, печән өстенә сикереп менәсең дә атны кибән салган төшкә йөгертәсең! Анда бауны чишүгә, тирле тәнеңне җиләсләтеп, атны чүмәлә алырга кире куасың! Менә шулай көн үткәнен сизми дә каласың!

Печәннән соң башка кыр эшләре дә килеп җитә. Арыш өлгерә. Арыштан соң бодай, Шакирҗанга да, Галимҗанга да бу вакытларда эш бик күп була...

Җәй көннәре тоташтан кыр эшләре, хуҗалык мәшәкатьләре белән генә үтми, әлбәттә. Галимҗан урманда җиләк, чикләвек, хуш исле мәтрүшкә җыярга да ярата. Әнисе, мәтрүшкәнең миләүшә төсендәге чәчәкләрен, баш яфракларын чәй шикелле парлап, суык тигән чакларда эчерә. Башка яфракларын кыяр тозлаганда кулланa.

Галимҗан бигрәк тә малайлар белән төнлә ат көтәргә ярата иде. Менә бүген дә ул Шакирҗан абыйсы белән авыл малайларына кушылды. Өйдән ипи, йомырка, тоз, чи бәрәңге алып, атларга атландылар. Өченче атның тезгенен Шакирҗан үзе менгән атның йөгәненә бәйләде. Алмачуар, әлбәттә, өйдә, абзарда калды.

Малайлар, шаярыша-шаярыша, атларын Кинҗәгол тавы ягына каратып чаптырдылар. Анда, текә яр астында, бормаланып-сырмаланып Аургазы елгасы ага. Су буйларын куе сусыл үлән каплап алган.

Килеп житкәч, малайлар атларын тышаулап көтүгә җибәрделәр. Үзләре учак ягарга коры чыбык-чабык эзләп киттеләр.

Кояш баеп бара иде инде. Тирә-як әкрен генә караңгыланып килә. Һава салкыная башлады. Күк йөзендә анда-санда гына йолдызлар да җемелди. Малайлар учакны ягып җибәрделәр дә үзләре белән алып килгән азык-төлекләрен чыгардылар. Бәрәңге пешерер өчен күмер төшкәнне көтеп, учак тирәсенә җыелдылар.

Эссе бәрәңгене учларында тәгәрәтә-тәгәрәтә, сап-сары булып көйгән кабыгын кетердәтеп ашый башлаганда тәмам караңгы төште. Йолдызлар күбәйде, алар яктырак җемелди башладылар. Төрле кызык сүз сөйләшә торгач, төн уртасы җитте.

Малайларның берсе Галимҗанның җиңеннән тартты:

— Берәр әкият сөйлә әле, Галимҗан, югыйсә, йокы баса башлады!

Галимҗан сискәнеп китте. Ул ниндидер уйларга батып онытылып утыра иде. Су өстендә уйнаган кызгылт шәүләләр дә, шомлы кара төскә кергән су үзе дә, җемелдәп торган йолдызлар да аны ниндидер бер сихерле көч белән үзләренә тарта, сагышландыралар иде. Малайларның үтенечен кире какты ул:

— Юк, әнә, Садыйк сөйләсен. Ул әкиятне күбрәк белә, — диде.

Садыйк мондагы малайлардан өч-дүрт яшькә олырак иде. Малайлар арасында чыннан да матур итеп әкият сөйли белүе белән дан тота ул. Сөйләгәндә үзенең хыялында туган уйдырмаларын кушып әкиятне бизи белә. Ул сөйләгәндә әллә кайчан ишеткән әкиятләр дә өр-яңа кебек тоела. Малайлар Садыйкның чабуына ук ябыштылар:

— Дөрестән дә, Садыйк, сөйлә әле!

— Кот очарлык әкият булсын!..

— Су анасын сөйлә!..

Ябык, озын буйлы, тар күкрәкле Садыйк учакка якынрак килеп утырды. Бераз вакыт зур соры күзләрен утка төбәп, уйланып торды. Кулына чыбык алып, утлы кисәүләрне аралаштырды. Аннары нигәдер елмаеп куйды. Чыгынкы яңаклы битендәге елмаюын сүндермичә генә, сабырсызлык белән көтеп торган малайларны күздән кичерде. Аннары:

— Ярар, алайса, мин сезгә су анасы Гөлбану турында сөйлим. Тик бүлдерештән түгел! — диде.

Малайлар бер-берсенә тагы да елыша төштеләр. Садыйк исә, тезләрен кочаклап, елга ягына карап утырды. Ут аның яңагына кызыл шәүләләр төшереп уйный иде...

Әкиятне болай дип башлады ул:

— Бу әкиятне мин Әбдрәшит бабамнан ишеткән идем. Шушы безнең Аургазы буенда, әнә теге тегермән янында булган хәл ди торган иде ул. Менә шулай...

Борын-борын заманда, каз — губернатор, үрдәк — урәдник, эт — түрә булган вакытларда, Аургазы елгасы буенда, кечкенә генә бер өйдә, үзенең бердәнбер кызы белән көтүче карт яшәгән. Бу кыз матурлардан да матур булган. Аның янына хан кызларын бастырсаң, алар гөлчәчәк янындагы кыр чәчәкләре кебек кенә булып калырлар иде ди. Кызның үз исеме Галиябану икән. Ә яңа ачыла башлаган гөлчәчәккә охшаганы өчен ана Гөлбану дип дәшә торган булганнар. Матурлыгы өстенә бик йомшак күңелле дә икән бу кыз. Кемгә ярдәм кирәксә, авырсынмый булыша. Берәрсе кайгы-хәсрәткә тарса, ул кешенең кайгысын уртаклаша икән. Шуның өчен кызның баскан эзендә чәчәкләр калкып чыга, кулы нәрсәгә генә тимәсен, ул әйбер яңарып, нурланып китә ди. Күп егетләр аңа өйләнергә теләсәләр дә, ул аларның берсенә дә әйләнеп тә карамый ди, чөнки күрше авыл баена урманда утын кисәргә ялланган Сәгыйт исемле бер егеткә гыйшык тота икән.

Бу яшь егет әтисенең өченче улы икән. Үзләре фәкыйрь ди. Шуңа күрә әтиләре олы улларын өйләндерергә дә акча арттыра алмый икән. Үзегез уйлап карагыз, абыйлары буйдак булып йөргәндә бу егет өйләнү турында әтисенә берәр сүз әйтә аламы соң? Урманга барганда ул көтүченең өе яныннан уза, кызга багышлап җырлар җырлый икән. Гөлбану да, Сәгыйтнең җырын ишетү белән, көянтә-чиләкләрен ала да, суга барам дигән булып, өеннән йөгереп чыга ди. Яулыгының очы белән битен каплап, егетнең җырын тыңлап тора, артыннан карап кала икән.

Көннәрдән бер көнне Гөлбану кыюланып егеткә:

Яшел чирәмнәр өстендә
Чәйләр эчәсем килә,
Кемгә җырлар багышлыйсың,
Шуны беләсем килә,

— дип җырлаган ди.

Бу жырны Сәгыйт кенә түгел, су иясе дә ишетеп калган. Көтүче өендә күзгә дигән нәрсә кайдан килсен! Шунлыктан Гөлбану, басма өстенә басып елгадан су алганда, иң элек, көзгегә караган төсле, бөгелеп суга карый икән. Менә шунда су иясе кызны күреп, аңа гашыйк булган. Кызның жырын ишеткәннән соң Сәгыйт ничаклы куанса, су иясенең йөрәген шул чаклы явызлык, көнчелек уты яндыра. Нинди генә булса да юл табып, кызның күңелен Сәгыйттән кайтарырга, аны үзенә каратырга уйлый ул. Әгәр инде Гөлбану аның байлыгына кызыкмаса, су иясе матур кызны үзенең су астындагы сараена көчләп алып китәргә ниятли.

Көннәрдән бер көнне, Сәгыйт күздән югалгач, кыз инде суга барыйм дип елга ягына караса, ни күрсен: алдында бик матур, әйтеп бетергесез бай киемле бер егет тора. Гөлбану аптырап кала. Яулык чите белән битен капларга да оныта.

Бу — су иясе икән. Гөлбану Сәгыйтнең артыннан карап калган арада, ул судан чыккан. Бу вакытта аны берәр кеше күргән булса, йөрәге ярылып үләр иде. Чәче-сакалы ямь-яшел, озын, юеш. Күзләре балык күзе кебек төссез, зур икән, менә хәзер жиргә тәгәрәп төшәрдәй булып кабарып торалар икән. Авызы чуртан балыгыныкы төсле зур ди. Тик ул судан жиргә чыгу белән теләсә нинди кыяфәткә керә белә икән. Гөлбану янына килгәндә инде ул искиткеч матур егеткә әверелә. Йөзе тулган ай төсле нур чәчеп тора, тик күзләре генә әүвәлгечә зур, куркыныч икән. Аның күз карашыннан Гөлбануның йөрәге өшеп китә. Куркуыннан кыз артка чигенә. Шул вакыт су иясе Гөлбануга:

— Син курыкма миннән, матур кыз! Мин сине кыерсытмам, рәнжетмәм! — ди. — Дөньяда сине минем кебек яраткан адәм баласы юктыр. Әгәр син миңа кияүгә чыксаң, мин сине баштанаяк алтын-көмеш, асыл ташлар белән бизәрмен, — дип әйтеп әйтә икән.

Гөлбану, коты алынып, тагы да арткарак чигенгән дә әйткән:

— Юк, юк! Миңа синең үзең дә, байлыгың да кирәкми. Мин куркам синнән!.. — дигән, көянтә-чиләкләрен жиргә ташлаган да качып киткән. Куркуыннан өч көн, өч төн өйләреннән чыкмаган.

Сәгыйт, аны өч көн күрмәгәч, көтүче картның өйдән чыгып киткәнен көтеп тора да, барып кызның тәрәзәсен чиртә. Шуннан соң гына кыз тәрәзә пәрдәсенең читен күтәреп тышка караган. Сәгыйтне күреп бик шатланган һәм аңа теге су иясе турында сөйләгән.

Шунда инде кыз белән егет сүз куешканнар: безгә туй да, бер нәрсә дә кирәкми, дигәннәр. Егет көтүче карт белән дә, үзенең әтисе-әнисе белән дә сөйләшергә, аларның хәер-фатихаларын алып, кыз белән никахлашырга, көтүче картның өенә күчеп килергә була.

Алар шулай иткәннәр дә. Кыз белән егет өйләнешеп бик тату гына гомер сөрә башлаганнар.

Тик су иясе һаман да кызны су астына алып китү уеннан кайтмаган. төрле хәйләләр эзләгән. Бер көнне ул Сәгыйтнең эшкә киткәнен күреп кала да бераз вакыттан соң судан чыга. Сәгыйт ялланып эшләгән байның ялчысы кыяфәтенә керә. Тәрәзәгә килеп картны чакырып чыгара да болай ди:

— Әхмәт бабай, бай сине тизрәк урманга барсын, диде. Сәгыйт анда казага очраган ди.

Карт бик куркып:

— Ни булды икән? Урман зур бит ул. Мин аны ничек табармын соң? — дип кабалана башлый.

— Ни булганын мин белмим. Бу турыда бай миңа бер нәрсә дә әйтмәде. Сәгыйт Шайтан яры дигән жирдәге кишәрлектә икән, — ди су иясе.

Әгәр иртә белән юлга чыксаң, бу Шайтан ярына тик көн уртасында гына барып житәсең икән.

Карт ашыга-ашыга урманга китә. Гөлбануны борчымас өчен бу хакта аңа бер сүз дә әйтми. Башта барып үзен күрим, бәлки куркырлык хәл юктыр, дип уйлый. Кызына:

— Ни өчендер бай мине бик ашыгыч чакыртып җибәргән,— дип кенә әйтә дә өеннән чыгып китә.

Карт Шайтан яры тирәсендә никадәр эзләнсә дә, никадәр кычкырып чакырса да, Сәгыйтьне таба алмый. Ул тәмам хәлдән таеп, җил аударган бер агач өстенә утыра да: «Мине шайтан вәсвәсәгә салмыймы икән? Әллә ялчы берәр нәрсә буташтырдымы икән?» — дип уйлана.

Күптән түгел Сәгыйтьнең яшен суккан карт имән янындагы кишәрлектә эшлим дип сөйләгәне исенә төшә аның.

— Шуннан барып карыйм әле, — дип, карт аякларын көч-хәл белән кузгатып, шул якка китә.

Барса, Сәгыйть чыннан да шунда икән. Ул инде кискән утыннарын арбага төйи башлаган. Шөкер ходайга, сау-сәламәт икән!

Бабай ни өчен килгәнен сөйләп биргәч, Сәгыйть бик борчыла. Икәүләп утыннарны арбага тиз-тиз төйиләр дә өйгә кайтырга ашыгалар. Бу вакытта инде кояш байый башлаган була.

Көтүче карт урманга киткәч, су иясе кызның әтисенә әверелә дә, өйгә кереп, Гөлбанудан чәй сорый. Гөлбану аңа:

— Өйдә бер тамчы да су юк, әткәй. Үзең беләсең бит, ялгызым суга барырга куркам мин,— дип җавап бирә.

— Алай булгач, әйдә, кызым, бергәләп барыйк. Мин сине саклап торырмын, — ди Әхмәт бабай кыяфәтенә кергән су иясе.

Гөлбану көянтә-чиләкләрен алып аның артыннан суга китә. Кыз басма өстеннән иелеп чиләген суга батыру белән, су иясе үз кыяфәтенә кереп, кызны басмадан сөйрәп төшерә дә су астына алып кереп китә. Бичара кыз кычкырырга да өлгерми. Менә шулай, су иясе мәкерле хәйлә белән Гөлбануны үзенә ала, аны сихерләп су анасы ясый.

Карт белән Сәгыйть Гөлбануның өйдә юклыгын күргәч, елга буена йөгереп төшәләр. Басма өстендә аның бер чиләге белән көянтәсен, басманың бер тактасына эләгеп калган яулыгын күрәләр. Шунда гына ни булганын белеп алалар. Кайгыларының иге-чиге булмый. Күп тә үтми, әтисе хәсрәтеннән үлеп китә. Сәгыйть исә үз авылына кайтып китә.

Гөлбану су анасы булгач, коры җирдә яши алмый инде. Аның каны суына, үткән гомерен оныта. Шулай да күңелендә ниндидер сагыш кала аның. Менә шул сагышы айлы кичләрдә аны ярга тарта икән. Басма өстенә чыгып утыра икән дә ул, яшел төскә кергән озын чәчләрен алтын тарак белән тарый-тарый моңлы җырлар җырлый икән. Таң вакытында, әтәчләр кычкыра башлагач, үзе яшәгән өйгә соңгы тапкыр күз ташлый да әкрен генә суга чумып китә икән...

Садыйк сөйләп бетергәндә, Галимҗан, әкият тәэсиренә бирелеп, күзләрен елгага текәп уйланып утыра иде. Тоныч су өстендә чагылган сыек ут шәүләләре аның күзенә әле яшел чәчле су анасы, әле куркыныч кыяфәтле су иясе булып күренәләр. Һәрбер дулкын чайкалуыннан аның йөрәге коточкыч бер нәрсә көткән төсле кысылып, туктап калган сыман була. Судан Гөлбану килеп чыгар да бетмәс-төкәнмәс сагыш тулы матур күзләре белән Галимҗанның күзләренә карар төсле тоела иде...

Башка малайлар да тынып калганнар. Кайберәүләре яр буеннан ераграк та китеп утырганнар. Күрәсең, аларның да йөрәкләрен шундый бер курку баскан иде.

Көнчыгышта күк йөзе алсулана, торган саен кызара, ялкынлана башлады. Тәмам яктырып җиткәч, малайлар битләрен юарга дип елгага таба чаптылар. Алар тизрәк авылга кайтырга ашыгалар иде.

Галимҗан тегермән буасына таба китте. Шунда ул яр читенә якын гына су эчендә ниндидер сәер бер нәрсә күреп алды. Бу нәрсә суга бер батып китә, бер калкып чыга иде. Галимҗан тукталып күзләрен уды,

эллә күземә ялгыш кына күренәме? дип уйлады. Юк! Ярга җитәргә берничә адым калды дигәндә, бу нәрсә Галимҗанның күзенә адәм гәүдәсе кебек булып күренде. Үз күзенә үзе ышанмыйча, шып туктады. Йөрәге дөп-дөп тибә башлады. Куркуга бирешмәскә тырышып, тагын берничә адым атлады. Шулай! Шиксез! Су эчендә бер яшь хатынның гәүдәсе ята иде. Өстендә бала итәкле чуар күлмәк, ак алъяпкыч. Чәч толымнарына эләгеп калган яулыгы...

Суга батып үлгән бу хатынның кыяфәте һәм төнлә Садыйк сөйләгән әкияттәге Гөлбануның фаҗигале язмышы малайның хыялында бергә кушылып, йөрәгенә дәһшәт салды. Ул ике кулы белән битен каплады да илереп кычкырып җибәрде. Ләкин үз тавышын ул үзе ишетмәде. Аның тавышын иптәшләре ишеттеләр.

## 7

Ат сакларга барган малайлар тегермән буасы янында су өстенә калкып чыккан яшь бер хатын гәүдәсе күргәннәр дигән хәбәрне ишеткәч тә, Мохтар Галимҗаннарга чапты.

Ян капкадан килеп керү белән, бакчадагы сәке өстендә мендәргә таянып яткан иптәшенә кул болгап:

— Монда нишләп ятасың?! Әйдә, киттек! Бөтен халык тегермән буасы ягына агыла!..— диде.

Галимҗан җавап кайтарып өлгермәде, бусагада Хәсәнә остабикә күренде. Мохтарның сүзләрен ишетеп өйдән чыккан икән ул.

— Аның анда күргәне артыгы белән җиткән! Күрмисеңмени: йөзендә чырае калмаган бит! Беркая да бармас ул! — дип кырт кисте остабикә.

Шушы сүзне ишеткәч кенә, Мохтар дустының йөзенә текәлебрәк карады. Чыннан да, Галимҗан агарынган, бик нык әсәренгән кебек күренә иде. Шулай да ул:

— Әнкәй, мин Аургазы буена бармам. Урамга гына чыгыйм инде! — дип үтенеп карады, ләкин анасы риза булмады:

—Юк дигәч юк! Ә син, Мохтар, котыртып йөрмә аны. Бүген үзең генә уйна! — диде остабикә.

Шуннан соң Мохтар бер сүзсез урамга чыгып китте. Галимҗан да, күңелсезләнеп, аның артыннан карап калды.

Бер хатынның суга батып үлүе турындагы хәбәр бөтен авылны аякка бастырган икән. Урамда халык гадәттән тыш күп иде. Һәркайсының телендә шул вакыйга.

— Бичара! Кем икән ул? Кем кызы икән? Безнең авылныкымы, түгелме икән? Үзе батып үлдеме икән? Үзе батып үлгән булса, яхшы көннән түгелдер инде! — диләр хатыннар, суга батып үлүчене кызганып. Ул арада юраучылар да табыла:

— Бу, мөгаен, Югары авыл Гайшә кызы Фатыймадыр! Ире аның өстеннән бик йөри, дип сөйлиләр иде. Кайнанасы да бик явыз икән...

— Тукта әле! Безнең үз авылыбызныкы булмагае! Салиха карчык килененә бер дә көн бирми иде бит! Ничә тапкыр үз күзем белән күргәнем бар бичара Зөләйханың үксеп-үксеп күз яше түккәнен! Әйдә, барып карыйбызмы?

— Безнеке ачуланмасмы дим. Әнә бит үзе дә урамда йөри әле. Ирләрдән узып кая барасың?!

Ирләрнең кайгылары да, сүзләре дә башкачарак:

— Яшь кешенең шулай булуы, — ай-һай, сөйләп торасы да юк инде, бик кызганыч! Тик, нишләсәң дә, үлгәнне терелтеп булмый шул инде...

— Җәйге эшләрнең нәкъ кызу чагына туры килде бит! Инде урядниклардан, приставлардан котыла алмассың. Бөтен авылның астын өскә китерерләр!

— Әйтерең бармы, Хәйрулла! Җәйнең бер көне ел туйдырыр, дигәннәр, ә ул имансызлар судка да тартырлар әле. «Дөресен әйтегез: кем аны үтереп суга ташлады, кем батырды?» дип йөдәтерләр!

— Старостага әйтеп карасак, нишләр икән? Волость-урядникләргә белдермичә генә үзара үлекне танырга да, шунда күмәргә рөхсәт итсә, ни дә яхшы булыр иде дим. Зур бәладән котылыр идек! Син ничек уйлыйсың, Сафа?

Сафа дигәне ни әйтергә дә белмичә, башын селкеп уйланып торган арада, урам буйлап Юныс хәзрәт белән Гыйрфан мулла килгәне күренде. Сафа, Хәйруллага җавап бирүдән котылуына куанып:

— Әнә, берьюлы ике мулла килә. Алар белән киңәшергә кирәк. Алар ни дип әйтсә, шул булыр, — диде.

Муллалар якынлашу белән, мужиклар, кулларын күкрәкләренә куеп, сәлам бирделәр. Муллалар сәламне кабул итеп җавап кайтаргач, Хәйрулла кыюсызрак тавыш белән сүз башлады:

— Безгә бер киңәш бирсәгез икән... — диде дә тамак кыргалап алды.

Юныс хәзрәт тә, Гыйрфан мулла да сүзнең суга баткан хатын турында булачагын аңлыйлар иде. Чөнки шушы хәбәр аркасында ирләрнең дә, хатыннарның да эшләрен ташлап урамга чыгулары аларның күз алдында иде. Шулай да алар Хәйрулла белән Сафаның тел төпләрендә ни барлыгын чамалап бетермиләр иде әле.

Хәйрулла үзенең фикерен аңлаткач, Гыйрфан мулла: «Юныс хәзрәт миннән олырак, бәлки киңәшне ул бирер», — дигән сыман аңа күтәрелеп карады. Ләкин карт хәзрәт мондый эштә киңәш-уңаш бирергә теләмәде, Гыйрфан муллага:

— Син миңа караганда күп яшь. Дөнья эшләрен миннән яхшырак беләсеңдер, — дип, киңәш бирүне аңа йөкләде.

Әйткән фикере анык аңлашылсын өчен, Гыйрфан мулла һәр сүзенә басым ясап:

— Юк, юк, Хәйрулла туган! Кыңгыр эш кырык елдан соң да беленә ул. Кыңгыр эшнең өсте ачылгач ни булачагын уйлыйсыңмы?! Бәланың иң зурысы менә шунда булачак...— диде.— Аннары, ул бәхетсез хатынның кем икәнен дә, үзен-үзе үтергәнме, ягъни катиле нәфес иткәнме, яисә аягы таеп, башы әйләнеп егылган да суга батканмы — без бит әле берни дә белмибез. Староста дисез. Аның да башы ике түгел, бер генә. Закон кушканны эшләр. Ул инде бу кара хәбәрне ишеткәч үк волость правлениесенә кеше җибәргәндер.

Гыйрфан мулланың фикере дөрес, әлбәттә. Шулай да мужикларның күңелләре тыныч түгел иде. Алар тугры сүзгә җавап таба алмыйча, башларын түбән иеп, мулла абзыйлары артыннан күпергә таба киттеләр.

Алар тегермән буасы янына килеп җиткәндә, су читенә халык байтак җыелган иде инде. Бер читтәрәк, битләрен яулык очы белән каплап, хатыннар басып тора. Алар тирәсендә бала-чага чуалыша. Су кырыенарак өстәл белән дүрт урындык та китереп куелган. Бер урындыкка урядник, икенчесенә, муенына түгәрәк медаль тагып, кибетче Мәхмүт утырган. Ниндидер эш белән урядник үзе Солтанморатка килеп чыккан икән. Шунлыктан аңа хәбәр бирер өчен Корманай авылына ат чаптырырга да кирәк булмаган.

Муллаларның килгәнен күреп, староста урядниктән:

— Ике пунәтәй кирәк дип әйткән идең. Мулла абзыйларны чакырсак ничек булыр? — дип сорады.

Урядник күп уйлап тормыйча:

— Чакыр! Кем булса да, миңа барыбер,— диде.

Староста кулын болгап муллаларны чакырды, аларга моңарчы буш торган ике урындыкны күрсәтте. Мулла абзыйларның исем-фамилиялә-

рен сорашканнан соң, урядник протокол яза башлады. Ниһаять, язуыннан туктап, старостага:

— Халыкка кычкырып әйт: берәм-берәм килеп үлекне карасыннар. Бәлки танучы кеше табылыр. Үзең мәетнең битен барып ач, — дип әмер итте.

Урядникнең бу сүзен ишеткәч, Гыйрфан мулла старостага:

— Ир кешеләргә хатын-кызларга күз салу нәмәхрам [1] булгач, алар хатын-кызларны каян танысыннар? Бигрәк тә безнең авылныкы булмаса. Әнә, монда гына бер көтү хатыннар, карчыклар тора. Башта шулар карасалар иде. Инде алар танымаса, аннан ир-ат караса да булыр... — диде.

Өстәл тирәсендә утырганнарның үзара сөйләшкәннәрен халык дикъкать белән тыңлап торган икән. Старостаның муллага ни дип җавап биргәнен дә көтмичә, хатыннар арасыннан:

— Тагын бер тапкыр карамасам да, мин аны бик яхшы таныйм,— дигән тавыш ишетелде. Мулла да, староста да ялт итеп шул якка карадылар. Бу — Солтанморатка гына түгел, Иске Кәлчер авылына да «мин беләмлеге», усал, үткен теле, кызу табигате белән атаклы булган Салиха карчык иде. Хәзер дә ул тартынмыйча ирләр арасына килеп басты һәм яулыгының очы белән иреннәрен сөртә-сөртә сөйләргә кереште:

— Әйттем ич, мин аны әллә кайчан таныдым дип. Алъяпкычымны чишеп, аның битенә каплаган чагымда ук менә Гөлзифага: «Бу — минем кодагыйның туганнан туганы Мәстүрә кызы Зәйнәп дип әйткән идем. Аны Иске Кәлчер авылыннан Корманай авылына кияүгә биргәннәренә әле ике ел да тулмагандыр...

Салиха карчыкның тыны кысылды бугай, ул тирән итеп бер сулады да, артына әйләнеп, хатыннарга таба бармагын төртеп күрсәтте:

— Миңа ышанмасагыз, әнә Гөлзифадан сорагыз!

Уен-көлке урыны булмаса да, кайберәүләр түзмәде, Салиха карчыкның бу кыланышыннан көлеп җибәрделәр. Урядник бераз татарча белсә дә, сабыры беткәнгәме, старостага карап русча кычкырынды:

— Что она там трещит без конца, как сорока?! Пусть отвечает только на вопросы!

Салиха карчыкны староста шелтәләп алгач, урядник татарчаны үзенчә боза төшеп сораулар бирә башлады:

— Бү үлек катынга исем-фамилия ничек?

Салиха кулы белән ботына сугып куйды:

— Пәрәмәч! Кара син аны: тагын сорый бит! Әйттем ич инде: бу — Иске Кәлчер авылыннан Мәстүрә кызы Зәйнәп дип! Аның памилиясен мин каян белим? Әткәсенең аты дисеңме? Аның әткәсен Иске Кәлчердә белмәгән кеше юк! Черегән бай инде! Корманайдагы зур базарның берсеннән дә калмый. Кызын да, менә шушы Зәйнәпне дә, шул Корманай базарында килешеп кайткан булган... Әткәсенең аты дисеңме? Әйтмәдемме әле? Аның аты — Мортаза бай, Мортаза! Акча өчен, мал өчен җанын фида итәр. Шуның өчен аңа Малпәрез [2] Мортаза дип әйтәләр...

Суга батып үлүченең Иске Кәлчер авылы кызы, Корманай авылы килене икәнлеге аңлашылгач, мәетне волостька, ягъни Корманайга алып китәргә булдылар. Бусы урядник өчен һәр яктан уңайлы иде. Волостьта фельдшер дә бар. Бу хатынны үтереп суга ташлаганнармы, әллә ул үзе батып үлгәнме, фельдшер шуны ачыклар. Урядникнең үзенең өе дә шунда. Тикшерү эшләре беткәнче җиде чакрымны арлыбирле үлчәп йөрергә туры килмәс. Юл уңаеннан, Иске Кәлчердә тук-

[1] Нәмәхрам — хәрам, ягъни шәригать буенча ярамый, гөнаһ.
[2] Малпәрез — малга табынучы.

тап, мәрхүмнең эти-энисенә кызларының фаҗигале үлеме турында хәбәр итәргә, аларны Корманайга алып китәргә мөмкин. Шуларны уйлап, урядник сорауларын, протоколын артык сузмаска булды.

Староста, мужикларны күздән кичереп:

— Ат-арба бирү чираты кемдә? — дип сорады.

Ирләр төркеме арасыннан Хәйрулла атылып чыкты. Башка вакыт булса, бәлки болай ук ашыкмас та иде, ләкин хәзер ул ни өчендер үзен бу бәхетсез яшь хатын алдында гаепле кебек тоя иде.

Хәйрулла арбасына калын итеп печән түшәп килүгә, мәетне күтәреп арбага салдылар һәм Зәйнәпнең җансыз гәүдәсен аның туган авылына алып киттеләр.

Хәсәнә остабикә үзе дә тегермән янына бармады, Галимҗанны да җибәрмәде.



## Кадим мәдрәсәдә

### 1

Унтугызынчы гасырның азаккы айлары.

Көннәр кыскара, караңгылана бара. Агачлар инде яшелекләрен җуйганнар. Аларның карайган юеш ботакларында саргаеп суыкта куырылган яфраклар калтырана — беренче салкын җил исү белән өзелеп төшәргә торалар. Күк йөзен әледән-әле соры болытлар каплап ала. Алар кургаш төсенә кереп, авыраялар, җиргә таба шуып төшәләр кебек... Шыбырдап көзге вак яңгыр ява башлый. Мәдрәсәгә китү вакыты көннән-көн якынлаша бара...

Мәдрәсәдәге әчегән аш, күптән мунча күрмәгән тирле тән, ишек янына өелгән чүп-чар исләре аңкып торган тынчу һава хәтеренә төшү белән, Галимҗанның бер дә өйдән китәсе килми иде. Ләкин бу көн дә килеп җитте. Әнисе төенчекләргә ике каз, сумсалар, майда кыздырылган сарык ите һәм башка ашамлыклар төйнәп, арбага чыгарды. Шакирҗан белән Галимҗан китап тулы букчаларын алып, арбага менеп утырдылар. Әтиләре кулына дилбегәне тотты. Ялчы Әхми капканы ачып җибәрде. Хәсәнә остабикә, күз яшьләрен сөртә-сөртә, балалары артыннан карап калды...

Мәдрәсә һаман шул. Былтыргыга караганда бертөрле дә үзгәреш юк. Су урамы белән Татар тыкрыгы чатында — беренче каты яртылаш җиргә иңгән таш бина. Гарәпчә «Каедкый-ятән вакуфи фиәлсудебни палата. 1872 сәнә[1]» дип таш стенаны казып язган сүзләр. Тәрәзә пыялалары юылмаган. Ватыклары урынына фанер такта, иске киез кисәкләре кагып куелган. Бусаганы атлап керүгә, ишек янында бер өем чүп-чар, комганнар, пычрак су тулы ләгән, иске кәвешләр... Коридор буенда ике якта икешәр ишек. Дүрт бүлмәгә дүрт хәлфәнең исеме бирелгән: Ахун бүлмәсе, Җәмил хәлфә бүлмәсе, Заһидулла хәзрәт бүлмәсе, Габдулла хәлфәнеке. Галимҗан урнашкан зур бүлмә төрле төстә кәрле чаршаулар белән берничәгә бүленгән. Һәр бүлем эчендә биш-алты шәкерт. Беренче бүлемдә Галимҗаннан иртәрәк килгән шәкертләр «Бәдәвам» китабын кычкырып укып утыралар:

Исерек — таңре дошманы,
Дошман бел һәм син аны.
Җәһәннәмдер мәкане,
Алла дигел бәдәвам,

— дип көйлиләр.

[1] «Вакуф шартлары судебная палатада саклана. 1872 ел» дигән сүзләр.

Икенче бүлемдә, күзләрен йомып, бер алга, бер артка чайкала-чайкала «Сөбателгаҗизин» китабыннан җырлыйлар:

Җирнең бардыр үгезе,
Үгезнең бер мөгезе.
Кодрәт белән тотып тора
Бөтен җирне бер үзе...

Башкаларыннан зуррак икенче бер бүлемдә буй җиткән берничә шәкерт — мәдрәсәне бетереп тә, берәр җирдә муллалык урыны табылмасмы дип көтеп яткан пишкадәмнәр — җыелган. Боларның берсе кечкенә генә кул көзгесенә карап, эскәк белән сакал-мыегын йолкып утыра. Башкалары «Исагуҗи», «Шәмсия» [1], «Тәфсир» [2] кебек китаплар өелгән тәбәнәк өстәл тирәсенә утырганнар да, күзләрен акайтып, арык муеннарын сузып, кулларын бутый-бутый, берен-берен уздырырга тырышып кычкыралар. Аларның тавышлары колак тондыргыч иде. Галимҗан моңа гаҗәпләнмәде. Былтыргы уку елыннан ук ул яхшы белә: бу — моназарә, ягъни бәхәс, сүз көрәштерү. Мондый бәхәсләрнең кайвакыт үзара сугыш белән беткән чаклары да булгалый.

Ниһаять, Галимҗан түрдәге тар гына бүлем алдына килеп туктады. Монда ике шәкерт сыярлык кына урын бар иде. Былтыр Галимҗанны беренче тапкыр мәдрәсәгә алып килгәндә, әтисе, хәзрәт белән килешеп, ишектән ераклыгы һәм тәрәзә пыяласы бөтен булганы өчен, шушы бүлемне сайлап, улын урнаштырып киткән иде.

Бүлем алдына килеп туктауга, иң элек Галимҗанның күзенә аркасын почмакка терәп боегып утырган бер малай чалынды.

Малай, Галимҗанны күргәч, аннан курыккан сыман маңгай астыннан гына карап, почмакка тагы да сыена төште.

Галимҗан:

«Былтыр бу малай юк иде ич. Каян килде икән? Үзе болай төскәбиткә чибәр күренә, тик өсте-башы бигрәк алама икән»,— дип уйланып, төенчекләрен күтәргән хәлдә, эндәшмичә бераз басып торды.

Малай чыннан да чибәр иде. Сызылып торган кара кашлы, кара күзле. Тик түгәрәк йөзе шактый сулган, ябык. Яз, җәй буе авылда ял итеп, яхшы ашап ныгып килгән Галимҗан янында бу бала, әлбәттә, бик ябык, чирләшкә булып күренә иде.

Малайның куркынган йөзенә карап торгач, Галимҗан үзенең дә бу мәдрәсәгә килгән беренче көннәрен хәтерләде. Ул менә шулай маңгай астыннан гына карап, олырак шәкертләр тагын нинди мәгънәсез, усал шаяртулар уйлап чыгарырлар да мине мыскыллый башларлар икән? — дип куркып утырган иде.

Галимҗан: «Бу бичараны да шулай үчекли торганнардыр», — дип, малайга карап дусларча елмаеп алды. Аннары төенчекләрен эчкә алып кереп, тәбәнәк өстәл өстенә куйды.

Галимҗанның елмайганын күргәч, малайның күңеле бераз тынычлана төште шикелле.

Хәзер инде ул аның һәрбер хәрәкәтен кыюлана төшеп күзәтә башлады. Галимҗан исә, өстәл янына килеп, иске киез өстенә тезләнеп утырды да, яңа бүлмәдәшенә ничек сүз катарга белмичә аптырабрак торды. Бу малайның кем икәнен, каян һәм кайчан килгәнен, сабагын нинди китап буенча укыганын беләсе килә иде. Башка юл тапмады, туп-туры:

— Исемең ничек соң? — дип сорады.

Малай каушаганрак тавыш белән:

— Шәһит, фамилиям — Әхмәдиев,— дип җавап кайтарды.

---

[1] **Исагуҗи, Шәмсия — мантыйк (логика) фәненең бүлекләре.**
[2] **Тәфсир — корьәннең тәрҗемәсе.**

— Син кайчан безнең мәдрәсәгә килдең?
— Инде бер атна булды.
— Йолдыз санаттыңлармы?

Шәһит җанлана төште, хәтта Галимҗанга таба елышыбрак утырды.

— Санатмакчылар иде дә, мин санамадым. Мин беләм аны, ничек санатуларын! Безнең Ялтан мәктәбендә дә яңа килгән шәкертләргә йолдыз санатабыз дигән булып, чикмән җиңеннән түшәмгә караталар да битләренә салкын су коялар иде. Мине алдый алмаслар!

Галимҗан, малайга беркадәр гаҗәпләнеп: «Кара син аны: алдый алмаслар ди бит! Ә былтыр мине шулай алдап, битемә әллә нинди сасы су койганнар иде»,— дип уйлап куйды, сүзсез калды. Шуннан соң төенчегенең берсен алып чишәргә кереште. Бу төенчектә кәбестә бәлеше, эремчек сумсалары, йомыркалар икән. Икенчесен чиште. Монысында майда кыздырган берничә кисәк сарык ите, бер бөтен каз бар иде. Актарына башлагач, ашыйсы килде. Төенчектән ике сумса алып читкәрәк куйды. «Бераз ит тә кисеп алсаң, зарар итмәс иде», дип уйлап, кесәсеннән пәке эзләп карады, тапмады. Бәлки Шәһитнең пәкесе яки пычагы бардыр дип аңа әйләнеп карагач, хәйран булды. Шәһит муенын сузып, өстәл өстендәге ризыктан күзен ала алмыйча катып калган. Аның бик ашыйсы килгәнлеге күренеп тора иде.

Галимҗанның әнисе аш-суга оста булу белән бергә бик кунакчыл да. Шуңа күрә Галимҗан да кеше сыйлауны гадәти бер хәл дип карарга өйрәнгән иде.

Менә хәзер дә ул Шәһиткә карап, әнисенең сүзләре белән:

— Рәхим ит, өстәлгә якынрак утыр, ашка житеш! — диде.

Шәһитнең күзләре елтырап китте, шулай да малай ышанып җитмәде, мыскыл итәргә теләмиме икән дип шикләнде. Сынар өчен:

— Бая зур шәкертләр миннән самавар куйдырткаиннар иде. Әле суынмагандыр. Кайнар су алып килимме? — дип сорады.

Галимҗан төенчегеннән чынаягын чыгарып, өстәл кырыена куйды.

— Миндә чынаяк бер генә. Синең үзеңнеке бардыр,— диде.

Шәһит почмакка сөяп куйган букчасыннан тирән агач савыт чыгарды, аннары Галимҗан чынаягын чәнчә бармагы белән эләктереп, кайнар су алырга китте. Ул арада Галимҗан өстәлгә берничә телем майлы күмәч, сарык ите, сумсалар куйды. Икесе дә өстәл янына утырдылар. Шәһитнең карыны бик ач булса да, беренче булып кул сузарга — әдәпсезлек күрсәтергә теләмәде, Галимҗанның ашый башлавын көтте. Бу әдәп кагыйдәсе Галимҗанның да исенә төште:

— Бисмилля! — дип, кулына сумса алды.

Шуны гына көтеп торган Шәһит иң элек сарык итенә сузылды. Бик күптәннән бирле ит күрмәгән иде ул. Майда кыздырылган ит аңа җәннәт нигъмәте булып тоелды. Бөтен чыраенда хозурлык балкыды. Алган кисәген ашап бетергәч, тагын да иткә сузылса, яки бер сумса алса, яңа иптәше ачуланмасмы дип, икеләнеп торды. Галимҗан исә, Шәһитнең тукталганын күреп, тагын әнисе кебек кыстый башлады:

— Ашап-эч, Шәһит! Әллә яратмадыңмы? Менә бу сумсалардан авыз ит. Әллә күкәй ашыйсың киләме?

Шәһит кыюлана төште. Өстәлгә якынрак килеп утырды. Кулына сумса алып, Галимҗанга үз итеп карады һәм балаларча беркатлылык белән:

— Нигә яратмаска?! Бик тәмле! Тик күп ашый бу дип ачуланмассыңмы дип курыккан идем,— диде. Сыйлаучы иптәшенең әле исемен дә белмәгәнен хәтерләп: — Ә синең исемең ничек соң? — дип сорады.

— Галимҗан. Мин былтырдан бирле бу мәдрәсәдә укыйм. Ә син моңарчы кая укыдың?

— Мин үз авылыбыздагы, Ялтандагы мәктәптә укыдым.

Сөйләшә торгач, алар икесе дә шәрик[1] булып чыктылар, бер китап буенча[2] укыячаклар икән. Бәлки әнә шуның өчен дә Шәһитне Галимҗан торган бүлемгә урнаштырганнардыр.

Шәһитнең ятим малай икәнлеген белгәч, Галимҗанның күңеле тагы да йомшарып китте. Ятимлекне күз алдына китереп: «Минем дә әти-әни үлсә, ни эшләр идем?!» — дип уйлагач, куркудан йөрәге кысылып куйды. Үзенең кызгануын ничек күрсәтергә белмичә, Шәһитне тагын сыйларга керешге:

— Аша, Шәһит, курыкма! Бетсә, монда, «Хөсәения» мәдрәсәсендә минем абыем укый. Ул берәр нәрсә биргәләр. Аннан соң әти миңа ике тәңкә ярым акча да калдырды әле. Ипигә җитәр! Юлаучы була калса, әни дә авылдан берәр нәрсә пешереп җибәрер. Ач булмабыз!..

Ләкин Шәһит туйган иде инде. Икәүләп ашамлыкларны җыеп алдылар. Бүген кич, иртәгә иртә белән ашыйсы азыкларын аерып алып, урлый күрмәсеннәр дип, Галимҗан ята торган урынның баш очына, киез астына яшерделәр. Калган ризыкларны мәдрәсәнең чормасына менеп, Галимҗанның мехзанына[3] бикләп куйдылар.

Тамагы туйгач, дуслык җылылыгы да тойгач, Шәһит бөтенләй рухланып, елгырланып китте. Галимҗанга рәхмәтен ничек күрсәтергә белмичә:

— Әйдәле, түшәк-юрган, киезләрнең тузанын кагып керик! — диде.

Кинәт күрше чаршау артыннан:

— Әй, малай! Син кая югалдың? Самавар куй! — дигән тавыш ишетелде.

Шәһит сискәнеп:

— Хәзер! Барам! — дип кычкырды да Галимҗанга карап: — онытып җибәргәнмен икән: күрше шәкертләргә самавар яңартасым бар бит! — диде.

Галимҗан:

— Әллә син аларга хезмәт итәргә килештеңме? — дип сорады.

Шәһит чыгып барган җиреннән туктады да:

— Мин алар белән көненә өч тапкыр самавар куярга, кибеткә йөрергә, тәлинкәләрен юарга килешкән идем, — дип аңлатты. Аннары: — Алар миңа аена утыз тиен түләргә булдылар. Кесәдә акча да, эчәргә кайнар чәй дә булып торыр, бәлки калган аш та тигәләр! — дигәч, йөгерә-ашыга чыгып китте.

Ябык тәнле, кечкенә генә бу малайның шул кадәр җитез, эшчән булуына Галимҗан хәйран калды. «Килеп өлгермәгән, үзенә эш тә тапкан, акча да эшли башлаган!» — дип уйлады.

---

[1] Шәрик — сабакташ. Бер сыйныфта укучы шәкертләр.

[2] Кадим мәдрәсәләрнең программасы унике китап укытудан гыйбарәт булган, һәрбер китапны укып чыгу бер елга сузылган. Бу китапларның бишесе — гарәп теле грамматикасы, тагын бишесе — корьән һәм хәдисләрнең тәфсире, соңгы икесе — мантыйк кагыйдәләре, моназарә кылуга өйрәнү булган.

[3] Мехзан — шәкертләрнең азык-төлекләрен бикләп саклый торган капкачлы кечкенә-кечкенә шүрлекләр.

*Дәвамы бар.*

## Сажидә Сөләйманова

### Соңгы патрон

Исән икән әле, тутыкмаган,
истәлекле, исем-тамгалы.
Салкын тимер...
Утлар-сулар кичкән
кайнар гомер —
әткәм нагады.

Хәтәр еллар!..
Шлемдагы йолдыз —
әткәемнең тапсыз вөжданы.
Соңгы чара — соңгы патрон калып,
тезләнгәнче соңгы дошманы,
ул сугышкан.
Кырга тургай кайткан.
Чәчәк аткан миләш-баланнар.
Басуларда агач сукаларны
алмаштырган корыч сабаннар.
Ничә тапкыр
дошман
коммунаның
Соңгы сәгатьләрен санаган!
Гадел атлы әткәм күзләренә
хыянәтчел үлем караган
ничә тапкыр...
Ятим итә алмас
бер дошман да миндәй баланы!
Күңелемдә әткәм елмаюы,
мендәр астындагы наганы...

Патроннары баш калкытмый гына
сакта яткан —
җиңү сагында.
Ил чигенә кара шәүлә булып,
янә яулар килгән чагында,

«өйрән», диде әткәй, наган бирде.
Карачкыга, әткәй кушканга,
алты патрон аттым.
— Ә соңгысы?
— Соңгы патрон —
соңгы дошманга.

«Соңгы пуля үз-үземә» дигән
җырны безнең әткәй белмәгән.
Дошманының үкчәсенә басып
бәреп кергән чит-ят илләргә.

Җаны калган кайчак кыл өстендә,
мылтык көпшәсендә —
гомере...
Соңгы сулышкача
фашистларның
соңгы ояларын җимерде.

Исән әле наган...
Салкын тимер
сискәндерде уяу хәтеремне.
Бик сак кына кулларыма алам,
сакланганмы соңгы патроны?

Дус, дошман бар.
Тыныч заманнарда
җырлар үлчи илнең киңлеген.
Чикләр аша уклар төбәлгәннәр
сынар өчен кемнең кемлеген.

Очар пуляларны туктатырдай
җырлар бармы? —
утлар комарлы.
Соңгы патрон әле атылмаган.
Ул атылса, дөнья тынармы...

Соңгы патрон әле атылмаган,
онытылма, йөрәк, хушланма!
Гадел атлы әткәм әманәте:
Соңгы патрон —
соңгы дошманга!

## Ил чикләре

«Чик буйлары тыныч түгел», ди ул,
Кышны тагын анда каршылый.
Күз нурлары белән яктырадыр
Ил чигенең һәрбер аршины.

Йөрәгемнән өзелеп төшкән улым
Чик буенда, дөнья сагында.
Ил язмышы аның кулларында,
Үзе һаман өйне сагына.

Сагынганга да бит сакчы сизгер:
Төнме — кара, җилме — сызгыра...
Чиксез сөю тулы күңелләр бар,
Шулар аша чикләр сызыла.

## Чүлдә

Җир дә, күк тә монда бер үк төстә,
Күз ачкысыз кояш тирә-юнь.
Чүл кояшы әллә кайнар ташка
Әйләндергән Мәҗнүн йөрәген? —

Сахраларда җилләр җиләс түгел,
Кояш усал, кояш аяусыз!
Пәрәнҗәләр каплый кызлар йөзен,
Мәхәббәтләр яна чарасыз...

Уклы нурлар юлны яктыртмыйлар,
Күз ачкысыз эссе тирә-юнь...
Кайтып җитсәм, бер туйганчы җылыйм
Сиңа ятып, яшел чирәмем!

●

Табигать...
Җилләр, яфраклар
бер сулыш монда, бер тын.
Шәһәрләр, юллар, тузаннар
онтылган сихри бер төн...

Сагындым!
Тагын сайладым
салават күперенең
сарысын.
Утка тарыдым,
ялкында бөтерелдем.

Яшеле — яшьлеге белән,
зәңгәре — гыйшкы янды.
Шәмәхә шәлнең чуклары
алланып җиргә тамды.

Сагындым.
Сиңа сарылыйм,
зәңгәр күк, яшел үлән.
Бәйгегә чыга йөрәгем
яңгырлы яшен белән!

Салават күпере — дуга:
кызыллы да зәңгәрле.
Кемгә күк капусы ачты
мәхәббәт пәйгамбәре?

Яфракта чыклар, керфектә...
Бер тирән сулыш, бер җан.
Тәрәзә ачык,
күңелләр
пәрдәсез аткан бер таң.

## Бәхеткәме

Син кайгыртып кеше кайгыларын,
Кай тарафта хәзер йөрисең?
Кояш чыгыш, кояш баюларын
Каршылыйм да озатам бирүзем.

Эссе җәйләр яшел ялкыннарда —
Утларыңда яшерен дөрләвем.
Син бу хакта, хәер, белмәссең дә,
Хәерледер бәлки белмәвең,—

Каерылып уңган арышлардан
Аерылыр иде күңелең.
Ә сиңа бит кеше күңелен күрү,
Мәшәкатьле эшкә күмелү,

Җир күчәрен әйләндерү кирәк,
Тетрәүләрен үзең кичереп.
Шундый фидаи затлар көче белән
Алга бара бит ул кешелек.

Бәхеткәме — өнңәреңдә калып,
Төшләремә килеп керүең...
Син бу хакта, хәер, белерсең дә,
Хәерледер бәлки белүең.

Эссе җәйнең яшел ялкыннары
Әйләнәләр, янып, сарыга.
Каерылып үскән арышлар да
Күкрәгенә җирнең сарыла.

Сарылсаң да сансыз сарыф булма,
Алтын байлык, ялкын-сагышым!
Кай тарафта хәзер йөрисеңдер
Син кайгыртып дөнья язмышын.

## Көнләшү

Я мәхәббәт җиңә, я нәфрәтем...
Кайда, кайда гади урталык?
Көнләшүне үтә түбән хис дип,
Дорфалык дип саный бар халык.

Ә мин көнлим сине — ят күзләрдән,
Иңнәреңә яткан чал туннан,
Алларыңа алтын чәчен сибеп,
Сер бүлешкән төнге лампаңнан

Мин бит кер кундырмый, тел тидерми,
Сиңа гына серләр сакладым.
Икәү генә булыр чакны бүлеп,
Чабып керә хыял чаптарың! —

Алып китә... Аһ, мин беләм, беләм,
Боз да эри синең караштан!
Киңәерме күңелем, бүтән берне
Мине яраткандай яратсаң?

Сыйдырырмы күңел үзеңне дә,
Миннән читтә булган хисеңне?
Ул кысыла һаман, ул нечкәрә,
Нечкә кыллар үтә сиземле.

Кыл очларын көмеш йөгән итәм,
Кылыч болгыйм — озак офтандык!
Көнләшү ул бәлки түбәнлектер,
Йөрәк-чаптар, кайтыйк ил танып.
Я мәхәббәт, я нәфрәттә яныйк,
Кирәк түгел гади урталык!

●

Сынаулар үттең, сынатма,
Сокланыйм, калыйм хәйран —
Буйсындыр мине, сындырма,
Буй-сыным Урал-таудан.

Биклә дә мине үзеңә,
Чикләмә сагың белән, —
Җыр булып ташып чыгармын
Чыгышым Агыйделдән.

Атмый тор, оча бер лачын,—
Ташкыннар, кошлар юлы.
Аккошлар күлләргә кунсын,
Син Идел сыман олы.

Буй салам, дулкын-уй салам,
Буйсынам, сынмасам да.
Аккошлар юлыдай елым,
Күлләрдә кунмасам да.

## Үзбәк Саттаров

# КЫЗЫМ ХИКӘЯЛӘРЕ

### «Аларның да су эчәсе килә бит!»

Җәйге эссе көн. Без кичкә каршы өйгә кайтып керүгә, гөлләребез шиңеп ләшпереп төшкәннәр. Кичә дә су сибәргә онытылган, күрәсең. Әнисе ашыга-ашыга аларга су сибә башлады. Кече кызым Гөлнара сорау артыннан сорау биреп, тагылгансыман, әнисе артыннан йөри:

— Әни, гөлләр ник шиңгән?

— Су сипмәгәнгә.

— Аларга су ник кирәк?

— Син дә сусыз тора алмыйсың бит. Алар да шулай сусыз тора алмыйлар.

— Гөлләр дә су эчәмени?

— Әйе, кызым, гөлләр дә су эчә!

— Гөлләрнең авызы юк бит, алар су эчми инде!

— Юк, кызым, алар суны балчыктан тамырлары белән суырып алалар.

Шуның белән сүз өзелде. Бераз вакыт тынлык торды. Боларга ни булды икән — тындылар дип залга чыксам, Гөлнара гөл янында кайнаша. Шул арада әнисе дә килеп чыкты. Карасак ни күрик: Гөлнара гөлнең өч ботагын өзеп, гөл төбендәге балчыкка утырткан, дүртенчесен өзеп кайнаша. Әнисе аның ни эшләгәнен күрү белән: «Нишлисең син, кызым!» дип йөгереп янына килеп җитте. Бала, өзгән гөл ботагын кая куярга белми аптырап, куркып калды. Ул бер әнисенә, бер миңа карап куйды. Аннары акланырга тырышып:

— Аларның да су эчәсе килә бит! — диде дә өзелгән гөл сабагын әнисенә сузды.

### «Кычкырма, бәбәйне уятасың!»

Күршебез Фатыйма безгә имчәк бәбәен күтәреп кергән. Бәләкәй әле, әнисенең алдында утыра. Булдыра алган кадәр йомшак итеп көлеп мин янына килә башлаган идем, чырылдап кычкырып әнисенә елышты. Беренче генә күрүе түгел бит инде, югыйсә, барыбер миннән курка. Ә менә Гөлнараны күргәч, кулларын сузып, кызымның чәчлә-

рен эләктерә һәм аны үзенә таба тарта. Гөлнарасы да бит әле үзенең дә күптән түгел генә сөйләшә башлаганын белми, бәбәй белән бәбәйләрчә кыланган була:

— Әгъга,— ди. Ә тегесе шунда шаркылдап көлә. Алар уйный калдылар, ә мин икенче бүлмәгә чыктым. Бераздан янbackyma Гөлнара керде:

— Эти, бәбәй оялмый да кешедә имеп утыра!— ди. Бераздан без Гөлнара белән әниләре янына әйләнеп кергәндә, бәбәй йоклый иде инде. Гөлнара, аның йоклаганын белмичә, кычкырып сөйләшә башлаган иде, әнисе баш бармагы белән иреннәрен каплады да, башлап «тсс»... диде. Аннары бармагы белән янап:

— Кычкырма, күрмисеңмени, бәбәй йоклый, уятырсың,— дип өстәде. Гөлнара тын калды. Кирәк әйберен пышылдап әнисенең колагына әйтте дә кухняга чыгып китте.

Ун-унбиш минут вакыт узгач, без әнисе белән кухняга кергәндә Гөлнара баштанаяк вареньега чумып өлгергән иде инде. Вареньега батырган бармагын авызына илтеп җиткергәндә генә:

— Әрәм иткәнсең ич күлмәгеңне,— дип, әнисе кычкырып җибәрде. Гөлнара күтәрелеп әнисенә карады. Аннары авызы янына килеп җиткән бармагын яламыйча иреннәренә куйды:

— Тсс... — диде. Аннары вареньеле бармагы белән бәбәй йоклый торган бүлмәгә күрсәтеп, нәкъ әнисе кебек итеп:

— Кычкырма, бәбәйне уятырсың... — дип өстәде.



## «Минем белән уйнасын!»

Фәридә Гөлнараны төртеп еккан. Гөлнараның өсте пычрак. Әнисе кызының күлмәген салдыра-салдыра:

— Фәридә белән уйнама, яме!— ди.

Сизелеп тора, кызның Фәридә белән уйныйсы килә.

— Әни, нигә Фәридә белән уйнарга ярамый?

— Чөнки Фәридә начар кыз.

Гөлнара бераз аптырап тора.

— Әйбәт кызлар белән уйнарга ярыймы соң?

— Ярый...

— Ә мин әйбәтме?

— Әйбәт.

— Алай булгач, Фәридә минем белән уйнасын!

## «Аюның да ашыйсы килә»

Хәерниса апасы Гөлнараның туган көненә аю бүләк итте. Аю кызыма бик ошады. Ул гел аюы белән уйный башлады, бервакытта да кулыннан төшерми, хәтта шуны кочаклап йокыга да китә.

Бер көнне кич эштән кайтып керсәм, аю идәндә ята. Ялтырап торган борыннары, күзләре боткага баткан. Мин аптырап:

— Кызым, аюыңны ник пычраттың? — дим. Гөлнара аюга борылып та карамый.

— Пычрак түгел ул. Ул — ботка! — ди.

— Нигә аның авызын, күзләрен боткага буядың?

— Буямадым. Мин аны ашаттым.

— Нигә аюыңны идәнгә ташладың?
— Ул әйткәнне тыңламады.
— Нәрсәне тыңламады?
— Мин аңа ботканы ашап бетерергә куштым, ә ул ашап бетермәде.
— Ә нигә ботканңы үзең ашап бетермәдең?
— Мин бит үземнекен ашап бетердем.
— Аюың белән икәү ашап бетерерсез әле,— дип, әби миңа ботканы тагы өстәде. Аю шул ботканы ашап бетермәде, ә әби аюны түгел, мине ачуланды.

## «Әти дә әнигә ияреп йөри»

Дөнья булгач балалар белән йөрергә ярамаган җирләр дә була. Ияруләреннән куркып, балаларга сиздермәскә тырышып, тавышсыз-тынсыз гына хатын белән ишек төбендә киенеп кайнашабыз. Өлкән кызым Гүзәл безнең киенгәнне күреп алды да, әнисенең күз кысуына карамастан, балаларча беркатлылык белән:
— Әни, сез кая барасыз? — дип кычкырып та җибәрде. Гөлнарага шул гына кирәк тә инде:
— Туктагыз! Чыгып китмәгез, мин дә барам,— дип йөгереп безнең янга килде дә, рөхсәтсез-нисез, ашыга-ашыга киенә дә башлады. Гүзәле дә аңа кушылды. Әнисе дә, мин дә безгә һәр вакыт ияреп йөрергә ярамавын, безнең үзебез генә барып хәл итәсе йомыш барын аңлатырга тырыштык. Аңламыйлар. Әнисе пычратмасыннар, ватмасыннар дип, көн дә бирми торган матур курчакларын да чыгарып бирде, матур рәсемле журналлар да китереп тоттырды, аларның да файдасы тимәде.
Безгә ярдәмгә әбиләре килде:
— Үскән кызлар әнигә ияреп йөрмиләр инде,— диде. Бу сүзнең тәэсире шунда ук сизелде: Гүзәл киенүеннән туктап пальтосын кире элеп куярга омтылган кебек булды. Гөлнарасы да нидер әйтергә дип авызын ачкан иде дә, бер сүз дә әйтми уйланып торды да:
— Әти бездән дә зуррак үскән, ник әнигә ияреп йөри соң? — диде. Үзе тагы да ашыгыбрак киенә башлады.

## «Акчаны кайда саталар?»

Яңа универмаг ачылгач, кирәкле әйберләрне дә алырбыз, балаларга яңа кибетне дә күрсәтербез дип, дүртәүләп универмагка килдек. Мондый зур кибетне балаларның беренче тапкыр күрүләре. Халык күп. Товарлар берсеннән-берсе шәп. Нәрсә генә юк монда! Үзләре матур! Балаларның барысын да берьюлы аласылары килә. Нәрсә очраса шуны алып бирергә кирәк аларга. Товар янына килеп туктау белән, икесе дә!
— Әйдә, әни, алабыз! Әйдә алабыз! — дип шаулый башлыйлар.
Шулай күп кабатлана торгач, әниләре:
— Шауламагыз әле, акча юк! — дип көрсенеп куйды. Балалар тынып калдылар. Ләкин бераздан Гүзәл кулымнан тарта башлады:
— Әти, дим, әти! Монда бөтен нәрсә дә бармы?
Мин эшнең нидә икәненә төшенмим әле:
— Әйе, кызым, монда бар нәрсә дә бар. Бу кибеттә ни теләсәң шуны алырга була, бу бит универмаг,— дим.

— Ә монда акчаны кайда саталар?
— ...
— Әйдә, барып күп кенә акча сатып алыйк та, аннан соң безгә күлмәк алырбыз!

## «Мин — мәшәкать!»

Тыштан пычранып кергәне өчен әнисе кече кызым Гөлнараны шелтәли:
— Әй, мәшәкать, пычранмыйча уйный гына да белмисең бит!
Шул вакыт Хәерниса апа килеп керде. Гүзәл Хәерниса апасы янына беренче булып килеп җитте. Гөлнара да, әнисенең әрләвеннән котылырга сәбәп чыгуына шатланып, кунакны каршыларга йөгерде.
Хәерниса апа балаларны бик ярата, алар белән балалар телендә сөйләшә белә. Ул:
— Һаман онытам, кем әле шушысы,— дигән булып, Гүзәлгә колачын җәеп килә башлады.
Гүзәл йөгереп килеп Хәерниса апасын кочып алды:
— Карлыгач! Мин бит карлыгач. Әтием миңа «карлыгачым» ди.
Гүзәлнең Хәерниса апасын үзеннән алда «алуына» болай да шелтә эләккән Гөлнараның күңеле кителде. Ул стенага барып сыена башлаганда гына, Хәерниса апасы эшнең хәтәр икәнен сизеп алып, Гүзәлне калдырды да кулларын җәеп Гөлнара янына килә башлады:
— Ә бусы кем соң әле монын, бусы — кем?
Гөлнара башын аска игән, күзләре идәнгә төбәлгән, үзенең яшьләре бәреп чыгарга тора.
Мин дә кызымның кәефен күтәрергә теләп башыннан сыпырдым:
— Я, әйт әле, кызым, Хәерниса апаңа, син — кем? — дидем.
Гөлнара башын күтәрми әкрен тавыш белән:
— Мин — мәшәкать! — диде дә елап та җибәрде.

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

**1974 ЕЛ, ЯНВАРЬ**

«Шулай итеп, вакыт ягыннан төзелеш үзенең өчтән ике өлешен үтте. Узган бишьеллыкта болын, басу һәм куаклык булган урында хәзер двигательләр, тимерчелек, кою, җыю, пресс-рам заводларының барлык төп производство корпуслары диярлек калкып чыкты. Ремонт-инструмент заводы продукция бирә башлады. Төп тематик бурыч та нигездә хәл ителде: гомуми производство мәйданы миллион ярым квадрат метр булган завод корпусларының түбәләре ябылып бетте, аларга җылы бирелде»,— диде КПССның Чаллы шәһәр комитеты беренче секретаре Р. Беляев шәһәр партия активы җыелышында ясаган докладында.

**«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».**

Украинаның машиналар төзү буенча уннарча заводы КамАЗның почетлы заказларын үти. Алар арасында Коснор исемендәге Харьков заводы да бар. Аның коллективы: «Камадагы автогигант өчен барлык заказларны срогыннан элек үтәргә!» дигән девиз белән эшли.

Завод мәйданчыгыннан бик төгәл эшли торган ике шомарту станогы дүрт айга элегрәк озатылды. Социалистик Хезмәт Герое Петр Иванович Хухлянский җитәкчелек итә торган участок эшчеләре бу заказны тизләтелгән график нигезендә үтәделәр.

Харьков станок төзүчеләре июньдә үк инде камазлыларга зур детальләрне эшкәртү өчен түгәрәкләп шомарта торган ике станок әзерләгәннәр иде, ә 1973 ел ахырында алар бишьеллыкның мөһим төзелешенә мотор детальләрен эшкәртү өчен махсус 19 станок җибәрделәр.

**ТАСС, Харьков.**

Безнең чынбарлыгыбызда КамАЗның ничек тиз һәм ныклап урнашуы гаҗәпләндерерлек. Илдә ел саен меңләгән яңа төзелеш башлана, әмма без аларның исемнәрен белмибез. Гомуми сафта КамАЗ исеме югалып калмады. Бик кыска вакыт эчендә КамАЗ гомуми кумәклек исеменә әверелде. Аның шөһрәте танылган кино артистлар данына тиң, хәтта югарырак та.

**«Литературная газета», Мәскәү.**

Ремонт-инструмент заводында — Кама автомобиль комплексының эшли башлаган беренче объектында — үзешчән сәнгать коллективлары эшне активлаштырдылар. Күптән түгел генә төзелгән хор рус халык җырларын, совет һәм чит ил композиторларының әсәрләрен бик оста башкаруы белән шөһрәт казанырга өлгерде. Слесарь Николай Нефедов җитәкчелегендәге тынлы оркестр завод цехларында, төзелеш мәйданчыкларында зур уңыш белән чыгыш ясый. Казан консерваториясен тәмамлаган Юрий Лидяев хәзер вокаль ансамбле төзи.

**«Советская культура», Мәскәү.**

«Татэлектромонтаж» трестының Чаллы монтаж идарәсе коллективы январьның беренче декадасы заданиесен уңышлы үтәде. Айлык задание буенча 200 мең сумлык эш башкарырга кирәк, ә торак һәм культура-көнкүреш объектлары төзүдә катнашучы эшчеләр ун көндә 70 мең сумлык эш башкардылар. Л. Быков һәм А. Закиров җитәкчелегендәге бригадалар алда бара. Алар хезмәттә һәм бишьеллыкның мөһим елы социалистик ярышында бик яхшы нәтиҗәләргә ирештеләр.

«Социалистическая индустрия»
на строительстве Камского автозавода».

Пермь-Ижевск газ үткәргечен төзүчеләр корыч торбаларның соңгы километрын эретеп ябыштыра башладылар. Төмән өлкәсендә чыга торган газ 247 километр озынлыгындагы җир асты юлыннан Көнбатыш Урал аша Удмуртия башкаласына киләчәк.

Элек Удмуртия зәңгәр ягулыкны тугандаш Татарстаннан ала иде. Хәзер газ Миннебай-Ижевск газ үткәргече буйлап кире якка таба агачак. Себер газы бу магистральдән Чаллыга юнәләчәк.

Магистральне төзү — халыкларның тугандаш дуслыгының тагы бер чагылышы. Монда руслар, башкортлар, татарлар, удмуртлар иңгә-иң торып эшлиләр. Украина, Россия Федерациясе һәм башка союздаш республикаларның машина төзүчеләре төзелешкә югары җитештерүчән хәзерге заман машиналары һәм агрегатлары җибәрделәр.

ТАСС, Ижевск.

«Камадагы автогигант төзелешенең Коммунистлар партиясе таләпләре рухында оста хуҗалык итү, производствоның эффектлылыгын күтәрү үрнәге булачагына нык ышанабыз. Башлана торган ел зур йөкле Кама автомобилен чыгаруга хәзерлекнең әһәмиятле этабы булачак.

Бөек Октябрь ачкан безнең перспектива — тыныч төзелеш перспективасы. Сез, Кама автомобиль комплексын төзүчеләр, күп миллионлы төзүчеләр армиясенең беренче сафларында барасыз. Башкалар сезгә тигезләнәләр, сездән өйрәнәләр. Бөек төзелеш байрагын югары тотыгыз, билгеләнгән юлдан ныклы адым белән барыгыз!

Кадерле камазлылар! Яңа ел белән чын күңелдән тәбриклибез, хезмәттә һәм укуда яңа уңышлар, шәхси тормышыгызда бәхетләр телибез!» — Бу юллар беренче бишьеллык геройлары Алексей Стаханов, Петр Кривонос, Мария Виноградова, Александр Бусыгин, Иван Гудов хатларыннан китерелде.

КамАЗ төзелеше башланганнан соң Полтаваның төньяк читендә 30 мең квадрат метр мәйданда автоагрегат заводының яңа цехы корпусларын салуга керештеләр. Монда «КамАЗ» автомобиль прицепларының тормоз һәм күтәрү системалары өчен узеллар һәм аппаратуралар җитештереләчәк. Цехны тизрәк төзергә карар иткән төзүчеләр коллективында башланган социалистик ярышта «Харьковстальконструкция» трестының 120 номерлы Кременчуг төзелеш идарәсе монтажчылары беренчелекне алып торалар.

ТАСС, Полтава.

Смоленскидан килгән иҗади работниклар группасы: шагыйрь Юрий Пашков, СССР Язучылар союзының Смоленск бүлеге җаваплы секретаре Алексей Мишин, прозаик Нина Семенова һәм композитор Николай Писаренко Чаллыда кунак булдылар. Алар төзелеш мәйданнарына бардылар, тулай торакларда очрашу кичәләре үткәрделәр, ремонт-инструмент заводында чыгыш ясадылар.

Сәнгать белгече, Мәскәү дәүләт филармониясе лекторы М. М. Гринберг «Төзүчеләр» клубында, вак күзәнәкле бетон заводы поселогында һәм «Энергетик» культура сараенда музыка турында лекцияләр укыды.

«Социалистическая индустрия»
на строительстве Камского автозавода».

Алма-Атаның түбән вольтлы аппаратура заводы КамАЗ төзүчеләрнең беренче заказын үтәде. Электр энергиясен бүлүче иң яңа конструкциядәге йөзләп аппаратура Чаллыга озатылды. Предприятиедә элек чыгарылган җайланмага караганда аның эш ресурсы ике тапкыр югарырак, чыдамлыгы да артыграк.

Бишьеллыкның дүртенче елында Кама автогигантын төзүчеләр өчен шундый меңләгән җайланма әзерләнәчәк. Предприятиедә продукция чыгару срокларын кыскарту өчен эчке резервлар эзләү дәвам итә.

**ТАСС, Алма-Ата.**

Казанның сынлы сәнгать музее КамАЗ төзүчеләре өчен ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Сергей Лывин картиналарыннан күргәзмә оештырды. Күргәзмәне ачканда рәссам иҗади планнары белән уртаклашты, «Буровой янында», «Бөгелмәгә юл», «Кечкенә култык», «Соңгы кар» картиналары өстендә ничек эшләве турында сөйләде. Аларның барысы да Татарстанда эшләнгән һәм туган якны поэтик төсләрдә сурәтлиләр.

**«Советская культура», Мәскәү.**

...Ремонт-инструмент заводында киемнәр күргәзмәсен зур кызыксыну белән каршы алдылар. Автомобиль промышленносте министрлыгы соравы буенча ВИАлегпромның махсус киемнәр бүлеге 48 модель күрсәтте. Алар арасында утка чыдамлы, сварщиклар кия торган, гомуми кулланыштагы киемнәр бар иде.

...«Главмосстрой»ның төзелеш идарәсе коллективы 1973 елның 17 декабренда 23/03-Б тулай торагын эксплуатациягә тапшырды. Моның белән ул еллык тематик заданиене срогыннан элек үтәде — КамАЗ өчен 270 мең квадрат метр тулай торак тапшырды.

**«Социалистическая индустрия»**
**на строительстве Камского автозавода».**

Төзелеш үзенчә, сопроматтагы кебек, яшь инженерларны «сугуга, бөгүгә, өзүгә» сыный, шәхес буларак сыный. Төзелеш вузларны да сыный. 1973 елда «Камгэсэнергострой»да гына да югары белемле 300 яшь белгеч бар иде. Шулар арасыннан эштән качучы берәү дә булмады диярлек. Төзелештәге бу факт югары мәктәпләрне тәмамлаучыларның гражданлык ягыннан өлгерүен күрсәтә.

Хәзер илнең күпчелек вузлары, бигрәк тә географик һәм административ бәйләнештә булганнары, КамАЗга исәп тота. Казанның авиация һәм төзүчеләр институтлары шундыйлардан.

Казан галимнәре үзләренең эшләрен КамАЗ проблемаларына бәйләп хәл итәләр. КАИда автомобиль төзелеше өлкәсендә, КИСИда бу тармак предприятиеләрен төзүдә фәнни тикшеренүләр алып барыла. Студентларның курс һәм диплом проектлары реальрәк була баралар һәм шул ук проблемаларга багышланалар.

Камада яңа завод, яңа шәһәр генә үсми. Монда булачак «альма матер»ның — вузның беренче ташлары салына. Илнең фәнен һәм культурасын үстерү өчен күп әрсәләр эшләгән Казан, иске университет шәһәре — вузның «кендек әбисе».

**«Молодой коммунист», Мәскәү.**

## Кави Латыйпов

# БҮГЕНГЕ БАТЫР

„Мөдәррис энең үлде, җирләшергә кайт»,— дигән хәбәр килде Галимуллага туган авылы Мирҗәмнән. Күпме генә баш ватса да, энесенә ни булганын күз алдына китерә алмады: «Сукса тимер өзәрлек егет иде бит Мөдәррис. Һич кенә дә башка сыймый».



Аның энесе колхозда ат караучы иде. Җәй көннәрендә авылга кайткан саен абыйсын Мөдәррис үзе белән кырга атлар сакларга алып чыга торган иде. Кырдагы соңгы очрашу Галимулла хәтерендә нык сеңеп калды. Җәйге матур вакыт... Серле төн, чикерткәләр черелди, черкиләр безелди. Елга тып-тын, гүя ул ике туганның үзара сөйләшүләрен тыңлап тора:

— Шәһәрдә дә ай шундый тулы һәм матурмы, абый?

— Әлбәттә.

— Ә табигать башкарак инде анда, әйеме?

— Юк, энем, шәһәрдә дә шул ук ай, шул ук кояш, шул ук табигать. Тик күрә генә белергә кирәк.

— Ә менә мин, абый, шәһәрдә яши алмас идем...

— Ни өчен, Мөдәррис?

— Кем әйтмешли, атларсыз — миңа дөнья сансыз.

— Ә мин, энекәш, корыч атларны, корыч кошларны күңелгә хуш күрәм.

— Мондагы болын, мондагы елга юктыр ул беркайда да. Шул елгадан минем бахбайларым су эчә...

Аннары Мөдәррис үзе караган һәр аты турында аерым итеп сөйләде: «Имеш, бу җирән кашка узган елгы сабан туенда баш килде, ә теге бурлысы өч ел элек... Монысын ломовой диярсең — куәте белән бер тракторыңа торырлык. Урманнан агачларны эһ тә итми тартып чыгара... Син икенче елга сабан туена кайт әле... Безнең як бит ул элек-электән шау-гөр килеп торган як. Ата-бабаларыбыз ярминкәләр оештырган... Төрле матур ефәк, хәтфә, комач тукымалар, болыныбыз шикелле күз чагылдырырлык келәмнәр сатканнар. «Арча» — асламчы дигән сүз икән ул. Беләсеңме, моны кемнән ишеттем: бер карт чувалтан. Арча базарына кәрзиннәр сатарга килгән иде. Миңа «асламчы» сүзе бик тә ошый, мин аны үземә кушамат итеп алам әле. Бүгеннән син миңа асламчы дип әйт, яме?.. Ә мин сиңа тылсымчы дип эндәшермен. Тылсымчы икәнеңне беләм бит мин синең. Балчыктан сыбызгы, калайдан тартма, тимердән курай ясый беләсең бит син, абый... Заводтан эшләп кайткан кураең өчен рәхмәт. Курай уйнап үземне танытырга өйрәтәм әле мин бахбайларымны... Истәлеккә син

калдырган алмазыңны саклап тотам. Син бит малай чагыңнан ук кешеөйләренә тәрәзәләр куя идең... Инде менә самолетлар төзү заводында эшлим дисең. Барып чыгам әле мин дә син эшләгән заводка. Син яраткан корыч кошларны күрәсем килә...»

Мөдәррисне җырләгәч, заводтан бер-ике көнгә генә сорап киткән булса да, энесенең балаларын калдырып шәһәргә китәргә ашыга алмады Галимулла. Ул караган атлар да: «Инде без кемгә калдык? Безне кем ашатыр, эчерер?» дип карыйлар кебек иде. Мөдәррис бит ат өчен үлеп тора иде. Аның фаҗигале үлеме дә шул ат аркасында булган икән...

Көчле яңгыр явып елга ташыган чакта, Мөдәррис печән төялгән олау белән суга килеп кергән: абзарда ябылып калган атларын ашатырга вакыт җиткән булган. Шуларга печән чабып кайтарыр өчен иртән-иртүк чыгып киткән ул. Печәнне чалгы белән чапкан, таптаптаптап олауга төягән. Кинәт чиләкләп яңгыр ява башлаган. Яңгыр түгел, таш яуса да, атлары янына кайтырга карар кыла Мөдәррис. Менә ул аты белән елгага килеп кергән. Яшен яшьни, күк күкри, җилдавыл дулый икән. Елга уртасында кендек чыгып, Мөдәррис печән төялгән олау астында калган. Моны сизгән ат авылга чапкан, урамнар буйлап кешнәп йөргән: хуҗасын коткарыр өчен шулай кешеләрне җыеп, аларны үзенә ияртеп һәлакәтле урынга алып килгән. Хәвефле кешнәгән тавышны ишеткән атлар да җыелышып елга буена чапканнар. Бөтен авыл мәхшәр килгән. Ыгы-зыгы беткәч, атлар башларын салып, конюшняга кайтканнар. Хуҗаларын коткара алмаганлыкны, судан мәете генә табылуын сизгәннәр булса кирәк...

Энесе яраткан шул малкайларны ташлап китә алмыйча шактый вакыт яшәде Галимулла туган авылында. Малай-шалайларны ияртеп, атлар белән кырга чыкты, учаклар якты, айлы кичләрне, чулпанлы таңнарны күрде, кошлар сайравын, наратлар шаулавын тыңлады. Кара урманнан хәтта шүрәле килеп чыгар кебек иде аңа. Бәләкәчләрне ат өстендә йөрергә өйрәтте, «Пугачев һәм Бәхтияр Канкаевлар белән патша гаскәрләре арасында «кылыч сугышы» оештырды — тал чыбык «кылычлар» туктаусыз чыжылдап торды. Учак янында шәһәрдә үзе ишеткән завод эшчеләрнең җырларын җырлады, шаулы урман да шуны тыңлап тын калгандай тоелды. Тукай-Кырлай яклярында һәр үлән, һәр яфрак сихәтле — шифалы булып күренде аңа. Тик менә Мөдәррис кенә юк инде...

Кеше — җир улы, табигать баласы, ләкин бер табигать кенә яшәтми икән аны, үзең яраткан, күңелең тарткан, сине кеше иткән һөнәр дә кирәк икән. Ә андый һөнәр Галимулла өчен фрезерлык хезмәте иде. Ул моны заводтан аз гына вакыт булса да читтә яшәгәндә, йолдызлар белән, табигать белән икәүдән-икәү серләшкәндә-киңәшкәндә аңлады. Нигәдер авыл өстендәге барча йолдызлар аны һаман да Казанга, заводка, корыч кошлар күтәрелгән җиргә чакырып торды сыман. Фрезерлык — Галимулланың патшалыгы, алай гына да түгел, әкият патшалыгы, хыялы-уйлары иде. Юк, ул кыр-дала баласы түгел, ә заводкала баласы. Иген игеп түгел, ә металл, тимер эшкәртеп ашаган икмәге тәмлерәк тоелды аңа. Туган җир туфрагын тимер сабан, корыч машиналар белән эшкәртү турында ата-бабалары да гомер-гомердән хыялланган бит. Сугыштан соң туган ил җирләре моны җан авазы белән сорый кебек тоелды... Ә сугыш елларында күпме туфрак сөрелми-эшкәртелми ятканы Галимулланың хәтерендә. Сугыш башлангач, ул мәктәп балалары белән бергәләп бәрәңге алды, басуда башак җыйды. Ул елларда кеше, ат, үгез урынына җигелеп, сука тартты, урман ташыды... Берсе дә, берсе дә онытылмый — авылдан-авылга барып укып йөрүләр дә, ФЗӨга китүләр дә...

Төшендә күргән бер кыз сәбәп булды аның ФЗӨга китүенә. Аны шәһәргә-заводка шул чакырды:

— «Батырым! — дип әйтте беренче сүзен кыз.

— Нәрсә, матурым?

— Тукай батыры шүрәлене җиңгән, ә менә син шундый көчле була аласыңмы?

— Була алам.

— Алайса, менә сиңа балта, бер сугуда имәнне аудар.

Галимулланың кизәнүе булды, агач гөрселдәп җиргә егылды.

— Көчле икәнсең! Инде менә сиңа чәч калынлыгыдай корыч чыбык, шуны өз...

Егет куллары белән тартып та, ташлап та карады — барып чыкмады.

— Булмый.

— Алайса, шушы агачны сырлап бир...

— Менә! — диде егет матурлаган агач кисәген кыз кулына тоттырып.

— Матур! Ә хәзер тимерне сырла...

— Булмый, — диде Галимулла.

— Ә менә барысын да булдыра торган урын бар,— диде кыз елмаеп.

— Кайда?

— Шәһәрдә, дөресрәге, заводта. Анда хәтта корыч кошлар ясап һавага очыралар... Җитмеш төрле һөнәр белүчеләр үсә. Син, егетем, җитмеш төрле һөнәр башкара алгач, мине эзләп табарсың, яме?.. Әлегә хуш!..»

Кыз, шулай дип, китте дә югалды. Өендә шикелле булып тоелды бу сөйләшү Галимуллага.

Өстенә фуфайка кигән, юл капчыгы аскан Галимулла Казанга килде. Сораша торгач, ул авиация исеме белән аталган бер заводка килде. Капка янында бер кызый басып тора иде. Заводка чакыручы, җитмеш төрле һөнәр турында сөйләүче чибәр булып күренде ул егет күзләренә. «Синең сүзне тыңлап килдем... Син бит мине корыч кошлар белән сихерләдең»,— дип әйтәсе килде Галимулланың.

— Корыч кошлар ясаучы завод шушымы инде? — диде ул.

— Юк, монысы түгел, икенчесе. Биредә моторлар гына ясала, ә тегендә самолет үзе эшләнә. Үз кулларың белән эшләп чыгарган самолетны күрүләре ни тора: күңелең әйтерсең үзе дә канатланып, күккә оча. Сөенеп туя алмыйсың!

— Ә мине шунда алырлар микән?

— Ник алмасыннар ди, алырлар. Анда директор бик тә шәп кеше.

— Шәбен шәптер дә... Ләкин аның янына ничек узарга?

— Директорның секретаре минем ахирәт кыз, ул сөйләшер.

— Кирәкмәс. Минем үз телем дә бар ич... Тотам да керәм.

Кыз елмаеп куйды: «Тырышып кара, булдыра алырсың микән?»

Юк, авылдан яңа гына килгән егет монысын булдыра алмады. Аны проходнойдан уздырмадылар, пропуск сорадылар. Ә заводта эшләмәүче кешегә андый документны кем бирсен?

— Я, егетем, директорда булдыңмы? — диде кыз Галимулланы тагын күреп.

— Юк, кертмиләр икән...

— Син, алайса, кадрлар бүлегенә бар, теләгең-хыялыңны сөйләп бир. Һөнәр үзләштерәсем, корыч канатлы кошлар ясыйсым килә, диген. Минемчә, сине алырлар. Мондый яшь егетлар заводка бик тә кирәк.

Галимулла кадрлар бүлегенә килде, үзен эшкә алуларын сорады.

— Нинди дә булса һөнәрең бармы соң?

— Юк, — диде егет ык-мык итеп.

— Алайса, сине ФЗӨга җибәрәбез.

— Нәрсә соң ул ФЗӨ?

— Синең кебекләрне һөнәргә өйрәтү мәктәбе.

«Ике куллап риза — җибәрегез генә, рәхмәт төшкерләре!» — дип әйтәсе килде егетнең.

Галимулла фрезерлык һөнәренә, әкияттәге шикелле, көн өйрәнде, төн өйрәнде, мөстәкыйль рәвештә җайланмалар эшләүгә иреште. Квалификацияле фрезерчы дигән таныклыкны кулына алгач, авызы колагына җитәрдәй булды. Инде аның үз һөнәре бар! Сырлый белү генә түгел, хәтта тимерне дә чәчәк итә ала. Теге «сихерче» кыз очраса, шундый чәчәкләр ясап, кулына бер букет тоттырыр иде: зәңгәр, яшел, ак, кызыл... төстәгеләрне. Тик сарыны гына кушмас иде. Сары төс — сагыш, кайгы-хәсрәт, аерылышу, югалту билгесе, диләр бит...

Заводка килгәч, Галимулланы «ДИП-300» дигән яңа станокка куйдылар. Ул андый маркалы станок белән таныш иде инде — ФЗӨда нәкъ шушындый станокта өйрәнде. Өйрәнү, танышу бер булса, ә менә, һөнәр остасы булып, үз станогында эшләү, аның холкын белү, шуның белән дусларча серләшү, шуны үз ихтыярыңа буйсындыру бөтенләй икенче нәрсә. Яшь фрезерчы моны заводта эшли башлавының беренче атналарында ук бик яхшы аңлады. Бу хакта станокта эшли-эшли мыек-сакал чыгарган, чәчләре агарган Һидият агадан да ишеткәләде: «Станок дигәнең хатын-кыз шикеллерәк нәрсә ул. Я капризлы була, я беренче хәрәкәтеңнән үк сине аңлап ала. Станок холкына тәмам төшенер өчен бер пот тоз ашарга кирәк, энекәш. Менә мин ничә ел инде шул станокта эшлим, ләкин серләренә һаман төшенеп беткән юк әле. Ә менә гармун телләре белән мин сөйләшә дә, серләшә дә беләм...»

Үзе әйткәнчә, станокның барлык серләрен белеп бетермәсә дә, оста куллы кеше иде Һидият. Галимулла үзе белмәгәннәрен күбрәк аңардан сорашты. Тегесенең эчендәгесе тышында иде: норманы күбрәк бирим, акчаны каерыбрак төшерим дип, иптәшләреннән яшерен-батырын эшләмәде, белгәнен сөйләде, уртаклашты. Галимулланы эш күрсәтеп тә, сүз белән дә өйрәтте. «Син — яшь кеше, безнең кебекләрдән күбрәк белергә, күбрәк эшләргә тиешсең»,— дип әйтә иде ага кеше егеткә.

Менә Галимулла эштә рекордлар да куя башлады. Һидиятне дә узып китте. Остаз болай ук булыр дип уйламаган иде, әлбәттә. Ачулы кеше үз туныннан да үч алыр дигәндәй, Һидият, гармун белән артыграк мавыгамдыр дип, көмеш телле тальянкасын үз-үзеннән яшереп куйды һәм теш-тырнагы белән эшкә ябышты: «Ничек кенә булса да, Галимулла белән тигезләнергә!» Әмма, күпме генә тырышса да, шәкертен куып җитә алмады: норма белән дә, сыйфат ягыннан да. Азакта хәтта һөнәрен алмаштырырга мәҗбүр булды. Һидият Галимулла рекордлар куяр дип уйламагандай, Галимулла да Һидияттән моны һич көтмәгән иде. «Әллә вакытлыча гынамы?» — диде шәкерт, укытучысы турында уйланып. Бер атна, өч ай, хәтта ярты ел узды. Элеккеге өйрәтүчесе, әллә күпме фрезерлык стажы булган тәҗрибәле эшче, яңадан станогы янына басмады, ә шул ук цехта правщик булып эшли бирде.

Станогына кире кайтмаса кайтмады Һидият, шулай да Галимулланы армия сафларына озатырга вокзалга килде. Тальянкасы белән. Ул гармун уйнады, Галимулла җырлады. Юк, елап түгел, җырлап китте егет көнбатышка — әтиләре, абыйлары кан койган якларга.

Өч ел көтте станок армиядәге саперны, «моңаеп-зарыгып», кәләш көткән шикелле көтте... Менә солдат тагын үз заводына кайтты, станогы янына басты. Ә станок, шуны сизгәндәй, бөтен куәтенә гүләп эшли. Ахры, ул да үзенең чын иясе кем икәнен сизә, аның кулларын

тоя иде. Солдатның кайтуына цех начальнигы, чуваш егете Василий Николаевич Колосов та бик сөенде: «Ку екет пе эшлэмэ пулать!» [1].

Очар кошның терәге — канат, ә самолетта исә — лонжерон. Бермәлне лонжероннар-канатлар сафтан чыгу ешаебрак китте һәм алар дефициткa әверелде. Эшчедән алып директор хәтле директор телендә шул лонжерон булды: цехтамы, завод идарәсендәме, сынау мәйданчыгындамы... Элек лонжерон өч күчерештә эшләнде. Аны ясаганда кул хезмәте өстенлек тотты. Фрезерчы Галимулла исә аны әзерләүдә үз ысулын тапты: махсус почмаклы фрезер тәкъдим итте, барлык эшләр бер күчерештә башкарылды. Нәтиҗәдә, кулдан эшләү шактый кимеде, хезмәт җитештерүчәнлеге икеләтә артты. Яңа ысулны хезмәттәшләре дә файдалансын өчен, фрезерчы эскиз сызды һәм цех начальнигы кулына тоттырды. Конструкторлар Галимулла ысулын фрезерчыларга өйрәтеп «Лонжерон проблемасы»н хәл иттеләр. Галимулла тырышлыгы белән заводта тагын берничә проблема хәл ителде: әйтик, мәсәлән, элек үзәк белән эшкәртелгән торец үзәксез башкарыла башлады, корыч детальләрне эшкәртү өчен текә почмаклы спираль тәкъдим ителде, ике җайланма белән эшләнгән оснасткалар бер җайланмага калды.

Галимулла эшли алмаган фрезер станок юк заводта — нинди генә модельле булмасын, ул аның белән уртак тел таба, аны үзенә буйсындыра, тыңлата. Заводта андыйларны «универсал» диләр, алар теләсә нинди эшне башкара ала. Галимулла да инде универсал эшче. Ә эшчenең универсаллыгы физик эш белән акыл хезмәтенең производствода тигезләнүенә китерә. Фрезерчы Галимулла инженер да, конструктор да, технолог та түгел, ә квалификацияле гади эшче. Аның югары белем дипломы да юк. Ул — практик, чирек гасыр стажлы оста эшче.

Ә бит тәҗрибәгә бай практиклар арасында шундыйлар да була: нормаларын, йөкләмәләрен арттырып үтәп киләләр, авырлыклардан зарланмыйлар, шактый зур хезмәт хакы алалар — кыскасы, үз буразналарыннан салмак кына атлап алга баралар. Ә рационализаторлык эше, уйлап табу, яңалык кертү, техниканы камилләштерү аларны бик үк кызыксындырмый, теориягә ис-акыллары китми. Иске багаж, җитәр-җитмәс булган белем белән яшиләр. Җитмәсә тагын, без практиклар дип горурланып та яшиләр әле...

Галимулла да, әйткәнебезчә — практик. Ләкин ул хыялланып, уйлап-фикерләп, техник идеяләр белән «җенләнеп» яшәүче, яңалыклар эзләүче, аларны производствога кертү өчен янып-көеп йөрүче хезмәт иясе. Мин практик дип масаймый ул, киресенчә, күбрәк белемгә, теориягә өстенлек бирә, техника новаторларын аеруча хөрмәт итә. Галимулланың хәл итәсе, очына чыгасы үз проблемалары бар, шуңа ул рационализаторлык һәм уйлап табу эшләре белән шөгыльләнә, эзли, таба, кайчакта исә тапканын үзе үк кире кага, аннары тагын эзли, производствога тагын ниндидер яңалык кертә. Практика белән бәйле теория — менә шул булыр аның юлындагы якты маяклар.

«ДИП-300» станогы — фрезерчылык эшенең патшасы ул дияргә була. Советлар Союзында, шул исәптән Сергей Петрович Горбунов исемендәге авиация заводында да, фрезерлык эшләре нигездә шул станокта башкарыла. «ДИП-300» — Галимулланың күптәнге танышы, иске дусты. Әмма станок тизлегеннән тулысынча файдаландым дип әйтә алмый әле ул. Галимулла үзалдына шундый бурычны куйды: мөмкин хәтле зур тизлек белән эшләтергә станокны! Ул бик күп уйлады, җиде кат үлчәде, бер кат кисте, технологик процессларны камилләштерү юлларын эзләде, кайбер җайланмаларның станокта кирәкләре юк дип тапты, үзе конструкцияләгән чыдамлы фрездан файдалан-

[1] Ку екет пе эшлэмэ пулать — бу егет белән эшләп була!

ды... Болар конструкторлар, инженерлар, техниклар бәяли торган эшләр дип әйтергә була. Ә бит эшченең әле тик үзе генә белгән тагын күп нәрсә бар. Ул — эш урынын дөрес һәм акыллы итеп оештыра белү. Монысын инде югары белемле бер генә белгеч тә уйлап та чыгара, күрсәтә дә һәм әйтә дә алмый. Моны югары уку йортларында өйрәнелә торган дәреслекләр дә, чал чәчле профессорлар да Галимулла белгәнчә нечкәләп аңлатмастыр төсле.

Эш урынында аның һәрбер хәрәкәте санаулы. Эшкәртеләчәк заготовкалар һәм әзер детальләр станокка якын урынга, бер-берләре белән янәшә куелган булыр. Заготовканы алу һәм әзер детальне кую өчен бары тик җиде хәрәкәт ясарга кирәк. Кирәкле җайланмалар махсус стеллажда тора, ә инструмент — тумбочкада, кыскасы, аларның барысы да эш операцияләре башкарылган тәртипкә көйләп куелган, һәркайсы — тезелгән төймәләр кебек — үз урынында, берсен дә эзләп торасы юк. Бу исә эштә ритмлылык тудыра. Мәсәлән, үлчәү коралы — штангельнең «прапискасы» билгеле бер җирдә, шуңа фрезерчы аны карамыйча, «сукыр» килеш ала — башын да бормый, гәүдәсен дә селкетми. Шулай итеп, көч саклана, хәрәкәт экономияләнә. Ә бит фрезер станогында инструментлар, детальләр, җайланмаларны кую һәм кире алу өчен утыз-кырык процент вакыт китә һәм болар барысы да кулдан башкарыла. Галимулла операцияләрнең нинди тәртиптә башкарылуын тәртипкә салды, кул хезмәтенә киткән вакытны ун-унбиш процентка калдырды. «ДИП-300» станогы белән янәшәдә генә башка төр җиһазлар тора, кирәк икән, детальләр икенче төр станокта әзерләнә. Заготовкаларны эш урынына ярдәмче эшчеләр алдан ук китерә, әзер детальләр күперле кран белән озатыла тора. Цехта «Бүген — иртәгесе өчен» дигән принцип белән эш итү кагыйдәгә кергән. Галимулла, моны үзенчә файдаланып, иртәгәге задание белән бүген ук танышып куя, сызымнарны, технологияне өйрәнә, кирәкле инструментларны һәм җайланмаларны әзерләп калдыра. Иртәгесен эшкә килү белән үк ул детальләр эшкәртүгә керешә. Эштә катгый дисциплина һәр минутның кадерен белергә өйрәтә.

Бары тик югары сыйфатлы продукция генә җитештерә Галимулла, әзер детальләрне беренче күрсәтүдә үк тапшыра, техник-контроль бүлеге аша түгел, ә турыдан-туры җыю цехына — аның шәхси клэймәсе бар. Заводта беренчеләрдән булып коммунистик хезмәт ударнигы дигән югары исемгә лаек булган хезмәт новаторына һәрнәрсәдә дә ышаналар. Галимулла Социалистик Хезмәт Герое, авиациянең атаклы белгечләре Николай Максимов, Ленин ордены кавалеры Василий Колосов, хәзерге цех начальнигы Сергей Павлинский, цех парторгы Миңнур Шәйхуллиннар тәрбиясендә эшче мәктәбен үткән кеше. В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу алдыннан Павлинский һәм Шәйхуллин аңа партиягә керергә рекомендация бирделәр. Остазларының ышанычын аклап эшли Галимулла: узган елның июнендә бишьеллыкның өч еллык заданиесен үтәде, планнан тыш бик күп продукция бирде. Бишьеллыкның бөтен заданиеләрен киләсе елның май аенда төгәлләргә сүзе бар.

Галимулланы заводта чын мәгънәсендә өйрәтүче, тәрбияче, наставник дип атыйлар. Аның шәкертләре күп. Шулардан Байтуллин, Давыдов, Вахитов кебек югары разрядлы фрезерчылар эш нормаларын һәр көнне 140—150 процентка үтәп баралар. Заводта эшләү дәверендә Галимулла егерме кешене һөнәргә өйрәтте.

Галимулла Әсһадуллинның СССР Верховный Советы депутаты булып сайлануына әле бер ел да юк. Ә аңардан киңәш яки ярдәм сорап депутат булмасенә дә, Ленин районының Армавир урамындагы таш йортка да әнә нихәтле сайлаучы килде инде. Кичке техникумда укырга комачаулыйлар... Өйләнештек, квартира кирәк. Баланы бакчага ур-

наштырасы иде, энием авырый. Поселок йортларының барысына да су һәм газ кертәсе иде... Нинди генә сораулар белән мөрәҗәгать итмиләр кешеләр. Хәтта бер әби: «Йоклый алмый аптырыйм, Мәскәүгә баргач, Кремль врачыннан дару алып кайтмассыңмы икән?» — дип тә килгәнен елмаеп әйтте ул. Галимулла, чәй куеп, аның белән бик озак сөйләшеп утырган. Шул хәтле арада өйдә хатын-кыз заты күренмәгәч:

— Депутат башың белән әллә хатынсыз торасыңмы? — ди икән әби.

— Больницада, апай, тормыш иптәшем,— ди Галимулла сабыр гына. — Улым каты авырый, шуның янында ул.

— Ә мин йоклый алмыйм дип, синең башыңны әйләндереп йөрим тагын, кичер инде, мин карчыкны... Ә улыңа озын гомер телим, тизрәк сау-сәламәтләнсен. Минем аягым җиңел, улым, терелер, терелер!..

— Йортың әйбәт, җиһазларың мул. Казенныйдыр инде, депутат дип биргәннәрдер?

— Ялгышасың, апа. Үзебез салдык, хатыным Равилә белән. Заводтан кирпеч, ә исполкомнан урын алдык.

— Алмагачларны да үзегез утырткансыз инде, алайса?

— Үзебез, апа, үзебез. Дөрес, авылдан килгән Мөдәррис энем булышкан иде. Бик тә табигать җанлы кеше... Җәен килеп, аның балалары бездә ял итә, күбәү алар, ә бердәнбер абыйлары мин...

Әбинең күзләренә урындык артына элеп куйган костюмдагы ялтыравык йолдыз чалынып китте.

— Син героймыни, улым?

Галимулла дәшмәде.

— Герой да, депутат та, бик тә булдыклы кеше икәнсең. Яраталардыр шул үзеңне, яраталардыр?..

Әйе, Галимулланы заводта да, яшәгән урынында да, туган җирендә дә яраталар һәм аның исемен зур хөрмәт белән телгә алалар.

Галимулла Арча якларындагы сиксән-туксан йортлы, кечкенә генә Мирҗәм авылында туып үскән. Мәшһүр Тукаебыз сурәтләгән Былтыр йөргән карурманнарның шавын тыңлаган, инешләреннән сулар эчкән. Былтыр да батыр, Галимулла да батыр... Ләкин ул бүгенге батыр. Кечкенә Мирҗәм авылының дүртенче батыры. Социалистик Хезмәт Герое исеменә ул зур тырышлыгы һәм эшкә бирелгәнлеге өчен лаек булды. Аның күкрәген Ленин ордены белән бергә Алтын Йолдыз медале бизи, алар белән янәшә Хезмәт Кызыл Байрагы ордены балкый. Хезмәт кешене әнә нинди биеклекләргә күтәрә!..

Җиңү салюты яңгыраган көнгә тиздән 30 ел тула. Озакка сузылган авыр сугыш була бу. 1941 елның 22 июнь таңында башлана һәм 1945 елның 8 маенда төш турында тәмамлана. Барлыгы 1417 көн һәм төн. Һәр минуты тиңсез батырлыклар белән билгеләнгән көннәр иде ул. Авыр сынаулар инде артта калды. Ләкин барысы да әле кичә генә булган кебек. Бөтен халык батырлыгына әйләнгән ул көннәрне онытып буламы соң! Вакыт күбрәк узган саен ул вакыйгаларның зурлыгы күбрәк күренә, сугыш дәһшәтләрен узган кешеләрнең рухи байлыгы ныграк ачыла гына бара.

Бөек халкыбыз белән бергә бу изге сугышта илебезнең язучылары да катнашты. Алар совет солдатының батырлыгы турындагы беренче әсәрләрен окопларда, авыр походларда яздылар.

Ватанчылык һәм батырлык темасы, мәхәббәт кебек үк, мәңгелек тема. Менә утыз ел инде язучылар халкыбызга Ватан сугышы сәхифәләре турында романнар, повестьлар, шигырь һәм поэмалар, пьесалар, кинофильмнар бүләк итәләр. Бу әсәрләр сугыштан соң килгән яңа буынга әтиләренең батырлыкларын сөйлиләр, дошманны җиңү гыйлемен өйрәтәләр.

Әле күптән түгел генә Мәскәүнең «Детская литература» нәшриятында «Безнең батарея сугышчылары» дигән китап чыкты. Бу җыентыкка сугышка үзе катнашкан, җиңү көнен якынайтуга автомат һәм каләм белән булышкан илле язучының әсәре тупланган. Илле язучы — утыз милләт вәкиле. Бу данлы батареяда татар язучылары — лейтенант Сибгат Хәким һәм Заслонов берләшмәсе партизаны Зәки Нури да бар.

Журналыбызның бу саныннан башлап «Безнең батарея сугышчылары» дигән шушы китаптан төрле милләт сугышчыларының батырлыклары турында сөйләгән хикәяләрне биреп барырбыз.

## Петр Павленко

# ЯКТАШЫМ ЮСУПОВ



Безнең батальонда Торгонбай Юсуповтан башка бер үзбәк тә юк иде. Юсупов русчаны начар белә, шунлыктан башка сугышчылар үзләренең колхозлары, хатыннары һәм балалары турында сөйләргә җыелсалар, тыңлап торудан бүтән чарасы булмый.

Барысының да уртак сүзләре бар, тик ул гына ятим булып утыра. Мондый хәл күзгә тиз ташлана. Мин дә Торгонбайны күргәч тә аңа авыр икәнен аңлап алдым.

Без Донның югары агымында артык тирән булмаган дала үзәнендә ята идек. Еракта сугыш бара. Батальон нәкъ немец позицияләренә, ут эченә табарак күченү өчен караңгы төшкәнен көтә. Саперлар миналар һәм бикфорд җепләрен әзерләп куйдылар. Инде төш җитеп килә, баш очында кояш кыздыра. Дала өсте кызды-

рылган икмәк ярылгандай кыштырдый, ләкин ул меңнәрчә чикерткәләрдән килгән тавыш кына.

Без баш очында үзебезнең һәм немецның истребительләре сугышканны карап, шиңә башлаган куе үлән арасында ятабыз. Вакыт туктап калган кебек. Кояш баерга җыенмый да, күпме теләсәң, шул хәтле сөйләшеп ятарга мөмкин.

Уралдан килгән өч сугышчы уртак танышлары турында сөйләшеп ята. Полтавалы Горб Орлов егете Вырубовның якташы булмаса да, Мариупольдә ике сезон бергә эшләгәннәр, заводны, шәһәрнең урамнарын, бакчаларын туган җирләре кебек сагынып сөйлиләр. Торгонбай Юсупов кына алардан бер читтәрәк, кечкенә генә инеш буенда нидер эшләп маташа. Ул агымга каршы таш куйган икән дә, таш аркылы челтерәп аккан су тавышын тыңлап ята.

Мин Юсупов янына шуып килдем дә иңбашына кулым салдым.

— Торгонбай әкә! — дидем,— Ферганәдә яхшыдыр хәзер! Кояш. Персиклар. Арыкта су челтери. Арыкка кирпечне утыртып куйсаң шарлавык була. Төнлә арык өстенә топчан куясың. Ятасың шулай, ә арыкта әкрен генә су челтери, әниең җырлап йоклаткан кебек була.

— Әй, иптәш! — ди Торгонбай һәм бәхеттән тынсыз кала: ул бит Ферганәдән килгән.— Син безнең Ферганәне беләсеңмени? Әй, яхшы! Әй, рәхмәт сиңа! Күптән беләсеңме?

— Ферганәне барысы да белә,— дим мин, ләкин ул боегып башын чайкый. — Без барыбыз да анда булдык,— дип сүземне дәвам итәм, Торгонбайның кулын алып; аның кулы коры һәм шоп-шома. — Сез Зур Ферганә каналын төзегәндә күңелебез белән без барыбыз да шунда идек.

Мин, терсәкләремә күтәрелеп, сапер Арменак Папазьянга дәштем:

— Арменак! Ферганәне беләсеңме?

— Юк,— диде ул, күктән күзен алмыйча, анда безнең һәм дошманның дистәгә якын истребительләре җан тартышып сугышалар иде.

— Ә Ферганә ысулын?

— Ул ысулны беләм,— диде ул күкрәгенә капланып ятып һәм каш өстенә кулын куеп миңа карады.— Ферганә ысулы — матур әйбер ул,— диде Арменак.— Зур эффект бирә.

— Кем зур эффект бирә? — дип сорады Горб.

Аңар аңлатып бирделәр.

— Нәрсәдер инде ул, шул Ферганә ысулы? Күпме укыдым шуның турында, ни икәнен төшенә алмадым.

Торгонбай чыбык алып, үзләренең Ферганә каналында ничек эшләүләре турында сөйли башлауга сержант Циглер бүлдерде:

— Без Кубаньда,— диде ул,— Тщик сусаклагычы төзегәндә Ферганә ысулын үзебезгә камилләштердек. Хәзер Ферганә ысулы дип түгел, ә Кубань ысулы дип әйтү дөресрәк булыр. Ә бөтен эш менә нәрсәдә тора...

Ләкин Юсупов аңа сөйләргә бирмәде. Ул ант иткәндәгедәй кулын күтәреп, тезләнеп утырды.

— Иптәш сержант! Алай ярамый! — диде ул. Аның күзләре шартлап чыгарлык булып түгәрәкләнде, җете кара төскә керде.

Сүзгә ярлы иде ул, фикерен әйтеп бирә алмаудан курыкты.

— Менә безнең якташ,— дип, Торгонбай миңа күрсәтте. — Ул әйтсен. Зинһар, аңа комачаулама.

Мин Ферганә ысулы, беренче канал батырлары турында сөйләдем. Шау-шулы халык трассасындагы төнге утларны искә алдым. Төзелештә халык энтузиазмының көчле дулкынын үзбәкләргә кадәр әле беркем күтәрмәгән иде. Бөтенесе дә бик яңа, хәтта бәхәсле дә иде. Бар нәрсә

халык арасында, хәрәкәттә туа, шунда ук ныгый да. Гаҗәеп бер бәйрәм булды ул, халык китмәне белән сөйләнгән сокландыргыч әкият.

Соңыннан аны Әрмәнстанда, Әзербайҗанда, Кубаньда, башка бик күп җирләрдә кабатлап сөйләделәр. Әмма аның туган җире Ферганә иде.

— Билгеле, беренче булып үзбәкләр башлап җибәрде, алар кебек җир казучыларны эзләп табасы да бар әле, дип безнең белән Циглер да килеште. Шулай да соңыннан Кубаньда бу ысулны күп мәртәбә яхшыртуга ирештеләр, дип тә куйды ул.

— Ә Ферганәдә мин үзем булдым, андагы тормышны карарга барган идем,— диде Циглер. — Ферганә белән Маргелан — менә дигән шәһәрләр. Бакчалары да искиткеч. Ә виноград — андые инде Кубаньда да юк. Виноград — искиткеч!

Торгонбай белән без җиңдек.

Һәм җиңүчеләр буларак тартынмыйча сөйләргә хакыбыз да бар иде.

— Ә Дүсмәтов кайда? Сарымсаков кайда? Кайда Кендынбабаев? Җор телле, шат күңелле Мирзамахсудов кайда?

Юсупов иңбашларын җыерып куйды:

— Августның җиденче көне.

— Ул елны җиде көн моннан элек каналда зур эш башланды.

— Ул елны өченче көн Кендынбабаев сигез норма бирде, бүген — тугыз, ә иртәгәсе көнне ун норма иде!

Шулай диде дә Юсупов шатланып һәм горурланып көлеп җибәрде.

— Хәтерлисеңме, каналга Хәлимә Насыйрова килгән иде,— дип сорадым мин аннан. — Хәтерлисеңме, бер төнне ул җырлады һәм кешеләр йөрәкләрен тартып алып җырчыга бирергә теләгәндәй, кулларын күкрәкләренә суга-суга, аңа: «Китмә! Югалма!» дип кычкырдылар.

Торгонбай хәтерлим дип башын какты һәм безгә Хәмзә җырын җырлап күрсәтте. Куйган-Яр плотинасында Хәлимә җырлаган җыр иде ул. Без әле ул чакта, бөтенебез бер йөрәк булып, аны тыңлаган идек. Арменак Папазьянның бу җырны әллә радиодан, әллә пластинкадан ишеткәне бар икән, ә Горб Хәлимәнең рәсемен бөтенсоюз күргәзмәсендә күргән. Шулай сөйләшеп утыргач без үзебезне тагын да якынрак туганнар күк сизә башладык. Ул арада көн дә үтеп бара икән, кояш баерга якынлашып килә. Караңгыланып барган күк йөзендә соңгы сугышлар да басылды, бездән алдарак шаулаган туп тавышлары да миналар чапылдавына, ракеталар җемелдәвенә юл куеп, теләр-теләмәс кенә тындылар.

Караңгы төшүгә, җир өсте дә тынычланды. Тын булып калды. Бу тынлыкта салкынча, рәхәт булып китте.

Караңгы сапер сәгате якынлашты. Без Юсупов белән янәшә ятабыз. Ул биек күк йөзенә караган, ә күз алдында туган җире иде булса кирәк. Мин дә шул яклар турында уйлыйм.

Без Ферганәнең күләгәле бакчаларын, яшел җир өстенә ташланган күк йөзе кыйпылчыкларын хәтерләткән дөге басуларын, җимешләре кызыл хрусталь кебек асылынып торган гранат агачларын күргәндәй, канатларын әкрен генә шапылдатып өй түбәсендәге ояларына очып килгән зур ботлы ләкләкләрне ишеткәндәй булдык. Ферганә юлларының төтен кебек җиңел коры тузаны әйтерсең лә күзебезне әчеттерде.

Хәлимә! Элекке кебек үк җырлыйсызмы икән сез? Җырлагыз, Донның югары агымындагы үзбәкләр дә сезне ишетсен. Руслар да бит сезне белә, алар да сезне ишетсен! Җырлагыз, һәр вакыт. Торгонбай Юсупов янында булгандай итеп җырлагыз!

— Хәлимәнең җырлавын телисеңме, Юсупов?

— Алар белмиләр,— дип, иптәшләр ягына баш какты ул.— Алар аның портретын гына күргәннәр. Ферганә ысулының да портретын гына күргәннәр алар. Мин җырлый алмыйм, ә Ферганә ысулын төнлә күрсәтермен әле,— диде ул һәм горурлыктан, ашкынудан тирән итеп сулап куйды. — Ферганә ысулының яшәве мөмкин, Ферганә ысулының үлүе мөмкин...

Төн көтмәгәндә килеп басты. Мәченең акрын адымын сизеп алгач, качып киткән тычкан кебек кичке якның барлык төсләре бердән югалды.

— Әзерләнергә! — дигән приказ сугышчыдан сугышчыга күчеп йөрде.

Юсупов инешкә аркылы куйган кирпечне алып ташлады, су чылтыравыннан тукталды. Ул яна торган сыекча тутырылган ике шешә, шартлаткыч һәм нечкә тимер чыбык кисәге алды.

— Минаны нигә әрәм итәргә? — диде ул.— Җирнең авыры була, җиңеле була. Монда нәкъ җиңеле. Карап тор, мин менә нәрсә ясыйм.

Һәм ул ике шешәне ничек итеп җиргә күмүен, аларны шартлаткыч тагылган тимер чыбыкка тоташтыруын күрсәтте. Озак вакыттан соң шартлый торган минага охшашлы иде бу.

— Мин китмәнче. Җирне беләм мин, китмәнче-сапер. Арзанга төшәр — бик күңелле булыр!

Без саубуллаштык.

Бер сәгать үткә, немецлар окобы каршында ук бере арты бере көчле шартлаулар башланды. Төн яктырып китте. Автоматлар такылдарга тотынды. Югарыга ракета артыннан ракета очты.

Немецлар бөтен участок буйлап ут ачтылар.

Мин майор блиндажында таң атканын көтеп утыра идем.

— Нәрсә дип шул хәтле минаны әрәм итәсез,— дип батальонга шалтыратты ул.— Нәрсә? Ферганә ысулы белән?.. Ул нәрсә тагын? Әһә! Шәп! Культурно... Бүләккә куярга, бүләккә! Яратам тапкырлыкны! Культурно!

— Димәк, минем якташ үзен күрсәтте, — дидем мин майорга.— Торгонбай Юсупов ул.

— Сез дә үзбәкмени?

— Юк, ләкин без аның белән якташ.

— Төпле халык,— диде майор, һәм мин аның караңгыда елмаюын сиздем.— Ферганә ысулы белән! Кара син аны! Культурно! Позициядә өч җирдән юл ясаганнар, тагын ике җиргә алдавыч куйганнар. Бер минасыз бит! Бик тә культурно! Чын менә! Яратам!

# ИМПЕРИЯ КАНЦЕЛЯРИЯСЕН ШТУРМЛАГАНДА




елның 2 маенда Совет Армиясе сугышчылары немец фашистларының соңгы терәге — империя канцеляриясенә ныгып урнашкан соңгы өерен тар-мар иттеләр. Фашизмның үзәк өне туздырылды. Нәкъ менә шушы канцеляриядән инде бөтен дөньяны яулап алырга хыялланган Адольф Гитлер үзенең иң астыртын һәм иң ерткыч боерыкларын биргән. Монда Советлар Союзын «яшен тиз-легендә» басып алу турындагы «Барбаросса» планы эшләнгән. Һәм шушында ук Гитлер агу эчеп үз-үзен үтергән.

Әйе, бу канцелярия ерткыч гитлерчыларның үзәк штабы. Гитлер һәм аның генераллары шуннан торып дөньяны канга батыру, халыкларны колга әйләндерү яки кырып бетерү, дәүләтләрне җимерү, шәһәр-авылларны хәрабәгә әверелдерү белән идарә иттеләр.

Империя канцеляриясен штурмлауга Исхак Гомәров полкы иң беренчеләрдән булып ташлана. Бу турыда үзәк газеталарда һәм журналларда шактый материаллар булды. «Азат итү» кинокартинасында да империя канцеляриясен алучылар арасында бер татар каһарманы фамилиясе телгә алына. Менә шулар мине уйланырга, эзләнергә, Совет Армиясе архивына хатлар язарга, Берлин операциясендә катнашкан кешеләр белән элемтәгә керергә, аларны күреп сөйләшергә мәҗбүр итте.

Кем ул Гомәров? Кайда туган һәм хәзер кайда яши? Менә бу сорауларга җавап табу өчен мин шактый юллар урадым. Соңга таба Гомәровның Уфада торганлыгын белдем.

Гомәров Исхак Идрис улы 1912 елның 10 апрелендә Башкортстанның Баймак районы Үрге Мәмбәт авылында туган. Исхак өченче бала булган һәм бик кечкенәдән үк әтисеннән ятим калган. Шуның өчен аңа унбер-унике яшеннән үк әнисе Хәмидәгә булышырга туры килә. Баймак районында бик күпләр бакыр һәм алтын чыгару эшендә йөргәннәр. Кечкенә Исхак та алар белән алтын эзләп ком-ташлар актарган...

Үрге Мәмбәт авылы табигатьнең матур җирендә урнашкан. Сөзәк таулар, челтерәп аккан чишмәләр, төз наратлар, ап-ак каеннар, яшел әрәмәлекләр авылга ямь биреп тора. Ерак түгел генә Сакмар елгасы ага.

Тырыш, эшчән комсомолец Исхакны 1933 елда Кызыл Армия сафына алалар. Ул комсомол чакыруы буенча Казандагы хәрби мәктәпкә укырга керә.

Бу хәрби мәктәпнең комиссары Нигъмәт Еникеев яшь егеттә ташып торган энергия күрә һәм Исхакка хәрби белемне отличнога үз-



ләштерергә һәм үзен армиягә багышларга киңәш бирә. Курсант Исхак аның киңәшләрен җиренә җиткереп үти, курсны уңышлы тәгәлли һәм кызыл командир булып чыга.

Исхак Казанда укыган вакытларда татар язучылары белән якыннан аралаша — Кави Нәҗми, Муса Җәлил, Мөхәммәт Әблиев аның дуслары була. Казанда ук спорт ярышларында катнаша, алдынгы урыннарның берсен алып Мәскәүгә бара. Хәтта сабан туенда батыр да кала.

Татар-башкорт хәрби мәктәбен 1936 елда бетергәннән соң Гомәров Камчаткага китә. Анда ул рота командиры булып хезмәт итә. Соңыннан Хәрби академиядә укый.

Бөек Ватан сугышы башланган көннәрдә Исхак Гомәров Белоруссиядә була. Ул сугышның беренче көненнән үк дошманга каршы алгы сызыкта көрәш сафына баса. Смоленск шәһәре өчен сугышларда, Мәскәү янындагы бәрелешләрдә дивизия командирыннан берничә тапкыр рәхмәт ала.

Сталинград янындагы сугышларда көнгә унар-егермешәр мәртәбә атакага күтәрелергә туры килә. Гомәров сугышчылары, фашистларны тар-мар итеп, «Кызыл Октябрь» заводын азат итәләр. Аннан соң дошманны куа-куа Украинага килеп керәләр. Сугышларда күрсәткән батырлыгы һәм кыюлыгы өчен Гомәров подполковник дәрәҗәсенә күтәрелә һәм полк белән командалык итә башлый. Аның полкы Орел-Курск, Яссы-Кишинев, Висла-Одер һәм Берлин операцияләренә катнаша.

Берлин өчен барган кан коюлы сугышларда да подполковник Исхак Гомәров полкы батырлыгы белән танылa.

Исхак Гомәров полкы беренчеләрдән булып Шпрее елгасын кичеп чыга һәм дошманның беренче траншеяларына, ныгытмаларына бәреп керә. 29 апрельдә гестапо йортына һөҗүм башлана. Сугышчылар «Фашистларга үлем!», «Гитлерга үлем!» дип ярсый-ярсый алга ташланалар. Окопларга, подвалларга, йортларга, чормаларга ныгып урнашкан гитлерчыларга каршы кул сугышлары башланып китә.

Империя канцеляриясен фашистларның иң ышанычлы, өчәр-дүртәр тимер тәре ордены алган сугышчылары саклый. «Тигр» танклары һәм туплар туктаусыз атып тора.

Һәр карыш җир өчен сугыш кызганнан-кыза.

Каты сугышлар барган вакытта подполковник Исхак Гомәровның команда пунктына ак флаг күтәргән дүрт немец килүе күренә. Гомәров атуны туктатырга куша. Подполковник Зейферд, Геббельс рефе-

ренты Вольф Хейрисдорф, бер солдат һәм тәрҗемәче команда пунктына килеп керә.

Геббельс референты Вольф Хейрисдорф 301 нче укчы дивизия командиры генерал Антоновка һәм подполковник Гомәровка Георгиевский тәре төшерелгән алтын вензельле көмеш портсигар бирә. Бу портсигар рус офицерына 1760 елда Берлинны алган өчен бүләк итеп бирелгән була. Аннан соң ул, немецлар Украинаны 1918—20 елларны басып алгач, яңадан немецлар кулына күчә.

Геббельс тарафыннан җибәрелгән референт еларга җитешкән кыяфәттә совет командирларына баш ия һәм немец телендә болай ди:

— Көмеш портсигарга Берлиндагы Бранденбург капкасының ачкычы төшерелгән. Россиянең Германияне җиңүен танып, символик ачкыч төшерелгән портсигарны сезгә тапшырам. Германия сугышта оттырды. Хәзер без җиңелдек.

Совет командованиесе бер генә таләп куя: капитуляция!

1050 нче полкның күзәтү пункты һәм штабы. Ул Дания посольствосы бинасына урнашкан. Капитан Петр Япрынцев җимерек стеналарга ышыкланып, ут-төтен һәм кирпеч ватыклары арасыннан икенче төркем парламентерларны алып килә. Подполковник Гомәров һәм башка командирлар күзләрен кан баскан немецларны каршы алып, аларның ни өчен килүләрен сорыйлар. Немец парламентерларының берсе алгарак чыга һәм Гитлерның адъютанты генерал-майор фон Бургдорф кул куйган, дүрт-биш урыннан сургучланган пакет тапшыра. Пакет эчендәге кәгазьгә 30 апрельдә 15 сәгать 55 минутта Германиянең фюреры Адольф Гитлерның үзен-үзе үтерүе, империя белән җитәкчелек итүне доктор Геббельска тапшыруы язылган була.

Капитан Япрынцев 1 май көнне Гомәров штабына фашист генералы Кребсны китерә.

Совет командованиесе каршылык күрсәтүне туктатырга дип немецларга тәкъдим итә.

Бу вакытта Берлинда каты сугышлар бара. «Красная звезда» газетасы хәбәрчесе телефон аша Берлин белән сөйләшә һәм 1945 елның 1 маенда түбәндәгеләрне язып чыга:

«Совет гарнизоны начальнигы һәм Берлин коменданты генерал-полковник Берзарин сөйли.

— Исәнмесез, иптәш генерал, хәзер Берлинда нәрсәләр булуы турында сөйләвегезне үтенәбез.

— Шатлыклы хәбәрләр белән сезне куандырырга телим. Безнең сугышчылар һөҗүмне уңышлы алып баралар, дошманны кысрыклап фашистлар Германиясе башкаласының үзәк районнарында яңаданяңа кварталлар алалар.

Бәрелешләр бик каты, гитлерчылар нык каршылык күрсәтә. Ләкин безнең данлы сугышчыларыбыз алга һәм алга баруны дәвам итәләр.

— Кемнәр бүген сугышларда үзләренең батырлыгы белән танылдылар?

— Берлин урамнарында Советлар Союзының барлык милләт уллары сугышалар. Аерата батырлык һәм ныклык күрсәтеп генерал-майор Фомичев, Гаспарян, полковник Кондратенко, подполковник Терехин, подполковник Гомәров, Радаев, Чайка сугышчылары һәм офицерлары сугышалар».

Гитлерның соңгы өмете булган малайлар һәм картлар төркем-төркем булып пленга төшәләр.

1050 нче укчы полк солдаты комсомолец Николай Некрасов гестапо бинасының түбәсенә Кызыл флаг элә. Шул ук полкның офицеры— өлкән лейтенант Сәиджан Алимов һәм солдат Иванов Авиация министрлыгы бинасына флаг куялар. Империя канцеляриясенә һө-

җүм иткәндә Сәиджан каты яралана, ләкин алгы сызыктан китми.
Подполковник Исхак Гомәров командалыгындагы полкның политбүлек инструкторы майор Анна Никулина империя канцеляриясе өстенә Җиңү байрагы элә. Монда күрсәткән батырлыгы өчен ул Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә.

Империя канцеляриясенә штурм вакытында 1050 нче полк сугышчылары фашистлардан берничә йортны һәм госпитальне алалар. Яралы немецлар үзләренә үлем булыр дип көтеп торганда, подполковник И. Гомәров яралыларны ашатырга һәм аларга медицина ярдәме күрсәтергә куша. Аның мондый мәрхәмәтле булуын күреп торган яралы солдат Курт Мерхардның күзләреннән яшь бәреп чыга.

— Без совет сугышчыларыннан мондый яхшылыкны көтмәдек. Безне руслар атып үтерерләр дип бик каты курыккан идек. Рәхмәт сезгә,—ди ул.

Каты сугышлардан соң империя канцеляриясе алына. Канцеляриянең подвалында Гитлер өчен махсус эшләнгән бункерда илледән артык яхшы җиһазландырылган бүлмә булып, тышкы дөнья белән телефон аша гына элемтә тотылган. Җир асты канцеляриясенә бары тик эчке яктан гына керергә мөмкин булган.

Менә шушы бункерда фашизмның башлыгы—Адольф Гитлер һәм аның сөяркәсе Ева Браун үзләрен агулап үтергәннәр.

Бункер бүлмәләренең берсендә доктор Геббельс, аның хатыны һәм балалары агуланып үлгәннәр.

1050 нче укчы полкның сугышчылары дөнья өстенә куркыныч афәт булып торган фашизмның символы—зур һәм кара свастиканы империя канцеляриясенең түбәсеннән бәреп төшерәләр. Фашизмның оясы туздырыла.

1945 елның 8 маенда Гитлер Германиясе капитуляция ясады.

9 май Җиңү көне дип игълан ителде. Берлинда—рейхстагта, империя канцеляриясендә, гестапо бинасы өстендә Җиңү байраклары җилфердәде. Дүрт ел буе авыр сугышларда катнашкан совет сугышчылары туган җирләренә тыныч төзелешкә кайттылар. Подполковник Исхак Гомәров армия сафында калды. Ул каты контузия алуына карамастан, төрле җаваплы хәрби эшләр башкарды. Соңгы елларда гына пенсиягә чыкты.

Авыр сугышларда чыныккан, утлар-сулар кичкән батыр командир Исхак Гомәров хәзерге көндә, лаеклы ялда булуына карамастан, төрле җәмәгать эшләренә катнаша. Ул завод-фабрикаларга, колхозларга, хәрби частьларга бара, эшчеләр, колхозчылар һәм Совет Армиясе сугышчылары белән очраша, аларга сугыш эпизодлары, империя канцеляриясен штурмлавы турында сөйли. Ул Уфада гына түгел, Мәскәүдә, Волгоградта, Варшавада, Ленинградта, Кишиневта, Харьковта, Орелда һәм Курскида көтеп алынган кунак. Һәр елны Җиңү көнендә ул полкташлары белән очраша, алар белән үткән көннәрне — сугыш гарасатларын, җиңеп алга барган шатлыклы вакытларны искә алалар.

Бөек Ватан сугышы ветераны, подполковник Исхак Гомәров күкрәгендә утызга якын орден һәм медаль балкый. Ул Варшаваны азат итүдә батырлык күрсәткән өчен Польша дәүләтенең дә ордены һәм медале белән бүләкләнә.

Батыр сугышчы турында китапларда, газета-журналларда язып чыктылар. Шулар арасында Советлар Союзы маршалы, дүрт тапкыр Советлар Союзы Герое Г. К. Жуковның «Истәлекләр һәм уйланулар», «Правда» хәбәрчесе Мартен Мержановның «Бу шулай булды» дигән китаплары аерата игътибарга лаеклы. Бу батыр кеше турында «Красный воин», Комсомольская правда», «Красная звезда», «Вечерняя Москва», «Вечерний Тбилиси», «Неделя» һ. б. газеталарында, «Юность», «Огонек», «Новое время», «Военно-патриотический журнал» һ. б. ларда язылды.

САМАТ ШАКИР

**Ян Грант,**

Латвия язучысы

# КЕЧКЕНӘ ИНЕШНЕҢ БАШЫ

Бу инеш оператив картада, кызлар кулының зәңгәрсу тамыры кебек, бормаланып ята, ә үзе җеп калынлыгында гына, окоплар каршындагы урында аның киңлеге ун метрдан артмый. Капитан Огле картага караган көе, бу инеш кайдадыр зур елгага коя, ә елга үзенең суларын диңгезгә илтә, дип уйлый.

Елгалар үткән юл турында Огле әле сугышка хәтле үк, дөньяда бар нәрсәдән дә ныграк туган җирендәге суларны сагынганда уйлый иде. Аларны ул биредә, сазлыкта утырганда да сагына. Ләкин бу турыда уйларга вакыты гына калмый аның.

Яр буендагы землянканың һавасы дымлы, тынчу һәм граната ярылгандагы кебек әчкелтем ис килеп тора. Ә бүрәнә стеналар артында әкрен генә таң атып килә. Тал агачлары җилдә туктаусыз шаулап утыра һәм вак дулкыннар чапылдый. Капитанның яралы аягы тагын бот төбенә кадәр сызлый башлады.

...Алар иптәшләрен кичә, эңгер-меңгер төшкәч, алыштырдылар. Төн уртасында яңгыр башланды. Рота элекке позицияләргә — берничә атна элек, каты сугышлардан соң алынган окопларга урнашты. Ул сугыштан соң озак та үтми, полк ялга киткән иде, шунлыктан капитанның бу тирәләр турындагы мәгълүматы бик аз булды. Яңадан кайтып, позицияләрне тикшереп чыккач та ул шушы берничә көн эчендә хәлнең үзгәрмәвенә ышанды. Бары тик табигатьтә көзге төсләр генә арта төшкән иде.

Окоплар кызыл балчыклы яр буйлап сузылганнар, яр читендә осколкалар тиеп сирәкләнгән, пулялардан яргаланган куаклар үсә. Елганың каршы як яры биегрәк булып, сөзәк иңкелле тауга әйләнә, әле күптән түгел иңкелдә авыл булган. Хәзер аның картадагы исеме калган да, кайчандыр күләгәле аллея булган урынны күрсәтеп, янып көйгән тал агачы гына утыра. Җимерелеп беткән авыл читеннән калкулык тагын да текәләнеп китә, ә аның нәкъ түбәсеннән немецларның алгы позициясе үтә.

Ялангач тау битеннән шылт иткән тавыш та килми. Үзәнлек һәм яр буенда үле тынлык. Ләкин моңа беркем дә алданмый.

Огле елганың үзән белән кисешкән җирендәге ротаның сул флангысындагы оборона системасыннан риза түгел иде. Тал, шомырт һәм

абага белән капланган үзән шактый ара немец позицияләренә параллель бара да кинәт борыла һәм мәгарә авызы сыманрак бер урын ясап, авылның көньягында елга ярына ук барып житә. Шуннан ишетелгән сирәк атыш тавышлары жир астыннан килгәндәй булып яңгырый. Бу тавыш баштарак капитанның игътибарын артык жәлеп итми. Әмма ул бу турыга немец снайперларының атып торуларын, аларның пулясыннан ялга киткән ротаның командиры һәм берничә кызылармеецның һәлак булуын исенә китерә. Огле тагын картага күз төшерә, ату тавышларына колак сала һәм авылдан аталар дигән фикергә килә. Моның өчен үзән жайлы урын түгел. Землянка почмагында, адашып калган бала кош кебек, кыр телефоны пипылдый. Элемтәче, линияләрне тикшереп, я «Чыршы», я «Нарат», я «Имән» яки «Каен» белән сөйләшә. Огле бераз гына түземсезлек белән аның сөйләшеп бетергәнен көтә. Ләкин сабырсызланып телефонистны бүлдерә дә команда пунктына Төймәчекне алып килергә боера.

Берничә минуттан кечкенә буйлы бер кыз керергә рөхсәт сорый. Сугышка кадәр бу кыз оек фабрикасында сортировщица булып эшләгән. Аның чын исеме Дайна Лиепа. Төймәчек дигән кушаматны кызга санбаттан Огле ротасына күчкән көнне, снайпер винтовкасыннан ике немецны атып алгач та биргәннәр иде. Ни өчен шундый сәер кушамат тагуларын Дайна үзе аңламый калды.

Кызга нинди генә кием бирсәләр дә, барысы да аның юка инбашыннан төшеп, нәзек билендә капчыкланып торды. Сугыш тынган аралларда ул аларны үзенә яраклы итеп төгәргә ашыкты. Бары тик касканы гына үзгәртергә мөмкин түгел иде. Ияк астыннан каеш белән бәйләп куйсаң да күзгә төшеп тора, я ак маңгае өстенә үк күтәрелә. Аның жилдә кызарган йөзе каска күләгәсендә тагын да карарак булып күренә.

Огле күп сүзле кеше түгел. Бу юлы да ул хәрби заданиене аңлата торган берничә фраза белән генә чикләнде. Тәмәкедән саргайган бармагы белән кирәкле урынны күрсәтте дә Дайнага китәргә кушты...

Кыз иелмичә дә ишектән чыгып китте.

Кичүгә сиздермичә генә барып житәрлек юлны ул озак эзләде, аннары суга ауган агач ботакларына басып елга аша чыкты. Снарядлар казып бетергән уң як яр буйлап сазга бата-бата килде дә, үзәнгә житкәч, яшел куаклар арасына кереп югалды.

Аягы катырак жиргә тиде. Моннан баруы жиңелрәк иде. Ләкин бу юл белән тагы да алгарак бару куркыныч. Саргая башлаган абагалар аша бормалы яр өстен күрү мөмкин түгел. Дайна кебек үк задание алган дошман снайперының һәр адымда сагалап торуы мөмкин. Житмәсә, үзәннең миналанган булуы да бар. Бу фикерләр Дайнаны юлын үзгәртергә һәм барасы жиренә икенче яктан китәргә мәжбүр иттеләр.

Елгага авып төшкән агач астыннан иелеп чыккач, ул борылып карады. Су буендагы куаклыклар арасыннан бер кеше үтәрлек кенә урман межасы сузылган. Аның аша яр буе, ак каеннан салган күперчек күренеп тора иде. Бу межаның кинәт очравына гажәпләнсә дә, Дайна, снайперга хас күзәтүчәнлек белән, аны яхшылап өйрәнде.

Кыз, саргаеп килгән чирәмгә сөенеп китәрдәй булып, терсәкләре һәм тезләре белән этә-этә, озак шуышты. Каскасы күзенә төшсә, жиргә төртеп күтәрә, йөзеннән тир агып, чигә тамырлары сулкылдый башласа, яңагын салкын жиргә куеп тора иде. Шуннан соң жир салкыны белән тәненә яңа көч кайткандай була.

Жил тынды. Яңгыр да туктады. Болыт арасыннан сыек кояш нурлары күренде. Бу вакытта Дайна авылның көнчыгыш читенә килеп житкән иде инде. Сәгать ярымга ул бары тик өч йөз метр гына ара

ЯН ГРАНТ ◆ КЕЧКЕНӘ ИНЕШНЕҢ БАШЫ

китә алды. Аның бер вакытта да шулай әкрен кыймылдаганы юк иде. Булса да, беренче адымнарын атларга өйрәнгәндә булгандыр. Дайна сугышчан хәзерлеккә китерелгән винтовкасына кайнар яңагын куеп күзәтә башлады.

Авыл нәкъ нейтраль полосаның уртасындагы калкулыкта утыра. Аны икегә бүлгән үзәк урам олы юлга чыга. Ике якка да үләп баскан тыкрыклар китә. Әремнәрне аралап, запас позицияләр әзерләгәндә Дайнаның күзенә фундамент калдыклары, җимерелгән мичләр күренеп китә. Бар җирдән дә кайнар көл һәм көек исе килә. Тып-тын. Сирәк-мирәк кинәт исеп киткән җил генә хәрабәләр өстеннән үтеп, җирдә яткан түбә калайларын әкрен генә дөбердәтә. Ә дошман яшеренгән...

Инде кич житеп килә. Көнбатышта күк йөзе аксыл-сары төскә керде. Кинәт кенә немец пулеметы тырылдап куйды. Аңар икенчесе, өченчесе кушылды. Алар төбәмичә генә аталар иде. Дошманны карангы төшеп килү борчый. Яктыртучы пулялар шартлап җиргә кадалалар.

Дайна пулемет ояларын күрергә теләп башын күтәрә төште. Яр буенда, көндез ике дзот күренеп калган җирдә, пулеметлар юк иде. Болыт артына кереп барган кояшның соңгы нурлары туп-туры йөзгә төшә, шунлыктан тирә-якны яхшылап күрергә дә мөмкин түгел. Пулеметлар берсе арты берсе тындылар. Соңгы пулялар талга барып тиде. Утлы ук аның бердәнбер ботагын кыеп төшерде. Тал ботагы сәер тавыш белән агач кәүсәсе янына ауды. Баш очында сирәк йолдызлар кабынды.

Кире кайтырга вакыт иде. Кызганыч — бу юлы аңа бер тапкыр да атарга туры килмәде. Дошман көн үткән саен саграк була бара.

Караңгы төшкәнне көтеп ятканда, Дайна медсанбатта эшләгән вакытын, яралыларны бәйләгән чакларын, аларны санитар машиналарында озата баруларын уена китерде. Ул чагында аны, сугыш өчен бик аз эшлим, дигән фикер туктаусыз борчый иде. Ул чагында илебезгә сугыш белән килүчеләрнең берсен генә булса да үз куллары белән үтерсә, үзенең бурычын үтәгән булыр күк тоела иде.

Шулай итеп ул снайпер булды. Ул үтергән беренче немец сазлыкта чергәндер дә инде. Хәзер аның хисабында алтмыш, ләкин ул да тулысынча үч алу түгел әле. Соңгы оккупантны үтереп бетергәндә генә үч алу булачак!

Дэилна һәлак булгач, комсомол җыелышында Дайна дусты өчен үч алырга вәгъдә иткән иде. Шул вәгъдәсен үти алуы турында хәбәр итә алмасмы икәнни ул?

Караңгы төште. Томан күтәрелә башлады. Утлы пулялар караңгыда сирәк-сирәк кенә сызылып үтәләр. Ракета яктыртканда җиргә ятып, ул сүнгәч тагын торып, Дайна елгага таба китте.

Ә икенче көнне ул таң атканчы ук кузгалды. Тирә-якта соргылт караңгылык иде. Җирне куе томан каплаган. Кичүдә, суга егылып төшмәс өчен, һәр адымны капшап атларга туры килде.

Вакыт-вакыт караңгыдан:

— Тукта! Кем килә? — дигән тавышлар ишетелеп торды.

Часовой тавышлары иде ул. Дайна пышылдап кына парольне әйтте һәм алар бере арты бере артта калдылар.

Әгәр томан булмаса, бу берничә метр араны ул күз йомып та үтә алыр иде. Ул һәр вакыт киткәндә дә, кайтканда да караңгыда йөри. Томан булуы гына комачау итә. Һәр вакыт аңа дөм караңгы масса артында кемдер йөри, менә-менә аннан немец фигурасы килеп чыгар кебек тоела. Дайна еш кына иелеп җиргә колагын куя, озаклап караңгылыкка карап тора. Ләкин үзенең йөрәк тибешеннән башка берни дә ишетми.

Аягы үләнгә сөртенә башлагач, ул цельгә ерак калмаганын аңлады. Ләкин томан монда да, цель янында да бар нәрсәне танылмаслык итеп үзгәрткән иде. Дайна кичә әзерләгән позицияләренең берсен, иң аргысын, көчкә табып алды. Снаряд шартлаган җирдәге чокырны ул кичә эрем ботаклары белән каплаштырган иде. Әле вакыт бар. Ашыкмаска һәм позицияне яхшылап әзерләргә була.

Дайна нәкъ авыл читендә ята. Ихтимал, алда яки аның белән янәшә үк, немец разведчиклары я снайперлары ятадыр. Сугышта андый хәлләр дә була. Үлән сабагын тешләп Дайна томанның кайчан күтәрелү мөмкинлеге турында уйлый, ләкин әлегә аның берниндн билгеләре дә сизелми. Түземлелек белән көтәргә генә кала.

Салкын булып китте. Каскага кыр тычканы килеп бәрелде һәм чыелдап оясына кереп качты. Дайна сискәнеп башын күтәрде. Шул вакыт аның йөзенә салкынча дымлы җил китереп бәрде.

«Яхшы,— дип уйлады Дайна,— тиздән томан күтәрелер».

Инде таң атып килә. Ләкин тирә-як элеккечә үк тып-тын әле. Кинәт әйләнә-тирә ап-якты булып калды. Томан тиз таралды, дошман позицияләре күренә башлады. Кичә күренгән дзотларның берсе янында каскалы озын немец басып тора иде. Томан күтәрелүгә, Дайна кебек үк, ул да аптырап калган, ахры. Күкрәгендәге биноклена һәм аерым бер нәзакәтлек белән сигаретын авызына китерүенә караганда ул офицер булырга тиеш иде.

Бу иртәнең беренче ату тавышы кинәт кенә камчы шартлаткан кук яңгырап китте. Немец егылды. Прицельдән күзен алмыйча гына Дайна винтовкасын янадан корды һәм күзәтүен дәвам итте. Дошманның яраланган булуы бар, тагын пуля тимәсен өчен хәйләләп ятуы мөмкин. Немец балчыктан өелгән тәбәнәк вал артында чалкан ята. Бу вал аны дзот ягыннан каплап тора. Бинокльдән немец кулындагы сигаретның төтенләп торуы һәм бераздан сүнеп китүе күренде.

Ату тавышын немецлар әллә ишетмәделәр, әллә ишетеп тә әһәмият бирмәделәр. Ләкин иртәме, соңмы алар офицерның юкка чыгуын сизеп алырлар, күзәтүне көчәйтерләр, ихтимал, Дайнаны эзли дә башларлар...

Чыннан да, берничә вакыттан соң дзот янында икенче солдат күренде. Ләкин Дайна, ничек кенә тырышмасын, аңа төби алмады. Немецның кечкенә генә хәрәкәтчән башы һәр вакыт нәрсәгә булса да ышыкланып өлгерә иде. Киеренкелектән кызның күз алды караңгыланды.

Немец үтерелгән офицер янына шуышып килде. Ул башын бераз күтәрде дә бер генә секундка авыл ягына карап торды. Шул җитте дә. Аяз һавада яңгырап киткән ату тавышыннан соң немецның кулы көзән җыергандагы кебек калтыранып куйды, уч тутырып сутлы балчык йомарлады...

Дайна төбәмичә генә рәттән берничә тапкыр атты. Ул үзенең позициясен ачарга һәм дошманның бер генә ут ноктасын булса да күреп калырга теләгән иде. Ул ялгышмады: минут та үтмәде, беренче пуляләр сызгыра да башлады.

Ләкин Дайна ул урында юк иде инде. Кичәге пулеметларның берсе тырышып аның калдырып киткән позициясенә ата. Кыз үзенең яңа позициясендә, янган бүрәнәләр арасындагы ярыктан карап, пуляларның җиргә кадалып керүләрен күрде. Озак аттылар. Бер туктадылар, тагын башладылар. Дайна бөтен игътибарын биреп, пулемет аткан җирне эзләде. Менә, менә, бирелән ата дип уйлап та бетермәде, пулемет туктап калды. Берничә тапкыр шулай булды, ә яңадан ата башлагач, Дайнага ул инде икенче җирдән бәрә кебек тоелды. Кызның күзе яшьләнде. Ул, күзләрен кысып, маңгаен кулы белән каплады,

ләкин күз алдында һаман ут уйнады. Җирдән салкын бәрә башлады, кич җитә иде. Дайна ут ноктасын нинди тырышлык белән эзләсә, немец пулеметчысы да шундый ук үҗәтлек белән атуында булды. Ул утын шикле күренгән һәрбер урынга күчерде, пуляларын бөтен авыл буена сипте. Аларның кайберләре күптән ташланган траншеяда Дайнаны яшергән бүрәнәләрнең өске катын тишеп үтте.

Ниһаять, ул немец окоплары алдында ниндидер хәрәкәт барганын сизде. Дайна бу урынны җентекләбрәк күзәтә башлады. Искитәрлек берни дә юк кебек үзе. Шулай да... Ул ниндидер кара әйбернең сул ягына төбәде дә, пулемет тырылдый башлагач, атып җибәрде. Пуля, ком өере күтәреп, күләгәдән берничә адым читкә килеп тиде. Дайна траншея буйлап сулгарак каерылды һәм тагын дүрт тапкыр рәттән атып җибәрде. Тузан күтәрелде, тып-тын булып калды. Яралы солдат пулемет янынннан читкә шуышып китте. Икенче пуля аны окоп янында куып җитте. Калкулык артында, барабан каккан кук, тавышлана башладылар. Бу тавыш бик таныш иде: дошман минометы атарга тотынды. Дайна җиргә сыенды. Колак тондыргыч тавыш чыгарып, берьюлы өч мина ярылды, берсе аңа бик якын төшкән иде. Мина кыйпылчыклары һәм кирпеч ватыклары ява башлады. Дайна тузан йотып, җирне дер селкеткән шау-шуны тыңлап ята. Аның колагы тонган. Каскасына авыр таш килеп тигәч, тәне катып калгандай булды. Башы ярылырлык булып авырта иде. Күз аллары караңгыланды һәм ул, бөтен көче белән, аңын югалтмаска тырышып ятты.

Ничек тә мәктәп янына барып җитәргә кирәк иде. Аның исән калган бетон почмагы осколкадан сакланырга ярдәм итәчәк. Миномет тына төшкәч, Дайна металл белән казылып беткән, тетенләп торган җир буйлап шунда таба шуып китте. Баш артының авыртуы әкренләп басылгандай булды.

Ә дошман атудан туктамады. Артиллерия авылның икенче башын тетә иде. Ут өере әкренләп мәктәпкә таба да якынлашты. Монда калу инде мөмкин түгел иде. Дайна тагын кузгалып китте. Үзәнгә ул елга аша авып төшкән агач турыннан килеп чыкты. Колакта әле һаман мина тавышы. Дайна арыган гәүдәсен рәхәтләнеп турайтты. Кинәт ботак сынган кебек тавыш ишетелеп китте. Кыз тиз генә җиргә капланды. Тагын урман межасы күренеп китте. Дайна тын да алмыйча хәрәкәтсез ята. Немец снайперының пулясы агач ботагына килеп тигәнгә генә исән калганлыгын аңлый ул. Инде үзенә дә чират җитте, ахры...

Ләкин көтелгән ату тавышы кабатланмады. Моннан файдаланып калырга кирәк иде. Ул сазлыктан кулларын тартып алды, аякларын чыгарды да җайлабрак ятты. Аңар атмыйлар. Бу хәл кыюлык бирә: Дайна винтовкасын төби башлады. Нәкъ шул вакыт күзгә күренмәгән дошманның пулясы аның янагына тия язып узды, пуляның кайнарлыгы битен пешереп китте. Димәк, ул яшеренгән урын бик үк ышанычлы түгел. Кыз тирә-ягына карап алды. Урман межасы аша ак күпер күренеп тора иде. Күпердән капитан Огле килә. Ротаның элекке командирының ничек һәлак булуын да Дайна шунда ук аңлап алды. Ул тынын кысып көтә башлады. Ләкин ату тавышы ишетелмәде. Ул арада капитан күздән югалды. Немец снайперы үзенең яшеренгән урынын сиздерергә теләми дип уйлады Дайна. Юкса, ул күптән көтелгән мөмкинлекне ычкындырмас иде.

Шунда Дайна күп сыналган хәйләне кулланмакчы булды. Сакланып кына каскасын салды да елгадан алган казык башына элде, аннары алгарак сузып бераз югары күтәрде һәм күзәтә башлады. Озак көтәргә туры килмәде: абага яфраклары арасыннан атып та җибәрделәр. Каска тәгәрәп төште. Дайна винтовкасын иңбашына кысты. Ул озак итеп, җентекләп төзәде. Имән бармагы әкрен генә курукка басты.

Кыз тагын каскасын күтәреп куйды. Абага арасыннан атмыйлар иде инде. Дайна винтовкасын яңадан корды да, абага яфракларын аралап, шуышып китте...

...Пуля немец снайперының йөзенә килеп тигән иде.

Дайна КПга килеп җиткәндә тәмам караңгы төште. Капитан Огле землянкасында ниндидер елгалар турында сөйләшеп утыралар иде, нигәдер аның да исемен телгә алдылар. Дайна котчыккыч арыганлык сизеп, тыштан ишек яңагына сөялде.

— Бөтен елгалар да башта кечкенә була. Кешеләр дә шулай...

Бу Огле тавышы иде.

— Баштарак бу кыз белән ни эшләргә дә белмәдем. Ни киертсән, шул зур була. Винтовка прикладлы иңбашы хәтле ике, ә киеменә үзе кебек ике кыз сыярлык. Беренче задание биргәндә мондый тар җилкәләр өчен сугышның артык авыр нәрсә икәнен дә белдем, билгеле. Ләкин иң авырын аның үзенә күтәрергә туры килде...

Дайна, башын иеп, авыл ягыннан көл һәм дары исе китергән җил кыштырдавын тыңлый иде. Аның янына часовой килде:

— Сине анда көтәләр, Төймәчек,— ди ул.

Ул керүгә сөйләшүдән туктадылар. Телефонист аппараты белән булыша башлады, ә Огле кызның донесениесен тыңлап, үтерелгән немецның документларын алды. Фоторәсемгә карагач, аның кызыксынуы арта төште, язуын кычкырып укый башлады:

— Марта Шеер.

Шул вакыт телефон шалтырады. Капитан Оглены полк командиры чакыра иде. Дайна да, Огле да шунда бүленеп калган сүзне башка беркайчан да яңартмадылар.

Иртә таңнан безнекеләр һөҗүмгә күчеп, дошманны көнбатышка таба куып киттеләр.

**Григорий Коновалов,**
РСФСР язучылар союзы секретаре

# ТАРИХИ ЯЗМЫШЛАРЫ ЯГЫННАН БЕРТУГАННАР

Волговерховья авылы янында кечкенә генә бер чишмә җир астыннан яктыга чыккан да, кыяк үләннәре арасыннан үзенә юл ярып, чылтырап аккан тавышы белән бүтән чишмә һәм бәләкәй елгаларны—эне һәм сеңелләрен дә үз янына чакырып китереп, зураеп, куәтләнеп ага башлаган. Шулай итеп, Ра — Идел-Волга елгасы барлыкка килгән. Бозлык заманнарында хасил булган Вышневолоцкий калкулыкларын үткәндә, ул тиз агымлы бусагаларда һәм текә борылмаларда шаулаган. Ока һәм Кама белән кочаклашып, Жигулиның кыялы күкрәкләрен юып, Соколиные горы буйларыннан үтеп, салмак кына, яшьлеге белән шаярып-уйнаклап, Каспий белән күрешергә киткән. Үзе үк кадерләп үстергән халыкларны ашата һәм эчертә ул. Аларның җаннарын канатландырып, зирәк тарихи хәтерләрен гасырлар буена саклап килә.

Аның дулкыннары чайпалышын, урманнарның уйчан сөйләшен, шифалы яшел үләннәрнең үзара тын гына серләшүләрен тыңлап үскән халыклар гение тарафыннан беркайчан да кабатлана алмый торган чын мәгънәсендә милли һәм гомумкешелек ягыннан үлемсез Алып батыр һәм Микула Селянинович, Җик Мәргән һәм Вольга, Джангар һәм Святогор образлары тудырылган.

Әкият, сөйләк һәм поэма геройлары халык җанының яхшылыгы, аның акылы һәм батырлыгы аркасында яши. Һәр милләтнең йөрәгендә үзенең күршесен яхшырак белергә, дәрәҗәсен төшермичә генә, шул күршесе белән тыныч һәм аңлашып яшәргә омтылыш сүрелми. Халык—беркайчан да сатылмый торган җырчы. Аның карашы ачык, акылы зирәк, йөрәге кешегә мәхәббәт белән җылытылган. Вакыт нииндидер аерым кешеләргә ярашырга тырышып эш иткән елъязмачылар кулыннан каләмнәрен бәреп төшерә. Ләкин шул ук каләм үз халкының сүзләренә тугрылыклы булганнарның гадел кулларында ныгый.

Гөлне киссәң — гөл кала,
Телне киссәң — тел кала,
Башны киссәң — ил кала,
Илдә туган тел кала.

*(Илдар Юзеев.)*

Болгарлар Идел-Кама җирләренә моннан унике гасыр элек Азов буйларыннан килеп, җирле халык белән аерылгысыз дәрәҗәдә туганлашканнар, Болгар һәм борынгы Русь җирләренә котырынып һөҗүм иткән хазарлар белән кискен көрәш вакытында үз-үзләрен саклап калганнар. Русь дәүләте 965 елда Хазар каганатының юлбасарлык оясын туздырып ташлый, башкаласы Бөек Болгар булган беренче дәүләт—Идел-Кама Болгарын төзүне җиңеләйтә.

Ләкин авыр еллар килә, һәм бөтен галәм өстенә монгол арканы еленә.

Арымас аяклы атлар ташкын булып агыла һәм халыкларның котын очыра... Чәчәк атып торган Болгар, Биләр, Суар шәһәрләре җир белән тигезләндерелә. Көньяк Русь җиңелә. Яулап алучыларның электән килгән гадәтләре буенча, җирле халыклар арасында үзара дошманлык утын кабызып, ханнар — чыңгызчылар Идел буе һәм Русь җирләрендә озак еллар буена хуҗа булып, ныгып урнашалар.

Кояш чыга да бата. Кылычлар үткенәя һәм кыршыла. Кара козгыннар бөркетләрне кыра, ә анары, күр—җилдә канатларын җилпеп, бөркетләр җир йөзен каплап алалар.

Җир хезмәткәре йөрәгендә мәңгегә урнашкан кеше яхшылыгы дигән нәрсә авыр газаплар белән, кан аша үзенә юл сала. Балларын алыр өчен, бал кортларын төтен белән төслиләр. Халык өстеннән идарә итү өчен, аның җанын һәм акылын дини һәм милли сөрем белән агулыйлар. Әгәр бәхетсезлек канат җәйсә, илгә талану, җимерелү куркынычы туса, әхлакый яктан буй җитмәслек бөек булып, аны коткару өчен халык күтәрелә.

«Без һәм Казан дәүләтенең барлык кешеләре Нижний Новгород һәм Идел буендагы башка шәһәрләр белән, тау һәм болын татарлары һәм болын чирмешләре барыбыз да килешеп һәм бергәләшеп эш итәргә, Мәскәү һәм Казан дәүләтләре яклы булырга килештек». Зур фетнә елында, 1612 елда, Мәскәүне чит ил басып алучыларыннан, алдакчы боярлардан саклап алып калырга барганда халыклар әнә шундый карарга киләләр.

Әгәр халыклар үзләренең тапкырлыклары һәм батырлыклары белән Россияне кызу рәвештә үзгәртеп коруга тартылмаган булса, Полтавада һәм диңгездә җиңүгә китергән юлларны үзләренең сөякләре белән түшәп салмаса, Санкт-Петербургка фундамент булып ятмаса, Бөек Петрның куллары эшкә ул кадәр үк оста була алмас (ул ундүрт төрле һөнәр белгән), сугыш эшендә ул шул кадәр зур уңышларга ирешә алмаган булыр иде. Һәм болар барысы да коллык һәм көчләү шартларында эшләнгән эшләр бит әле.

Идел халык күз яшьләре белән тулып ташыган, талаучыларга, азгынлык кылып йөрүчеләргә, һәртөрле ачык авызларга карата туган кайгы, нәфрәт һәм аһ орулардан болганган. Һәм шул чакта Степан Разинның дәһшәтле тавышы яңгыраган: «Сарынь на кичку»![1]

Тәмугтагыдай каты җәзаларга өйрәнгән палачлар атаманның чыбыркы белән телгәләнеп беткән тәненә кызган тимер басып карасалар да, аның авызыннан бер генә сүз дә ала алмыйлар. Ирекле, батыр казакның менә шулай батырларча дәшми калуы үзен җәзага дучар иткән әфәнделәргә котылгысыз үлем киләчәген алдан әйтеп кую шикелле була.

Чәчәннәрнең — үлемсез Гомéрларның — җыр һәм сөйләкләрен йөрәгенә сеңдергән, башкорт далалары шагыйре, атаклы гаскәр башлыгы Салават Юлаев һәм татар халкы улы, Пугачев полковнигы

[1] Дошманга ябырыл! дигән мәгънәдә — ред. искәрмәсе.

Бәхтияр үз язмышларын, димәк, үз халыклары язмышын да, Емельян восстаниесе белән мәңгегә бәйлиләр. Русларның, башкортларның, чувашларның, мариларның, мордваларның күп еллардан бирле күңелләрендә җыелып килгән газап һәм ачулары чигеннән ташып, тышка бәреп чыга.

Крестьяннар восстаниесе коточкыч катылык белән бастырыла. Ятимнәрнең һәм тол хатыннарның күз яшьләреннән ачыган, халык каныннан тозланган елга, батырлар асылган дар агачларын салларда чайкалдырып, мужикларның яндырылган-таланган авылларыянныннан талгын гына ага бирә... Ул елга өстендә хайвани ачудан адәм кыяфәтен югалткан җиңүче-крепостникның чалшайган йөзе чагыла... «Югары даирә»дәге рус, татар, поляк һәм немец палачлары, үзләре койган халык каны кешеләрне бер-беренә якынайта гына баруын сизмичә, типтереп йөриләр.

Илгә үлем куркынычы килгән елларда халыклар дошманга каршы күтәреләләр.

Бик тиз арада Европадагы дәүләтләрнең ил чикләрен таптап үтеп, акыллы Наполеон Бонапартның кара явы Россия өстенә ябырыла. Шул яуга күкрәкләре белән каршы тору өчен, рус сугышчылары сафына Идел буе халыклары да килеп кушыла. Аларның гәүдәләре Наполеон гвардиячеләре гәүдәләре белән бергә сугыш кырында ятып кала. Мәетләрнең ачык калган күзләрендә кичләрен ялтыр ай яктысы чагыла.

Солдатлар, казаклар, татар, башкорт атлы гаскәрләре, дөяләргә атланган калмыклар Парижга барып җитә.

Узган җәй көне әйбәт шагыйрь Муса Гали миңа шул заманнарда башкортлар Булон урманында үзләренең атлары, далалары, Агыйдел елгасы турында җырлаган җырларны җырлап күрсәтте. Аның саф, тәэсирле тавышы бал, болын исе килеп торган дала киңлекләрен күз алдына китерде...

Елгалар бозларын ватып чыга. Таллар әчкелтем исле бөреләрен яра, кошлар оя кора. Көйгән дала, яңгыр суы белән юынып, яшеллеккә күмелә. Җир кара, әмма ул икмәк үстерә. Таш астыннан чишмәләр агып чыга. Тормыш үзенең беркайчан да сүнмәс тереклеген дәвам итә. Халыклар тормышы кискен борылышлардан, сугышлардан, восстаниеләрдән, революцияләрдән генә тормый — алар, бу үзәк моментлар, туктаусыз агып тора торган киң һәм тирән халык елгасының бусагаларын тәшкил итә. Һөнәрчелек, иген игү, сәүдә, сәнгать, кул хезмәте һәм рухи хезмәт әсәрләре белән үзара алмашып, бер ил күге астында яшәүче халыклар, Идел-ана чишмәләрне һәм елгаларны үзенә тарткан шикелле үк, табигый рәвештә бер-берсенә якынайганнар. Алар бер үк җирдә тир түккәннәр, бер төрле үк чишмәләрнең суын эчкәннәр, таңнарның матурлыгын барысы да бер дәрәҗәдә яратканнар.

Александр Пушкинның һәм Габдулла Тукайның шифалы йогынтысы аркасында дуслык күптән туган. Пушкин рус әдәби телен тудырган булса, халык шагыйре һәм зур фикер иясе, революцион-демократ Тукай үзенең кыска гына тормышында да милли гомумхалык теле нигезендә бай шигъри тел тудырган. «Пушкинга» һәм «Милли хисләр» (1906 ел) исемле шигырь һәм мәкаләләрендә ул рус һәм татарларның гасырлардан килә торган дуслыкларын ныгыткан.

Фәнни хезмәтләр һәм әдәби әсәрләр авторы Каюм Насыйри татар әдәбиятының матур, бай теленең гүзәл бинасына нык ташлар тезгән.

Башкорт әдәбиятына нигез салган, ике туган халыкның—башкорт һәм татарларның—классигы Мәҗит Гафуриның таланты күп эшләр эшләде. А. Островский һәм Г. Камал поэзиянең иң югары һәм тирән мәгънәле, тере жанрларының берсендә—драмада—үз халыкларының

җанын ачып бирделәр. Максим Горький һәм Галимҗан Ибраһимов зур талантлары белән үз әдәбиятларын юмарт баеттылар. Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр»е шиңми, ул сурәтләгән татар хатыны һәм Совет власте өчен көрәшкән дала батырларының йөзендәге алсулык сүрелми, чөнки аларның да, халыкның да йөрәкләре бер.

Яшь В. И. Ленин үзенең үлемсезлеккә илткән юлын, үткен күзләрен тормыш тирәнлегенә төбәп, Казан университетыннан башлап җибәрә. Яңа типтагы партия төзеп, ул Россиянең күп милләтле эшчеләр сыйныфын крестьяннар белән бергә берләштереп, бөек революцион көрәшкә алып барды.

В. Тихомирнов һәм Мулланур Вахитов, В. Куйбышев һәм М. Фрунзе контрреволюциягә каршы көрәштә Идел буе халыклары белән җитәкчелек иттеләр. Җир өчен, дустанә кешеләр тормышы өчен башланган халык хәрәкәте, социаль һәм милли гаделсезлек, башбаштаклык һәм көчләү богауларын барысын да җимереп, көчле язгы ташкын булып җәелде. Кешелек тарихында беркайчан да күрелмәгән бу миллионнар көрәшендә халыкны Ленин партиясе рухландырды... Идел-ана, Кама, Ока, Агыйдел ярларында, дала һәм урманнарда һәлак булып калган көрәшчеләрнең туганнар каберлегенә илтә торган сукмакларны беркайчан да үлән басмас.

Җанга төшеп, күңелләрне сулкылдатып сызлаткан кайгы-хәсрәтләр, вакыт үтү белән азрак җиңеләеп, дуслык өчен башларын салган әтиләребезнең халык күңелендәге якты истәлеге булып калды. Генетик дуслык төше әнә шул көрәш вакытында яралды да инде. Һәм ул дуслык безнең халыкларның җанын, акылын, канын тәшкил итеп тора. Гитлер безне бөтен дөнья каторгасын төзәргә генә яраклы этник материал дип кенә исәпләде, халыкларның күкрәк читлегенә ут һәм тимер белән сугып, тынсыз итәргә ниятләде. Түбән культуралы булганлыктан, ул инде XIII йөздә үк болгарларның (хәзерге татарларның) «Йосыф һәм Зөләйха» поэмасын язган Гали (1210 ел) исемле шагыйрьләре булганлыгын, ә Мәхмүд Болгариның (1358 ел) «Нәһҗел-фарадис»ны иҗат иткәнлеген белмәгәндер шул. Шул ук культурасызлыгы нәтиҗәсендә «фюрер» русларның «Слово о полку Игореве»лары булуын да башына китермәгәндер. Гитлер үзен СССР халыклары дуслыгы таркалыр дип юатты. Чөнки ул көнчыгышта халык юк, бәлки рус-татар аномалиясе генә бар дип саный иде.

Иделдә фашист армиясе бик зур җиңелүгә дучар ителде. Сталинград сугышы—аның кояшы баю, ә безнең кояшыбызның чыгуы иде. Дәһшәтлелеге ягыннан тиңе булмаган Бөек Ватан сугышында безнең күп милләтле армиябезнең каһарманлыгы Европаны коткарып калды. Һәрбер социалистик милләт дөньяга батырлыкның, горурлыкның һәм кешелеклелекнең югары классын күрсәтте.

Үткән сугыш тәҗрибәсе күп нәрсәгә өйрәтте һәм, сүз уңаеннан әйткәндә, фикер йөртә белгән һәр тарихчының шундый нәтиҗәгә килүе мөмкин: техниканы, бигрәк тә хәрби техниканы, теләсә кемнең, беренче чиратта басып алучыларның, (әлбәттә, эшчеләр һәм галимнәр кулы белән) тудыра алуы мөмкин. Ә менә халыклар арасындагы туганнарча дуслыкка дөньяга коммунистларча караганда гына ирешергә була. Капиталистик тәртипләр кешеләрнең йөрәкләрен бер-береннән аеруга нигезләнгән, ә без исә үзебезнең фундаментыбызның ныклыгына кешегә хөрмәт, халыкларның какшамас дуслыгына тирән ышану (фәнни нигезләнгән ышану) юлы белән ирешәбез. Дөньяда бик күп могҗизалар булган. Шуларның берсе—борынгы Египет пирамидалары. Ләкин иң бөек, берни белән дә чагыштырып булмый торган ачыш һәм могҗиза—безнең җәмгыятебез төзегән яңа, социалистик строй, ә андагы халыклар дуслыгы—могҗизаларның могҗизасы.

Бу гуманизмның безгә җиңел генә бирелмәгәнлеген оныту—балачагалык булыр иде. Безнең хәтер алай кыска түгел. Халыклар дуслыгын интернационализмның мүкләнеп беткән дошманнарыннан, алар җырын җырлаучы сукыр наданнардан саклаганда да, һәм һәр халыкның яңа, коммунистик сыйфатлы матур, бай милли үзенчәлеген сызып ташларга бик алгысып торучылардан саклаганда да безнең сәламәт акылыбыз бик сизгер һәм сак. Андыйлар бигрәк тә сәнгать иҗаты, сүз иҗаты сферасында аеруча әрсезлек һәм тынгысызлык күрсәтәләр. Чөнки алар рухи яктан фәкыйрь—ертык сумкаларында вак-төяк сүз боткасыннан башка берни дә юк.

Халык һәм тел—аерылгысыз. Һәр халыкның теле никадәр көчле булса, социалистик культура шул кадәр баерак, матуррак була.

Мин һәр әдәбиятчы турында аңа лаеклы булган сүз әйтергә теләр идем. Ләкин Идел буе бассейнындагы халыкларның әдәбиятларында нәтиҗәле эшләп килүче язучылар, шагыйрьләр, драматурглар, тәнкыйтьчеләрнең зур отрядының иҗаты турында сөйләп чыгарга бер кешенең генә көче җитәрлек түгел. Мин исә үлгәннәргә дога кылып, исәннәргә сәламәтлек теләп утыра торган поп түгел. Атаклы кешеләрнең исемнәрен санап чыгарга күнеккән тәнкыйтьче дә түгел мин. Нәфис сүз өлкәсендә эш итүче кара эшче буларак, әдәбиятта эшләүче каләмдәшләремнең исемнәрен мин зур хөрмәт һәм ихтирам белән атап китәм...

В. Маяковскийның «Ленин» һәм Һ. Такташның «Гасырлар һәм минутлар» поэмаларында Ленинның мәңгелек образы яши. Ш. Камалның «Таң атканда» китабында сурәтләнгән, социаль хисләр ташкыныннан куркыныч булып кайнап торган Октябрьга кадәрге авыл М. Шолоховның «Тын дон»ы, Л. Леоновның «Барсуки»ы белән аваздаш. Шолоховның «Күтәрелгән чирәм»ендә, Ш. Камалның «Матур туганда»сында, К. Горбуновның «Бозлар акканда» һәм Ф. Панферовның «Бруски»ында яңа авыл кешеләре көрәшәләр, тулы канлы тормыш белән яшиләр.

Үлемсезлек югарылыгына һәм зурлыгына ирешкән Муса Җәлил ил һәм дөнья күләмендә танылды. Я. Ухсай һәм Никул Эркай, Сәйфи Кудаш һәм П. Хузангай әдәбиятка халык сөйләме байлыгын өстәделәр.

Зур талантлы Михаил Луконинның куәтле, тирән үзенчәлекле поэзиясе баһадирларча батырлыкларны сурәтләп үсте. Мостай Кәримнең шиңмәс «Таштагы чәчәкләр»е—искиткеч матурлар. Михаил Львов шигырьләреннән бал исе килә. В. Богатыревның «Чапаев» поэмасында дивизия начальнигының батыр йөрәге тибеп тора. Николай Благов иҗатында мул сулы Идел халыкчан сурәтләнгән. Давыт Кугельтдиновның фәлсәфи шигърияте югары әхлакый хисләр белән сугарылган. Зәки Нури үзенең иҗаты белән җанны баета, тормышчанлыкны ныгыта. Сеспель тормыштан яшьли китеп барды, ләкин ул чуваш әдәбиятында беренче классик мирас калдырды.

Гомәр Бәшировның «Намус»ы үзенең халыкчанлыгы белән нык һәм саф. А. Малышкинның «Севастополе»ндәге шикелле үк, аның «Сиваш»ындагы батырлык сүрелми.

Идел буе җирләре һәм елгалары халыкларга А. Толстойны, К. Федииңы һәм М. Алексеевны, мордваның зур язучысы Кирдяшкинны һәм калмык халкы тормышының елъязмачысы Амур-Сананны, мари язучысы Чавайны, Әнвәр Бикчәнтәевны, Рафаэль Мостафинны һәм Григорий Боровиковны, Артем Веселыйны, Николай Кочинны һәм Сәгыйт Агишны, Әнвәр Давыдовны, Әхмәт Исхакны һәм Сибгат Хәкимне бирде.

Ф. Сухов, Ә. Ерикәй, Ә. Фәйзи, Ш. Маннур, М. Шестериков, Б. Пильник, В. Жуков, М. Казаков һәм М. Агашина әсәрләрендә ха-

лыкның хезмәттәге һәм сугыштагы батырлыгы, сафлыкка-гаделлеккә омтылыш бик тулы чагылдырылган. Н. Сухов, Н. Шундик, В. Московкин, Б. Жилин, В. Карпенко һәм Ю. Селенскийларның җитди проза әсәрләре укучыларда җанлы теләктәшлек таба.

Минем картларча карашым буенча, яңа буын үзен һаман саен ышанычлырак һәм нигезлерәк сиздерә. Һәм алар һәркайсы үзенчәлекле һәм бай иҗади шәхес булсалар да, мин тирән хөрмәт хисе белән һәм шул ук вакытта озак тукталып тора алмавым өчен уңайсызланып, аларның исемнәрен генә атап китәргә мәҗбүрмен: И. Юзеев, И. Малохаткин, Ю. Адрианов, В. Шапошников, И. Корнилов, В. Колумб, Е. Мельников, Бося Сангаджиева, И. Беликова.

Туган-әдәбиятчылар минем турыда бу кеше буш сүз сөйли яки хәйләләп безнең үзара тәнкыйтьне киметергә, иҗат потенцияләребезне түбәнәйтергә ниятли икән, дип уйлый күрмәсеннәр.

Халык турында һәм халык өчен китаплар язганда сез үзегезне аерым бер зур дан казанабыз дип уйламыйсыз, чөнки үзегезнең гади бер культура хезмәткәре икәнлегегезне аңлыйсыз. Сезгә, үз халкыгызның кызларына һәм улларына, халык һәм аның Партиясе турында язмыйча тагын кем турында язарга соң? Сезнең йөрәкләрегез партиягә бирелгән.

Халыкның хезмәт эшчәнлеге бай һәм күп кырлы, аның уйлары катлаулы һәм тирән. Безнең китапларны халык батырлыгы белән үлчәп, тере тарих бездән тыелгысыз кайгыртучанлык белән шуны сорый: халык елъязмачыларының кыюсызлыгы нигә артык озакка сузылды? Безнең кайберләребезне төп магистральдән тар сукмакларга алып керүдән, заводлардан һәм кырлардан тар көнкүрешкә борудан ни мәгънә?

Халык рухының серләренә без әле яңа кагылдык кына. Үзебезгә таләпчән булыйк. Без үз халкыбызның телен, аның җырын, мәңге яшь җанын сакларга һәм баетырга, шуларны, күз карабыздай итеп, барысын да тигезләргә тырышучы хиссезлектән—дөньяда мәхәббәт һәм батырлык барын тик ишетеп кенә белә торган рухи гарип җаннардан сакларга тиешбез.

Экономист-галимнәр, планлаштыручылар, халык хуҗалыгында үз тармакларын яхшы белүчеләр һәм бигрәк тә алдан күрүчән социологлар юлына аркылы төшүне һич тә күз алдында тотмастан, делитантларча оялып-шикләнебрәк кенә кайбер материаль пунктларга тукталып китмәкче булам. Акыллы кешеләр моның өчен миңа ачуланмаслар, ахмакларны чиркәүдә дә тукмыйлар дигән әйтемнән файдаланмаслар дип уйлыйм.

Идел бассейны һәм аның кушылдыклары буенда йөз миллионга якын зирәк, эшчән, нык халык яши. Халык үз хезмәте белән ул елганы дөнья магистраленә әйләндерде, анда куәтле ГЭСлар корды, шулай итеп аның ил күләмендәге әһәмиятен тагын да арттырды. Волга-Дон һәм Волга-Балт исә илкә һәм республикаларның бай промышленность продукциясен илебезнең барлык экономик районнарына һәм чит илләргә чыгарырга мөмкинлек бирде. Йөк суднолары Иделдән Обь һәм Лена тамакларына, Гамбургка, Стокгольмга һәм Швециягә бара алалар. Сормово судноларына диңгез штормнары да куркыныч түгел. Тиз йөрешле, су асты канатлы ул судноларны чит илләр бик теләп сатып ала. Иделнең үзенә муафыйк флоты бар.

Барысын да бик җентекләп тикшерә торган геологларның әйтүенә караганда, нефть меридианы Фарсы култыгыннан алып, Идел-Кама бассейны буйлап, Ухтага һәм Воркутага кадәр сузылган. Безнең җиребезнең уникаль байлыклары Оренбург газын ачу белән тагы бер кат ныклап расланды. Башкортстан елына 40 миллион тонна нефть чыгара, ә Татарстан инде 100 миллионнан да арттырып җибәрде. Болар-

дан тыш, Куйбышев, Саратов һәм Волгоград өлкәләре дә байтак кына нефть бирә. Тиешле энергетик куәтне тәэмин итү өчен, нефть безнең үз илебез хуҗалыгын тукландыру белән генә чикләнми, бәлки туган-даш социалистик илләргә дә җибәрелә.

Мин беренче бишьеллыкларны башлап җибәргән буын кешеләре вәкиле. Хыяллана белү дигән нәрсә безгә дә хас иде. Ләкин промышленностьның менә шушылай гигант үсеше безнең төшебезгә дә кермәгән иде. Химия үсеше аеруча таңга калдыра. Алдан күреп эш итүче Д. И. Менделеев кайчандыр Бондюг химия заводын салдырган. Хәзер, әгәр Идел буйлап түбәнгә төшәсең икән, һәркайда химияне очратасың. Дзержинск—тоташ химия. Казан—органик синтез. Куйбышев—химия производствосының тулы бер комплексы. Балаково—корд, күкерт кислотасы, суперфосфатлар, «Жигули» өчен резин-техник әйберләр. Энгельс—капрон. Саратов—нитрон, ә гади халык теле белән әйткәндә—ясалма йон һәм җеп эрләү производствосы. Европадагы иң зур азык чүпрәсе заводы—Кировта.

Идел—чын мәгънәсендә автомобильле елга. Ярославль, Горький, Ульяновск, Тольятти, КамАЗ. Әгәр шушыларга Энгельс заводында троллейбуслар, Ока буендагы Павловск заводында автобуслар эшләнүен дә китереп өстәсәк, Иделнең кешеләр хезмәтен җиңеләйтү өчен никадәр җитди кайгыртканы бик ачык күренер.

«Як-40» самолетларын җитештерә торган Саратов авиация заводы Иделнең канатлы икәнлегенә ишарә ясый. Ул самолетларны чит илләр бик теләп сатып ала. Бишьеллыкның беренче җимеше, сугыштан соң көл арасыннан калыккан Волгоград трактор заводы турында сүз әйтми үтү гөнаһ булыр иде. Куйбышевта, Горькийда, Кировта, Ульяновскида, Саратовта оста куллар көче белән куәтле, яхшы сыйфатлы станок төзү промышленносте булдырылды... Ә бу уңышларга эшчеләр сыйныфының техник белеме югары булуы нәтиҗәсендә ирешелде.

Идел—икмәкле елга. Үткән ел түбән һәм урта Идел буйлары дәүләткә миллиард потка якын икмәк тапшырды. Идел аръягының сирәк очрый торган югары сыйфатлы каты бодае он тарту промышленностенда элек-электән дан тотып килә.

Англия хөкүмәте Идел аръягында үскән бодайны бүтән барлык бодайлардан да артыграк күрә. Волгоград, Саратов, Куйбышев тирәләрендәге Идел аръягында сугару системалары төзелеше киң, стратегик рәвештә алып барыла. Җире әйбәт, кояшы һәм җылысы җитәрлек, тик дымын гына булдыр—гарантияле уңыш амбарда булачак.

464 километрлы Идел—Урал каналы төзелгәч, ике миллион гектар җир сугарылачак һәм җиде миллион гектарга якын җир сулан-дырылачак. Дөнья әле мондый ясалма елгаларны белми.

Плаулар күбрәк пешсен өчен, түбән Идел буйларында Черноярдөге сугару системасын төзеп бетереп килаләр. Актүбәдә субүләр буа калкып, суны балыклар уылдык чәчә торган тармакка таба агыза башлаячак. Идел—университетлар, институтлар, культура елгасы. Россиядәге өченче университет 1804 елда Казанда ачыла; Н. Лобачевский, А. Бутлеров, Н. Зинин аңа дан китерә. Алдынгы татар галимнәре И. Хәлфин, Х. Фәезханов, М. Мәхмүдов аңа үзләренең акыл һәм йөрәкләрен бирә. Университетта Л. Толстой, И. Н. Ульянов, В. И. Ленин укыган. Шәрыкны өйрәнүдә ирешкән уңышлары белән Казан университеты бөтен Европада танылуга лаек булды. Арбузовлар мәктәбе химия фәнен баетты. Шул ук Казанда—СССР фәннәр академиясе филиалы. Саратов (1909 ел), Горький, Куйбышев университетлары да күп кенә кадрлар әзерләп чыгара. Ә институтлар, фәнни-тикшеренү институтлары күпме! Проект институтлары бөтен илгә һәм чит илләргә дә эшлиләр.

Кешеләргә эштән соң барыр урыннар да җитәрлек: һәр шәһәрдә

театрлар бар. Шулар арасында иң өлкәннәреннән берсе—Волков исемендәге Ярославль театры. Бер шаян кеше, культура дәрәҗәсе кәгазь куләме белән билгеләнә, дип әйткән ди. Кәгазьне Иделдә бик күп ясыйлар, Балахнаны гына карагыз. Ярославльдә, Калининда полиграфия промышленностеның үсеше бик югары. Саратов комбинаты елына 50 миллион данә дәреслекләр бастырып чыгара.

Әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-политик журналлар һәр республикада да бар, ә Казанда алар унау. Бер хатын-кызлар журналы («Азат хатын»—ред.) гына да 300 меңнән артык тираж белән басыла. Саратовта «Волга» исемле гомум Россия журналы чыга. Әсәрләребезне бастырыр урын җитәрлек.

*

* *

Минем бәхетем шунда, мин, рус кешесе, Оренбург җирендә, татар, башкорт, мордва, украин халыклары арасында яшәдем. Җиде яшемдә аттан егылып төштем. Өстемнән ат көтүе чабып үтте. Мине Гомәр авылына Госман исемле карт дәвачы янына алып бардылар. Ул мине үләннәр, бал һәм кымыз белән дәвалап аякка бастырды.

Аның чибәр кызы Гөлҗамал исемле иде. Ул кызның кара күзләре минем гыйшкый йөрәгемне борчуга салды. Гөлҗамал мине авылларының басу капкасын чыкканчы озата килде. Утызынчы елларда, «Университет» исемле романымны язган чакта, шул кызның образы минем күңелемдә яңадан туды. Һәм, күрәсең, ул кыз һәм аның әтисе тикмәгә генә минем китабымның төп геройлары—Батуевлар итеп сурәтләнмәгәндер. Мин аның атасын Гомәр дип алдым, ә үзен нәкъ шулай Гөлҗамал килеш калдырдым.

Тыныч көннәрдә һәм сугыш елларында мин татарлар, башкортлар, калмыклар, марилар, чувашлар, удмуртлар, комилар, украиннар белән бергә эшләдем. Талчыгу газабын бергә кичердек, сарык һәм ат итләрен бер казаннан ашадык, флотта су асты көймәләре бригадасында бер камбузда тукландык. Тарихи эшебезнең хаклыгына сүнмәс ышаныч белән яшәдек. Һәм безнең барыбыз өчен дә иң кадерле нәрсә үзара дуслыгыбыз иде.

Дусларым-калмыкларда кунакта чакта мин аларның җырларын, Давыт Кугельтдинов, Михаил Хонинов, Бося Сангаджиева, Лиджи Инджиев шигырьләрен, өлкә комитетының беренче секретаре Басан Городовиков хикәяләрен тыңладым. Шунда калмык Төмәнне һәм аның чибәр хатыны Баяртаны—минем балалык һәм яшүсмер елларымның әйбәт юлдашларыннан берсен искә төшереп утырдым...

Минем бабама беренче дустаганын тоттырган чагында Төмән аңа өч яхшы теләк теләгән: яңгыр үз вакытында явып торсын өчен, бармагын шәрабка тиереп алып, шәраб тамчыларын һавага очырган; аннары, учакта беркайчан да ут сүнмәсен, дип ул шәрабны утка сипкән; үләннәр һәм чәчәкләр үссенгә, җиргә дә шул ук шәрабны тамызган. Ә саубуллашканда исә, йөрәге дусларын бер вакытта да онытмасын өчен, шәрабка манчылган бармагын бабамның күкрәгенә тидергән.

Каннар катнашуы Идел бассейнында яшәүче, тәннәре һәм рухлары сәламәт һәм нык кешеләрнең кайнар хисле һәм үзенчәлекле матурлыгын тәэмин итә. Яшь кызларның бераз кыргыйрак нәфислеге серле һәм ымсындыргыч. Идел һәм аның иксез-чиксез туфрагы халыкта яшьләрчә гаярьлек, эштә һәм сугышта тормышчан ныклык тәрбияләгән. Безнең бөек В. И. Лениннан мирас булып калган әхлакый таләпчәнлегебезне партия арттыра һәм чыныктыра.

**В. НУРУЛЛИН тәрҗемәсе.**

# МУЗЫКА ПРОФЕССОРЫ МАНСУР СОЛТАНОВ

Кызык нәрсә бу архив дигәннәре. Сиңа кирәкле материалларны кайвакытта еллар буе эзлисең — таба алмыйсың. Ә кайчакта бер дә көтмәгән урыннан көтелмәгән документ килеп чыга...

Менә берничә ел инде, Идел һәм Урал буе халыкларының тарихына багышланган, аларның культура үсешен күрсәткән төрле чыганакларны кызыксынып карап киләм. Монда яшәгән һәр халыкның үзенең гыйбрәтле тарихы бар, патша хөкүмәтенең рус булмаган милләтләрне гасырлар буе төрлечә кысрыклавына карамастан, буыннан-буынга бирелеп килгән шактый бай культура үрнәкләрен дә күрергә була. Тик шулай да Бөек Октябрь революциясенә кадәр үк элекке Минзәлә өязеннән музыка профессоры чыгуы ярыйсы ук сәер ишетелә. Һәм мин дә аның турындагы материалны республикабыздан шактый ерак торган урыннан табармын дип уйламаган идем.

Урал архивларының берсендә эшләгәндә, көтмәгәндә, Мансур Исламович Солтановка багышланган бер «дело» кулыма килеп керде. Аңа төрле документлар: Солтановның тормыш юлы турында профессор И. В. Липаев язган кыскача бер очерк, берничә таныклык, Солтановка багышланган һәм төрле газеталардан кисеп алынган материаллар, бер истәлек һәм башка кайбер язулар теркәлгән. Алар безнең якташыбыз, музыка профессоры Мансур Солтановның тормыш һәм иҗат юлын берникадәр яктыртырга мөмкинлек бирәләр.

Ул 1875 елның 25 апрелендә элекке Уфа губерниясе, Минзәлә өязенең Мәчти авылында отставкадагы сотник семьясында туып үсә. Әтисенең дворянлык званиесе алуы аның малае Мансурга ул заманда хезмәт иясләре өчен ябык булган уку йортлары ишеген ача һәм аңа югары белем алырга, үзенең талантын ачарга мөмкинлек бирә.

Башта ул Уфа реальный училищесында укый, анда ук инде, бик тырышып, училище оркестрында флейта һәм башка инструментларда уйный башлый. Һәм менә шушы кызыксыну аны 1897-1898 уку елында Мәскәү консерваториясенә китерә. Анда ул флейта классы буенча профессор В. Крейчманда укый. Талантлы егет беренче айлардан ук инструментта уйнау буенча гына түгел, башка теоретик һәм практик дәресләрдән дә бик яхшы бара.

1898 һәм 1899 елларда ул консерваториянең укучылар хорында Веберның «Сихерле укчы» («Волшебный стрелок») һәм Бетховенның «Фиделио» операларын башкарганда катнаша. Ә 1901 һәм 1902 елларда консерватория укучылары кичәләрендә флейтада уйный. 5 курста ул инде, Моцарт, Рубинштейн һ. б. классик композиторларның катлаулы әсәрләрен уңышлы башкарып, тыңлаучыларның игътибарын үзенә җәлеп итә.

1903 елның 27 маенда Мансур өчен консерваторияне тәмамлау кичәсе дә килеп җитә. Мәскәүнең иң күренекле музыкантлары каршында Мансур Солтанов Ядиссонның концерт-фантазиясен башкара, аның уйнавын тыңлаучылар бик җылы каршы алалар. «Новости дня» газетасында музыка тәнкыйтьчесе Семен Кругликов Солтановның оста флейтист булып өлгерүен күрсәтә, аның уйнавына югары бәя бирә.

Инструментта зур уңыш белән чыгыш ясавын исәпкә алып, консерваториянең художественный советы Мансур Солтановны «Зур көмеш медаль» белән бүләкли һәм шул замандагы сәнгать уку йортларын бетергәннән соң бирелә торган «Ирекле художник» («Свободный художник») званиесе бирә. Мансур Солтановны Мәскәүнең күренекле симфоник һәм опера оркестрлары җитәкчеләре үзләренә чакыралар. Шулай ук ул солист-флейтист буларак эстрада концертларында да уйный.

1906 елны Мансур Солтанов, конкурсны уңышлы үтеп, Мәскәү Зур академия театры оркестрына кабул ителә. Ләкин, ни сәбәптәндер, ул монда озак эшләми. Тиздән Ялта шәһәренең симфоник оркестрына эшкә күчә һәм анда шактый гына уңыш казана.

1912 елны Мансур Солтанов Саратов шәһәре консерваториясенә профессор итеп чакырыла һәм шушы елдан башлап гомеренең соңгы көненә кадәр монда башта флейта классы, ә аннан соң музыка теориясе буенча да зур педагогик эш алып бара. Шушы елларда ук аның флейта өчен язылган махсус күнегүләр җыентыгы Саратов консерваториясе нәшриятында бастырылып чыгарыла. Моннан тыш ул консерваториянең симфоник концертларында, музыка кичәләрендә Бетховен һәм башка классикларның әсәрләрен яратып һәм уңышлы башкара. Ул вакытта Саратовта чыга торган газеталар аның чыгышларын һәр вакыт югары бәялиләр.

Архив материалларыннан күренгәнчә, Мансур Солтанов татар һәм башкорт көйләрен җыюга һәм эшкәртүгә дә беренчеләрдән булып керешкән музыкантларның берсе.

Чыгышы буенча заманының югары катламыннан булса да, таланты, аң-белеме аны гади халыкка этәрә, чын сәнгатьне халык иҗатыннан да эзләргә кирәклекне күрсәтә, халкына хезмәт итүен таләп итә. Безнең уебызча, профессор Мансур Солтановның эшчәнлеге, иң беренче чиратта, шушы максатны аңлавы белән кадерле. Һәм ул шуннан чыгып бәяләнергә тиеш тә.

Гадәттә яз һәм көз айларын Солтанов үзенең туган авылы Мәчтидә үткәрә. Ул монда халык җырларын һәм көйләрен җыя һәм язып ала. Материаллардан күренгәнчә, халык арасыннан иң оста курайчылар һәм җырчылар аның белән тыгыз элемтәдә торалар, аңа үзләренең һөнәрләрен күрсәтәләр. Архивта булган З. Шакиров истәлекләре профессор Солтанов эшчәнлегенең бу ягына ачыклык кертергә ярдәм итә.

Истәлекләрендә ул Солтановлар гаиләсен шактый яхшы белүен, алар яшәгән Мәчтидән 25 чакрым ераклыкта урнашкан Аеш авылыннан булуын яза. З. Шакиров үзе Казанда берәр уку йортында укыган булса кирәк. Ул һәр елны каникул вакытларында әти-әнисе яшәгән Аешка кайтуын, Мансур Солтановның кыз туганнары Әминә һәм Зөһрә белән якыннан таныш булуын күрсәтеп үтә. Ә Мансур Исламович белән ул беренче тапкыр 1914—1915 еллар тирәсендә Азякуль пристанендә пароход көтеп торганда очрашуын әйтә һәм аның белән бергә Кама тамагына кадәр пароходта барулары турында сөйли. Ә аннан Солтанов — Саратовка, З. Шакиров Казанга китә.

Автор үзенең Мансур Исламович белән ниләр сөйләшкәнен һәм аңардан ниләр ишеткәнен язмый. Солтановның үзе янында флейтасы булуын гына искә ала. Мансур Солтановның иҗаты турында З. Шакиров күбесенчә аның сеңелләре сөйләгәннәрдән чыгып яза. Алар сөйләвеннән күренгәнчә, Мансур халык музыкасын һәм җырларын бик ярата. Мәсәлән, башкорт көйләрен һәм җырларын җыю-эшкәртү өчен ул Бәләбәй өязенә махсус бара торган була. Архивта бер фотокарточка да саклаңган. Анда Мансур, өстәл артында утырган килеш, курайда уйнаучыдан башкорт көйләрен язган вакытта төшерелгән.

Җыелган материалларның бер өлешен Солтанов 1916 елда, эшкәртеп һәм ноталарга салып, Саратовта китап итеп бастырып чыгара. Архивта бу брошюраның бер нөсхәсе теркәлгән. Ул авторга көйләр җыюда зур ярдәм күрсәткән Сәлимгәрәй Сәетхановыч Жантурингa багышланган. Китапның беренче битенә «Башкирские и татарские мотивы. Записал преподаватель Саратовской консерватории Мансур Султанов, выпуск I» диеп куелган. Ә соңгы битендә шушы ук сүзләр рус шрифты белән татар телендә бирелгән. Китапка профессор кыска гына кереш сүз дә язган. Авторның көйләргә биргән бәясе һәм аларны берникадәр анализлау булганлыктан, ул шактый кызыклы. Сүз башының русчадан тәрҗемәсен тулысы белән китерәбез:

«Бу җыентыкка минем тарафтан Өфе губерниясендә язып алынган башкорт һәм татар мотивлары керде,— диелә анда.— Гадәттә, алар курайда башкарылалар. Бу инструмент рус крестьяннарының агач дудкасын хәтерләтә. Аерма шунда гына — ку-

райда көй төрле динамик оттенклар биреп уйналырга мөмкин һәм, авазлар рәтенең чикләнгән булуына карамастан, башкаручыга берникадәр дәрәҗәдә күңел хисләрен, тойгыларын чагылдырырга мөмкинлек бирә. Бу мотивлар өлешчә мөстәкыйль инструменталь көйләр булып тора, ә өлешчә халык җырларының текстлары белән хисаплашмый, аларның көйләрен һәртөрле үзгәрешләр белән кабатлаудан гыйбарәт. Шуның өчен дә аларның һич ничек тә җырлау өчен билгеләнмәүләрен әйтергә кирәк».

Җыентыкка барлыгы 10 көй: «Салават» (бу көйнең ике варианты китерелә), «Кәрван-сарай», «Коергазы», «Карлыгачкай», «Кабан өсте», «Уңган ирләр», «Җизнәкәй», «Каргалы», «Омская» дип исемләнгән көйләр кергән. Автор аларның нинди темпта уйнауларын һәм нинди үзенчәлекләргә ия булуларын да күрсәтә.

Бу көйләрдән кайберләренең хәзерге концерт репертуарларында очрамавы алар белән кызыксынуыбызны тагын да арттыра.

Мансур Исламович Солтанов 1919 елда кинәттән генә корсак тифы авыруыннан үлеп китә. Бу югалтуны Саратовның музыка җәмәгатьчелеге тирән кайгы белән кичерә.

Профессор И. В. Липаевның язуынча, консерватория профессорлары һәм мәрхүмнең иҗатын сөючеләр кайгы кичәсендәге чыгышларында Солтановны «күренекле музыка эшлеклесе» дип атыйлар.

Мансур Исламович Солтанов Саратовта татар зиратына күмелә.

З. Шакировның күрсәтүенчә, Солтанов җыелган материалларының бер өлешен генә бастырып чыгарырга өлгергән. Профессор үлгәннән соң, аның сеңелесе Зөһрә, мәрхүмнең васыять язуы нигезендә, аның бай гына китапханәсен консерваториягә тапшыра. Консерваториянең бер профессоры Солтанов җыйган материалларны эшкәртүне һәм бастырып чыгаруны үз өстенә ала.

Бүгенге көндә Мансур Солтанов җыеп калдырган материалларның язмышы ничек? Кем дә булса аларны эшкәртеп бастырып чыгару хәстәрен күргәнме? Әллә алар онытылып калган яисә югалганмы? Һәм тагын бер сорау: ни өчен аның турындагы материаллар Пермь өлкәсендә җыелган? — Болар хәзергә билгесез.

Бу мәсьәлә безнең татар музыкасын өйрәнүче галимнәрне кызыксындырыр һәм эзләнүләргә этәрер дип ышанасы килә. Татар һәм башкорт халыкларының прогрессив культура тарихында халык көйләрен беренчеләрдән булып җыю һәм эшкәртү эшенә керешкән музыка профессоры Мансур Солтановның да, әлбәттә, үз урыны бар.

**РИФ ХӘЙРЕТДИНОВ,**
**тарих фәннәре кандидаты.**

# БЕРЕНЧЕ РУС РЕВОЛЮЦИЯСЕНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА

## БЕРЕНЧЕ РУС РЕВОЛЮЦИЯСЕНДӘ ТАТАРЛАР ҺӘМ ХӘЗЕРГЕ БУРЖУАЗ ИСТОРИОГРАФИЯ

Илебез эшчеләре һәм крестьяннары беренче буржуаз-демократик революциягә күтәрелгән көннәргә җитмеш ел тула. Изелгән һәм кимсетелгән хезмәт ияләре коточкыч Россия чынбарлыгына — царизм белән беренче мәртәбә коралга корал килеп сугышка керештеләр, өстенлек итүче сыйныфларга каршы һөҗүм игълан иттеләр. Питер һәм Казан урамнарында, Донбасс һәм Урал шахталарында, заводларында, Мәскәү һәм Мотовилиха баррикадаларында, Грузия һәм Идел буе авылларында — барлык урыннарда халык массалары яңа тәртипләр урнаштыруны: патшаны бәреп төшерүне, демократик республика оештыруны, алпавыт җирләрен конфискацияләүне, илдәге барлык җирләрне национализацияләүне, сигез сәгатьлек эш көне кертүне таләп иттеләр.

1789 елгы француз революциясеннән соң берниндиі буржуаз-демократик революция дә 1905—1907 еллардагы рус революциясе кебек халыкара колач ала алмады. Бу очраклы хәл түгел. Бүтән буржуаз революциядән аермалы буларак, Беренче рус революциясе яңа тарихи чорда — империализм чорында булды. Безнең гасыр башында Россиядәге кебек социаль каршылыклар бер илдә дә андый ук кискен түгел иде. Иҗтимагый мөнәсәбәтләр буржуаз-демократик революция өчен генә түгел, аны социалистик революциягә үстерү өчен өлгергән иде. Россиядә революцияне башкарып чыгарга сәләтле иҗтимагый көчләр — эшчеләр һәм крестьяннар бар иде инде. Царизмга һәм алпавытларга каршы көрәшкә аларны ленинчыл коммунистлар партиясе рухландырды һәм оештырды.

1905—1907 еллардагы революция шулай ук илебездәге күп санлы милләтләрне, шулар арасыннан татар халкын да, көрәшкә уятты. Беренче рус революциясенә татарлар актив катнаштылар. Бүтән милләтләрнең эшчеләре һәм крестьяннары белән бергә алар яшәп килә торган патша строеның нигез ташларын җимерергә фидакарь рәвештә ташландылар. Татар эшчеләре һәм крестьяннары, рус, украин, әзербәйҗан иптәшләре кебек ук, патша ялчылары пуляларыннан һәлак булдылар. Кызыл байракка аларның каны да сеңгән.

Татар хезмәт ияләренең Беренче рус буржуаз-демократик революциягә катнашуы күп кенә хезмәтләрдә сурәтләнгән. Г. Ибраһимовның «1905 елгы революциядә татарлар» дигән китабы шундый хезмәтләрнең иң беренчеләреннән берсе. Ул китап егерменче елларның уртасында татар һәм рус телләрендә басылып чыга. Соңрак бу тема Р. Рәимов, К. Фасеев, Х. Хәсәнов һ. б. лар хезмәтләрендә яктыртыла.

Әмма бүтән рухтагы язмалар да юк түгел. Мондый язмаларның максаты вакыйгаларның асылын ачу түгел, ә бәлки каплап калдыру, фактларны бозып күрсәтү, революциядә сыйныфларның һәм партиянең ролен ала ягу. Бу язмаларның авторлары — «советолог»лар, дөресрәге, империалистик буржуазиянең социаль заказларын үтәүче буржуаз галимнәр.

Совет тарихчылары мондый яла ягуларны читләтеп үтә алмыйлар. Аларның бурычы: барлык «советолог»ларның, тарих фальсификаторларының чын йөзләрен фаш итү.

*

* *

XX гасыр башында рус булмаган халыклар кыргый милли изү астында яшәделәр. Даими җәберләү, милли культураны мыскыллау, көчләп руслаштыру, халыкларның социаль үсешен һәртөрле юллар белән тоткарлау — рус царизмының карагруһ политикасы шулардан гыйбарәт иде.

Әмма бу әле мәсьәләнең бер ягы гына. Икенче яктан, рус булмаган халыкларның хезмәт ияләре шундый ук авыр сыйнфый изелү кичерделәр. Төрле милләтләрнең алпавытлары, фабрика-завод хуҗалары, сәүдәгәрләре, банкирлары, кулаклары хезмәт халкының җилкәсендә яшәделәр, аның канын имделәр. Ә болар турында тарих фальсификаторлары дәшмиләр.

«Советолог»лар татар буржуаз милләтчеләреннән (Г. Исхакый, М. Солтангалиев һ. б. лардан) «бердәм агым теориясен» үзләштергәннәр. Бу «теория» буенча, янәсе, татарлар революциягә кадәр интереслары гомуми булган бердәм масса булганнар һәм бердәм ислам диненә омтылганнар. Буржуаз тарихчылар, бу концепциядән чыгып, татарларны сыйнфый каршылыклардан азат булган социаль бердәмлек итеп сурәтлиләр.

Француз тарихчылары А. Беннигсен белән Ш. Келькеже болай дип язалар: «Татар җәмгыяте 1917 елның февраленә кадәр байлык иясе сыйныфы һәм шәһәр, авыл пролетариаты арасында чын антагонизм белмәде. Урындагы җир биләүчеләрнең зәгыйфьлеге аркасында татар крестьяннарының дәгъвасе тулысынча диярлек рус байларына каршы гына юнәлдерелгән иде һәм шулай итеп ул «социаль» характерда түгел, башлыча «милли» характерда иде. Ә Россия империясенең бөтен территориясенә таралган татар пролетариаты XX йөз башында революцион хәрәкәттә мөһим роль уйнады, әмма бу Бакуда, Себердә, Донбасста булды. Бу урыннарда да ул рус буржуазиясе белән дәгъвалашты» [1].

Димәк, аларча, татар алпавытлары һәм кулаклары татар крестьяннарын түгел, әллә кемнәрне эксплуатацияләгәннәр, татар капиталистлары татар эшчеләрен түгел, әллә кемнәрне изгәннәр булып чыга. Тарихи фактлар татар җәмәгатьчелеге эчендәге сыйнфый дөньяны идиллик картиналарда сурәтләгән буржуаз тарихчыларның ялганнарын тулысынча фаш итә. Татар алпавытлары һәм морзалары — Алкиннар, Акчуриннар, Халитовлар һәм башкалар — татар крестьяннарының да, рус, чуваш, удмурт һәм башка халык хезмәт кешесенең дә каннарын бертигез эчкәннәр. Алар ярлы татар крестьянының кулын да, аягын да кабаль договорлар белән бәйләгәннәр. Күп кенә крестьяннар, алпавытлардан арендага җир алып, уңышның яртысын аларга түләгәннәр, өстәвенә, алар өчен бик күп эшләр башкарырга мәҗбүр булганнар.

Кулаклар татар ярлыларының бик зур дошманы булган. Татар авылларында сыйнфый антагонизм торган саен кискенләшә барган. Мәсәлән, Казан губерна земствосы чиновниклары 1883 елда Тәтеш һәм Чистай өязләрендәге татар хуҗалыкларына статистик тикшерү үткәргәннәр һәм «югары һәм түбән крестьян катламнары арасында аерманың бик кискен» булуын билгеләп үткәннәр. Чистай өязенең Егоркин волостенда сөрү җире уртача чуваш хуҗалыкларына — 1, 24; русларга — 0,87; татар хуҗалыкларына 0,71 дисәтинә туры килгән. Ә кулак хуҗалыкларында — 1,53 (чувашларда), 1,07 (русларда); 1,65 (татарларда) дисәтинә булган [2]. Икенче төрле әйткәндә, татар хуҗалыклары өчен шул характерлы: татар ярлыларына сөрү җирләре иң аз туры килгән, ә кулаклар иң күп җир мәйданын биләгәннәр. Мондый фактларны күп китерергә мөмкин. Тагын бер мисал: Бөгелмә өязенең Бәйрәкә авылында 650 ярлы крестьян хуҗалыгына бары 2 мең 450 дисәтинә җир туры килсә, 43 кулак хуҗалыгы 3 мең 410 дисәтинә җир биләгән [3].

[1] A. Bennigsen et C. Quelquajay. Les mouvements nationaux chez les musulmans de Russie. Le «Sultangalievisme» au Tatarstan. Paris. Mouton, 1960, p. 44.
[2] Л. Рубинштейн. Ленинчыл милли политика өчен көрәштә (рус телендә). Казан. 1930. 22—23 битләр.
[3] «Кызыл Татарстан». 21 октябрь, 1935 ел. № 243.

Бу саннарга аңлатма бирүнең кирәге юк, алар татар ярлы крестьяннарының жирсезлектән ни дәрәҗәдә җәфа чигүләрен, кулаклар һәм алпавытлар тарафыннан рәхимсез эксплуатацияләнүләрен ачык күрсәтәләр.

«Советолог»лар шулай ук татар эшчеләренең татар промышленниклары тарафыннан ерткычларча изелүләрен читләтеп үтәргә төрле юллар эзлиләр. Казан губернасындагы җирсезлектән, ярлылыктан интеккән татар крестьяннарының промышленность үскән районнарга эш эзләп китүләрен дә алар үз максатлары өчен файдаланырга маташалар. Казан губернасында да, Уфа, Оренбург, Сембер һ. б. губерналарда да татар ярлылары татар буржуазиясенә ялланып эшли. Алар анда төрле Үтәмишевләрнең, Гобәйдуллиннарның, Арслановларның, Дибирдиевләрнең «барлык мөселманнарның бертуган» булулары турындагы икейөзле бугаз корытуларын үз җилкәләрендә татыйлар.

Предприятиеләрнең күбесендә эшчеләр 12 шәр, 14 әр сәгать, хәтта артыграк та эшли. Эшчеләрне штрафлар белән җәфалыйлар. Эш шартлары гаять авыр, куркынычсызлык техникасы бөтенләй юк. Күп кенә эшчеләр гарипләнә, хәтта һәлак була.

Закир Рәмиев приискасындагы татар эшчеләренең хәлен М. Гафури «Шагыйрьнең алтын приискасында» дигән автобиографик повестенда чынбарлыкта булганча сурәтли. Эшчеләр иртә таңнан караңгы төнгәчә эшлиләр, аларны штейгерлар мыскыллый. Шахталарда, әледән-әле туфрак ишелеп, кешеләр җир астында кала. Шундый авыр хезмәт өчен тиеннәр генә түләнә. Яшәүләре пычрак казармаларда. «Шахтада эшләп, кояшка чыккан эшчеләр төркемен беренче рәт күргәндә, кояш төшми торган келәт астында саргылт, зәгыйфь һәм нечкә булып үскән үсемлекләр күз алдына килә», — дип тасвирлый М. Гафури ул замандагы татар эшчеләрен.

Татар капиталистлары Казаков, Фәйзуллин һәм Фәйзиннарның итек фабрикаларында (Мамадыш һәм Малмыж өязләре) татар балаларын да аяктан егылганчы эшләтәләр. Юеш чүпрәккә төрелгән балаларны агач кәрәккә утыртып мичкә тыкканнар, чи итекләрне тезеп торырга мәҗбүр иткәннәр. Еш кына балалар өстендәге кием пыскып янарга керешкән... Ә татар капиталистлары, эшчеләрне эксплуатацияләүдән килгән акчаларны саный-саный, икейөзләнеп «мөселман туганнарына ярдәм итүләре»[1] турында аһ оралар. Антагонистик сыйныфлар бар икән, димәк, халыкның төрле катламнарында уртак интереслар булу мөмкин түгел. Эшче сыйныфында — пролетар идеология, буржуазиядә — буржуаз.

Тарихи үсешнең объектив законнары һәр җәмгыятьтә ташкын булып үзенә юл яра. XIX гасыр дәвамында рус иҗтимагый фикере йогынтысы нигезендә татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте башлана. К. Насыйри, Г. Мәхмүдов, Г. Ильяси һ. б. мәгърифәтчеләр, язучылар урта гасырлардан дәвам итә торган торгынлыкка каршы чыгалар, фикер йөртүдә ирек яклап чыгалар, шуның белән алдынгы иҗтимагый идеяләргә шытым бирәләр. XIX йөз ахырында һәм XX йөз башында татар революцион демократларының (Г. Тукай, М .Гафури, Г. Камал һ. б. лар) дөньяга карашлары формалаша. Аларның дин әһелләреннән гомумән, шәригатьтән ачы көлүләре, югары катлау вәкилләренең чын йөзләрен фаш итүләре, иҗтимагый тормышта демократик идеяләрне алга сөрүләре халык массаларын уятуда зур роль уйнады.

Ниһаять, шул ук чорда татар хезмәт ияләре арасында марксизм-ленинизм идеяләре тарала башлый. Хөсәен Ямашев, Гафур Коләхметов, Галимҗан Сәйфетдинов, Садыйк Сәгыев, Сибгат Гафуров, Зариф Сәфәргалиев, Миңнулла Вахитов һ. б. беренче большевиклар үзләренең актив эшчәнлекләрен башлап җибәрәләр. Дөрес, Беренче рус революциясе алдыннан марксизм татар хезмәт ияләренең киң катламына тирән үтеп кермәгән була әле. Әмма аның торган саен киңрәк тарала баруы 1905—1907 елгы революция хәрәкәтендә татар эшче сыйныфы алдынгы вәкилләренең актив катнашуы турында сөйли.

Шулай булса да буржуаз тарихчылар буржуаз-демократик революция турында сөйләгәндә либераль буржуазиягә (татарларда да шулай ук) гегемонлык ролен ябыштыралар. Янәсе, алар революциядә иң актив катнашучылар.

Либераль буржуа революцион көч була алмады һәм булырга да мөмкин түгел

---

[1] «СССР пролетариаты тарихы» (рус телендә). Җыентык. 1 (17). Мәскәү. 1934 ел. 74—75 битләр.

иде. Ул буржуаз-демократик революциянең җиңеп чыгуын теләмәде, ә реформизм позициясенә басты. Либералларның массалар хәрәкәтеннән һәм даими демократиядән реакциядән куркуга караганда да күбрәк куркуын В. И. Ленин күрсәтеп киткән иде [1]. Бу сүзләр тулысы белән татар буржуазиясенә дә карый.

Татар буржуазиясенең «Иттифак-әл-мөслимин» партиясе программасында бер генә дә революцион таләпләр юк иде. Бу турыда үзенең китабында Галимҗан Ибраһимов та ачык итеп яза. «Иттифак» программасында кайбер либераль мотивлар булса да (мәсәлән, телләрнең тигез хокуклылыгын таләп итү), алар аның төп асылын билгеләмиләр иде. Г. Ибраһимов дәүләт строе һәм җиргә карата мөнәсәбәт турында өч мөһим мәсьәләне анализлый. «Иттифак»ның политик идеаллары шулар: дәүләт төзелеше — конституцион монархия; шәхси милек — кагылгысыз; крестьяннар җирне сатып кына алалар. Г. Ибраһимов «Иттифак»ның программасына бу өч пунктын кертеп үз асылын күрсәтүен, чынлыкта русларның конституцион демократлар партиясе — кадетлар программасына охшаш булуын бик дөрес билгеләп үтте [2]. «Урал» газетасы исә иттифакчыларны түбәтәй һәм чалма кигән кадетлар дип бәяләде.

«Советолог»лар «Иттифак»ның эшчәнлегенә бик киң тукталалар: аның съездлары, съезд карарлары, Дәүләт думасындагы эшләре турында бик тәмләп язалар, әммә андагы әһелләрнең патшага табынулары һәм куркаклыклары турында бер сүз дә әйтмиләр. Ә фактлар иттифакчыларның эшчәнлеге демагогик нотыклар сөйләүдән, патша хөкүмәтенә дигән петицияләргә имзалар җыюдан, патшага тугрылыклык турында адреслар юллаудан узмаганлыгы турында сөйли.

Татар либераллары маңгайларын ярганчы патшага табыналар, патша хәзрәтләренең гаилә членнарына сәламәтлек, озын гомер теләп гыйбадәт кылалар. III Дәүләт думасының мөселман фракциясе составындагы иттифакчылар патшага адрес җибәрү өчен тавыш бирәләр. Ә ул адреста: «Ышанычыгыз безгә, падишабыз, без 17 октябрь (1905 ел — М. А.) белән яңартылган, Сез хөкемдар ихтыярындагы дәүләт строен ныгыту, ватанны тынычландыру, анда законлы тәртип урнаштыру өчен бөтен көчебезне, барлык белемебезне, тәҗрибәбезне салдык»,— диелгән була [3].

Иттифакчылар сыйфатындагы татар буржуазиясенең либераль агымыннан «советолог»лар 1906 елда оешкан «Таң» төркеменең юнәлешен «социалистик» агым дип аерым карыйлар. Беннигсен белән Келькеже карашынча, имеш, таңчыларның дөньяга карашы «саф социалистик», чөнки социаль өлкәдә алар «җирне социальләштерү»не, ә милли өлкәдә — «рус федерациясе эчендә мөселман Идел-Урал дәүләтләренең территориаль бәйсезлеген «алга сөрәләр...» [4].

Билгеле булганча, «җирне социальләштерү» идеясен народниклар уйлап тапкан, аннары аны эсэрлар үзләштергән. Чынбарлыкта исә «җирне социальләштерү» идеясе «социалистик» дип исемләнсә дә, вак буржуазия интересларын яклый.

Америка профессоры Р. Пайпс, таңчыларны эзлекле революционерлар итеп күрсәтергә тырышып, «кадетчыл «иттифак» белән алар арасында мөнәсәбәт салкын, вакыты белән дошманнарча иде» [5] — дип яза. Вакыты белән таңчыларның кайбер шапырынуларын Пайпс революцион чыгышлар дип күрсәтергә тырыша. Таңчыларның эшче-крестьян массаларына хыянәт итеп, татар либераль буржуазиясе белән элемтәгә керүен читләтеп үтә. Билгеле булганча, таңчылар «Иттифак»ның I съездына катнашалар, ә III съездында бу «социалист»лар съездны ачу һәм аның программасын төзү комиссиясенә кертеләләр. Алай гына да түгел, ул съездда таңчылар төркеме татар буржуазиясенә «дин һәм идеология мәсьәләсендә аның белән кулга-кул тотышып» барачагын белдерә. Төрле шапырынулар һәм шул ук вакытта буржуазия белән элем-

---

[1] В. И. Ленин. Полн. собр. соч. (рус телендә). Т. 22. 48 бит.
[2] Г. Ибраһимов. 1905 ел революциясендә татарлар (рус телендә). Казан. 1926 ел. 161 бит.
[3] А. Аршаруни һәм Х. Габидуллин. Россиядә панисламизм һәм пантюркизм тарихыннан. Мәскәү. 1931 ел. 38 бит.
[4] A. Bennigsen und C. Quelquajay. Der «Sultangalievismus» und die nationalistischen Abweichungen in der Tatarischen Autonomen Sowjetrepublik — «Forschungen zur osteuropäischen Geschichte», Band 7, Berlin, 1959, SS. 326—327.
[5] R. Pipes. The Formation of the Soviet Union. Communism and Nationalism. 1917—1923. New York, Revised Edition, 1968, p. 15.

тәгә керү таңчыларның вак буржуаз икейөзлелеген ачык күрсәтә. Беренче рус революциясе җиңелгәч, таңчылар ачыктан-ачык һәм бөтенләе белән буржуазия ягына чыктылар. Бөек Октябрь революциясен алар кабул итмәделәр, ә таңчыларның лидеры Гаяз Исхакый Совет властеның куркыныч дошманына әверелде. Таңчылар дәгъва иткән «социализм» әнә шуннан гыйбарәт иде.

Буржуаз «советолог»лар асылда кадетлар позициясендә торалар, чын революцион сыйныфларны — эшчеләр һәм крестьяннарны «икенче сорт» көчләр итеп кенә карыйлар. Беннигсен белән Келькеже, мәсәлән, болай дип яза: «Татар эшче сыйныфы... берникди политик көчкә дә ия түгел иде»[1]. Бу тезисны аклау өчен «советолог»лар татар эшчеләренең квалификациясе түбәнлеген, аларның вак предприятиеләргә таралган булуын, профсоюзлар оешмаларының һәм житәкче кадрларның юклыгын күрсәтмәкче булалар.

Беренчедән, татар эшчеләренең төрле предприятиеләргә таркалган булуы — ул әле беркинди тупланган масса юк дигән сүз түгел. Татар эшчеләре күпләп-күпләп Донбасс шахталарында, Себер һәм Урал рудникларында, хәзерге Татарстан республикасы территориясендәге предприятиеләрдә — Алафузов, Крестовников предприятиеләрендә, казна заводында һ. б. ларда эшләгәннәр. Хәтта Беннигсен белән Келькеже дә Татарстандагы күп кенә предприятиеләрдә татар эшчеләренең 25—40 процент, ә Бондюг заводларында яртысыннан артык булуын танырга мәҗбүрләр. Икенчедән (монысы иң мөһиме), татар эшчеләре рус һәм башка милләт эшчеләре белән бер сафта көрәшәләр. Бу аларның царизмга каршы, буржуазиягә каршы көрәшләренең әһәмиятен көчәйтә. Интернационализм — буржуаз җәмгыятьтә бары тик пролетариатка гына хас сыйфат ул. Интернационализм пролетариат көрәшенең колачын киңәйтә, аны тулы җиңүгә китерә торган шартларны тәэмин итә. Шуңа күрә татар эшчеләрендәге интернационализм хисе аларның зәгыйфьлеге түгел, ә көче.

Шул ук вакытта «советолог»лар татар эшче сыйныфының «саф» татар большевистик группасын төзергә теләмәүләрен зәгыйфьлек билгесе итеп күрсәтмәкчеләр. Алар татар большевикларын туган телдә «Урал» газетасын чыгарудан ары китмәүдә гаеплиләр[2]. Шуның белән алар тупас рәвештә ленинчыл оештыру принципларын фальсификацияләргә тырышалар. РСДРПның II съездында ук В. И. Ленин үзләрен Россиядә еврей пролетариатының бердәнбер вәкилләре итеп дәгъваларга тырышучы бундчыларны кискен тәнкыйтьләгән иде. Ә татар большевиклары, партиядә демократик централизм принципларын яклап һәм тормышка ашырып, үзләрен чын пролетар интернационалистлар итеп таныттылар. Ә татар телендә чыккан «Урал» газетасына килгәндә, ул татар хезмәт ияләре арасында марксистик-ленинчыл идеяләрне аңлату эшен көчәйтү максаты белән оештырылды. һәм бу берничек тә партиядә демократик централизм принцибына каршы килми иде.

Большевиклар партиясе җитәкчелегендә башка милләт эшчеләре белән иңгә-иң торып көрәштә татар пролетариаты актив политик көч булып ныгыды. Революцион давыл кузгалу белән үк, татар эшче сыйныфы көрәшкә кушылды. Экономик забастовкалардан башлап, эшчеләр политик таләпләр дә күтәрәләр. Эшчеләрдә революцион аңның үсешен эшчеләрнең яртысына якыны татарлар булган Алафузов заводлары мисалында күрергә мөмкин. 1905 елда гына да Алафузов заводларында январь, июль, ноябрь айларында өч забастовка була. Алафузов заводлары эшчеләренең революцион хәрәкәткә катнашулары турында С. Лифшиц болай дип яза: «Рус эшчеләренә караганда да катырак изелгән, көчлерәк эксплуатацияләнгән татар эшчеләре стачкалар, кузгалышлар вакытында хәрәкәтнең авангардында булдылар. 6 июльдә, полиция кулга алганда, нәкъ менә татар эшчеләре «Алексей»ны[3] иң актив яклаучы булдылар. Алафузов эшчеләренең җәйге митинглары вакытында социал-демократ чыгыш ясаганда, аның тирәсендә татар эшчеләре сакта торды[4]». Әйтелеп үтелгәнчә, башка предприятиеләрдә дә татар эшчеләре забастовка хәрәкәтенә актив катнашалар.

[1] A. Bennigsen und Ch. Quelquajay. Der «Sultangalievismus» und die nationalistischen Abweichungen... S. 327.
[2] A. Bennigsen und Ch. Quelquajay. Der «Sultangalievismus» und die nationalistischen Abweichungen... S. 327.
[3] Профессиональ революционер С. А. Лозовскийның партия кушаматы.
[4] С. Лифшиц. Беренче революция елларында (1905—1907 еллар) Казан (рус телендә). Казан. 1930. 64 бит.

1905 елда Татарстанда революция давылының иң көчәйгән чорында наборщикларның, столярларның, тегүчеләрнең, приказчикларның беренче профессиональ оешмалары барлыкка килә. Аннан тукучылар, металлистлар һ. б. ларның профсоюзлары оеша. Аларның төзелеше һәм эшчәнлеге башта ук интернационализм принцибы нигезенә корыла. Мәсәлән, Алафузов заводлары эшчеләре профсоюзы уставына: «Промышленность предприятиеләренең барлык эшчеләре, милләтләренә карамастан, союзга керә алалар...»[1] — дип язылган була. Шуңа күрә татар эшчеләренә аерым милли союз оештыруның һич тә кирәге калмый, бу эшчеләр хәрәкәтенең зәгыйфьләнүенә генә китергән булыр иде.

Рус һәм башка милләт эшчеләре белән бергә татарның аңлы эшчеләре 1905—1907 еллардагы революциянең барлык этапларын үтәләр. Алар большевиклар төзегән сугышчан дружиналар составына керәләр, рус эшчеләре белән бергә шәһәр думасы бинасын карагруһчылардан һәм гаскәрләрдән саклыйлар.

1905—1907 еллардагы революциягә «советолог»лар «политик яктан оешмаган» дип бәяләгән хезмәтчел крестьян массалары да актив катнаша. Фактлар Казан большевикларының крестьян массаларына үскәннән-үсә барган зур йогынтысы турында сөйли. 1905 елның җәендә үк губернаның 125 волостеннан сайлап җибәрелгән крестьяннар җыелышында большевиклар үзләренең программаларын һәм тактик карашларын аңлаталар[2]. Большевистик идеяләр крестьяннарда зур кызыксыну уята. Бу кызыксынуны канәгатьләндерү өчен большевиклар барлык мөмкинлекләрдән файдаланалар: эшчеләр яки студентлар авылларга барсалар, алар артыннан яшерен әдәбият җибәрәләр, крестьяннар белән җыеннар үткәрәләр. Мәсәлән, Морки авылыннан татар телендә прокламацияләр җибәрүне сорап мөрәҗәгать итәләр[3]. Тәтеш өязеннән иптәш Василийның («Мишель») Татар Карлангасына барып татарлар белән җыелыш үткәрүе, аңа 10 кеше катнашуы, бик теләктәш итеп каршы алулары турында язалар[4].

Большевистик идеяләр тәэсирендә татар крестьяннарының көрәше кискенләшкәннән-кискенләшә бара. Алар алпавытларга, морзаларга каршы күтәреләләр. Мәсәлән, 1905 елның апрелендә алпавыт Халитовларга каршы (Алабуга өязе) ике авыл крестьяннары күтәрелә. Алар алпавыттан җир таләп итәләр. Хәтта полиция дә аларга каршы корал кулланырга курка[5]. Шул ук өяздә татар крестьяннары князь Шәехгали йортын ут төртеп яндыралар, алпавыт урманын кисәләр[6]. Буа өязенең Кече Чынлы авылы крестьяннары 1905—1906 елларда алпавыт җирләрен үзбашка эшкәртергә керешәләр.

Эшчеләрнең һәм крестьяннарның революцион күтәрелеше патша монархиясенә, капиталистларга, алпавытларга үлем куркынычы тудыра. Бу инде либераль буржуаның коры шапырынулары гына түгел. Шуңа күрә царизм татар либераль буржуазиясенең ул шапырынуларына җитди игътибар да бирми, ә татар эшчеләренең һәм крестьяннарының чыгышларын корал көче белән бастыра. Мәсәлән, Кече Чынлы крестьяннары күтәрелешен бастырганда 200 дән артык кеше үтерелә һәм яралана[7]. Болардан ачык күренә: революциядә либераль буржуазия түгел, ә халык массалары төп рольне уйный.

Беренче рус революциясен патша хөкүмәте канга батырды. Күп кенә сәбәпләр нәтиҗәсендә революцион эшчеләр һәм крестьяннар җиңелде. Әмма 1905—1907 еллардагы революция «генераль репетиция» ролен үтәде. 1917 елның февралендә Россиянең кораллы эшчеләре һәм крестьяннары патша строен юк иттеләр һәм социалистик революциягә юл алдылар. Алар арасында татар хезмәт ияләре дә күп иде. Бу фактны бернинди фальсификаторлар да кире кага алмый.

**МИДХӘТ АБДУЛЛИН,**
**тарих фәннәре кандидаты.**

---

[1] Татарстан партия оешмалары тарихы буенча очерклар (рус телендә). Казан. 1973. 99 бит.

[2] Татарстан партия оешмалары тарихы буенча очерклар. 92 бит.

[3] 1905—1907 елларда Татарстанда революцион хәрәкәт (рус телендә). Казан. 1957. 252 бит.

[4] Беренче рус революциясе көннәрендә Татарстан (рус телендә). Казан. 1955. 74 бит.

[5] Х. Х. Хәсәнов. Татарстанда 1905—1907 еллардагы революция (рус телендә). Мәскәү. 1965. 74—75 битләр.

[6] Беренче рус революциясе көннәрендә Татарстан. 67 бит.

[7] Х. Х. Хәсәнов. Татарстанда 1905—1907 еллардагы революция (рус телендә). Мәскәү. 1965. 245 бит.

**Вил Галиев,**
тарих фәннәре кандидаты

# ТЫЛМАЧЛАР, СӘЯХӘТЧЕЛӘР, ДИПЛОМАТЛАР

Татарларда иҗтимагый фикерләү тарихы Идел буе һәм Урал белән генә түгел, ә башка халыкларның тарихи язмышлары белән дә тыгыз бәйле. Казагыстан һәм Урта Азия халыкларының тарихи үсешендә татарлар шактый мөһим урын алып тора. Алар, рус хөкүмәтенең вәкиле булып, бу халыклар арасында актив эш алып барганнар.

Унсигезенче йөзнең икенче яртысыннан башлап тылмачлар аерым категория кешеләре булып әвереләләр. Чөнки рус администрациясенә казакъ түрәләре белән элемтә урнаштыру көн тәртибенә килеп баса.

«Кыргыз авылларына җибәрелгән тылмачлар,— диелгән «Акмолинские областные ведомости» журналының 1876 елда чыккан 2 нче санында,— урыннарда дала тормышының хокукларын һәм гореф-гадәтләрен өйрәнергә, старшиналар һәм алар кул астындагы кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләрне белергә, күрше ырулар һәм авылларны даими һәм ныклы күзәтү астында тотарга тиеш булдылар».

Әлбәттә, бу кешеләр тәрҗемә итү белән генә чикләнмәгән, аларга шул ук вакытта сәяхәтче галим дә, дипломат та булырга туры килгән.

XIX гасыр башында Оренбург чик буе комиссиясендә тылмач булып Гобәйдулла Әмиров эшләгән. Аңа кадәр үк инде ул казакъ далалары аша Һиндстанга һәм Урта Азиягә сәяхәт кылган булган. Г. Әмировның бу сәяхәтләре турында сөйләгәннәрен Казагыстан тарихын тикшерүче галим Г. Ф. Генс язып алган һәм эшкәрткән. Һәм алар 1825 елда «Азиатский вестник» журналында басылып та чыккан. 1855 елда П. Небольский аларны кабат бастырып чыгарган.

Г. Ф. Генс шулай ук Оренбург чик буе таможнясы тылмачы Байкшиев һәм Әбҗәлил Варкиевләрдән дә әһәмиятле белешмәләр язып ала. 1820 елда аңа Бохарада Негри миссиясендә катнашкан татар Мортаза Фәйзуллин да үзенең күргәннәрен сөйләгән. Алар барысы да Г. Ф. Генсның шәхси фондында саклана [1].

Бу чорда татар сәяхәтчеләре Җиде Су, Тибет якларына да барып чыгалар.

1814 елда Тибетка Рафаилов дигән фамилияле надворный советник җибәрелә. Ул Казанда һәм Семипалатинск шәһәрендә Мөхәррам Габдерәшитов белән Сәифсаттар Сәйфелмөлеков дигән ике татар кешесен үзенә юлдаш итеп яллый. Юлда барганда, Яркәнд шәһәрендә Рафаилов кинәт кенә үлеп китә. Әмма Габдерәшитов белән С. Сәйфелмөлеков юлларын дәвам итәләр: Тибетка сәяхәт кылып, Россиягә кайталар. Кашгарга сәяхәте нәтиҗәләренә йомгак ясаганда алар җыйган материалларны

[1] Оренбург Дәүләт архивы. 166 фонд. 1—8 эшләр.

казакъ галиме Ч. Ч. Вәлиханов та файдалана [1].

Вәлиханов Фәйзулла Сәйфуллинны (С. Сәйфелмөлеков сәяхәт вакытында шул фамилиядә йөри. *Автор.*) искә ала. «Рафаиловның үлеме турындагы хәбәрне беренче тапкыр 1823 елда ук татар Фәйзулла Сәйфуллин алып килде,— дип яза ул.— Степан Попов дигән Семипалатинск сәүдәгәрендә приказчик булып эшләүче Казан татары Фәйзулла Сәйфуллин 1821 елда... Кашгарга бара... Корпус командиры Капцевич әфәндедән тау кыргызларыннан депутация җибәрергә боерык алган Сәйфуллин атаклы өч ыру башлыгының улларын үзе белән бергә ияртә. Кашгарда Рафаиловның үлемен ишетеп, ул... Кашгардагы Коканд илчесеннән хат язуын сорый һәм аны... Яркәндкә җибәрә, шул уңайдан ул вакытта Тибетта булган инглизләрнең дә биш хатын кулга төшерә һәм аларны да, безнең хөкүмәткә карата берәр начарлык кылырга җыенмыйлармы икән дип, Яркәндтәге иптәшләренә юллый».

XIX йөз башында чик буе комиссиясендә һәм Себер кыргызлары идарәсендә татарлар шактый була: М. Кабуллин, Г. Кильметьев, И. Биккулов, Әхмәтов, Ф. Сөбханкулов һәм башкалар [2].

Фәйзулла Сөбханкулов турында кыскача белешмә дә сакланып калган. 1779 елдан туган. Атасы солдат булган. Бик иртә, биш яшьлек вакытында укый башлаган. 1794 елдан башлап Оренбург чик буе комиссиясендә тылмач булып эшләгән [3]. 1809—1810 елларда — инде поручик чинында — Бохарага сәяхәт кылган. Сөбханкулов анда әмир Мир Хәйдәр хан белән күрешкән, аңа канцлер Румянцевтан һәм Оренбург губернаторы Волконскийдан галиҗәнаб грамота тапшырган. Оренбургка өйләнеп кайткач, ул кара-калпакларның, Бохара ханлыгының, Коканд һәм Ташкент калаларының хәле турында тулы отчет төзегән. Бу документларның күчермәләре Ч. Вәлихановның югарыда телгә алынган хезмәтләрендә бар.

Мортаза Фәйзуллинның эшчәнлегенә аерым тукталасы килә. Ул 1807—1825 елларда казакъ далалары буйлап сәяхәт итә. Сәүдәгәрлек иткән булып, дипломатик эшчәнлек белән шөгыльләнә, Россия белән Олы Йөзнең якынаюына булышлык итә. М. Фәйзуллин 1816 елда Терек-дабанга барып чыга. Ә Терек-дабан ул вакытта Ош-Кашгар юлында Тянь-Шань тавын кичү урыны була. М. Фәйзуллин 1820—1821 елларда Бохарада Негри миссиясенә дә катнаша. Э. Эверсман Фәйзуллинның Кызыл-Ком чүлен кичкәндәге тапкырлыгы һәм кыюлыгы турында болай яза: «Бохарадан кайтучы кыргызлар безгә Йоз Кодык янында дүрт мең хивалы көтеп торганын әйтте. Безнең белән баручы татар Фәйзулла — сәяхәтебез вакытында, бигрәк тә хәзер, Бохарада, безгә бик зур хезмәт күрсәткән кеше — бу хәбәрнең дөреслеген тикшерү өчен алдан китте. Бер тәүлектән соң, чүлне кичеп беткәч, ул безне көтеп алды. Ул беркемне дә күрмәгән, беркемне дә очратмаган. Озакламый без дә аның сүзләренә күреп ышандык» [1].

Бер елдан соң инде ул — Җиде Суда, казакъ далаларының иң ерак почмагында. 1822—1823 елларда М. Фәйзуллин Олы Йөз казакълары һәм Җиде Су кыргызлары арасында Россиягә кушылу буенча агитация алып бара, һәм шул агитация нәтиҗәсендә казакъ һәм кыргыз делегацияләре Омскига килә. Тагын бер елдан ул — тагын Бохарада. Аның бу сәяхәте турында танылган тикшерүче М. Венюков болай дип яза: «1824 елда Бохарага югарыда исеме телгә алынган сәүдәгәр Фәйзуллин килә. Аның сөйләгәннәрен, башка бик күпләрнеке белән бергә, танылган Урта Азия белгече Генс язып ала» [2]. 1824 елда М. Фәйзуллин белән бергә декабрист А. А. Жемчужниковны Арал диңгезенә озата барган Әхмеров та Бохарага килә [3].

Пушкин һәм Грибоедовның якын дусты В. Д. Вольховский да Казагыстанга берничә сәяхәт ясый. 1825 елда Бохарага сәяхәте вакытында аны Фәйзулла Ногаев озата бара. Аннан соң Ф. Ногаев Сыр-Дәрья линиясендә хезмәт итә. Тарихчы Вельяминов-Зернов-

---

1 Ч. Ч. Вәлиханов. Әсәрләр җыелмасы. Алма-Ата. Каз. ССР. Фәннәр академиясе. 1964. 146, 147 битләр.

2 Каз. ССР Үзәк Дәүләт архивы. 4 фонд. I тасвирлама. 1175 эш. 3—5 битләр.

3 Шунда ук, 1097 эш. 9 бит.

1 А. Васильев. Доктор Эверсманның Бохарага сәяхәте. Оренбург гыйльми архив комиссиясе хезмәтләре. XIV чыгарылыш, 1905 ел. 205 бит.

2 «Военный сборник». 1877 ел. № 7. 73 бит.

3 Каз. ССР Дәүләт архивы. 4 фонд. I тасвирлама. 4721 эш. 53 бит.

ның да аның белән бергә эшләве турында белешмәләр сакланган. Аннан Ф. Ногаев Җиде Суга җибәрелә, П. П. Семенов-Тянь-Шанский, Чокан Вәлиханов сәяхәтләренә катнаша. Бу турыда шундый документ сакланып калган. Аны Чокан Вәлиханов турындагы мәкаләсендә А. Маргулан китерә (Ч. Вәлиханов. Әсәрләр. I том. Алма-Ата. 1962 ел. 17 бит): «Вәлиханов карамагына, аңа тапшырылган эштә ярдәм күрсәтү өчен, даими рәвештә Тау ордасында яшәгән, 1824 елда ук генерал Мейдорф һәм Негри белән тылмач сыйфатында Бохарада һәм Хивада булган, шуның өчен тархан исеме белән бүләкләнгән Касыйм татары Фәйзулла Ногаев җибәрелде. Аның Ерак Азия илләре белән якыннан танышу булуы, кыргызлар арасында яшәве, бу илгә еш килеп йөрүче Кашгар сәүдәгәрләре белән аралашуы, Тау кыргызлары старшиналарына йогынты ясарга сәләте аркасында Вәлихановка кыргызлар арасында эшләве куркыныч булмас».

Егерменче елларда И. М. Бикмиев казакъ далаларында үзенең дипломатлык эшчәнлеге белән таныла. Ул егерме яшендә үк, 1817 елда, Омскида Себер кыргызлары идарәсенә тылмач итеп эшкә алына. 1819 елда казакъ түрәләре депутациясен Петербургка алып бара. 1822 елдан башлап Петербургта чит ил эшләре министрлыгының Азия Департаментында тәрҗемәче булып эшли. Бик еш командировкаларга йөри: 1824 елда Омскига, 1827 елда Эчкәре Ордага бара, 1830 елда төрек илчеләрен Одессага кадәр озата. 1832 елда И. Бикмиев Оренбург чик буе комиссиясенә советник итеп билгеләнә. 1837 елда Бохарага бара, ә 1843 елда Бохара илчесен Петербургка озата. И. М. Бикмиевнең йөргән җирләрен санап чыгу үзе генә дә аның Казагыстанда һәм Урта Азиядә зур дипломатик эшләр башкаруын күз алдына китереп бастыра[1].

Сәяхәтчеләр Казагыстан далаларына яки Урта Азиягә генә түгел, ераграк илләргә дә баралар. Шундыйларның берсе Троицк сәүдәгәре А. Бакиров 1845 елда Троицкидан казакъ далалары аша Чугучакка сәяхәт кыла. Аның күргәннәрен 1851 елда Н. П. Небольский «Вестник географического общества»да бастырып чыгара (1 кисәк).

1840—1860 елларда Оренбург чик буе комиссиясендә тәҗрибәле тылмачлар коллективы туплана. Әмма алар тәрҗемә эшләре белән генә шөгыльләнмәгәннәр, көнчыгышны тикшерүче галимнәргә дә зур ярдәм күрсәткәннәр: фәнни материаллар, этнографик әйберләр, борынгы акчалар җыйганнар, борынгы калаларның хәрабәләрен үлчәгәннәр, халыкның гореф-гадәтләрен, йолаларын өйрәнгәннәр. Кайберләре уку йортларында да укытканнар, В. В. Григорьев, А. А. Бобровников, А. Лазаревский һ. б. кебек белгечләр һәм галимнәр белән бергә эш алып барганнар. Шундыйларның берсе Мөхәммәт Шәриф Рәхмәтулла Аитов булган. Хезмәт вазифасы буенча эшләгән эшләре исемлегенә караганда, ул дәүләт хезмәтенә 1830 елны кергән. 1842 елда, А. Леман белән Н. В. Ханыковның Бохарага сәяхәте вакытында, аларны озата барган. 1849 елда Оренбург тирәсендәге казакъларның попечителе итеп билгеләнгән. Шул ук елны Көнчыгыш казакъ ордасы башлыгы Солтан Әхмәт Җантүрә сараена илче итеп җибәрелгән. Ә 1850 елда Аитов казакълар делегациясен Петербургка озата барган.

Кырыгынчы-илленче елларда Звериноголовск таможня заставасында Оренбург казакъларының чик буе идарәсендәге Мөхәммәт Хәсән Әхмеров дигән кеше эшләгән. Аның да эшләгән эшләре турында белешмә сакланган. Бу заставада ул дүрт ел эшләгәч, 1854 елда, танылган көнчыгыш белгече В. В. Григорьев тәкъдиме буенча, Оренбург чик буе комиссиясенә тылмач итеп алынган. 1854—55 елларда Урта Азия белгече О. Я. Осмоловский белән бергә Бохарага экспедициягә катнашкан.

XIX йөз барышында Себер һәм Оренбург учреждениеләрендә тылмачлык эше, аның традицияләре нәселдән нәселгә күчкән. Тылмачларның балалары яшьтән үк дипломатия эшенең нечкәлекләрен белеп үскәннәр, аларга белем алу юллары да ачык булган.

Шундыйлардан XVIII гасырда гади тылмачтан коллежский советник дәрәҗәсенә күтәрелгән чиновник Мәндияр Бикчуринның улы Н. Бикчурин Оренбург чик буе комиссиясендә эшләгән.

[1] Каз. ССР Үзәк Дәүләт архивы. 4 фонд. 2264 эш. 1—7 битләр.

Ул Оренбургта кадетский корпусны тәмамлаган һәм галим Г. Ф. Генсның якын дусты булып әверелгән. Сүз уңаенда шуны да әйтергә кирәк, инде картайгач, 90 нчы елларда, Н. Бикчурин Г. Генс турында истәлекләр дә язган һәм алар басылып та чыккан [1].

Кырыгынчы елларда ул, тылмачлык эше белән бергә, Оренбург кадет корпусында гарәп һәм фарсы телләрен дә укыткан. Шул ук вакытта гыйльми эш белән дә шөгыльләнгән: гарәп, төрек һәм фарсы телләрен өйрәнү өчен кулланма язган.

Сәхибгәрәй Шаһимәрдән улы Чанышевның да эшчәнлеге игътибарга лаеклы. Ул 1829 елда туа, 1845 елдан Оренбург земский судында писарь булып эшли. 1851 елда чик буе комиссиясенә күчә тылмач итеп эшкә алына, башта Урал ныгытмаларында хезмәт итә, аннан В. В. Григорьев аны Петербургка алдыра. 1852 елдан өлкән тылмач итеп күтәрәләр һәм ул Бохара эшләрен алып бара. 1857, 1859 елларда Оренбургта Бохара илчесен каршы ала. 1863 елда Арал диңгезе флотилиясе судноларында Сыр-Дәрья һәм Алыс елгаларын тикшерүгә катнаша [2]. Шул ук елларда (1856—1868) С. Чанышев чик буе комиссиясе каршындагы казакъ мәктәпләре надзирателе була һәм 1869 елдан башлап Тургай идарәсендә тылмач булып эшли [3].

С. Еникеев та үзенең хезмәтен Оренбург өяз судында писарьлыктан башлый. 1865 елда Илецк таможня заставасына күчерелә, ике елдан Оренбург казакълары идарәсендә эшли башлый. Ә Омскида Азия тылмачлары мәктәбен бетергән А. Бардашев илленче елларда Җиде Суда эшли. Анда П. П. Семенов-Тянь-Шанский һәм Ч. Вәлиханов экспедицияләренә ярдәм күрсәтә. Рус география җәмгыяте XIX йөз ахырында А. Бардашев аркылы Чокан Вәлиханов кульъязмаларын эзләп таба. А. Бардашевның үзенең дә фәнни эш белән шөгыльләнүе турында билгеле. Мәсәлән, ул үзенең Н. Ф. Костилецкийга язган хатында болай ди:

[1] Оренбург гыйльми архив комиссиясе хезмәтләре. 1907 ел. 19 чыгарылыш. 158—167 битләр.

[2] Каз. ССР Үзәк Дәүләт архивы. 4 фонд. I тасвирлама. 3268 эш. 7—11 битләр.

[3] Шунда ук. 25 фонд. 5 тасвирлама. 245 эш. 179—185 битләр.

«Буш вакытларымда үзем җыйган кыргыз җырларын һәм әкиятләрен тәртипкә китерәм... Бу эшне бетерү белән аларны Сезнең хөкемгә җибәрергә ашыгабыз» [1].

XIX йөзнең алтмышынчы елларындагы Оренбург һәм Иртыш тирәләрендә эшләүче тылмачлар, югарыда әйтеп кителгәнчә, күбесенчә, үз һөнәрләрен олы туганнарыннан яки аталарыннан мирас итеп алганнар. Шундыйлардан Ә. Собханкуловны һәм Бикмиевне әйтергә була.

Әсфәндияр Собханкулов 1863 елга кадәр Оренбург кадет корпусында укый, аннан Оренбург казакълары идарәсенә писарь итеп алына. Соңыннан тылмач булып эшли.

Бикчуриннар нәселе дә җитмешенче елларда тылмачлык һәм дипломатлык эшләрен актив дәвам итә. М. Бикчурин 1873 елда Аму-Дәрья елгасының борынгы ермагын тикшерү буенча А. В. Кульбарс җитәкчелегендәге Урун-Дәрья экспедициясендә катнаша, ә бер елдан Н. А. Маев белән бергә Бохара ханлыгында эшли [2].

Аның туганы Мирсалих Бикчурин — фәндә сизелерлек эз калдырган кеше. Ул берничә фәнни хезмәт язган һәм бастырып чыгарган: «Урта Азиядә безнең сәүдәнең торышы», «Төркстандагы Хәзрәт мәчетенә тасвирлама», «1866 елда Урта Азиядә безнең казанышлар» [3] һ. б. лар.

XIX йөз ахырында бер төркем татар зыялылары Оренбург гыйльми комиссиясендә, рус география җәмгыятенең Оренбург һәм Көнбатыш Себер бүлекләрендә актив эшчәнлек күрсәтәләр. М. Кәримов, А. Мөхәммәтьяров, Т. Еникеев шундыйлардан [4]. Мөхәммәт Сафи улы Рәмиев 1904 елда архив комиссиясенә үзенең кульъязма китабын тапшыра. Аның аерым урыннарын В. В. Бартольд бастырып та чыгара һәм аларга аңлатмалар бирә [5].

[1] Ч. Вәлиханов. Әсәрләр җыелмасы. Алма-Ата. 1964 ел. 598 бит.

[2] А. О. Маслова. Урта Азиягә рус экспедицияләре һәм сәяхәтләре. Өченче кисәк. 1869—1880 еллар. Ташкент. 1962 ел. 49—84 битләр. А. В. Кульбарс. Аму-Дәрьяның түбән агымы. 1873 елдагы тикшеренүләр: Гомуми география буенча рус география җәмгыяте хәбәрләре. 1881 ел. IX том. 2 бит.

[3] Каз. ССР Үзәк Дәүләт архивы. 4 фонд. I тасвирлама. 2647 эш.

[4] Оренбург гыйльми архив комиссиясе хезмәтләре. XIV чыгарылыш. 1905 ел. 45—49 битләр.

[5] Шунда ук. XIX чыгарылыш. 1907 ел. 117—157 битләр.

XIX йөз ахырында Казагыстанда танылган географларның берсе Корбангали Хәмиди (1846—1913) була. Ул башта Аягуз мәдрәсәсендә, аннан Семипалатинск мәдрәсәләрендә белем ала. Берникадәр вакыт ул Бахты ныгытмаларында яши, ә 1874 елдан Чучучак каласындагы мәчетләрнең берсендә имам була. К. Хәмиди, Н. Ф. Катанов, В. В. Радлов, А. Вамбери һ. б. шул заман галимнәренең хезмәтләре белән таныш була. Үзе дә «Тарихи җәридәки Җәдидә» (1889), «Таварихи Хәмсәки шәркый» (1910) дигән китаплар язып Казанда бастырып чыгара. К. Хәмиди үлгәч, «Шура» журналы үзенең 1913 елның 15 мартында чыккан санында аңа карата некролог чыгара. Анда К. Хәмиди хезмәтләренең гыйльми әһәмиятенә зур бәя бирелә.

XVIII йөзнең ахыры, XIX йөз дәвамында татар иҗтимагый һәм гыйльми фикерләүнең үсешен тикшергәндә татар тылмачларының һәм дипломатларының, гомумән, татар зыялыларының Урта Азия, аеруча Казагыстан халыкларын өйрәнүгә керткән хезмәтләрен читтә калдыру мөмкин түгел. Алар Россиядән беренчеләрдән булып ерак далаларга килләр, андагы халыкларның рухи һәм материаль культураларын өйрәнәләр, үзләренең дипломатик эшчәнлекләре белән Урта Азияне һәм Казагыстанны Россиягә кушылуга әзерлиләр. Дипломатик хезмәттәге татар зыялылары рус галимнәре һәм тикшеренүчеләре (ә алар арасында рус һәм поляк революционерлары да шактый була) белән тыгыз бәйләнештә эш итәләр.

Татар тылмачлары, сәяхәтчеләре һәм дипломатларының тоткан юлы мәгърифәтче-демократлар белән бер үк юнәлештә була.

# МӘҢГЕЛЕК ДУСЛЫК

Миңа елдан артык инде башкорт язучысы Сәгыйт Агиш дөньяда юк. Барысы да күз алдында, әле генә, кичә генә булган кебек. Шунысы кызганыч — киләчәге юк. Аның киләчәге истәлекләрдә генә сакланыр. Искә төшкән саен яңа бер сыйфаты ачылыр һәм «Мин аның турында шул кадәр аз белгәнмен... Әгәр ул исән булса...» дигән уйлар йөрәкне чеметеп узар.

Сәгыйт Агиш — минем бабам, тормышның серле көченә ия булган кеше, кайчан да булса бу дөньядан китәр дип башыма да китерми идем. Сәгыйт Агишны кичәләргә, очрашуларга, конференцияләргә, җыелышларга чакырып әле һаман телефон шалтырап торыр кебек иде.

Кеше белән никадәр яхшы таныш булсаң да, аерылгач, аны бик аз белүеңне аңлыйсың. Ә мин бабам турында кешеләргә дә сөйли алырлык итеп беләм дип уйлыйм.

Әле кечкенә вакытымда ук мин аның аяк тавышын урамнан ук танып ала идем. Без шәһәр уртасындагы йортның беренче катында яшәдек һәм аның шаярып сөйләшкән ачык тавышы урамнан өйгә яхшы ишетелеп торды. Ул подъездга килеп кергәч, ашыкмыйча атлаган аяк тавышына таяк шакылдавы да кушыла иде. Мин бабамны ишек төбенә килеп каршы алам һәм аны шатландырырга теләп, «Картатай, Казаннан концерт бирәләр!» — дип әйтәм. Ул Казан тапшыруларын һәр вакыт яратып тыңлый торган иде. Ә мин әйткәч, көлдерергә теләп, шаккаткандай кычкырып җибәрә һәм юри ашыккан булып кылана. Бер минут та үтми, бүлмәбезне «Киек казлар» моңы белән тутырып, бөтен көченә радио яңгырый башлый. Ә бабам кулын колагына куеп радиоалгычка ук иелә һәм аның йөзе уйчанланып, моңсуланып кала. Мин аның хатын-кызларныкы шикелле кечкенә кулына, көмеш сыман йомшак сакалына карыйм һәм шаяра башлавын көтәм. Ләкин көтеп ала алмыйм, үзем дә җыр тыңлый башлыйм.

«Киек казлар» — әбиемнең яраткан җыры. Ул җырны тыңлагач, ни өчендер, аның күзендә яшь күренә, ә бабамның йөзе артык җитди була. Шуңа күрә мин бу җырны яратмыйм.

Концерт тәмамлангач, әбием белән бабам миңа таныш булмаган татар язучылары, шагыйрьләре, композиторлары турында сөйләшә башлыйлар. Хәер, аларның берсен мин ул вакытта ук яхшы белә идем. Бабам аны Хәсән агай дип йөртә иде. Хәсән Туфан Уфага килгән саен безгә керми калмады. Йомшак күңелле, ягымлы Хәсән агайны мин дә ярата идем. Әбием белән бабам аны зур хөрмәт белән телгә алалар, Хәсән агай дип дәшүләре дә ничектер аны иркәләп әйткән сүз кебек тоела иде.

Бервакыт Хәсән Туфан Уфага кыш көне килде. Без дүртәүләп каядыр барырга чыктык. Хәсән агайның өстендә җиңел пальто. Ул чандыр гәүдәле һәм миңа бик озын буйлы кебек тоелды. Ә бабамның өстендә җылы пальто. Башында колакчын бүрек, кечкенә кулларына күпереп торган йон перчаткалар кигән. Юлыбызда балалар шуып шомарткан бозлавыклар очрый иде. Бабам, таеп егылудан куркып, шул җирләрдән әкрен генә әйләнеп үтә. Ә Хәсән агай, яшьләрчә, йөгереп килгән уңайдан боз өслэп шуып уза, ә үзе балаларча шатлана иде. Бабам гаҗәпләнеп: «Фәрдәнә, кара әле,



*Сулдан: Сәгыйт Агиш, Хәсән Туфан, Сәйфи Кудаш*



кара!..» — дип әйтә. Әбием көлеп: «Унҗиде яшьлек егетмени!» — дип җавап бирә, бабам да аңа кушылып көлә.

Алар гел шулай икесе бергә рәхәтләнеп көлә торганнар иде.

Безнең өйдә еш кына гаилә концертлары була иде. Төп башкаручы, билгеле, минем бабам. Ул менә дигән импровизатор һәм декламатор иде. Андый кичәләрдә мин диванның башына ук посып утырам, бәрхет тышлы кечкенә мендәрне ни өчендер кулыма алам һәм бабамның шигырь укыганын тыңлый-тыңлый, аны тегеләй дә, болай да изгәлим. Бер шигырьнең исемен дә, авторын да хәтерләмим, анда сүз тормышта ялгыз калган кешенең капчык асып сукбайлыкка чыгып китүе турында бара иде. Бу шигырьне бабам аеруча кызганыч итеп сөйли. Юллы ефәк пижамасының җиңеннән кулларын чыгара, үзе ничектер бөкрәеп үк бетә, йөзе кызганыч кыяфәткә керә, тавышы мескенләнә...

Мин күз яшьләремә буылам, бабамның селкенеп торган буш җиңе күз алдымнан китми. Түзә алмыйм, кычкырып ук елый башлыйм. Моны күргәч бабам кинәт кенә Тукайның «Алтын тарак» шигыренә күчә.

Бервакыт ул Һади Такташның «Тиләләр» шигырен укыды. Бу вакыт аның күзләренә карау куркыныч иде. Соңыннан мин аңа ошатып сөйләргә никадәр тырышсам да, булдыра алмадым. Шулай да бер шигырьне ул яратканча сөйләргә өйрәндем. Ул Хәсән Туфанның хатынына багышланган шигыре иде. Гомумән, безнең семьяда Хәсән агайның шигырьләрен яраталар, күбесен яттан беләләр.

Кечкенә чагымда, бабам белән утырып, фоторәсемнәр карарга ярата идем. Альбомда таныш рәсем чыкса, шатланып: «Хәсән агай! Минский!» дип күрсәтеп барам. Минем Габдрахман абый Минский белән кочаклашып төшкән рәсемем дә бар.

Бер елны Казанда башкорт әдәбияты һәм сәнгате атналыгы булды. Шунда бик күп язучылар, композиторлар, артистлар белән бергә бабам Сәгыйт Агиш белән әбием дә барды. Үзләре белән мине дә алдылар. Казанга пароход белән бардык. Алдыбызда Казан күренә башлагач, бабамның: «И Казан! Дәртле Казан! Нурлы Казан! Моңлы Казан!» — дип кычкырып җибәрүе әле дә хәтеремдә. Каршы алырга бик күп кеше төшкән иде. Палубаны чәчәкләр белән күмделәр. Менә шул декада көннәрендә Габдрахман абый мине үзе белән алып рәсемгә төште.

Гомеренең соңгы елларында бабам беренче тапкыр Һади Такташны күрүе, Туфан белән очрашуы, башка бик күп татар язучылары белән ничек танышуы турында сөйләргә ярата иде.

Оренбургта, бабам укыган педагогия техникумында, татар әдәбиятының күренекле язучысы Шәриф Камал укыткан. Шәриф Камал каләм тибрәткән яшьләргә бик игътибарлы булган. Хәтта техникум җитәкчеләре аны, яшьләр белән арагызда пәрдә юк дип, шелтәли торган булганнар. Ә бит шул пәрдә аркасында гына да Шәриф Камал яшьләрне күпме нәрсәгә өйрәтә алмый калган. Бабам аның «Таң атканда» романын, «Акчарлаклар» повестен ярата, аерым өзекләрен күңелдән укый иде. Ә соңыннан, үзе укытучы булып эшләгәндә, «Иң кызыклы дәресләрем Шәриф Камал турында», — дип әйтә иде.

Сәгыйт Агишка техникумны тәмамларга туры килми. 1924 елны аның күзе начарлана. Бу елларда Уфада атаклы профессор Одинцов эшли. Дәвалану өчен Агишны Уфага күчерәләр.

Уфада Сәгыйт Агишка бөтенләй яңа дөнья ачыла. Биредә ул атаклы язучылардан Мәҗит Гафури, Даут Юлтый, Нәкый Исәнбәт, Сәгыйт Рәмиев, Сәгыйт Сүнчәләй, Оренбургтагы танышы Булат Ишимгуловларны очрата.

Сәгыйт Агишның Мәҗит Гафури белән беренче тапкыр очрашуы кызык кына була. Ул ничектер бер вакыт, таныш егетләре белән, рабфак студентлары оештырган концертка бара. Тамашачылар чыгыш ясаган бер кешене көчле алкышлар белән каршылыйлар. Хәтта бик үк булдыра алмаганнарын да сәхнәгә кат-кат чыгаралар.

— Сөйләсәм минем чыгышны да яратырлар иде. Ләкин сәхнәгә ничек үтәргә, — дип уйлый Агиш. Уйлый торгач юлы табыла: сәхнәгә төрле кеше кулы белән язылган кәгазьләр килә башлый. «Залда Сәгыйт Агишев исемле бөек декламатор утыра. Аның чыгыш ясавын телибез», дип язылган була ул кәгазьләрдә.

Концертның икенче бүлеге тәмамлангач, сәхнәгә залдан чакырылган кешеләрне чыгара башлыйлар. Сәгыйт Агиш өчен дә көтелгән минут килеп җитә. Кичәне алып баручы кесәсеннән бер уч кәгазьләр чыгарып баш очына күтәрә дә:

— Дуслар, минем кулымда уннарча записка. Алар залда, нәкъ менә шушы залда, Оренбургтан килгән атаклы декламатор утыруын хәбәр итәләр, — дип кычкыра һәм иҗекләп Агишның фамилиясен укый, — иптәшне сәхнәгә сорыйбыз!

Башта бабам Тукайның «Пар ат» шигырен укый. Аны тагын сорыйлар. Бу юлы ул Һади Такташның бер шигырен, ахырдан көлке бер хикәя укый.

Нәтиҗә бабам көткәннән дә шәбрәк булып чыга. Аның янына таныш булмаган бер кеше килә һәм:

«Сез шигырьләрне зур хис белән сөйлисез. Үзегез дә язып карагыз. Булдыра алырга тиешсез», — ди. Бу хәл бабамны бик шатландыра, ләкин ул вакытта каршында атаклы Мәҗит Гафури үзе басып тора дип башына да китерми.

Бабам сөйләгәндә, мин аның йөзенә карыйм. Яшьлек елларын исенә төшергәндә, ул яшәреп киткәндәй була. Мин аның, кыек якалы күлмәкне яссы каеш белән буып, озын куньчлы күн итекләрдән йөргән чагын күз алдыма китерергә тырышам. һәм:

— Картатай! Син дә артист була алыр идеңме? — дип сорыйм.

— О! — дип куя бабам, үзен чыннан да артист кебек хис иткәндәй, канәгатьләнү белән.

— Юк, чыннан да? — дип бәйләнәм мин аңа.

— Чыннан дамы? — дип шаяруын дәвам итә бабам. — Бөек артист булган булыр идем, әмма бер «ләкин» бар.

— Ә нинди «ләкин?»

— Күрәсең бит, буй җитми, — ди бабам җитди төс алып, ләкин миңа барыбер ул шаярадыр кебек тоела.

Ә бит ул чыннан да Казанда театр техникумында укый. Шунда Габдрахман Минский белән танышып дуслаша.

Ул елларда Һади Такташ, Кави Нәҗми, Гадел Кутуй, Хәсән Туфаннар яшьләр арасында бик еш кына шигырьләр укый торган булалар. Уфада комсомол газетасында эшләгән вакытта Сәгыйт Агиш һәм аның дусты Гайнан Хәйри Казанга барып шул шагыйрьләр белән очрашырга булалар. Бу сәфәргә алар озак әзерләнәләр, яңа шигырьләр язалар, искеләрен төзәтәләр. Казанда Сәгыйт Агиш белән Гайнан Хәйрине Һади Такташ, Кави Нәҗми, Гадел Кутуйлар әйбәт каршы алалар.

— Казанга килгән һәр әдип иң башлап Галимҗан Ибраһимов белән танышырга тиеш,— ди аларга Кави Нәҗми.



*Әмирхан Еники һәм Сәгыйт Агиш*



Татар әдәбияты классигы Галимҗан Ибраһимов, гаҗәеп талант иясе булган язучы, татар халкына гына түгел, башка милләт укучыларына да бик кадерле була. Шуңа күрә Гайнан Хәйри белән Сәгыйт Агиш бу тәкъдимне шатланып каршылыйлар.

Галимҗан Ибраһимов озак көттерми, аларны кабул итә. Аның башкорт халкының тормышын, әдәбиятын, язучыларын, аларның иҗатын яхшы белүенә Сәгыйт Агиш белән Гайнан Хәйри шакката. Ул елларда Һади Такташ символизм агымының башында тора, Кави Нәҗми имажинистларның, ә Гадел Кутуй футуристларның җитәкчесе дип хисаплана. Сөйләшеп утырганда Галимҗан Ибраһимов шушы өч шагыйрьнең иҗатына бәя бирә һәм:

— Теге я бу әдәби агымны оештыру белән генә эш бетми. Үзеңнең халкыңны, укучыларыңны яратырга, хөрмәт итә белергә кирәк, — дип әйтә. — Язучы булу ул төрле агымнарга ияру түгел, ә халыкка якынлашу, аның омтылышларын, рухи хәрәкәтен дөрес яктырту...

Бу вакытта башкортның әдәби теле формалашып килгән еллар була. Орфографиядә нинди дә булса төпле бер принцип табылмаган. Галимҗан Ибраһимов кунакларының да бу мәсьәләдә артык йомшак булуларын сизеп, бераз шелтәләп ала.

— Сез әдәбиятка кагылышлы барлык мәсьәләләрне белергә тиеш. Язучыга әдәбият теориясен дә, дөрес язу кагыйдәләрен белү дә мәҗбүри. Ул теләсә нинди галим белән бәхәскә керә алырга тиеш.

Сәгыйт Агиш белән Гайнан Хәйри өчен бу очрашу зур сабак була. Алар үзләрен аяктан егардай көчле, әмма шифалы яңгыр астыннан үткәндәй сизәләр.

1927 елга кадәр бабам Туфанның шигырьләрен укып, иҗатын өзлексез күзәтеп барса да, үзе белән әле очрашканы булмый. Яраткан шагыйре белән ул Казанга укырга килгәч очраша. Шул ук елны Казанга Әстраханнан Габдрахман Минский, Башкортстаннан Әмирхан Еники, Мирсәй Әмир, Фатих Кәрим, Пермьнән Демьян Фәтхи килә. Бу яшь язучылар барысы да әдәби түгәрәккә йөриләр. Һәр вакыт дип әйтерлек түгәрәк утырышларында Һади Такташ белән Хәсән Туфан катнаша.

Түгәрәкнең җитәкчесе дә, аерым бер планы да булмый. Арадан берсе:

— Кемдә нәрсә бар? — дип сорый.

Кыюраклары бүлмә уртасына чыгып, я шигырь, я хикәя укый. Шигырьләрне тиешергән вакытта Такташ Байрон белән Гетене искә ала, Кутуй белән Туфан телендә күп вакытта Маяковский була.

Түгәрәккә күп халык йөри, аларның кайберләре Такташка, кайсылары Туфанга иярергә тырыша.

Такташ белән Туфан поэзиясенә булган мәхәббәтен бабам гомере буена саклый. Ул бик еш кына «Бибиевләр»не, «Ак каен»ны, «Кайсыгызның кулы җылы» шигырьләрен укый иде. Кайвакытны минем радио тыңлап утыруымны күрсә, әкрен генә килер иде дә: «Туфан агайның шигырьләрен бирәләр», — дип әйтер иде.

Татар әдәбияты белән бабам һәр вакыт кызыксынып тора иде. Соңгы елларда аның күзе бик зәгыйфьләнде, үзе укый алмый башлады, аның өчен һәр вакыт әбием укый иде. Яки ул сәгатьләр буе радиоалгыч янында утыра, бу аның әдәби кичәләрне, Казан концертларын тыңлаган сәгатьләре була иде.

Мин шулай кечкенәдән үк бабам авызыннан Габдулла Тукай, Һади Такташ, Хәсән Туфан, Гадел Кутуй, Кави Нәҗми, Салих Сәйдәшев, Бакый Урманче, Әмирхан Еники, Габдрахман Минский исемнәрен ишетеп үстем. Ул алар турында истәлекләр язды, иҗатлары турында мәкаләләр белән чыкты. 1964 елда ул «Якташлар» дигән повесть тәмамлады. Сәгыйт Агиш бу хезмәтен үзе белән бергә Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыган Муса Җәлилгә багышлады.

1975 елның 7 гыйнварында Сәгыйт Агишка 70 яшь тулган булыр иде. Һәм ул үзенең якын дуслары белән яңадан очрашыр иде. Аларның йөзенә үк иелеп карар иде дә, таный алса, балалар кебек шатланып кычкырып җибәрер иде. Әйе, ул таягын шакылдатып шаулап йөрер, дусларының кулларын кысар, шаярыр, көләр иде. Юбилей көннәрендә ул гадәттәгедән яшьрәк күренгән булыр иде. Чөнки ул күңеле белән һаман яшь булды.

**ГҮЗӘЛ АГИШЕВА,**
**Казан дәүләт университетының журналистика факультеты студенткасы.**

Әхсән Баянов

# ҮСЕШ ГАРМОНИЯСЕ

Соңгы елларда поэзия әсәрләренә бәя бирүдә принципларның төрлелеге, критерийларның томанлы булуы һәм шуның аркасында субъективлыкның чәчкә атуы хакында безгә байтак сөйләшергә туры килде. Сүзгә тиз арада нокта куяр мәл җитте дип, игълан ясау хәзер дә табигый булмас шикелле. Газета-журнал битләрендә күпләп басыла килгән рецензияләр һәм тәнкыйть мәкаләләренең авторлары башлыча механик рәвештә уңай яки кире бәя бирү максатын гына куя, җитди мәсьәләләр күтәрсә, көчсез, примитив төшенчәләр белән, шигъриятнең яңа үсешен чынлап теләгән хәлдә дә формаль һәм тышкы галәмәтләргә карап кына эш итә. Чын поэзиягә укучы зәвыгын тәрбияләү, шигъриятнең чын асылы, шул рәвешчә бер читтәрәк кала килә.

Поэзия мәнфәгате, аның киләчәк үсешен теләү һәм шуңа ышану мине шул хактагы кайбер фикерләр белән уртаклашырга мәҗбүр итә.

Хәзер шигырь техникасы бик нык үсте, дигән сүзләр соңгы вакытта еш ишетелә башлады. Бер-беребезгә таләпләрне шул үсеш дәрәҗәсен күздә тотып куябыз. Законлы таләпләр.

Техниканың югары иканлеген расларлык мисалларны чынлап та табарга мөмкин. Хәтта күпләп. Махсус сайлап тормыйча «Казан утлары» журналының кулга эләккән номерын ачам. Бәхетле егет икән, Г. Рәхим шигыре эләкте.

**Читтән генә сиңа карап торам.**
**Дөнья сиңа шундый килешә:**
**Күлмәгеңә болын рәсеме төшкән,**
**Ә күлмәгең рәсеме — инештә.**

Интим дигән лирикага масштаблы, эре буяулар төшкән, чагыштырма детальләр ассоциатив ераклыкка куелганнар. Болындагы матурлык белән кызның табигый гүзәллеге сүзсез генә, янәшәлек юлы белән берләшә. Элеккерәк елларда булса, шагыйрь, портрет сызуны болайрак дәвам итеп, ихтимал: «Сандугачлар сиңа көй биргәннәр» димәс, бәлки «Синең тавышың — сандугач сайравы» дияр, «Җикән камыш сиңа буй биргән» димәс, ә бәлки «Агыйдел камышлары күк синең зифа буйларың» дияр иде.

**Ялгыз казмы, моңлы талмы, әллә**
**Алсу таңмы — моңлы уй биргән.**

Халык иҗатында, шагыйрьләрдә гасырлар буе кабатланган бик гадәти детальләр төзелеш рәвешләрен бераз гына үзгәртәләр дә кабатланудан котылу чарасына әверелләр.

Заманның үзенә генә хас образлар да килеп чыга. Урамнарда хәзер кар шикәр кебек түгел, ә неон карлар ява, кичләрен анда көмеш нурлар түгел, неон яктылык сибелә. Зәңгәр һавада самолет калдырган тасмалар, космик кораблар, мегатонналар да шигырьгә башта тартыныбрак, ә соңынтын шактый табигый кереп утыралар.

Реквизит яңа булса, шигырь үзе дә яңарып, сафланып китә шикелле. Ләкин детальләр яңалыгына артык зур бәя бирү дөрес булмас иде. Шигырьдә төп бурычны детальләр хәл итми. Искерәк детальләр белән дә яңа конструкцияләр төзергә мөмкин. Моны хәзер осталыкта олы дан тотмаган шагыйрьләр дә эшли ала. Яшь шагыйрь Харрас Әюпов та менә гадәти чагыштырулар белән эш иткән:

**Хыянәткә барсам, тау ишелер,**
**Нәкъ урталай ярылыр бу болын,**
**Имәннәрне давыл йолкып ташлар,**
**Барысы бергә дәшәр:**
**— И-и-х, улым!**

Тау ишелер, җир ярылыр, давыл кубар — хәтта инде төсләре җуелып беткән тәгъбирләр. Ләкин бу шигырьдә авторның үзен табигать улы итеп тоюыннан, ахрысы, дуска хыянәт итүнең табигатькә каршы эш икәнлеге сүзсез генә сизелә дә — яңа төр әйтелеш килеп чыга.

Шигырь техникасының үсеше аерым елларны конкрет чагыштырганда бигрәк тә ачык күренә. Җөмләдән, илленче еллар башын алтмышынчы яки җитмешенче еллар белән чагыштыру кызык. Илленче елларда, сугыштагы җиңүләрне данлау дәвамында, тынычлыкны яклаган, олы гражданлык хисләре белән сугарылган авазлар көчле яңгыраса, яшәешкә, кешенең җаны, психологиясенә кагылганда, шигырь аю шикелле ипсез хәрәкәтләр ясый, тупас кылана, бөтен нәрсәне җиңел һәм бер селтәнү белән хәл итә, яки артык төчеләнә. Гомумән, үзенә караганда затлырак даирәгә килеп кергәч кулларын кая куярга белми аптыраган кунак шикеллерәк, югалып кала. Акылны риторика белән алдатып булмасына төшенгәч, ул конкретрак уйлап та карады, ләкин артык вакланып китте. Ваклану яраксыз икәне тиз ачыклангач, детальләр ярлылыгы башланды. Ярлылыктан бер күзәнәкле шигырьләр язу модасы туды һәм аерым очракларда ул үзен хәзер дә сиздерә. Бөтен кимчелекләрне шигырь техникасына кайтарып калдыру дөрес тә түгел, мөмкин дә түгел, әлбәттә. Социаль хәлләр һәм мәгънәләр хәтта технологиягә дә йогынты ясамый калмады.

Примитивизм куркыныч чир иде. Җитди, классик традицияләрдә тәрбияләнгәннәребезгә һәм шул рухта язылган шигырьләргә ул елларда юл бикле диярлек иде. Ул чорда эстетик таләпләрнең берьяклы булуы аркасында кешенең рухи халәтен чагылдырган күп күзәнәкле шигырьләр тупланган беренче шигырь китапларын чыгара алмагач, кайберләребез, квалификация үзгәртеп, әлеге бер күзәнәкле шигырьләрне язарга өйрәнеп күп кенә елларыбызны әрәм иттек.

Менә шул чор белән чагыштырганда, бүгенге поэзия, әлбәттә инде — җир белән күк арасы. Хәзер без шигырьне шәп язабыз дип күкрәк кагарга да хакыбыз бар шикелле. Ләкин чагыштырудан китсә, бүтән еллар чиратка басачак. Тукай, Дәрдмәнд, Сәгыйть Рәмиев иҗат иткән чор, мәсәлән. Алардан шәбрәк язабыз дип кайсыбыз әйтә ала? Такташ поэмалары кебек укыла торган поэмаларны кайсыбыз яза? Моабит дәфтәрләре дақын нинди яңа әсәрләр шәһрәте кумә алыр? Алай гына да түгел, әле мин «бер күзәнәкле» дип мыскыл иткән шигырьләр чорында да бишле билгесе куярлыклары, ә хәзерге катлаулы дип йөртелгән күп шигырьләр арасында икеле куярлыклары азмыни?

Хәзер әдәбиятка килүче яшь шагыйрьләрдән өметле диганнәренең берсен дә форма ягыннан примитивизмда гаепли алмыйсың. Юлның һәркайсы диярлек — метафора, шигырьнең һәркайсы диярлек — катлаулы детальләр тукымасы. Гомумән, фактура шәп. Ләкин күңелгә гомерлеккә кереп урнаша торган, үтә күренмәле, ачык соклandыра торганнары ул хәтле күп түгел. Ник?

Җавап бер: шигырь техникасы кирәк, шигырь техникасы бар, ләкин ул бөтен нәрсәне берьюлы хәл итә ала торган илаһи кодрәт түгел. Илаһи кодрәт — шагыйрьнең җаны, характеры, таланты.

Еш кына, техникасы хакында нинди дә булса мактау сүзе әйтү кыен очракта да, бернинди катлаулы тәгъбирләр, сурәтләү чараларсыз да әйбәт кенә шигырьләр барлыкка килә. Мисалны тагын сайламыйча гына китерәм. Бу юлы Р. Фәйзуллин шигыре әләкте.

Бар сөйләнгән купшы тостлардан
Мәгънәлерәк иде ал шәраб.
Тагын истә калган — бер сылуның
Күзләрендә күргән ишарә.

«Бер банкетта» дигән бу дүртьюллыкта искитәрлек алым күренми. Ул хакта уйламыйсың да. Шигырьне тикшерергә алынгач кына «ал шәраб» белән — «ишарә»нең шагыйрь үзе генә тапкан кызыклы рифма икәнлеген ачыклыйсың. Ләкин шигырьне сәнгатьчә иткән нәрсә — рифма гына түгел, ә беренче нәүбәттә кыю фикер. Шушындый мисаллар рәтенә кергән миниатюралардан тагын «Мин ашыкмыйм» һәм мәрхәмәтсез язылган «Вакыт или...» дигәннәрен хәтердә калдыру мөмкин. Кызганычка каршы, соңгы вакытта мондый кызыклы шигырьләр Р. Фәйзуллинда сирәгрәк очрый башлады. «Ә дөресен...» дип исемләнгән шигырьгә охшаганнары икенче төрле мисаллар рәтенә керә.

Минем яшьләр белән каен елый,
Күңелем белән көлә гөлчәчәк.
Кемдер: «Җаны туңган, беткән...» диде.
Ә дөресен — боз эрегәч дулкын әйтәчәк.

Мин дә дөресен әйтәм — бу шигырь баягылары белән чагыштырганда катлаулырак, образлар күп һәм аларның конструкцияләре яңача — ягъни техникасы шактый югары. Ә шигырь баягылары белән чагыштырганда шактый кайтыш. Анда отышлы дигән детальләрнең күңелдә хис туганчы ук оешып, аннары акыл ярдәмендә ясалуын чамаларга мөмкин. Технологиясе, осталыгы тыштан ук ялтырап күренгәндеме, әсәр сәнгатькә хас ышандыру көчен югалта.

«Иңемдә — ай!» дип космик масштабта фикер йөртергә яраткан Р. Әхмәтҗанов та гомуми олылыктан табигый конкретлыкка күчкәндә, күңелгә кагылырлык фикерләр әйтә ала.

Күрше ихатада, күзен сөртеп альяпкычка,
Әйтте бераү:
«Әй, исәннәр илгә бер кайта!»
...Ә ул минем әнием иде...
Сабый идем,
белмәдем шул аны юата! —

Техникасы аксый, әлбәттә. Ләкин шулай да тормышчан нечкә бер хисне укучыга күчерә ала торгандыр бу шигырь. Күпчелек очракта шигырь төзеклеген ихтирам итмәү, әсәрнең бәясен бөтенләй юкка чыгара торган булса да, аерым хәлләрдә, техник кытыршылык зур зыян китерә алмый. Соңгысына Н. Дәүлинең «Галәви» исемле шигыре характерлы. Аргамакка менеп йөрмәгән, илләр гизмәгән, үз бәхетен тик туган җирдән табармын дип өмет иткән, кояш баегач таңны көткән гади бер кеше дөньядан киткәч тә дөньяның боегыбрак калганы сизелә башлый бу шигырьдән, житди фикерләр һәм хисләр кузгала башлый. Кешегә гади дип карамаска, аның күңел матурлыгын күрә белергә, гомумән, миһербанлыкка өйрәтә алуы мөмкин иде бу шигырьнең. Ләкин артык озынга сузылганлыктан, тәмамлар өчен уңышлы фикер табылмаганлыктан, әсәрнең тәэсир көче бермә-бер кими.

И. Юзеевнең «Таш диварлар авазы» поэмасында мәңгелек тема — кешенең ирекке, коллыкка каршы көрәш темасы куела. Әсәр шундый ук житдилек һәм кырыс буяулар белән хәл ителгән. Укып барганда шигырь булмаган бер генә юл да күзгә ташланмый. Аерым сурәтләр оста эшләнгән һәм алар гомум сурәт тә барлыкка китерәләр. Бу инде сәнгать әсәре туды дигән сүз. Әмма шагыйрь тынычланып калмасын өчен бер кимчелекне дә искәртеп үтү мөмкин һәм кирәктер. Мозаиканы гомум сурәткә, гомум фикер тирәсенә туплап карасаң, поэманың чагыштырмача озын икәнлеге ачык күренә.

Поэмага мин өч төрле эш биреп карыйм. Беренчесе — ул укылырга тиеш. Иң уңышлы проза әсәрләре кебек үк, чыккан мәлендә укучы аны кулдан-кулга йөртергә тиеш. Икенчесе — әгәр андый дәрәҗәгә үк ирешмәсә, публицистик яңгырашы зур булсын. Бу очракта вакытлы матбугат, радио, телевидение аны автордан башка да

файдалана белә. Өченчесе — фәлсәфи эчтәлеге тирән һәм катлаулы булган, дөнья һәм тормыш үсешендәге яңа күренешләрне яки законнарны ачкан очракта, зур популярлык казанмаса да, ул «Фауст», «Илаһи комедия» шикелле җитди өйрәнелерлек булсын.

Өч төрле эшнең берсен дә башкармаган поэма — эшлексез.

Илдар моңарчы эшлекле поэмалар язып килде. «Таш диварлар» да эшлекле поэма булыр дип өметләнгән хәлдә, эчтәлеге һәм формасы пропорциясендә бераз озынрак булуы укылышында кыенлык тудырмасмы дигән сорау да куясы килә. Җавапны автор белән бергәләп вакыт бирер дип ышаныйк.

Соңгы елларда поэма өлгә форма кытлыгы, өлгә гомумән жанр кризисы кичерә. Шигырьдә генә түгел, хәтта поэмада, алай гына да түгел — романда сюжетны инкарь итү тенденциясе яшәгәндә, хәлне аңлау кыен түгел, әлбәттә. Әмма сюжетлы шигырьләр һәм сюжетлы поэмалар (примитив дип мыскыллауларга карамастан) яши бирә һәм ул жанрның төрле формаларда киләчәктә дә уңышлар китерә алачагына мин шикләнми карый алам.

Практикабызда доминионлык роле башкарган лирик поэмалар фонында С. Сөләймановаың «Фал китабы» поэмасы форма ягыннан кызыклы ялтырап китте. Анда, фикер һәм хис хәрәкәтенә нигезләнгән башлангыч белән бергә, сюжет үсеше дә бар һәм, әйтер идем, нәкъ шушы вакыйгага корылган өлеш әсәрне тотып, оештырып тора. Тулай торакта яшәп яткан кызларның (бигрәк тә лирик герой булган укытучы кызның) дөнья әхвәлләре хакындагы чәченке уйлануларына мәгънәви бүләк һәм «җанлы сорау булып», алар арасына «яшь баласын күкрәгенә кыскан» Гөлйөзем атлы кыз бала килеп кергәч, әсәргә дә җан керә, бүтәннәрнең аңа мөнәсәбәтендә сәнгать конкретлыгы барлыкка килә. Вакыйгага (димәк ки сюжетка) ышангач, баштагы уйлануларның нигәдер озынгарак сузылуын, кирпеч-таш төзүләр хакындагы очеркка хас публицистиканың бу әсәргә нигәдер ятрак тоелуын сизәсең. Язу техникасын бишләгә үзләштергән авторга композицион кимчелектән котылу нишләп кыен булды икән, дип гаҗәпләнеп тә куясың.

**...Бәндә ничек гел фәрештә булсын,**
**оҗмах, тәмуг — бер үк йөрәктә,**

— дигәндәйрәк гадәти фикерләрдән матурлык тойгысы тудыра алган шагыйрәгә;

**Күк барында —**
**җирдә уклар да бар,—**
**тыныч яшимени шагыйрьләр!**

— дип, матурлыкны дәреслеккә хезмәт иттерә алган шагыйрәгә,— гомумән, үзенең «Фал китабы» җыентыгында чын сәнгать дәрәҗәсенә күтәрелгән күп юллар һәм шигырьләрен иҗат итә алган талантлы шагыйрәгә китапның калган өлешен дә шул югарылыкка күтәрергә нәрсә комачау иткән икән?

Фикерне шулай дәвам иткәндә, шигырь техникасының шактый катлаулы нәрсә икәнлеге ачыклана. Шигъри морфология, синтаксис, строфалар төзелеше, ритмика һәм башка, һәм башка бик күп законнар хәтергә килә. Аларның әле без бөтен тирәнлеген күреп тә бетермибез бугай, чөнки теория үсә тора. Бер яклап үсә тора, ә икенче яклап фәкыйрьлектән ычкына алмый.

Строфалар бездә нигездә — дүрт юл. Актив үлчәүләребез — ун-тугыз, сигез-җиде, унике-унике, унбер-унбер. Барлык бу үлчәүләрдә сүз басымнары дөрес килмәү сәбәпле, еш кына ритмик тәртип сакланмый. Бертөрлелектән котылу нияте белән кайбер елларда вакытлы рәвештә ирекле шигырь, верлибр активлашып ала. Ләкин, гомумән, торгынлыктан чыга алмыйбыз. Хәтта шушы теоретик фәкыйрьлеккә мәгълүматсызлык та өстәлә. Күп мисалларның берсе — гаруз системасы. Безнең әдәбиятта үлчәү һәм строфиканы төрләндерү сәләте булган бу система кайчандыр актив эшләгән. Ә без аның бөтен төрләрен белмибез. Бәлки аны яңадан кулга тотып карарга, өйрәнергә, ихтимал, яңадан эшкә җигәргә вакыттыр. Техниканы сыйнфый дип игълан итүче вульгар социологизм кабере өстендә кылганнар чәчкә атып утыра бит инде. Мондый эзләнүләрдә безгә теоретиклар ярдәм итәргә тиешләр иде. Ләкин күп кенә

монографияләр чыгарсалар да, шушы конкрет юнәлештә безгә алардан файда булганы юк.

Технологик байлыкларны арттыру өчен чынлап көрәшергә вакыт. Ләкин шунысын да өстик, әле без булган байлыктан да тулысынча файдалана белмибез.

Сүзне ары табан кузгатып, Н. Дәүлинең «Син мине кичер» дигән җырына тукталыйк. Төзелеше ягыннан ул — үзенчәлекле, һәр куплет — җиде юл. Беренче юл белән икенчесе, дүртенче белән бишенчесе, өченче белән алтынчысының рифмалашуы, ягъни бер генә юлның да рифмасыз калмавы шигырьгә йөгерек тел, әйтер идем, хәтта халыкчан шомалык бирә. Шомалык бар, ләкин шигъри фикер, төгәл мәгънә юк. Баштан ахырга хәтле лирик герой бик олы җанлы булып, матур сүзләр әйтә-әйтә, сөйгәне белән хушлаша. Син мине кичер, исеңә төшер дип өзгәләнә. Ник аерылышабыз дигән сорау белән җәфалана һәм соңыннан «нигә киттем, нигә хуш дидем?» дип, сорауны кабыргасы белән китереп куя да, «Син минем бердәнбер дус идең, син мине кичер» дип «җавап бирә». Шомалык хакында артык кайгыртып, мавыгып, мәгънә дигән нәрсәне оныту мисалыдыр бу. Техникаң, кем әйткәндәй, никадәр генә ажур булмасын, нихәтле генә оста булма — моңарчы әле шигъри идеясез беркемнең дә уңышка ирешкәне юк.

Сурәтләү чаралары чын тойгы, конкрет тормыш материалы белән ныгытылса гына максатка ирешә. Ф. Яруллинның «Танышканга ун ел вакыт узган» шигырендә, мәсәлән, шундый материалның бершиксез булуы шагыйрь сүзләрен тагын да җитдирәк кабул итәргә мөмкинлек бирә.

**Ун ел узган.**
**Хәзер карыйм сиңа.**
**Үзгәрдең син, бик нык үзгәрдең.**
**Үзгәрмичә! —**
**Толым гына йөрткән иңнәреңә**
**Минем язмышымны күтәрдең.**

Шагыйрьнең уйлап чыгарылмаган чын идеясе чын лирик хис тудыра, һәм икенче бер әйбәт сыйфат, ышандыру көче хасил итә. Шагыйрьнең иң уңышлы шигырьләре үз тәҗрибәсе белән бәйләнгән. Н. Арсланов шигырьләре дә шушы яктан характерлы. Билгеле, бу иҗатта да акыл аша барып җитәргә мөмкин булган, башка шагыйрьләр йогынтысы тудыру ихтималы булган тәгъбирләр бер дә очрамый дип әйтү кыен. Андый шигырьләрсез бер генә шагыйрьне дә табу мөмкин түгелдер. Н. Арслановның да бары тик образлар әрәм булмасын өчен генә ясалган конструкцияләре байтак, ләкин алар арасында да сәнгать фактына әверелгәннәре күп. «Әйтсәм килә» шигырендә шундый строфа бар:

**Талаучылар басып кермәсен дип,**
**Биклләп куйган йортлар шикелле**
**Тора илләр, чиген сырып алган**
**Сакчылары, кортлар шикелле.**

Җир өстендәге чикләр һәм ямауларга карап язылган башка шигырьләр барлыгын автор белә, билгеле. Шул ук вакытта бу үзе генә тапмаган фикерләрне әйткәндә дә авторны ясалмалыкта гаепләү кыен.

Строфаларны төрләндерү, үлчәүләрне, ритмиканы баетырга тырышу — Н. Арсланов иҗатының табигый өлеше. Аерым алганда, ул газәл формасына мөрәҗәгать иткәли. Кайбер бүтән газәлләре кебек үк «Кайгы белән шатлык дуслар кебек җитәкләшеп» дигәне, тәҗрибә булу ягыннан шулай ук игътибарны җәлеп итә. Әсәр икеюллык бәетләрдән торып, беренче ике юлдан башкасы нәкъ газәл төзелешенә туры килә. Ләкин, башындагы беренче ике юл рифмалашмаганга, традицион формага ирешелми, шигырь газәлгә ишарә генә булып кала. Минемчә, бу әсәр фикер үсеше ягыннан да төзек түгел. Кайгы белән шатлык җитәкләшеп йөргәне хакындагы фикри үсешкә кушылыр-кушылмас, ирер-ирмәс башка идеяләр урын алып, ахырга таба шигырь бигрәк тә таркала шикелле. Шулай да шигырь төзелешен төрләндерү омтылышы мондый мисалларны уңай факт буларак билгеләп үтәргә куша.

Метафораны Н. Арсланов та күп куллана. Ләкин аннан башка язылган әсәрләре күбрәк түгелме икән? Шуңа да карамастан, шигырьләре моңа карап көчсезләнми, киресенчә, күп кенә шигырьләрдәге экспрессив дип исәпләнергә тиешле метафоралар системасына (әйе, хәтта системасына!) караганда, аның «образсыз» дип әйтелергә тиешле шигырьләре көчлерәк булып чыга. Мисал — «Һич булмаса» дигән шигырь.

Фирдәүсинең «Шаһнамә»сен шаһлар кабул итми, әсәр исәпкә дә алынмыйча онытыла. Ләкин еллар үтү белән бер әфган шаһы моның бәясен аңлап, бүләкләр төяп, шагыйрьгә кәрван җибәрә. Шәһәргә:

**Кыйммәт бүләк төяп кәрван керә,**
**Шагыйрь чыга соңгы сәфәргә.**

Сюжет шулай тәгәлләнә. Бернинди метафора юк, бүтән чаралар да күзгә ташланмый,— гади бер шигырь, ләкин нишләтәсең, дөньядагы гаделлек, дереслекнең җыңүе, шагыйрь язмышы һәм шундый бик җитди нәрсәләр турында уйлана башлыйсың. Димәк, шагыйрь максатына ирешкән.

Тагын шундый шигырь:

**Сез бит миңа дуслар идегез.**
**Элек якын күреп, юаткандай:**
**«Син талантлы шагыйрь!» дидегез.**
**Бар тавышыма җырлый башлау белән**
**Нигә болай кара кәйдегез!**

Шигъри дигән детальләр тагын юк, ә шигырь үзе тагын бар.

Билгеле, мондый шигырьләр арасыннан көчсезрәкләрен дә табарга мөмкин. Ләкин аларның да төп сәбәбе чаралар азлыгыннан түгел, җан җылысы җитмәгәннән. Бәхеткә каршы, Н. Арсланов өчен андыйлар характерлы түгел. Аның шигырьләре һаман акыллы фикерләр әйтә, дөрес нәтиҗәләргә китерә, иң әһәмиятлесе — техника фетишенең озын гомерле булмаячагына ишарәли.

Бүгенгесе көндә кайсы гына шагыйрьгә мөрәҗәгать итмә, метафорасыз язылган шигырь табу мөмкин түгел диярлек. Шигырь техникабыз югары дип кайберләребез, бигрәк тә яшьрәк шагыйрьләр, кайчак масаю кебегрәк хәлгә килеп җитәләр. Ләкин бу масаю шигырьдә кайбер җитди нәрсәләрне аңлап бетермәүдән килеп чыга.

Хәзер поэзиядә примитивизмның яңа төре — катлаулы формаларда бирелгән фикер һәм хис фәкыйрьлеге барлыкка килде. Бусы, минемчә, элеккесенә караганда да куркынычрак. Нигә дисәң, элеккесе тыйнак иде, монысының дәгъвасе зур — ул үзен укучыга фәлсәфи шигырь итеп таныткмакчы була һәм чын фәлсәфи әсәрләргә алама күләгә булып төшә. Укучы аны аңларга тырышып баш вата, интегә. Бу төр примитивизм — тәкәббер, һәр гадилеккә өстән карый, ә фактта үзе чын күңелдән язылган гади шигырьдән түбән. Ник дисәң, гади шигырьдән даһилыкка юл бар, ә катлаулы примитивизм — тупик, аннан беркая да юл юк. Ә кешесе бик тә акыллы һәм белемле булса, формализмга барып чыгарга да күп калмый.

Шигырь техникасына каршы баш күтәрү икенче бер акылсызлык булыр иде. Ләкин бөтен исәпне бары тик технологиягә корырга һич тә ярамаганлыгын ныклап әйтәсе килә. Чөнки, ни хәтле генә ялтырап тормасын, метафора искерә, бүген ничаклы матур һәм тирән тоелмасын, иртәгә ул буяулар барыбер уңачак. Буяулар уңгач, акшар коелып төшкәч, эчләре буш булса, алардан берни дә калмаячак, фактура көлгә әйләнәчәк, ә натура калачак, кичерешләр калачак. Сурәт үзмаксат түгел, ярдәмче генә. Чын оста моның нәрсә икәнен белә. Чын архитектор бер генә тәс, кызыл кирпеч белән Сөембикә манарасы кебек көчен җуймас биеклеккә күтәрелә. Хисең, фикерең булса, тәгәл әйтелсә, алар садә хәлендә хәтта затлырак.

Поэзиянең иң баш көче — хакыйкать. Аңа һәр очракта да тугрылыклы була алмасак, иң башта без үзебезне алдыйбыз. Фәлән кеше алдакчы шагыйрь дип кычкырырлык мисаллар булмаса да, читенрәк мәсьәләләргә, җентекләбрәк өйрәнү таләп иткән проблемаларга кагылсак, еш кына җиңел котылырга чамалыйбыз. Хәтта кыюлыкта сыналган дигәннәребез дә вакыт-вакыт шул җиңел юлга баса. Кайчакта бер

сәбәпсез, бары тик сүз юктан алдашырга тотынабыз. Г. Афзалның да соңгы шигырьләрендә шундый ялган сизелә башлады.

**Кызык түгел яшәү,**
**— Үрдәп-үргә генә,**
**— Түрдән-түргә генә үтүче булып.**
**Их, мин эшләр идем**
**— Урман буйларында**
**Яшел тугайларда**
**Көтүче булып.**

Ләкин мин әйтәм, әгәр Гамил Афзал кулына чыбыркы тоттырып көтү көтәргә кушсаң, ул рәнҗиячәк.

Тагын шундый юллар:

**Кешеләр катлаулы хосусән:**
**Гөнаһлы кешеләр куркучан.**

Гөнаһлы кешеләр куркучан булса, монда бернинди катлаулылык булмас иде. Ә кешеләрнең күбесе чынлап та катлаулы. Икенче яктан, «гөнаһлы кешеләр куркучан» дип кистереп әйтү — шулай ук дөреслеккә туры килми торган нәрсә дип карыйм. Мәҗит Гафуриның «Сарыкны кем ашаган» мәсәлә һаман искермәгән дип саныйм. Дөрес, гөнаһыннан куркучылар да бардыр. Ләкин шундый нахаллар бар, вөҗданында мең пот гөнаһ өелсә дә, биле бөгелми, гәүдәсе тәкәббер, күзеңә туп-туры карап, ул үзе сине оялтырга тырышыр. Автор мондый куркусыз кешеләр барын белә, билгелә. Ялганга ышандырыр өчен нинди генә баш җитмәслек образлар системасы ясап куйма, барыбер ышандыра алмаячаксың. Ә менә:

**Данлыларның данына сырыштың,**
**Дансызларга карамадың.**
**Бик күпләргә ярарга тырыштың,**
**Беркемгә дә ярамадың,**

— дип, тормышның мәгънәсен ярып салса, бүтән инде бернинди хәйлә кирәкми, бер сүзсез ышандыра ул сине.

Н. Арсланов һәм Г. Афзал кебек шагыйрьләрнең биографияләре бай, бүгенге көннәре актив. Алар халыкның тарихы, бүгенгесе, киләчәге хакында уйлап яшиләр, кешеләр белән аралашып, күргәннәрен кәгазьгә төшерә баралар. Күргән бер нәрсәне кәгазьгә күчерә торганда, билгеле, шагыйрьне чәчән хәлендә калу куркынычы алдый. Еш кына бу ике шагыйрьдә дә артык җиңеллек үзен сиздерә килә. Ләкин аларның тирән шигырьләре мондыйларына игътибар итмәскә мәҗбүр итә. Тормыш белән якын бәйләнештә тору аларны әлә әйтелгән уңышларга китерә.

Конкрет тормыш материалы белән ныгытылмаган шигырь — алтын белән беркетелмәгән акча — шигъри өйләнешкә, кызганычка каршы, күпләп һәм күпләп ыргытыла.

Ясалмалык — эмоциональ фәкыйрьлекнең, моңсызлыкның башы. Ә моңлы шигырьләрнең азая баруы бу елларда шулай ук нык сизелә.

Кем ничектер, моңлы шигырьләрне мин барлык башка төр шигырьләрдән өстенрәк дип саныйм. Андый шигырьләрнең фикер ягыннан сайрак сыман тоелуы ихтимал. Ләкин аларны алда әйткән идеясез әйберләр белән бутау — зур гөнаһ. Хәлбуки, аларны төссез шигырьләр рәтенә кертеп йөртергә тырышучылар күп кенә. Болар — моңсыз кешеләр. Күзне чагылдырырлык ялтыравыклы детальләр, зиһенне чатнатырлык көтелмәгән борылышлар гадәттә бу шигырьләр музыкасына туры килми. Аларда — настроение, җан хәрәкәте бар...

Шушы мәгънәдә миңа яшь шагыйрә Асия Минһаҗева шигырьләре ошады. Аларны анализлау шактый кыен, чөнки, әйткәнемчә, күзгә ташланып торган детальләр юк диярлек. Хәтта бәйләнерлек урыннарны да табарга мөмкин. Әйтик, егерме яшьлек кызның уңҗиде яшьлек чагын эзләп йөрүе сәеррәк тәсле. Болар — тышкы билгеләр. Уалучан мондый шигырьләрнең хатасын төзәтеп, аларны үтереп куярга мөмкин. Асия Минһаҗеваның журналда басылган шигырьләрендә шундый җан хәрә-

күтә сизелә, моң ишетелә. Киләчәктә моңлы бу бала бозылмасын, шигъри осталыгын үстергәндә чын лирик тойгыларын саклап калсын иде дигән теләк әйтәсе килә.

Р. Миңнуллинның «Әллүки» дигән шигыре моң хакында сөйли.

**Моң агыла җанга,**
**Моң агыла.**
**Әллә тылсым инде, әллә кой!!**
**Нәкъ Тукайны тетрәндергән сыман**
**Тетрәндерә мине «әллүки».**

«Бал, бал» дигәннән генә авызда бал тәме тоелмый, билгеле. Робертның башка шигырьләре тылсымлы тойгыларны чынлап та кичергәне аркасында уйландыра. Дөресрәге, шушы матур үзенчәлек аңарда формалашып килә һәм әйбәт өметләр уята.

Башкортстан шагыйре М. Кәрим шигырьләре бу мөнәсәбәттән бигрәк тә характерлы. Шигырьләрне туп-туры күңелгә алып керүче тылсым — җилкендергеч моң бар аларда.

Халыкның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге тудырган кичерешләр, халык кайгысы һәм шатлыгы бар иткән хисләр, эчкерсез ярату, музыка белән очрашып, бөтен табигать белән берләшеп шаулый кебек.

**Күктә бер кошчык сайраса,**
**Бар җиһан хәйран димен.**
**Җирдә бер кеше елмайса,**
**Җир йөзе бәйрәм димен.**

Сурәт алган сөенеч сүзе кемнең дә булса күңелен күтәрү, ярарга тырышу, яки бүтән максат белән әйтелми, хәтта моның сәбәбе ачык та түгел шикелле.

**Моннан соң да, исән булсам,**
**Утырмас инде акыл.**
**Һич вакытта белә алмам**
**Әйберләрнең үз хакын.**

Чын мелодия — табигатьнең үзендә. Без аны тик ишетәбез. һәм бүтәннәргә җиткерәбез.

Ундүрт яшьтә кыз бала качып кына яулык чигә, унсигездә аны хәләленә бүләк итә, өлешсезләр калмасын дип, картлык көнендә сандыгына тагын бүләкләр җыя һәм дөнья белән хушлашканда исәннәргә шул бүләкләрне калдырып китә — соңгы бүләк... Кызлар, апалар, әбиләр. Берниндн ясалма бизәкләрсез дә үзәкләрне өзә торган изгелек һәм нәфислек — халкыбызның үзендә, тәрбиясендә, табигатендә. Шуларны күрә белү осталыгы — язу осталыгы димим! — могҗиза тудыра. Күрә белү һәм ярата белү бар итә могҗизаны.

**...Шул ярга син аяк баскан саен,**
**Ком әйләнә барды алтынга.**

Комны алтынга әйләндерү өчен күпме йөрәк хисе — акыл көче димим! — кирәктер, аны инде шагыйрь үзе генә белә.

**Син кулыңа кабырчыклар алдың,**
**Алар энҗе булып яндылар.**

Могҗизалы сурәтләр, сурәт булып кына калмыйча, дөньяның, кеше гомеренең чиксезлеге, мәгънәсе хакында уйлануларга барып тоташа:

**Агачларда алтын моңсулыгы —**
**Әйе, монысы — инде көз иде.**

Сәбәбе ачык аңлашылып та бетмәстән, җан дигәнеңне диңгез һәм җил итеп шаулата торган мондый кичерешне кайберәүләр подтекст диләр, кайберәүләр бу әсәрдә демон бар дип, тискәрерәк мәгънә салалар. Карап торсаң әллә нинди зирәклек күренми мондый әсәрләрдә. Ләкин, Лорка термины белән әйткәндә, аларда

җен бар. Ә безнекечә, сихерле сыман яңа дөнья ача торган бу сыйфат — моң була инде. Монда чын оптимизм бер кайчан да көпрәюгә әйләнми, күз яшьләре ах-вах килеп үзәкләрне өзгәләргә маташкан сентименталь төчелек белән килешә алмый. Тормыш үзе гел фаҗигале, тормыш үзе гел яктыга таба бара.

Җитди әсәрләр белән тагын да ешрак очрашасы килә. Ләкин аларны иҗат итү дә, кабул итә белү дә бик җиңел түгел шул.

Әйтелгәннәрдән шундыйрак нәтиҗә килеп чыга: әйе, шигырьне без яза беләбез һәм күп язабыз, хәтта инде инфляция дәрәҗәсенә җиткердек аны. Ләкин... Ләкин менә шушы «ләкин» хакында уйланасыбыз һәм эшлисебез бар.

Бүгенге шигырьнең төп характеры шундый: чама белән әйбәт, чама белән начар, чама белән усал, чама белән юаш. Түбән үк тә очмый, өскә дә күтәрелеп китми. Сәбәпләре бер генә төрле түгелдер дип уйлыйм.

Шулай да, минемчә, төп сәбәпләрнең берсе — тормыш шартлары.

Тормыш шәп, күңел шат, поэзия — сүренке. Парадокс? Ләкин аны аңларга мөмкин. Хәзер безнең кайсыбызның да өй артында ач үлемнең куркусыннан ил еламый, беребезнең дә баш түбәсендә балта асылынып тормый, сыйнфый дошманнар махсус рәвештә уйларыбызны кирәкмәгән измнарга борырга тырышып гаиләбезгә хәтле үтеп керми — җан тыныч, һич тә аһ дип кычкырып җибәрәсебез килми. Шуннан башлана идиллия, шуннан башлана тук философия.

Аннары килеп, бер үк газетлар, бер үк журналлар укыйбыз, торган җиребез — шул ук Казан, кайнаган җиребез — Матбугат йорты. Бер төсле яшибез, бер төсле уйлыйбыз, бер төсле язабыз. Шул сәбәпле үзебезнекенә охшамаган әсәрләрне ярат-мыйбыз, колакка чак кына сәер ишетелдеме — долой!

Зинһар, моны дөрес аңларга тырышыйк. Әйтәсе килгәнем шул гына — бер-беребезнекеннән аерыла торганрак тормыш белән, үзенчәлерәк тормыш белән яшәсәк, поэзиягә моның файдасыннан башка бернинди начарлыгы тимәс иде, дим.

Поэзия техник алымнар үзенчәлеге генә түгел, поэзия, беренче чиратта, яшәү формасы, дөньяны күрү рәвеше. Яңа формалар тусын өчен башта аларны тормышта табарга кирәк, күрү өчен — йөрергә, күп җирләр, хәтта илләр гизәргә кирәк. Батырлыгың җый да кит КамАЗга, нефть чыккан җирләргә кит, авылга кайт, ерак китсәң килмәсә, Казанданиләр барын тикшер, өйрән. Шул тормышка катнашып, аның борчулары белән борчылып, шатлыклары белән шатланып, уйланып яшәмәсәк, акыл төзегән конструкцияләребез, тормыш материалы белән тутырылмыйча, матур каркас хәлендә генә кала бирер. Безнең көннәр үзенчәлеге шундый: производство мөнәсәбәтләрендә кешенең кичерешләре, гомумән, психологиясе көнкүрештәгегә караганда ачыграк күренә. Аларны шул мөнәсәбәтләрдән башка тулысынча аңлау мөмкин булмаган эш.

Инде килеп, иҗатка җитәкчелек итүче һәм юнәлеш бирүче тәнкыйть турында кайбер фикерләрне дә әйтик.

Соңгы елларда әдәби тәнкыйтьнең фәннилек дәрәҗәсе шактый үсте. Р. Мостафин, Т. Галиуллин, А. Әхмәдуллин, Ф. Миңнуллин кебек тәнкыйтьчеләр иҗатында бу күңелле тенденция аерымачык күренеп тора. Ләкин, гомумән алганда, тәнкыйтебез һаман да фәнсезлек чире белән интегә. Тәнкыйтьче кемне яратса, шуның хакында яза. Яратмаган килеш язып булмый дип кенә җибәрә кайберәүләр. Моның тагын бер зарарлы һәм куркыныч ягы бар: симпатияләр белән эш итү бер-берсенә симпатия тоткан язучы һәм тәнкыйтьчеләрне бер тирәгә, төркемнәргә туплый башлый, макташу чәчәк ата, кайбер эшкуарларга шушы хәлдән файдаланып хәтта аңлы рәвештә төркемнәр оештырырга, әшнәчелеккә юл ачылуы ихтимал. Иҗтимагый матбугатта шәхси симпатияләр алмашу, шуның тәмен сиздерешеп ләззәт кичерү — оят һәм ят күренеш.

Үзешчәнлек дәрәҗәсеннән фәнни камиллеккә өлгәшүнең беренче шарты — объективлык, план буенча эш итү, шәхси хисләрдән өскә чыгу, беренче планга хисне түгел, акылны кую. Хәзер инде без ярату сүзләрен түгел, дәлилле фикер дауларга хаклыбыз.

Әдәби хәрәкәткә җитәкчелектә фәнсезлек психикасын тәмам бетерү аңлы рәвештә үткәрелә торган гаделлектән, конкрет планнарны тормышка ашыра барудан башка мөмкин түгелдер дип саныйм.

Мостай Кәримдә шундый гыйбрәтле юллар бар:

**Ялтырап тормыймын. Дөнья**
**Таушалтты, шомартмады.**

Бу фикерне әдәби хәрәкәттәге, тәнкыйтьтәге киңәксез дипломатиягә, зарарлы симпатияләргә каршы куеп кына түгел, шигырь техникасын фетишлауга каршы куеп тә кабатлар идем:

— Таушалсак таушалыйк, әмма шомармыйк, иптәшләр.

...Татар совет поэзиясе Һ. Такташ, М. Җәлил, Ф. Кәрим кебек олы исемнәр белән бәйләнгән. Аларның шигъри батырлыгы әдәби күренеш кенә түгел, ә кешелек характерының асылыннан, дөньяга карашлары ныклыгыннан, соңгы сулышларынача барган яшәү рәвешләреннән һәм үзләре бәлки күеп өлгермәгән соңгы ноктларыннан чишмәләнеп килә. Шушы традициянең хәзер дәвам итүе хакында уйлансак, без беркатлык җавапсыз калабыз һәм җилкәләрнең сыгылып киткәнлеген тоябыз — аларның югары, әйтер идем, бөек миссиясен дәвам иттерүче булу җаваплылыгы артык авыр йөк шикелле.

Безнең иҗатта, билгеле, бүтән шартларда һәм яңа формаларда, күренекле әлгәрләребез калдырган төп сыйфатлар, әлбәттә, дәвам итә.

Беренчеләрдән булып, С. Хәкимнең «Курск дугасы», соңынтын язылган олы «Дуга»сы, бөек якташыбыз В. И. Ленинга багышланган һәм РСФСРның М. Горький исемендәге дәүләт премиясенә лаек булган поэмалары хәтергә килә. Аннан ары арсеналда ныклык сынавын әйбәт узган әсәрләре булган хәрби буын шагыйрьләренең бөтен бер плеядасын атап чыгарга мөмкин.

Әмма шушы ук урында художестволы эшкәртү өчен хәзерге заман материалының кыенрак, катлаулырак булуын әйтү фарыз. Материал каршылыгы дип аталган нәрсәнә без монда аеруча кискен тоябыз. Җөмләдән, шул нәрсә гаҗәп түгел, хәзерге яшь шагыйрьләр, сугыш вакытын хәтта китаплар буенча гына белгән иң яшь дигәннәре дә, сугыш темасында сизелерлек уңышка ирешсәләр, бүгенге көнгә кайткач, күпчелек очракларда рационализмга, ә начаррак хәлләрдә җиңел эстрада дулкынына бирелеп китәләр. Аларны укыганнан соң, үз иҗатларында сугышчы характерын саклап калган, үз сүзләрен тынычта да сугыш еллары хакында язгандагы шикелле үк энергияле итеп әйтә алган шагыйрьләрнең әсәрләренә хөрмәт икеләтә арта. Күпчелегебез белән бергә, алар өчен дә сынаучыл тема КамАЗ темасы булды дияр идем. Х. Камалов, С. Хәким кебек шагыйрьләр Кама киңлекләренә сугышчылар юлыннан килеп чыктылар.

Үзенең «Язмыш елмаюы» исемле яңа поэмасында Х. Камалов безне кызыклы вакыйгалар һәм характерлар белән таныштыра. Шагыйрь әле, ихтимал, үзенең барлык вакыйга һәм идеяләренә ачык һәм төгәл формалар биреп бетерә дә алмагандыр, алар хакында бәлки тагын да уйлана төшәргә, кайбер моментларны яңадан хәл итәргә дә ярыйдыр. Әмма әсәрнең сугышчан рухы күрәшкә омтыла һәм аренага чыга. Тормыштагы әйбәт яки гыйбрәтле күренешләргә бәя биргәндә проблемалар аша килүе, кеше хисләренең табигыйлеге, тирәнлеге белән әсәр укучы игътибарын җәлеп итәр дип ышанам.

С. Хәкимнең «Дәверләр капкасы» поэмасында да жанр мөмкинлекләрен баета торган яңалык сизелә, аерым алганда, бу әсәрдән аның авторына хас уйчан лирика трибуна интонациясе, туры, үтә күренмәле публицистика белән кушылып китә. Лириканың шулай публицистика белән органик кушылмасын тудырган шәп үрнәкләрне безгә шагыйрь Ә. Давыдов калдырды. Аның поэмаларында һәм иң яхшы шигырьләрендә язучының кайнар йөрәк тибеше әле дә ишетелеп, сизелеп тора. Сугыш еллары хакында шушы мәгънәдә уңышлы әсәрләр язган И. Юзеев, М. Шабаев, Ш. Галиев һәм кайбер башка шагыйрьләрдән без заман материалында шундый ук тәэсирле әсәрләр көтәбез икән, бу, минемчә, бик законлы теләк. С. Хәким, Ә. Давыдов, Х. Камалов кебек шагыйрьләрнең яхшы үрнәге нәкъ менә шунда бит — алар үзләренең күрәшче характерларын заман тормышында күрсәтә алдылар, үзләренең күләмле әсәрләрендә бүгенге һәм киләчәк әдәбиятка хас булган проблемачылык стадиясенә керделәр.

Шундый чакларны хәтерлибез — иске тормышка карата «юк!» дип, кискен сүз әйтү зарур заманнар бар иде. Соңынтын — яңача яшәү рәвешен раслар өчен бөтен тавышка «әйе!» дип кычкыру зарурлыгы килеп чыкты. Социалистик яшәү рәвеше тормышта, миллионнарча кешеләр акылында һәм характерында ныклап урнашкач, инде бу сүзләрне еш кабатлау гына җитми башлады. Тормыш безнең алга гаять күп яңа бурычлар куя һәм, алга барышны әкренәйтмәс өчен, тагын да югарырак күтәреләр өчен, безгә гаять тә күп яңа мәсьәләләр чишәргә, кыенлыклар, киртәләр аша үтәргә туры килә. Экономик тормышта, хуҗалыкта шулай эшләнә дә — заманның гаҗәеп катлаулы проблемалары хәл ителә бара, моның өчен анда югары квалификацияле инженерлар, фәнни-техник революция чорына лаеклы белгечләр бар. Космик тизлеккә омтылган чынбарлыктан иҗатта артта калмас өчен безнең үзебезгә сугышчан пафослы булырга кирәк. Гаҗәп түгелдер, нәкъ менә шушы социаль катлаулы чорда ничектер Һ. Такташ авазын, Х. Туфанның шул чактагы сугышчан тавышын яңадан ишетәсе килә...

Заманыбыз акыл кыюлыгына исәп тота. Хәзер без иҗтимагый тормышта закончалыклар ачып сурәтләү, тормышның катлаулы һәм хәтәр тоелган проблемаларын куркусыз хәл итү юлы белән генә үзебезнең иң тәэсирле һәм җитди «әйе» дигән сүзебезне әйтә алабыз. Декларатив кычкыруларга урын юк хәзер. Язучыда сугышчан характер, гражданлык кыюлыгы булырга тиеш. Вак мәнфәгатьләр белән яшәсә, кеше мәгънәсез-идеясез әсәрләр яза. Мондый хәлдә бернинди техник хәйләләр дә файдага китми. Укучыга чын лирик поэзия, гражданинның рухи яшәү нәтиҗәсе буларак туган поэзия, социаль һәм кешелек психологиясенең үз асылыннан килә торган поэзия кирәк.

Моңарчы Татарстанның барлыгын да белмәгән (әйе, белмәгәннәр!) Париж газеталары КамАЗ хакында язалар. Ләкин әдәби әсәрләребез андый араларны кыенлык белән, яман да зур кыенлык белән генә кичә шул. Әдәбиятның экономикадан артта калуы чагыштырып караганда аермачык күренә, тик ул диссонансны законлы күренеш дип исәпләү мөмкинлеге һич тә күренми. Әдәбият индустриянең шигъри батырлыкларга рухландыра торган гаҗәеп биеклекләре белән бертигез югарылыкта булырга тиеш.

Максатыбыз — үсеш гармониясе.

# ЭШЧЕ КОЛЛЕКТИВ НИЧЕК ТУА

Шамил Бикчуринның бу әсәре тиз телгә керде. «Каты токым» романы[1] Владимир Чивилихин тәрҗемәсендә «Москва» журналында күренүгә[2] Россия Федерациясе язучылары союзының 70 нче еллар прозасындагы яңалык темасына багышланган киңәйтелгән пленумында тикшерелде, Татарстан язучыларының VIII съездында да Ш. Бикчурин романы соңгы еллар татар прозасында эшче темасын күтәргән әсәрләрнең уңышларыннан берсе дип билгеләнде.

Башыннан күпне кичергән, бишенче дистәсенә күптәннән аяк баскан, чирек гасыр әдәби хезмәт белән яшәп һәм басылып килсә дә, бөтен союз укучысына моңарчы бик аз билгеле булган язучының бу әсәренә шушындый зур игътибарны нәрсә белән аңлатырга соң?

Ш. Бикчуринның әсәре разведкачы бораулау бригадасының көндәлек хезмәте һәм тормышы хакында сөйли. Автор — Татарстан нефтенең үзәге Әлмәт районы Миңнебай авылында туып үскән кеше — үзе сурәтли торган чынбарлыкны бик яхшы белә. Ул күп еллар буе башта эшче, аннары нефть объектлары төзелешендә инженер булып эшләгән, инде күптәннән нефтьчеләр шәһәре Лениногорскида яши. Романдагы чынлык атмосферасы, ышандыру көче әнә шуннан килә, һәм аны әсәрнең беренче битеннән соңгысына чаклы тоеп торасың.

Автор нефть разведчиклары хезмәтенең үзенчәлекләрен, аларның урыннан-урынга туктаусыз күченеп йөрүләр, көн итүдәге көйсезлек, тәүлек буена вахтада торулар, тәэминаттагы төрле өзеклекләр белән бәйләнгән шактый чуар, тынгысыз, әмма романтика, хәтта поэзия дигән нәрсәдән дә мәрхүм булмаган тормышларын җанлы һәм табигый итеп күрсәтүгә ирешкән.

Ләкин ул үзенең максатын эшче профессиясе вәкилләреннән берсенең тормышын һәм хезмәтен сурәтләү белән генә чикләми. Максат зуррак һәм мөһимрәк — ул эшче коллективының ничек аякка басып, ныгып китүен күрсәтергә тырыша, аны күмәк эш, иҗтимагый хезмәт процессында шәхеснең рухи үсеше, кристаллашуы кызыксындыра. Һәм менә шушы ахыр максат әсәргә масштаблылык бирә, тирәнлек өсти.

Ш. Бикчурин романы эшче темасына язылган күп әсәрләрдән аерылып тора. Аның барлык персонажларны үз тирәсенә туплаган төп герое юк. Ул язмыш яки биография романы түгел, ә вакыйга романы. Әсәрнең үзәгендә баш герой урынында бөтен бер бригада хәрәкәт итә. Бригада эшчеләренең башкарган хезмәте: чираттагы скважинаны бораулау, авария һәм аннан чыгу вакыйгасы, уңышсызлыкка очрау, яңадан эзләнү һәм, ниһаять, җиңүгә ирешү, перспективалы яңа нефть ятмасын ачу — болар барысы бергә сюжетны хәрәкәт иттерүче пружина вазифасын үтиләр.

[1] Шамил Бикчурин. «Каты токым». Роман, Татар телендә. Казан. Татарстан китап нәшрияты, 1974 ел.
[2] «Москва» журналы. № 2—3, 1974 ел, Вл, Чивилихин тәрҗемәсе.

Роман нефть эзлэүче бригаданың яңа «ноктага» күчү күренешеннән башлана. Эчке монологтан файдаланып, автор бригададагы һәр кешенең шәхси уйларын, кычкырып сөйләнми торган план-ниятләрен ачып бирә. Һәм шунда гаҗәпкә калдырырлык бер нәрсә билгеле була: монда беркем дә диярлек үз эшеннән канәгать түгел икән, мастерны да, бер-берләрен дә өнәп бетермиләр, һәркайсы диярлек бригададан китү уе белән йөри. Берәве укырга, белемен күтәрергә тели, ләкин туктаусыз күченүләр хәтта урта мәктәпне тәмамларга да мөмкинлек бирмәгән. Икенче берәү спорт ярата, ярышларда катнашу түгел, күнегүләр ясарга да шартлар булмавына эче поша. Өченчесе туган якларын сагына. Дүртенчесе, Мотгәрәй дигәне, күптән түгел мактаулы комбайнчы булган, тик председатель белән ачуланышып, колхоздан китеп барган. Ә яңа эшкә һич тә күңеле ятмый...

«Чегән тормышы» итәк куру белән күзе майлана торган Фәрхетдингә ошаса ошый. Ул әнә егерменче кешә итеп блокнотына «чираттагы корбанының» исемен язып куйган. Аңардан кала, тагын казакъ Үскенбаев эшеннән канәгать: ул тырышып калым жыя һәм алачак хезмәт хакы белән генә кызыксына. Мастер Зөбәеровка шомлалык урын бар. «Санап карасаң, бер төпле кеше дә юк бит бригадада. Берсе дә торырдан, эшләрдән түгел»,— дип уйлый ул.— Түзә алмам. Исән-имин Язтургайдагы скважинаны тәмамласам, ташлыйм барысын к чорту! Китәм Ибраһим-задә янына... керәм үзенә гади бораулаучы булып, эшлим кайгы-хәсрәтсез...»— дип ният кора.

Романдагы вакыйгалар 50 нче еллар башына, Татарстандагы нефть ятмаларын үзләштерүнең башлангыч чорына туры килә. Ул вакытта тәҗрибәле нефтьче кадрлар да, куәтле техника да җитешми, транспорт-мазар да азрак иде. Бригаданы төзегәндә Зөбәеровка сайланырга мөмкин булмады, кеше аз иде, кайда кем туры килсә, шуларны җыйды. Бригада белән без иң киеренке бер чорда очрашабыз: я нәрсә булса да булып калачак, я бригада таралып китәчәк. Әсәрдә драматизм, вакыйга киеренкелеге шулай туа һәм бу киеренкелек ниндидер ясалма алымнар, тышкы эффектлардан башка да укучыны кызыктырып, күңелен тартып тора.

Язучы кумәк хезмәт процессында, авырлыкларны бергә күтәрешеп, бергә кичереп атлаганда кешеләрдә бер-берсенә ышаныч ныгуын, ихтирам хисе уянуын, элек яшеренеп яткан потенциаль мөмкинлекләр ачыла барып, шәхеснең яңа сыйфатлар белән баюын төгәл һәм ышандырырлык итеп күрсәтә.

Романда шаккатырырлык вакыйгалар юк. Хәтта катламда инструмент кысылып калу кебек авария дә ниндидер гадәттән тыш вакыйга буларак түгел, ә нефть эзләүчеләр тормышында еш кына очрый торган бер күңелсез хәл итеп тасвирлана. Һәм тормыш шартларының нәкъ менә шушындый гадилеге эшчеләр коллективында яшәүче һәр кешенең күңелендә үсә барган рухи үзгәрүләрнең мәгънәсен тирәнәйтә.

Автор әсәрендә кагылып киткән проблемаларның берсе — коллектив һәм җитәкче проблемасы. Мастер Зөбәеров бригадада эшне тәртипкә салу өчен бөтен күңелен биреп тырыша. Ләкин аның әле тәҗрибәсе аз. Шунлыктан үзенең укытучысы, бораулау остасы төркмән Ибраһим-задәнең гадәтләренә, аның эш стиленә иярә, Ибраһим-задәнең чын мастер «кыядан каты, таудан биек» булырга тиеш, дигән сүзләрен кабатларга ярата. Ләкин бригада членнары бу ясалмалылыкны, аның үз кул астындагы кешеләр белән мөгамәләсендәге фальшьны, әлбәттә, сизми калмыйлар. Безнең заманның социология теле белән әйткәндә, Зөбәеров әлегә формаль лидер, формаль җитәкче генә. Чын лидерлыкны яулап алу өчен аңа бик күп көч сарыф итәргә туры килә.

Бу процесста мастерның хатыны Рәйсә үзенә күрә бер «катализатор» ролен уйный. Көннәрнең берендә имчәк баласын күтәргән килеш ул ире янына, җилләр уйнап торган палаткага килеп керә, башта җәйге ял вакытын үткәргәнче генә дисә дә, шунда торып та кала. Хатын-кызга хас сизгерлеге һәм күзәтүчәнлеге белән ул бораулап үтелгән метрлар саны, план күрсәткечләре аша ире күреп бетермәгән нәрсәләрне дә күрә башлый. Сак кына, җай белән генә ул аны кешеләр белән яхшырак мөгамәлә итәргә, игътибарлырак булырга, аларның ихтыяҗларын якыннан белеп торырга өйрәтә. Рәйсә монда яши башлаганнан бирле буйдак ирләр сүзне үлчәбрәк әйтә, тышкы кыяфәтләренә игътибарлырак була башлыйлар. Коллектив эчендәге атмосфера үзе үк ничектер җылынып, ямь кереп киткән төсле була.

Бу җәһәттән казакъ егете Сапарбай Үскенбаев вакыйгасы бик характерлы. Ул тик

бер максат — калымга түләнергә тиешле кырык-илле мең сумны (иске акча белән) тизрәк җыю теләге белән яши, икешәр смена рәттән эшли, тамагын да кыса, киемсалым да алмый, ике ел инде тиешле ялын да файдаланмый. Мастерны бу хәл өлла ни борчымый — эшен әйбәт башкаргач, шул җитмәгәнмени? Әмма Рәйсә ирен егетне отпускага, кәләше янына җибәрергә күндерә. Мастер бу эшкә бик авырсынып кына ризалык бирә, чөнки болай да кеше җитми, аннары ул Үскенбаевның кире кайтуына да ышанып бетми. Ләкин, озак та үтмәстән, Сапарбайга дигән кәләшнең өлла кайчан ниндидер офицерга ияреп китеп барганлыгы, хәйләкәр туганының, «калым» дигән булып, моңардан акча суырып ятканлыгы мәгълүм була. Сапарбай бригадага кире кайта һәм, ни гаҗәп, хәзер аны хезмәт хакына чыккан акча суммасы түгел, ә бораулауның барышы кызыксындыра, ул бергә эшләгән һәм тугандай якын булып әверелгән иптәшләрен сораша.

Кадерматнең рухи дөньясында да җитди үзгәрешләр бара. Ул кайчандыр хаксызга рәнҗетелгән авыр язмышлы кеше. Характеры белән кызу канлы, төксерәк булса да, үз эшен бик шәп белүче һәм җиренә җиткереп башкаручы кеше буларак ачыла бара, бригада каршында ихтирам яулый. Мастер Зөбәеровның да кешеләр белән эшләү стиле сизелерлек үзгәрә.

Алка композициясе методы буенча яңа «ноктага» күчү күренеше белән тәгәлләнүче романның ахырында без тагын әсәр геройларының эчке монологлары белән очрашабыз. Кешеләре шул ук һәм шул ук түгел дә. Бергә эшләгән айлар, бергә кичергән авырлыклар, җиңү шатлыгы эзсез югалмый. Әйтик, эшчеләрдән берсе Нәҗип элеккечә үк укырга китү турында хыяллана, Еланскийның да спорт белән саташуы кимемәгән. Әмма коллективизм тойгысы, бер-береңә ышану, зур һәм мөһим эштә үзеңнең кирәклегеңне тою хисе өстен чыга.

Мастер Зөбәеров элеккечә үк үз-үзеннән канәгать түгел, ләкин шулай да бригадасындагы кешеләр турында алай күңелсез һәм начар уйламый. Хәер, бригада кешеләре дә Зөбәеровның Ибраһим-задәдән ким түгеллеген аңлаганнар инде; әйе, ким түгел, әмма бөтенләй башка кеше ул.

Шулай итеп, кешеләрнең аңында барлыкка килгән үзгәреш, рухи һәм әхлакый үсеш процессы авторның игътибар үзәгендә тора. Күңелләрдә бара торган шушы рухи хәрәкәт, шушы яңару очраклы рәвештә бергә туры килгән чуар төркемне уртак максат өчен көрәшүче бердәм хезмәт коллективы итеп берләштерә. Авторның уңышын мин, барыннан да бигрәк, шушы коллективның психологик яктан дөрес булган, социаль яктан гомумиләшкән, һәм шул ук вакытта индивидуаль-анык портретын тудыруда күрәм.

Дөрес, күңелдә канәгатьсезлек хисе калдыручы моментлар да романда юк түгел. Әйтик, Тин-Тинычның Валяга мәхәббәтен сурәтләгән битләр миңа ясалма булып тоелды. Миңа калса, элекке диңгезченең «Огонек» тышлыгында күргән кыз рәсеменә гашыйк булып йөрүен автор артык җитди төсләрдә күрсәтә. Тин-Тинычның шул «хыял кызын» нефтьчеләр слетында очраклы рәвештә очратуы кебек күренешләр бик үк ышандырмый. Гомумән дә, бу мәхәббәт тарихына шул дәрәҗәдә үк җитди карау, күңелне артык нечкәртү урынсыздыр. Ул җиңел елмаю гына тудыра. Романның ахырына таба автор төрле кытыршылыкларны шомартырга, язмышларны бизәргә ашыккан. Монда алдан уйланган максатка ансат һәм җиңел генә ирешергә омтылу үзен сиздереп куя.

Әсәрнең прозаик Владимир Чивилихин тарафыннан башкарылган русчага тәрҗемәсен татарча нөсхәсе белән чагыштырганда, тәрҗемәченең үз вазифасын җаваплы һәм намус белән үтәгәнлеге күренә. Тәрҗемә төп нөсхәгә бик якын — формаль яктан түгел, ә стиле, эчке рухы белән, эшлекле, бераз сүлпән дип әйтерлек, тышкы яктан битараф тоелган хикәяләү манерасы белән якын. Урыны-урыны белән тәрҗемәче ике-өч фразаны бергә куша, абзацларны кыса, башка очракларда, киресенчә, кайбер психологик нигезләү-исбатларны ачыклый төшәргә, киңәйтергә тырыша. һәм моны мин тәрҗемәченең үз-үзенә артык ирек бирүе димәс идем.

Авторлыкка нигезләнгән тәрҗемә иң яхшы дигән үрнәкләрендә автор белән үзенә бертөрле иҗади хезмәттәшлеккә әверелә. Талантлы тәрҗемәче (әгәр ул бу очрактагы кебек танылган һәм үзенчәлекле каләм иясе булса, бигрәк тә) әсәрне бер телдән икенчесенә күчерүче булып кына калмый, авторга файдалы киңәшләрен дә бирә, аерым төзәтүләр кертә, әсәрне тиешле дәрәҗәгә җиткерергә

булыша. Мәсәлән, татарча вариантта Мотгәрәй бригадада бөтенләйгә кала. Тәрҗемәдә исә ул үзенең характер логикасына тугрылыклы һәм бөтен әсәргә ярашлы рәвештә, сөймәгән эшен ташлап колхозына кайта.

Шулай ук Тин-Тиныч һәм Валя линиясе дә тәрҗемәдә табигыйрак бер төс ала. Авторның ризалыгы белән эшләнгән һәм әсәрнең тәэсир итү көчен үстерә торган мондый үзгәрешләрне хупларга гына мөмкин. Бу үзгәрешләр вакыты белән әсәрнең татарча вариантына да кирәр дип уйлыйбыз.

Тагын шул: «Мәскәү» журналы редакциясе һәм тәрҗемәче әсәрнең русча вариантын дөньяга чыгаруда мактауга лаек өлгерлек күрсәткәннәр. Тәрҗемә рус укучыларына романның журнал варианты басылып чыкканнан соң ел ярым эчендә һәм әсәрнең туган телендә китап булып чыгуы белән бер үк вакытта килеп җитте. Гадәттә бу ике арада 2—3 ел үтә һәм вотылгысыз дип исәпләнелә, ә кайвакыт ул исә 5—6 елга сузыла иде. Ни әйтсәң, роман мондый өлгерлеккә тулысынча лаек.

**РАФАЭЛЬ МОСТАФИН.**

# АЧЫКТАН-АЧЫК

**Мәхмүт Хәсәновның «Кама таңнары» романында төп герой — инженер Имам Хисамович Котдусов. Мин аның белән күңелемнән фикер алышу үткәрдем.**

**Тәнкыйтьче.** Роман турында сөйләшүне башлаудан элек, мин сезгә шундый сорау бирер идем. Әсәр, белгәнебезчә, беренче заттан язылган. Ягъни сезнең исемнән. Язучы һәм сезнең арадагы бердәмлек, тәңгәллек баштан ахыргача сакланамы?

**Инженер.** Бөтенләй юк дисәм ялгыш булыр. Образның кешелекле, гуманистик ягын күрсәтүдә язучы мин була алган. Ә инженер буларак ача алмаган. Производство сферасыннан иң мөһим вакыйгаларны табып ала алмау сәбәпле, язучының уй-нияте тормышка ашмаган.

**Тәнкыйтьче.** Язучының сезне, төп эш урыныннан аерып, өзлексез командировкаларга йөртүе шуннан киләдер дә...

**Инженер.** Эрудицияле, зур масштаблар белән эш иткән җитәкче-инженер образлары әсәрдә тиешле биеклеккә күтәрелми. Романда күп урын биләгән Вәгыйз Гайнанов образының да язучы бүгенгесенә караганда үткән тормышын сөйләп чыгу белән мавыга. Шуңа күрә дә ул ярдәмче персонаж булып кына кабул ителә...

**Тәнкыйтьче.** Ике инженер арасындагы производство мәсьәләләренә караган конфликт күп әсәрләрдә кабатланган шаблон дип карамыйсызмы?

**Инженер.** Бер карашка бу шулай сыман, әмма мәсьәләгә нинди аспекттан килсәң бит. Нигезле, тирән анализланган яңа эчтәлекте бу тышкы форманы үзгә яңгырашта ачарга булыр иде. Әхсән Баяновның «Ут һәм Су» романында мондый конфликт, характерләр бәрелеше үзенчәлекле ситуацияләрдә бирелә шикелле.

**Тәнкыйтьче.** «Кама таңнары»нда Колун яңа эш ысуллары кертүгә каршы чыга. Сезнең арада бу мәсьәләдә бәрелеш тә булып ала. Колун — тәҗрибәле инженер, зур пост биләп тора. Әгәр ул яңалыкка каршы чыга алган икән, димәк, элекке алымнарның файда китерәчәгенә инанган. Аннан соң, ул белеменә, үз-үзенә нык ышанган кеше. Әгәр ул сәләтсез булса, яңа ысулларны инкарь итеп, үзен фаш итүдән ерак торыр иде. Романда бу ачыкланмый. Колун кешеләр өстеннән гаеп эзләп йөрүче һәм ахырдан тезелештән китәргә мәҗбүр булган вак шәхес дигән тәэсир калдыра.

**Инженер.** Әйе, яңалык өчен, социаль проблемаларны чишүдә актив көрәшче, үзенең тоткан урынын, иҗади мөмкинлекләрен белгән зур шәхесләр күрергә теләр идем мин романда. КамАЗ әлегә төзелү стадиясендә. Анда — хәрәкәт, дәвыллы романтика. Производство темасын күтәргән

роман әнә шул хәрәкәттәге бүгенгене, төзелешнең романтикасын, аны төзүчеләрнең психологиясен, тормыш фәлсәфәсен калку да, тирән дә итеп чагылдырсын иде.

**Тәнкыйтьче.** Әсәрдә уңышлы гына язылган бүлекләр бар. Һәдия — тол хатын, ике бала анасы. Уртак кайгы сезне таныштыра. Урта яшьләрдәге ир белән хатын арасындагы кешелекле мөнәсәбәт, сабыр мәхәббәт әзлекле үсештә, ышандырырлык итеп тасвирлана.

**Инженер.** Миңа әсәрнең бер бүлегендә күренеп кенә киткән Кәримулла карт образы ошый. Язучы аның портретын художникларча бирә. «Карт бик бетерешкән. Еллар үзенекен иткән. Җиткән сакал-мыеклары чаларып кына да калмаганнар, күк күгәрчен канатына охшап торалар. Кояшта янган кара-кучкыл муены әле генә сөреп ташланган җиргә охшап, буразналанып беткән».

**Тәнкыйтьче.** Мин аны, тамырларын тирән җибәргән, давылларга, тетрәүләргә бирешми торган йөзьяшәр имәнгә охшатам. Картның туган җирендә кузгалган төзелешкә карата үзенчә фикере, гомානлавы табигый. Һәм ул аны сезгә, төзелеш каһарманына, бигрәк тә авылдашына, җиткерми калмас иде. Сезне табигатьнең үзгәрүе дә, төзелеш пафосы да сокландыра. Ә картның мөнәсәбәте үзенчә бит. Менә шуны язучы тотып ала алмаган. Мин моны укучы буларак әйтәм. Укучы романны үзенчә күрә, вакыйгаларны күңелендә дәвам иттерә бит. Аннан соң улыгыз Ислам, латыш егете Янис белән сезнең очрашу моментына тукталасым килә. Алар икесе дә яшь галимнәр. Өстәл артында ике буын арасында зыялыларга хас фәлсәфи бәхәс, фикерләр уртаклыгы янсә бәрелеше булырга тиеш иде. Укучы шуны көтә, әмма автор өстәлгә килгән ашамлыкларны тәфсилләп күрсәтү белән мавыга һәм геройларны тизрәк өстәл яныннан торгыза да табигать кочагына алып чыгып китә.

**Инженер.** Килешәм. Әлбәттә, язучы Кама буе табигатен, анда ял итү күренешләрен уңышлы гына чагылдыра. Мәхмүт Хәсәновның кызык кына, тормышчан детальләр тотып алырга да маһирлыгы бар. Ләкин бу романдагы тормыш материалы КамАЗ төзелеше ритмы белән яраша алмый. Ягъни минем тормыш КамАЗда түгел, ә бөтенләй чит җирдә бара сыман. Роман кебек, киң диапазонлы әсәрдә үзәк герой берничә аспектта бирелергә тиеш: аның эше, тоткан урыны, кешеләр белән мөнәсәбәте, шәхси тормышы, эчке дөньясы. Шушы яссылыклар гармониядә булмаса, мин тулы җанлы геройны күз алдына китерә алмыйм.

**Тәнкыйтьче.** Сез әйткән аспектларның булырга тиешлеге чагыштырмача гына. Эчке дөньясы, рухи халәте аша да геройны төрле яклап ачарга мөмкин. Сәнгать әсәрендә сурәтләү предметы — кеше. Образның эчке дөньясы абстракт түгел, ә конкрет җирлектән, үзен чолгап алган тирәлек тәэсиреннән туа.

**Инженер.** Сез романдагы үзәк геройның шәхси, семья тормышын күрсәтү белән язучының артык мавыгып китүен акларга җыенмыйсыздыр бит?

**Тәнкыйтьче.** Юк, җыенмыйм. Мин бары зур гомумиләштерүләргә илтә торган фәлсәфи романнарның үзенчәлекләрен күз алдында тотам.

**Инженер.** Мин дә производство романнарында фәлсәфә алымы булмаска тиеш димим. Бу әсәрнең үзәгендә мәһабәт төзелешнең сулышы, пафосы, асыл проблемалары булырга тиеш иде. Язучы шулар аша фәлсәфи фикер күтәрә ала икән — мин килешәм.

**Тәнкыйтьче.** Проблема дигәннән, яңа төзелешләрдә алар бихисап. Язучыдан шуларны гомумиләштерә белү, үзәген тотып алу һәм проблеманы дәвамлылыкта күрү сорала да. Чөнки вакытлы проблемага корылган әсәр проблема хәл ителүгә үк кыйммәтен югалта, архивта урын ала. Төзелеш конфликты, төзелеш проблемасы белән бергә, кеше күңеленең диалектик үсеше бер рухта, бер югарылыкта бирелсә генә, әсәр яшәүчән һәм актуаль була. Мәхмүт Хәсәнов әсәрендә әнә шул җитми дә. Зур төзелешләргә без инде күнегеп тә барабыз шикелле. Ләкин һәр төзелеш үзенчә яңа: максаты белән, масштабы белән, кешеләре белән. Җитмешенче еллар төзүчесе — коммунистик җәмгыятьнең гуманистик идеологиясе белән коралланган, белемле, максатын ачык аңлаган фидакарь кеше. КамАЗны әнә шундый кешеләр төзи. Бүгенге төзелеш эпопеясы романнарда, көндәлек матбугатта, кинофильмнарда, поэмаларда калыр. Килер буыннарга бүгенгене нинди рухта, нинди югарылыкта илтә алабыз — бу сәнгать кешеләренә нык бәйле.

**Инженер.** Әйе, язучы өстенә җитди һәм авыр миссия йөкли торган бурыч бу. Кешенең формалашуына нинди генә фак-

торлар этәреш бирми. Урман, таулар... Табигать. Кеше күңелендә никадәр хыял, фәлсәфә тудырган алар. Кеше таулар каршында бик кечкенә булган. Тауларга ул сокланып та, үртәлеп тә караган. һәм... «тауларны» үзе төзергә керешкән. Зур төзелешләр ансамбле эчендә кеше үзен кечкенә итеп тоя алмый. Чөнки ул бу панораманы үз куллары белән төзи, торгыза. Шуңа күрә дә ул рухи яктан көчле. Горький әйткәнчә, «Кеше — горур яңгырый!» Мин бүгенге производство романнарында нәкъ шундый кеше образын күрәсем килә.

**Тәнкыйтьче.** Прогресс дибез, катлаулы бөек вакыйгаларга бай чор дибез. Ә прозадагы геройлар дәрәҗәләре, постлары белән генә югары күтәрелделәр. Дөрес, язучыларыбыз үз геройларының профессиясенә, эш процессына беркадәрле үтеп керә алдылар. Әмма әсәрләрдәге үзәк геройларның рухи дөньялары күп яктан ачылмаган утрау булып кала бирә.

**Инженер.** Профессия — киң төшенчә. Профессия ул — сине чолгап алган тирәлек, мохит, яшәү максаты, иҗат, тормышта үзеңне раслау дигән сүз.

**Тәнкыйтьче.** Мәхмүт Хәсәнов романында гына түгел, башка күп кенә прозаикларыбыз әсәрләрендә дә эш процессы берьяклы, фактографик сурәтләнә. Язучы үз объектын өйрәнгән, белгән, күргән булырга мөмкин. Ләкин ул аны йөрәге аша үткәреп, чын художестволы итеп бирә белмәсә, әсәр әдәби кыйммәтен югалта. Язучының принцибы: укучы күргәнне, белгәнне укучы күргәнчә, белгәнчә сурәтләү түгел, ә укучы тойган, сиземләгәнне яңа яктан ачып, анализда, бай иҗади фантазиядә бирүдә булырга тиеш.

**Инженер.** Сәләтле генә язучының да әдәби эшләнеше ягыннан түбән сыйфатлы әсәре дөнья күрә. Әсәрдән-әсәргә эзлекле үсә бармавы язучының сәләтенә генә бәйле микән?

**Тәнкыйтьче.** Моның беренче сәбәбе, язучының нык үзләштергән үз темасы булмауда, актуальлегенә кызыгып аның бер темадан икенче темага «сәлулап» йөрүендәдер. Безнең әдәбиятыбызда күренекле урын тоткан Г. Бәширов, Ә. Еники яки Н. Фәттах, А. Гыйләҗев иҗатларына күз салыйк. Аларның үз темасын һәр яклы өйрәнеп, баета барып, үзенчәлекле, тирән тормыш фәлсәфәсе ачкан әсәрләре моны расламыймыни? Сәләт дигәннән, шигырь китаплары чыгарып та шагыйрь була алмаган иптәшләргә тәнкыйть үзенең гадел, туры сүзен әйтте бит. Ә прозаиклар арасында андый һөнәрчеләр юкмыни! Ярый, автор күләмле әсәр язган, көч сарыф иткән, тырышкан дип әсәрне кабул итик тә ди. Ә Вакыт кабул итәрме? Мин Вакыт дигән төшенчә астында йөз елны түгел, әдәби кыйммәтен югалткан әсәрләргә хөкемдар булган биш-ун елны күздә тотам.

**Инженер.** Сез тема турында әйттегез. Классиклар иҗатына мөрәҗәгать итсәк, ул фикерегез бөхәскә урын калдыра түгелме? Мисал өчен Бальзакны алыйк. Нинди генә хезмәт кешеләре турында язса да, гаҗәп кызыклы үзенчәлекләрен күрә белгән. Кечкенә генә тормыш детален дә күңелендә тармакландырып, гомумиләштереп сәнгать дәрәҗәсенә күтәрә белгән.

**Тәнкыйтьче.** Билгеле бер темаң булу — бер төрле профессия кешеләре турында гына язу дигән сүз түгел әле. Тема, сез әйткәнчә, киң төшенчәне эченә ала. Әгәр Экзюпери әсәрләре очучыларның авыр, катлаулы хезмәтен чагылдыруга гына корылган булса, тавыш барьерын үткән бүгенге реактив самолетларда очучылар, астронавтлар заманында, ул әсәрләр тоныкланып калырлар иде. Экзюпериның иңләп алган темасы, поэзиясе киң планлы, ул сәнгатьчә югарылыкта бирелеше белән әһәмияткә ия. КамАЗда һәр язучы үз темасын табарга мөмкин. КамАЗ — зур дәрья. Киңлеген, тирәнлеген ачу өчен аңа каек булып түгел, ә кораб булып керергә кирәк.

**Инженер.** Заманча, интеллектуаль роман авторы, үз геройларын һәрьяклап чагылдыру белән бергә, социаль психологияне дә сәнгать чаралары ярдәмендә яктыртә алса, роман киң полотнолы чоръязма була алыр иде. Вакыйгалар сыйдырышлыгы ягыннан бүгенге роман жанры кысанланды шикелле.

**Тәнкыйтьче.** Жанрмы, әллә язучымы? Фикер алышуны тәмамлар алдыннан мин сезгә конкрет сорау бирер идем. Мәхмүт Хәсәновның «Кама таңнары» әсәрен жанр ягыннан ничек бәяләр идегез? Роман таләпләренә җавап бирәме ул?

**Инженер.** Әйтә алмыйм. Монысын инде белгечләр хөкеменә калдырыйк.

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ

# МУЛЛАНУР ВАХИТОВ һӘМ СӘИД ГАБИЕВ

Прогрессив максатларның бердәмлеге, җәмгыятьне үзгәртеп коруга омтылыш татар һәм Дагстан халыкларының алдынгы вәкилләре арасында да тыгыз бәйләнеш тудырды. Иҗтимагый үсешнең барлык этапларында алар бер-берсе белән янәшә, илебезнең башка халыклары белән бер сафта булдылар. Моны раслаучы фактлар бихисап. Мәсәлән, татар халкының танылган улы, турылыклы ленинчы-большевик Мулланур Вахитов белән Дагстанның күренекле вәкиле, мәгърифәтчесе һәм матбугатның революцион-демократик органнары нәшире Сәид Ибраһим улы Габиевның (1882—1963) иҗтимагый-политик эшчәнлеге шундый фактларның берсе.

Тугандаш халыкларның ике вәкиле, ике революционеры, ике көрәшчесе тормышында һәм эшчәнлегендә уртак яклар бик күп.

Аларның иҗтимагый эшчәнлеге революцион хәрәкәтнең бишеге булган Петербургта башланды. Россия һәм революция үзгәнә килгәндә аларның икесенә дә егерме ике яшь була. Монда алар белем алалар һәм революцион эш белән шөгыльләнә башлыйлар.

Мулланур Вахитов белән Сәид Габиев тормышыннан берничә мәгълүмат китереп үтик.

1907 елда Казанда реальное училищены тәмамлагач, М. Вахитов Петербургтагы политехник институтка укырга керә. Уку дәверендә ул Петербургның төрле вузларында укучы, патша Россиясенең төрле почмакларыннан килгән төрле милләт студентлар белән элемтәгә керә. 1910 елда революцион эше өчен институттан куылгач, Казанга кайта һәм пароходчылыкта тикшеренүче булып эшли. Монда ул тулысынча революцион эшкә бирелә. «Урындагы большевистик оешма җитәкчелегендә мөселман халкы арасында эш алып бара: большевиклар партиясе лозунгысын аңлата»[1]. Моның өчен ул Мөселман социалистлар комитеты органы булган «Кызыл байрак» газетасын файдалана.

1918 елның гыйнварында М. Вахитов Милләтләр эше буенча Халык Комиссариаты каршындагы Үзәк Мөселман Комиссариат комиссары итеп билгеләнә һәм турыдан-туры В. И. Ленин җитәкчелегендә эшли. Шушы ук елның 18 августында Мулланур Казанны басып алган ак гвардиячеләргә каршы көрәштә һәлак була. Хәзер Казандагы урам, клуб, мәктәп, химия комбинаты шушы ялкынлы революционер исемен йөртә.

Күп милләтле Дагстан халкы Совет власте өчен үз революционерлары белән актив хезмәттәшлек иткән кыю большевик М. Вахитов истәлеген олылап искә ала.

С. И. Габиев Петербург университетына 1904 елда укырга керә. Монда ул күпчелек югары уку йортларының студентлары белән нык элемтәдә була, күпләр белән хат алыша, студентларның революцион хәрәкәтендә һәм 1905 елгы баррикада сугышларында актив катнаша[2]. Шулар өчен ул патша власте тарафыннан күп тапкыр эзәрлекләнә. Университетны җиде елдан соң гына, 1911 елда, тәмамлавы да шул турыда сөйли.

Университет тәмамлагач, Сәид Петербургта кала һәм газета чыгара башларга омтылыш ясап карый. Газета аша ул милли окраиналардагы халыкның хәлен чагылдырырга, крепостнойлык калдыкларына каршы хәлиткеч көрәш алып барырга исәп итә. Ахыр чиктә ул «Дагстан таңы», соңрак «Мөселман газетасы» чыгару өчен рөхсәт алуга ирешә.

«Дагстан таңы»ның беренче саны 1912 елның 28 февралендә чыга. Монда газетаның программасы игълан ителә: 1. Илдәге барлык халыкларның тугандаш союзы.

---

[1] «Зур совет энциклопедиясе», 2 басма, 7 том, 61 бит.

[2] Даг. АССРның ҮДА. Р-ф 808, I билгеләмә, Саклау берәмлеге I, 1 бит.

2. Рухи һәм культура элемтәләрен киңәйтү. 3. Барлык милләтләрнең һәм халыкларның тигез хокуклылыгы. 4. Искелек калдыклары белән көрәш. 5. Балаларны алдынгы педагогика нигезендә укыту һ. б.

Программада җәмгыять строен революцион юл белән үзгәртеп кору турында сүз әйтелмәсә дә, газетаның бөтен эшчәнлеге шуңа юнәлтелгән була. Чыккан газеталарның эчтәлеге шуның дәлиле [1]. Редакторның тәмамланмый калган «Халыкка» исемле повесте да шул турыда сөйли. Патша власте тарафыннан бу повесть самодержавие строен какшатуга юнәлтелгән фетнә тудыручы әсәр дип бәяләнә.

«...Авторның санап үтелгән сүзләре халыкны гамәлдәге дәүләт строен бәреп төшерергә, шуның өстенә көчләү юлы белән бәреп төшерергә котырта («үлем җәзасыннан курыкмыйча, без халыкны уятырга тиешбез» һ. б.). Ә бу инде закон нигезендә хөкем итәрлек эшләр» [2] дип язган матбугат эшләре буенча С.-Петербург комитеты председателе С. Габиевны судка биргәндә.

Газета чыгару һәм аны тарату өчен сәләтле кешеләр кирәк була. Шуңа күрә Сәид Габиев үз тирәсенә милли окраиналардан килгән талантлы яшьләрне туплый, демократик газетаны чыгаруда ярдәм сорап танышларына һәм дусларына хатлар яза.

Габиевның дуслары үзләренең хатларында аңа теләктәшлек белдерәләр һәм игелекле эшендә ярдәм күрсәтергә вәгъдә итәләр. М. Вахитовның С. Габиев белән хат алышуы шуны раслый.

«Кадерле Сәид! — дип яза Мулланур үзенең бер хатында.— Бернигә көн элек бер-бер артлы синең ике хатыңны алдым. Соңга калып булса да, һәрберсенә җавап бирергә ашыгам. һәртөрле хәбәрнең миңа шатлык булуын әйтәсе дә юк. Әмма сине 120 статья нигезендә хөкемгә тартулары турындагы хәбәр мине дә, М. Расул белән Рәҗәптән башлап, сине ихлас күңелдән яратучы барлык дусларыңны да кайгыга салды. Сиңа нинди дә булса сизелерлек ярдәм күрсәтә алмавым да хәсрәтләндерә. Синең хәлеңне бик яхшы аңлыйм: бер яктан администрация, ә икенче яктан мәкерле һәм кабахәт кешеләр... Бәлки безгә бу каһәрләнгән, мимозалар белән йогышланган, үзләре кебек мәхлукларның назы һәм бер стакан чәе өчен данлы Дагстанның барлык горур табигатен алмаштыручы хәшәрәтләр һәм микроблар мыж килеп торган сазлыктан фикер алга һәм югары, якты көнгә омтылган яхшырак якка чыгарга мөмкин булыр.

Йогышлы пычрак авырулар һәм мәкерләр сазлыгы белән бәйләнештә булу безне бик тә туйдырды. Ә без синең киңәшләреңне тотарбыз, көчтән килгәнчә һәм аң җиткәнчә сиңа ишкәкләреңне ишәргә ярдәм итәрбез, әмма калышмабыз. Синең көймәңнән артка чигенмәбез.

Сез безне газетагызны таратуның техник ягы белән таныштырсагыз иде. План булмаганлыктан, мин һәм минем дусларым ихтирам казанган газетагызны тарату мөмкинлегеннән мәхрүмбез» [1]. (Монда сүз «Мөселман газетасы» планнары турында бара, күрәсең — С. А.)

Тәнкыйть мәкаләләре һәм «Халыкка» исемле повесть бастырганы өчен Петербург суд палатасы карары белән «Дагстан таңы» газетасы 1913 елның сентябрендә ябыла. Бу газета белән бергә С. Габиев 1913 елның языннан «Мөселман газетасы» да чыгара торган була. Бу газета да Россиянең изелгән халыкларын яклап чыга.

С. Габиев «Правда» газетасында чыккан публицистик мәкаләләрне «Мөселман газетасы»нда да бастыра. Моның белән ул җәберләнгән массалар интересын яклый, ерак Австриягә француз капиталисты алдап киткән башкортларның хәлен уртаклаша, Милюков әфәнделәрнең, Дагстан губернаторы Вольскийның ялганын һәм икейөзлелеген фаш итә һ. б. [2].

«Дагстан таңы» кебек үк, «Мөселман газетасы» да эзәрлекләнә һәм аңа да штрафлар салына. М. Вахитовның икенче бер хаты шуны раслый.

«Хөрмәтле Сәид әфәнде! Сезнең җәмәгать эшегездә никадәр теләктәш булуымны практик формада әйтеп бирергә көчем җитмәүне тоеп, минем йөрәгем сыкрый. Сезнең телеграмманы алгач, мин иптәшләрем янына ашыктым, әмма бушка... Бу юлларны язып, мин җәмәгатьчелекнең аз гына булса да Сезне яклавына ирешү бурычын өстемнән төшермим. Шушы максатлар өчен мин Фатих Әмирханга мөрәҗәгать иттем инде. Минем теләгемне үтәп, ул үзе чыгара торган «Кояш» газетасында

[1] Газетаның егерме саны чыга. Алар Ленинградта Салтыков-Щедрин исемендәге дәүләт китапханәсендә саклана.
[2] Ленинградның ҮДА, Ф, 776, 10 билгеләмә, 464 эш, 22 бит.

[1] Даг. АССРның ҮДА. Р-ф 808. 1 билгеләмә, Саклау берәмлеге I. 35—36 битләр.
[2] «Мөселман газетасы», 1913, № 23.

«Мөселман газетасы»ның унынчы санына 300 сум күләмендә штраф салынуын җәмәгатьчелеккә җиткерергә вәгъдә бирде. Петербургтагы иптәшләремә дә язып җибәрермен. Минем сездән штрафны кайчан түләп бетерергә тиеш булуыгыз турында хәбәр итүегезне сорыйсым килә.

«Мөселман газетасы»ның 12 нче саны хакында да языгыз. Сезгә чын күңелдән теләктәш Вахитов Мулланурыгыз.

11 апрель, 1914 ел[1]».

М. Вахитов эшчәнлеге дусты С. Габиевны барлык нәшрият эшендә материаль һәм әхлакый яклау белән генә чикләнми. Ул чорның актуаль проблемаларына багышланган хәбәрләре, мәкаләләре белән дә «Мөселман газетасы»на катнаша. Моны без Мулланурның өченче хатыннан беләбез.

«Хөрмәтле Сәид әфәнде! Хатыгыз өчен тирән рәхмәтемне белдерергә ашыгам. Бу хатны укыганда минем күкрәгемдә иң татлы, иң ашкынулы өметләр уянды. Без яшәгән караңгы көннәрдә, бер генә күтәренке рухлы, дәртле өндәү авазы да ишетелмәгән авыр тынлык эчендә, халык мәгарифенең изге юлында сыналган хезмәткәрләрнең теләктәшлек авазы безгә әверүча кадерле. Тарихыбызның газаплы, җәваплы чорында, тормышның яңа формалары бик авырлык белән туып килгәндә, Сез культура өчен көрәш мәйданына аяк бастыгыз. Һәм, кешe рухының якты омтылышларына дошман булган кара көчләргә каршы кыю һәм ныклы рәвештә ташланып, аларны җиңүчән идеяләр кылычы белән кыйрата башладыгыз. Нурлы байрак Сезнең куллрыгызда югары торсын, яңа тормышның шат хәбәрчесе булган кадерле «Мөселман газетасы»на мөселманнар бәхете хакына язмыш якты киләчәк әзерләсен.

Башымда күп уйлар чуала, күкрәгемдә күп тойгылар кайный, ләкин хат рамкалары мине эш турында сөйләргә мәҗбүр итә. Әгәр ихтирам казанган газетагызның киләсе санында, 8—9 саннарда, «М. Г.» дип басылган минем мәкаләдә җибәрелгән мәгънә үзгәртә торган хатаны әйтеп үтүне мөмкин дип тапсагыз, минем рәхмәтем чиксез зур булыр иде...

«Фәннән киткәндә» дип басылган.

«Фән сарайларыннан киткәндә» булырга тиеш.

Мәкаләмне урнаштыруыгыз өчен Сезгә эчкерсез рәхмәт белдерүне үземнең бурычым һәм шатлыгым дип саныйм. Форма ягыннан йомшак булган бу мәкалә миңа эчтәлеге ягыннан әверүча кадерле, чөнки ул мин озак вакыт уйлап йөргән түгәрәк тормышына кагыла. Ниһаять, үткән елда гына профессор Жаковның һәм күпчелек иптәшләрнең теләктәшлегенә таянып, мин үземнең хыялымны гамәлгә ашыру мөмкинлегенә ирештем.

Сезгә изге эшләрегездә бик зур уңышлар теләп сезнең Мулланурыгыз»[1], — дип яза Вахитов.

Күргәнебезчә, монда М. Вахитовның бөтен эшлекле табигате аңа хас булган революцион энергия һәм кыюлык белән, үткән тормыштагы барлык черек һәм җирәнгеч нәрсәләргә нәфрәт белән, иҗтимагый тормышның яңа формалары бик авырлык белән булса да туып килүенә шатлык белән безнең алга килеп баса. Бу хатның беренче өлешендә автор С. Габиевның культура өчен көрәш мәйданына аяк басуын, дошман көчләргә каршы ныклы рәвештә ташлануын, аларны җиңүчән идеяләр кылычы белән кыйратуын, якты һәм хакыйкать алып килүче, «караңгы патшалыкта якты нур» булган кадерле «Мөселман газетасы»н бик сөеп характерласа, хатның икенче өлешендә рухи омтылышлары игелекле булган, массаларны явыз көчләр белән көрәшкә әзерләү өчен түгәрәкләр һәм берләшмәләр төзеп йөргән Мулланур үзе күз алдына килеп баса.

Ихтимал, ике тугандаш халыкның ике вәкиле арасындагы дусларча мөгамәлә бу өч хат белән генә бетми торгандыр[2].

1914 елда «Мөселман газетасы» ябылганнан соң С. Габиев, суд хөкеменнән качып, Дагстанга кайта. Вахитов кебек үк, крайның җәмәгать тормышында актив катнаша: большевиклар партиясе политикасын яклаучы прогрессив матбугат чыгара, җирле партия оешмаларын төзүдә катнаша, ә Бөек Октябрь социалистик революциясе җиңгәннән алып гомеренең соңгы көненә кадәр — социалистик дәүләтне актив төзүче һәм үзгәртеп коруга яңалык кертүче була. Мулланур һәм башка бик күпләр эшләп бетермәгәнне Сәид Габиев кебек аларның меңнәрчә көрәштәшләре дәвам иттерделәр.

**С. АКБИЕВ.**
**Дагстан АССР,**
**Каспийск шәһәре.**

[1] Даг. АССРның ҮДА. Р-ф 808, 1 билгеләмә, Саклау берәмлеге I, 52 бит.

[1] Шунда ук, 50 бит.

[2] М. Вахитовның С. Габиевка язган тагы ике хаты авторга билгеле түгел икән. Ул хатлар «Азат хатын» журналының 1959 елның 11 санында басылган. (Редакция).

# ӘДИПНЕҢ ЯҢА ТАБЫЛГАН БЕР РӘСЕМЕ



*Рәсемдә (сулдан): Мирхәйдәр Фәйзи, Җәләй Рәхмәтуллин.*

Кара диңгез пароходчылыгында «Баймак» исемен йөртә торган бер пароход бар. Ә Баймак шәһәре—Башкортстандагы район үзәге. Менә шуңа күрә дә әлеге теплоход командасы белән Баймак районы хезмәт ияләре үзара дустанә элемтәдә торалар. Узган ел да Баймак районыннан теплоходка тагын бер делегация барып кайтты. Шул сәфәр вакытында без Одесса шәһәрендә үз районыбызның егерменче еллар комсомолы Җәләй Рәхмәтуллинны очраттык. Заманында ул Түбә приискасында эшләгән, шуннан Совет Армиясенә алынган һәм үзенең бөтен гомерен диңгездә хезмәт итеп үткәргән. Җәләй Рәхмәтуллин хәзер пенсиядә, герой шәһәрдә яши.

Очрашуыбыз вакытында ул безгә Мирхәйдәр Фәйзи белән бергә төшкән рәсемен бүләк итте. Күренекле драматург ул елларда Түбә приискасында китапханә мөдире булып эшләгән. Җәләй Рәхмәтуллин белән алар рәсемгә Баймак каласына комсомол киңәшмәсенә килгәч төшкәннәр. Рәсемнең артына драматургның үз кулы белән: «Актив комсомолец Җәләй Рәхмәтуллинга. Мирхәйдәр Фәйзи. 21 июнь, 1925 ел. Баймак авылы»,— дип язылган.

Б. СӘМИГУЛЛИН,
Башкортстан АССРның
Баймак шәһәре.

## Әхмәт Исхак

### Үтенеч хаты

Казандагы радиога бер хат килгән.
«Сәлам, — дигән, — барчагызга ерак җирдән!
Моны,— дигән,— без язабыз ике брат:
Шәмсиевләр — Габдесаттар, Габделморат.
Икебез дә яшибез бер төштә,— дигән,—
Алдынгылар саналабыз эштә,— дигән.—
Үсеп килә улларыбыз, кызларыбыз.
Бик акыллы һәммәсе дә, юк зарыбыз.
Казанда бер техникумны без бетереп,
Киткән идек Кукмарага ун ел элек.
Шуннан бирле кайтканыбыз юк Казанга,
Табалмадык вакыт та һич хат язарга.
Калды анда карт инвалид әтиебез
Һәм шулай ук пенсионер әниебез.
Икесе дә гомер буе алар шунда
Эшләделәр бер үк эштә — тимер юлда.
Алардан да хат-хәбәр юк ун ел инде,
Хәлләрен һич белалмыйбыз шуннан бирле.
Бик сагындык аларның без икесен дә.
Шулар гына уебызда көн дә, төн дә.
Килеп җитә «Тимер юлчы көне» тиздән.
Шул көнне сез, бүләк итеп икебездән,
Тапшырсагыз иде алар сөйгән көйне —
Бик ярата иде алар «Әллүки»не.
Әгәр исән-сау булсалар, тыңлап бәлкем
Шатланырлар иде моңа чиксез ул көн».

### Көзгеләр турында

Бар иде шундый көзгеләр
Без яшьрәк заманнарда:
Чагыла иде чын йөзең
Бозылмый һич аларда.

Карасаң, битләр аларда
Күренә иде элек

Кабарып пешкән, шоп-шома
Тутырган тавык кебек.

Яңаклар — алма, иреннәр —
Чияләр төсле иде.
Энҗедәй тешләр турында
Әйтеп тә тормыйм инде!

Күз төшсә узып барышлый
Кайчакны шул көзгегә,
Тукталып торсаң, гаҗәпме
Сокланып үз йөзеңә!

Юк хәзер андый көзгеләр.
Уйлама табарга да.
Күңелең хәзергеләргә
Теләми карарга да.

Йөзеңне хәзерге көзге
Күрсәтә шундый бозып:
Һәр җирдә ниндидер сырлар,
Җыерчык, чокыр, сызык...

Күренә, кырау төшкәндәй,
Чәчләрең соры булып,
Тешләрең тора саргаеп,
Иреннәр — куырылып.

Кыскасы, салсаң күзеңне
Хәзерге һәр көзгегә,
Китәсең килә төкереп
Көзгегә һәм үзеңә.

Бу хәлне абайлыйсыздыр,
Кордашлар, үзегез дә...
Күрәсең, ясый белмиләр
Шәп көзге хәзер бездә!

## Кайсы яхшырак

*Халык мәзәге*

Сораганнар бер хәкимнән:
— Әйт әле безгә шуны:
Кайсы яхшырак синеңчә,
Теге дөньямы, бумы?

Шактый гына уйлап торгач,
Әйткән хәким боларга:
— Дөрес, әле барганым юк
Минем теге дөньяга.

Шулай да, минем уемча,
Яхшырактыр тегесе.
Ник дисәң, шунда китә дә
Кире кайтмый бер кеше.

Яхшырак булса бире,
Кайтырлар иде кире!

## Бәхәс

Бер заманны ике хәким бәхәсләшә:
— Җирдә бик тиз бозылучан әйбер нәрсә?
Берсе:— Балык,— дигәч, әйтә икенчесе:
— Ә минемчә, андый нәрсә җирдә кеше!

## Хуҗа Насретдин һәм кунак

Кайсыдыр илдән бер көнне
Хуҗага кунак килгән.
— Авыр икән өйрәнергә,
Ай-һай, сезнең тел, — дигән.

— Кемгә ничектер бит, — дигән
Хуҗа көлеп аңарга. —
Шул телдә сөйләшә бездә
Өч яшьлек балалар да!

## Ана шатлыгы

Балаларым бигрәк әйбәт, бигрәк шәп, ди.
Аш ашарга чакырсаң да әйбәтләп, ди,
«Ярар! Ярар!» диеп кенә акыралар,
Чыгармыйлар әрләп яки дөмбәсләп, ди.

## Төгәл баланс

Бу дөньяда кыен балалар күп.
Бернинди дә бәхәс монда юк.
Ләкин кыен ата-аналар да
Алардан аз түгел шулай ук!

## Ихтыяр көче

Булмаса әгәр ихтыяр көче,
Бернишли алмый юньләп ул кеше.
Була ул ялкау, була ялганчы,
Була алдакчы, куркак, эчкече
һ. б. һ. б....

## Шигырь сөючегә

Аңламасаң укыганда беренче кат,
Ул шигырьне икенче кат син укып бак.
Өченче кат укып торма. Нәтиҗә шул:
Я син мәнсез ул чагында, мәнсез я ул!

## Кагыйдә

Китапта — Кари,
Журналда — Карый.
Китапта — Бари,
Журналда — Барый.

Шундый бездә кагыйдә!
Ничек язсаң да ярый.

## Бер шагыйрьгә

Гомер өчен җиде шәһәр даулашкан:
— Ул туды,— дип,— миндә!
Синең өчен җиде шәһәр талаша:
— Юк, туды, — дип, — синдә!

# ОСЕТИН МӘЗӘКЛӘРЕ

## Сукыр күп күрер

Авыл уртасындагы мәйданда ирләр җыелышып утырган. Урам буйлап бер җайдак узып бара икән.

— Менә бу ат дисәң дә ат, ичмасам! Нинди матур! Атламый, ә биеп бара! — дип сокланалар җайдакның атына.

— Ә үзе тагын нинди көр! — дип өсти арада утырган бер сукыр.

— Син аны каян белдең? — диләр моңа.

— Көр булмаса, биемәс иде!..— ди сукыр.

## «Скрипка уйныйм...»

Бер карак кибет басмакчы була. Йозак элгечен игәү белән кисеп ятканда, аны каравылчы тота:

— Нишләвең бу, хөрмәтлем?

— Күрмисеңмени: скрипка уйныйм ич...

— Ә нишләп музыкасы ишетелми?

— Музыкасын... иртәгә ишетерсең,— ди карак, усал елмаеп.

## Тапкыр җавап

Арраби исемле бер кешә сусыз далада тегермән сала. Шуннан узып барган Зондоби аңардан сорый икән:

— Ни корасың бирәдә, Арраби?

— Үзең бик зирәк кешесең, ә менә минем су тегермәне салуымны төшенмисең.

Зондоби тирә-якка күз сала һәм, елга-фәлән күренмәгәч, кычкырып көлмәкче була, шулай да, Аррабины үпкәләтмәс өчен, дәшми генә юлыннан китеп бара. Арраби, аптырап, аның артыннан:

— Зондоби, нишләп син мине котламадың? — дип кычкыра.

— Котлавын котладым мин. Әмма син аны ишетмәдең — чөнки тегермән сала торган елгаң бик каты шаулап ага,— дип җавап бирә тегесе.

## «Шулай дип әйт!..»

Берәү күршесенә киңәшкә кергән:

— Карале, дустым, минем тәкә яткан җиреннән тора алмаслык булып симерде, ләкин мин аны суярга кызганам, дөресе, нишләргә икәнен дә белмим.

— Ә син аны суй да иртәгә: «тәкәмне урладылар...» дигән хәбәр тарат. Көтүчеләр сиңа аның бәясен түләрләр.

Шундый киңәш биргән абзый төнлә тәкәне үзе урлый. Тәмам аптырашта калган күршесе иртән тагын аның янына йөгереп керә:

— Төнлә тәкәмне урлаганнар!..

— Нәкъ менә шулай дип әйт тә инде син аны, күрше!..

— Шаяртмыйча гына, ышан әле: тәкәне чынлап та урлаганнар бит!

— Әйтәм бит: шулай диген! Синең шәп чыга ул, ышанырлык!..



## Ике кунак

Садти белән Бадти кунакка барганнар. Иттән соң табынга кайнар шулпа куела. Садти комсызланып шулпа каба да һәм еларлык булып авызын пешерә.

— Ни булды сиңа? — дип сорый Бадти.

— Өйдә ишәгемнең чирләп калганы исемә төште дә шуны кызганып куйдым,— ди Садти.

Бадти шул арада үзе дә ашыгып шулпа каба һәм шундук чырае сытыла.

— Ә сиңа ни булды? — дип сорый Садти.

— Синең ишәгеңнең бик кызганыч тавыш белән акыруын күз алдыма китергәч, минем дә кәеф кырылды...

## Гөнаһ кичерү

Бервакыт чиркәүдә гыйбадәт вакытында гөнаһын кичертергә килгән берәү попның җилән кесәсеннән сәгатен чәлдерә.

— Я, хода бәндәсе, әйт, нинди гөнаһларың бар? — дип сорый поп.

Әлеге кеше болай дип җавап бирә:

— Кайчандыр бер попның кесәсеннән сәгатен урлаган идем, шуннан артык һичнинди гөнаһым барлыгын белмим. Зинһар, шул булганын кичерсәгез икән.

Поп тамак төбе белән көйләп әйтә шунда:

— И таңрем, бу кешенең шул гөнаһын кичер!..

## «Бер дә исегез китмәсен!..»

Берәүнең абыйсы бик оста ялганчы икән. Агасына охшарга теләп, көннәрнең берендә ул да алдашырга керешә. Мәйданда утырганда болай дип сөйләп китә:

— Искитмәле бер могҗиза әйтим әле сезгә, дуслар: бүген урманда бер болан аттым, ядрәм шуның колагына, мөгезенең бер тармагы

очына һәм арт тоягына эләккән. Ә сунардан кайтканда күктә әнчек әргәнен ишеттем.

Бөтен кеше: «Ялган бу, ялган!» диләр. Шул чакны тегенең алдакчы абыйсы сүзгә керешә:

— Бер дә исегез китмәсен, җәмәгать! Минем энем боланга ул арт аягы белән колагын кашып торган чакта бик тәз аткан дип белергә кирәк моны...

— Ә ни өчен күктән эт өргәне ишетелгән? — дип сорый арадан берсе.

— Монысына да исегез китмәсен: әнчекне козгын алган булган, ә көчек исә күкнең биеклегеннән куркып бик каты өрә башлаган...

## Ике алдакчы

Лахци белән Тепсыр һәр вакыт бер-берсен алдашалар. Алдауларга бер заман алар шул чаклы күнегә, хәтта үз сүзләренә үзләре ышанмый башлыйлар.

Бер көнне Лахци Тепсырга әйтә икән:

— Минем әтинең ат абзары чамасыз озын булган: бер ишектән кергәндә каплатылган бия икенче ишектән чыкканда инде колынлый икән!..

— Ә безнең,— дип ялгап китә сүзне Тепсыр,— шулай ук бик озын колгабыз бар иде: яшенләп яңгыр килгәндә, әни куркыныч болытларны шул колга белән минут эчендә таратып өлгерә иде...

— Кая тота идегез соң ул колганы?

— Кая булсын: сезнең ат абзарыгыз чормасында!..

## Бәхәстә оттырды...

Саулах исемле абзый шобага салырга яки бәхәсләшергә бик ярата иде. Әмма аның өчен бу беркайчан да тапкырлык яки спорт бәйрәмнәрендә нинди дә булса осталык күрсәтү ярышы булмады. Ул бары тик... ашау һәм эчү мәсьәләсе тирәсендә генә бәхәсләшә иде.

Менә ул бу юлы да, бәхәсләшеп, бер үгез башы ашап бетерде, бер чиләк аракы эчте. Әмма барыбер оттырды: ризыкны корсагы сыйдыра алмаган, күрәсең — Саулах җан бирде.

Аны күмәргә халык җыелды. Менә мәрхүмнең табутын өйдән алып чыгалар. Табут артыннан үкереп елый-елый хатыны атлый. Кулында — бер курҗын аракы.

— Менә шуны да баш астына куегызчы, зинһар. Һәр вакыт шулай үтенеп яшәде ул,— ди хатын.

— Син нәрсә,— дип ачуланды аны карт,— матәмне көлке итәргә уйлыйсыңмы әллә? Үзен дөньядан алган агуны шул кешенең баш астына куй, имеш!

— Ярый инде, ярый, кичерегез. Мин бит бер нәрсәдән генә куркам: теге дөньяда исенә аракы төшкәч, кабат бирегә кайтмасын, дип уйлавым иде.

— Алайса, бер бәйләм кызыл борыч та куй инде, ул бит аракыны борычлап кына эчә иде,— дип шаяртты әлеге карт.

## «Тузан кагам!..»

Берәү базарга ап-ак итеп дуплаткан тун алып чыга. Ниндидер бер ир заты тунны киеп карый һәм, күрәсең, хуҗадан үч алып калыр өчен, тузанлы җиргә ятып ауный башлый: имеш, эче авыртуына түзә алмый. Тун иясе эшне бик тиз аңлап ала да шаянны таяк белән дөмбәсләргә керешә.

Тавышка халык җыела.

— Ни өчен кыйныйсың син аны? — дип сорыйлар.

— Әй сез яхшылабрак карагыз: мин бит үз тунымның тузанын кагам,— дип җавап бирә тун хуҗасы.

## Көтүче куйган шарт

Ниндидер усал бер башлык үз көтүчеләренең берсенә болай дип әмер бирә икән:

— Әгәр син бүген әнә теге ташның тиресен тунап миңа китермәсәң, мин синең үз тиреңне тунатачакмын!

— Яхшы, олуг башлыгым! Синең әмерне бер шарт белән үти алам: мин көтү куып кайтканчы, бүтән хезмәтчеләрең ул ташны суеп куйсыннар.

— Нинди ахмак ишәк син,— дип кычкыра башлык,— кемнең дә булса таш суйганын кайда күргәнең бар?

Ә көтүче аңа әйтә:

— И бөек хуҗам! Суярга мөмкин булмаган ташның тиресен тунатырга теләгән башлык, минемчә, кешеләрнең җирдә иң акыллысыдыр!..

## Пешекченең ялгышы

— Повар, повар, мин ике өлеш ит сораган идем, ә миңа берне генә китерделәр.

— Ах, гафу итегез инде: мин аны урталай кисәргә онытканмын бит!..

## Ызгыш нидән башлана...

— Әти, ызгыш нидән башлана? — дип сорый бер малай.

— Үзеннән-үзе башлана һәм бик гадәти нәрсә ул,— ди ата кеше.— Әйтик, мәсәлән, безнең сакляга әниеңнең этисе, ягъни синең бабаң Бибо, килеп керә дә юк-бар сөйләп бәйләнә башлый...

— Йом авызыңны, юньсез! — дип кычкыра малайның әнисе,— минем эти синең шикелле җәнҗалчы түгел ул!

— Мин болай гына, мисал өчен генә әйттем... Ә син үзең ник һәр төшкә тыкшынасың да, ник минем сүзгә кысыласың әле?

— Шуңа кысылам: сүзеңне уйлап әйтә торган бул, телең белән тегермән тарттырып юләр сатма.

— Үзең юләр син! Менә шул! — дип ярсып, ата кеше урыныннан сикереп тора...

— Я, җитте сезгә, ызгыш нидән башланганын белдем инде мин!..— дип, малай әткәсе белән әнкәсен тынычландыра башлый.

## Хәкимҗан Халиков

### Зиләнең курчагы

Зиләнең бер курчагы бар,
Сузып кына: «Ән-нә»,— ди.
Сеңелем аңа:— Әттәбезне
Яратмыйсың әллә? — ди.—
Сөеп кенә тора безне,
Беләсең бит әтине...
Я үпкәләр, аңа да бер
«Әт-тә» диеп әйт инде?

### Дәваладык

Бүген иртән Зиләнең
Ишетсәгез елавын:
— Болай үзем каты да
Тартмадым,— ди,— колагын...
Өзелде дә чыкты бит,
Нишләр инде куяным?!
Юатырга, ичмасам,
Әнисе дә юк аның.
Мескенемнең, җитмәсә,
Ирене дә китек,— ди.—
Үзен әйдә хәзер үк
Больницага илтик,— ди.—
Доктор апа ничек тә
Берәр җаен табар,— ди,—
Бәлки әле колак та
Тегеп куяр аңар,— ди.
— Кайда әле, Зилә,— дим,—
Безнең энә-җебебез?
Куяныңны, әйдә,— дим,—
Дәвалыйбыз үзебез.
...Үз колагы үзенә:
Тегеп куйдык тиз генә.
Кояш чыкты яңадан
Зиләбезнең йөзенә.
— Ишетер бит инде ул?..
— Ишетер,— дим,— ишетер...
Куян исә елмаеп
Торган кебек ничектер.

## Оныткан

— Ашарга да утыргансың,
Юындыңмы әле син?
— Әллә минем юынганны
Күрмәдеңме, әни, син?
Колакны да юдым бүген...
— Ә битеңне, битеңне?..
— Бәби түгел лә мин хәзер,
Юдым дидем бит инде.
— Алай булса, кулың нигә
Буялган соң буяуга?
— Онытылып калгандыр ул
Бит юганда юарга.

## Хикмәт

Чүп утыйбыз бакчада.
Маңгайдан тир акса да,
Су буена төшмибез:
— Бетсен әле эш,— дибез.

Хикмәт кенә сынатты,
«Эче-ем!» — диеп тик ятты.
Эш беткәнне көттеме,
Авыртуы беттеме —
Су керергә барганда,
Җитезе юк аннан да...
— Ә син,— дибез,— ятып тор,
Эчең тагын авыртыр.
— Борчылмагыз, түзәрмен,
Чалкан ятып йөзәрмен.

## Кем батыр?

Су коенып чыктык та,
Утырабыз чирәмдә.
Бәхәсләшеп киттек бит,
Кайтыйк кына дигәндә.
Ә бәхәскә килгәндә...

Әйтеп куйды Илгизәр:
— Беләсезме, кем батыр?
Ике сәгать буена
Шушы күлдә кем ятыр —
Шул булачак иң батыр.

Илгиз әйтә:— Мин батыр!..
Давыт исә:— Юк, мин,— ди.—
Үрдәк кебек, көн буе
Мин бит судан чыкмыйм,— ди,—
Аннан эреп йоклыйм,— ди.

Олыраклар:— Туктагыз,
Нишлисез соң сез?! — диләр...
Ә Илгизләр чалкан да,
Колачлап та йөзделәр,
Туңсалар да түзделәр.

Судан чыгып аннары
Өйләренә чаптылар.
Соңыннанмы? Соңыннан...
Бер ай чирләп яттылар.

## Нарат

Калку кырда бер нарат бар,
Ямь-яшел чатыр сыман.
Давылга да бирешми ул,
Нәкъ Алып батыр сыман.

Бер карасаң, кош шикелле
Җилпенеп куйган сыман,
Хәзер күккә күтәрелеп
Китәргә торган сыман.

Ә ерактан күренә ул
Яшел парашют сыман...
Бездән башка бер җирдә дә
Мондый нарат юк сыман.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНДА

Татарстан язучылар союзы идарәсе президиумының һәм партия бюросының берләштерелгән чираттагы утырышында Язучылар союзының кабул итү комиссиясе расланды. Комиссиянең председателе итеп А. М. Горький һәм Габдулла Тукай исемендәге премияләр лауреаты шагыйрь Сибгат Хәким, членнары итеп Аяз Гыйләҗев, Тихон Журавлев, Рәис Даутов, Нил Юзиев иптәшләр билгеләнде.

*
* *

Узган елның 23 октябрендә Язучылар союзы партия оешмасының отчет-сайлау җыелышы булды. Партия бюросының отчет докладыннан соң фикер алышуларда язучылардан Риза Ишморат, Ләбибә Ихсанова, Геннадий Паушкин, Туфан Миңнуллин, Рафаэль Мостафин, Галимҗан Латыйп, Гариф Ахунов иптәшләр катнашты. Партия оешмасының яңа бюросы сайланды. Аның составына Сибгат Хәким, Гариф Ахунов, Зәки Нури, Габдрахман Минский, Кояш Тимбикова, Юрий Белостоцкий һәм Вакыйф Нуруллин сайланды.

Яңа бюроның шул ук көнне үткәрелгән утырышында оештыру мәсьәләләре каралды. Партия оешмасының секретаре итеп Вакыйф Нуруллин сайланды.

*
* *

Язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында Татарстан АССР Министрлар Советы Председателе Г. И. Усманов язучылар һәм китап нәшрияты хезмәткәрләре белән очрашып, аларга республикабызда тугызынчы бишьеллык барышында башкарылган һәм башкарылырга тиешле эшләр турында сөйләде. Аннары очрашуда катнашкан иптәшләрнең күп кенә сорауларына җавап бирде.

*
* *

22 октябрьда язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында «Казан утлары» журналының 1974 елгы 1—6 саннарын тикшерүгә багышланган җыелыш үткәрелде. Журналның әлеге саннарында басылган әсәрләрне анализлауга багышланган докладларны Рафаил Төхфәтуллин (проза), Зөлфәт (поэзия), Нур Гыйззәтуллин (тәнкыйть), Диләрә Зөбәерова (очерк, публицистика) ясадылар. Фикер алышуларда М. Әмир, Г. Ахунов, Р. Мостафин, Ф. Хөсни иптәшләр катнашты.

## «ЯШЬ ЛЕНИНЧЫ»НЫҢ ОЛЫ ЮБИЛЕЕ

Узган елның октябрендә ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты һәм В. И. Ленин исемендәге Бөтенсоюз пионер оешмасының республика советы органы — «Яшь ленинчы» газетасының чыга башлавына 50 ел тулды. Шул уңай белән 9 октябрьдә Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрының тамаша залында яшь корреспондентларның республика слеты үткәрелде. Слетта КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев «Яшь ленинчы» редакциясе коллективын һәм яшь корреспондентларны газетаның 50 еллыгы белән котлады, киләчәктә тагын да зуррак иҗади уңышларга ирешүләрен теләде. Аннары иптәш Вәлиев «Яшь ленинчы» газетасы редакциясе коллективына КПССның Татарстан өлкә комитетының түбәндәге котлавын тапшырды.

*«КАДЕРЛЕ ИПТӘШЛӘР!*

*КПСС өлкә комитеты сезне — журналистларны — пионер матбугаты активистларын, балалар язучыларын һәм республиканың күп меңләгән яшь ленинчылар армиясен олы бәйрәм — «Яшь ленинчы» газетасының 50 еллыгы белән чын күңелдән котлый.*

*Ярты гасыр буена «Яшь ленинчы» газетасы яшь буынны коммунистик идеаллар рухында, совет патриотизмы һәм интернационализм рухында тәрбияләп килде, балаларның дусты һәм киңәшчесе булды, пионерларны һәм мәктәп балаларын яңа җәмгыятьне төзүгә лаеклы кешеләр булырга, партиябезгә һәм халкыбызга, бөек Ватаныбызга, коммунизм эшенә лаеклы булырга өйрәтте.*

*Газета һәр вакыт илебез һәм республикабыз тормышы белән тыгыз бәйләнештә тора, шәһәр һәм авыл хезмәт ияләренең мактаулы эше турында кызыклы һәм мавыктыргыч итеп сөйли, балаларда хезмәткә һәм эшче профессиясенә карата, материаль һәм рухи байлык тудыручыларга карата хөрмәт тәрбияли, яшь ленинчыларның күп төрле иҗтимагый-файдалы эшләренең инициаторы булып тора, республикада пионерия хәрәкәтенең киң үсешенә булыша.*

*Газетаның, аның барлык активистларының бурычы — киләчәктә дә Коммунистлар партиясе эше өчен идея ягыннан иманган, тирән белемле, югары аңлы көрәшчеләр*

*тәрбияләү, КПСС-ның XXIV съезды карарларын үтәүдә үз өлешен кертү.*

*«Яшь ленинчы» газетасының данлы юбилее көнендә сезгә, кадерле иптәшләр, сезнең изге эшегездә зур иҗади уңышлар, нык сәламәтлек, бәхет телибез».*

Татарстан язучылары исеменнән юбилярны Язучылар союзы председателе, Тукай премиясе лауреаты Гариф Ахунов котлады.

«Яшь ленинчы» газетасына тапшырылган адреста түбәндәге сүзләр бар иде:

*«В. И. Ленин эшләренең, республикабыз тормышының, әдәбиятыбызның балалар күңелендәге тантанасы булып гел яшәр газетабыз син, «Яшь ленинчы»!*

*Син заман белән бер адымда барып ярты гасырлык гомер юлы уздың. Син һәр вакыт үзеңнең замандашларыңны — октябрятларны, пионерларны һәм яшь комсомолларны — якын һәм ерак дусны яратырга, илгә тугры булырга, физик һәм рухи яктан көчле булып үсәргә, батырларча яши белергә өйрәтәсең. Татарстан язучылары өчен шунысы куанычлы, син балаларның якын дуслары булган совет язучылары белән кулга-кул тотынып эшлисең. Бүгенге көндә совет кешеләренең героик символы булып әверелгән Муса Җәлил һәм Абдулла Алиш кебек язучылар синең битләреңә аша укучы белән сөйләштеләр. Син әле хәзер дә Татарстанның танылган язучылары әйткән кайнар сүзләрне укучыга җиткерәсең, яңа гына кулына каләм алган яшь язучыларга чыныгу мәктәбе булып торасың.*

*Синең гаҗәеп бер үзенчәлегең шунда ки, син бүген илле яшьлек язучыларга гына түгел, әдәбиятыбызның аксакалларына да, урта һәм яшь буын язучыларга да, мәктәп стена газеталарында беренче әдәби сүзләрен әйтүчеләргә дә яшьтәш! Шуңа күрә сине барыбыз да яратабыз, без барыбыз да синең укучылар.*

*Кадерле яшьтәшебез «Яшь ленинчы»!*

*Сине гүзәл бәйрәмең белән котлыйбыз, олы юбилееңны үзебезнең бәйрәм итеп кабул итәбез һәм сиңа бәйрәмчә матур теләкләрдә калабыз. Һаман үсештә бул, сөекле газетабыз, безне шатландырып яшә һәм яшәгән саен яшәрә бар».*

*
* *

Слетка килгән яшь корреспондентлар партиянең Татарстан өлкә комитеты нәшриятының утырышлар залында язучылар һәм журналистлар белән очраштылар.

Очрашуда катнашкан Сибгат Хәким, Нәби Дәүли, Хәсән Сарьян, Гәрәй Рәхим, Ләбибә Ихсанова, Равил Фәйзуллин, Рөстәм Мингалимов, Хәкимҗан Халиков һ. б. иптәшләр пионерларны үзләренең язучылык эшендә булган хәлләр белән таныштырдылар.

## ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР, ОЧРАШУЛАР

Язучылардан Риза Ишморат, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Рәдиф Гатауллин, баянчы Марс Макаров, җырчы Рафаэль Ильясов Әгерҗе районында булып кайттылар. Алар кыр батырларының район слетында катнашып, колхоз алдынгыларын үзләренең яңа әсәрләре белән таныштырдылар. Колхозларга барып, авыл клубларында һәм мәктәпләрендә әдәби кичәләр һәм очрашулар үткәрделәр. Әдипләр һәм артистлар китап сөючеләр белән очрашулар үткәргән көннәрдә алдагы ел өчен «Казан утлары» журналына язылучылар аеруча күп булды. Районның байтак кына колхоз идарәләре үзләренең алдынгы механизаторларын, сыер савучыларын һәм актив агитаторларын, бүләк итеп, колхоз хисабына бер елга «Казан утлары» журналына яздырдылар. Мәсәлән, Пушкин исемендәге (председателе Хәммәт Исмәгыйлов, партком секретаре Мидхәт Исламов), Чапаев исемендәге (председателе Мохтар Шабаев, партком секретаре Рәйсә Низамбиева), «Рассвет» (председателе Касыйм Мөлеков, партком секретаре Сәгыйт Тутаев), «Таң» (председателе Равил Мингалиев, партком секретаре Гариф Гыймранов), «Татарстан» (председателе Әнвәр Шәмсетдинов, партком секретаре Нургали Мурзин), Жданов исемендәге (председателе Котдус Салахиев, партком секретаре Сәгыйр Гобәйдуллин) колхозлар идарәләре үзләренең алдынгы колхозчыларын «Казан утлары» журналының бер еллык подпискасы белән бүләкләделәр.

*
* *

Яшь шагыйрь Роберт Миңнуллин Куйбышев өлкәсенең Кошка районы, Иске Фәйзулла авылында яшәүче авыру шагыйрь Гакыйл Сәгыйров янына барып кайтты. Ул Гакыйльне әдәбиятыбыздагы яңалыклар белән таныштырды һәм шагыйрьнең яңа шигырьләрен алып кайтып, «Яшь ленинчы» газетасында бастырып чыгарды.

*
* *

Әдипләребездән Гомәр Бәширов һәм Барлас Камалов Актаныш районында булып кайттылар. Алар культура работникларының район киңәшмәсендә катнаштылар һәм чыгыш ясадылар. Татар Әҗбие, Татар Суксуы һәм Мари Суксу мәктәпләре укучылары һәм «Гигант» колхозы хезмәт ияләре белән әдәби очрашу үткәрделәр. Г. Бәширов Актаныш районының «Коммунизмга», «Авангард» колхозларында һәм Мөслим районының «Маяк», Вахитов исемендәге колхозларында да булып, хезмәт ияләре белән әңгәмәләр алып барды.

*
* *

Г. Паушкин — республикабыз укучыларына яхшы таныш журналист һәм язучы. Соңгы елларда ул КамАЗ автогиганты төзүчеләре янында еш булды, алар турында очерклар, зарисовкалар иҗат итте.

«Ливадия» ял йортында ял итүчеләр белән очрашу вакытында Г. Паушкин үзе-

нең иҗаты, КамАЗ геройлары турында сөйләде, китап укучыларны кызыксындырган күп кенә сорауларга җаваплар бирде.

*

* *

Шагыйрьләрдән Рәшит Әхмәтҗанов, Фаил Шәфигуллин, баянчы Марс Макаров, җырчы Разия Гайнуллина республикабызның Чирмешән районы авылларында әдәби-музыкаль кичәләр үткәреп кайттылар. Ул кичәләр бөтен союз авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре көненә әзерлек барган чорга туры килде. Шул форсаттан файдаланып, колхоз житәкчеләре һәм партоешма секретарьлары әлеге әдәби кичәләрдә үз колхозларының хезмәттә алдынгы кешеләрен «Казан утлары» журналына подписка белән бүләкләделәр. «Жданов» (партоешма секретаре Сәләхетдинов Газимҗан, председателе Мисбахов Акдәс), «Киров» (партоешма секретаре Гыйләҗев Арслан, председателе Кәлимуллин Сираж), «50 лет Октября» (партоешма секретаре Шакиров Габдрәүф, председателе Билалов Тәүфыйк), «Алга» (партоешма секретаре Гайсамов Зөфәр, председателе Фәсхетдинов Радик), «Урал» (партоешма секретаре Җиһаншин Мөхтәр, председателе Фәттахов Минхәт), «Чишмә» (партоешма секретаре Шәрәпов Гомәр, председателе Әхмәтҗанов Кәрам) колхозларының һәркайсында алдынгы колхозчыга, бүләк итеп, колхоз хисабына «Казан утлары»на еллык подписка тапшырылды.

## «МОАБИТ ДӘФТӘРЕ» БЕЛОРУС ТЕЛЕНДӘ

Муса Җәлил тарафыннан халкыбыз өчен авыр сынау көннәрендә язылган шигырьләрнең һәр юлы совет кешесенең батырлыгына, чыдамлылыгына гимн булып яңгырый.

Белорус укучылары Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлил әсәрләрен тиздән үз телләрендә укый алачак: «Мастацкая литература» нәшрияты 1975 елда чыгару өчен аның «Моабит дәфтәре»н әзерләде.

## КОНКУРС НӘТИҖӘЛӘРЕ

Комсомол-яшьләрнең фидакарь хезмәтләрен чагылдыручы очеркларның идея эчтәлеген һәм сәнгатьчә эшләнешен яхшырту максатыннан чыгып, ВЛКСМ өлкә комитеты бюросы карары нигезендә «70 нче еллар Корчагиннары» девизы астында иң яхшы очеркка конкурс игълан ителгән иде. Конкурс барышында «Татарстан яшьләре» һәм «Комсомолец Татарии» газеталары битләрендә 11 авторның 12 очеркы басылды. Конкурс йомгаклары буенча жюри тәкъдимен карап тикшергәннән соң, ВЛКСМ өлкә комитеты бюросы «Запастагы лейтенант», «Безнең урамдагы Ринат абый» очерклары авторы С. Хәйретдиновны һәм «Мин һәм бригада» дигән темага сочинение» очеркы авторы Т. Воронова-Чернованы җиңүче дип тапты. Алар «Волга» халыкара яшьләр лагеренда ял итү өчен путевка белән бүләкләнделәр.

ВЛКСМ өлкә комитеты бюросы Р. Халитовның «Хезмәт хакын белмәүче отряд», Ш. Маннаповның «Люданың туган көннәре», М. Сальтинаның «Тормыш юллары гел такыр булмый», М. Хөснимәрдәновның «Аңлатмалы хатлар» очеркларының сәнгатьчә яхшы эшләнешен билгеләп үтте. Алар конкурста актив катнашканнары өчен ВЛКСМ өлкә комитетының Почет грамоталары белән бүләкләнделәр.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

РСФСР Верховный Советы Президиумының 1974 ел, 23 сентябрьдә игълан ителгән Указы нигезендә, совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен композитор **Хөснулла Вәлиулла улы Вәлиуллинга** (Хөснул Вәлиуллин) **РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе** дигән мактаулы исем бирелде.

*

* *

РСФСР Верховный Советы Президиумының 1974 ел, 2 октябрьда чыккан Указы нигезендә, совет сынлы сәнгатен үстерү өлкәсендәге хезмәтләре өчен республикабыз художнигы **Кондрат Евдокимович Максимовка РСФСРның** атказанган **художнигы** дигән мактаулы исем бирелде.

*

* *

«Яшь ленинчы» газетасының чыга башлавына 50 ел тулу уңае белән һәм балалар матбугатын үстерүдәге хезмәтләре өчен «Яшь ленинчы» газетасының редакторы **Венера Фәиз кызы Ихсановага** һәм газетаның җаваплы секретаре **Саимә Ибраһим кызы Ибраһимовага** Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1974 ел, 8 октябрьда игълан ителгән Указы нигезендә, **Татарстан АССРның атказанган культура работнигы** дигән мактаулы исем бирелде.

*

* *

Совет театр сәнгате өлкәсендәге уңышлары өчен Ленин комсомолы исемендәге яшь тамашачылар театры артисткасы **Анна Ивановна Никитинага Татарстан АССРның атказанган артисткасы** дигән мактаулы исем бирелде.

*

* *

Совет культурасы өлкәсендәге һәм хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләүдәге хезмәтләре өчен Әлмәт дәүләт драма театры директоры **Фазыл Хәйретдин улы Хәмәтдиновка Татарстан АССРның атказанган культура работнигы** дигән мактаулы исем бирелде.

*

* *

Яшьләр арасында нәтиҗәле тәрбия эше өчен һәм «Яшь ленинчы» газетасының 50 еллыгы уңае белән редакциянең бүлек мөдире Илгизәр Кәли кызы Сәмигуллина Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән, Нургали Хөсәен улы Булатов (бүлек мөдире), Мәҗит Әһли улы Вәлиуллин (өлкән корреспондент) Татарстан АССР Министрлар Советының Почет грамотасы белән бүләкләнделәр.

*

* *

Үзләренең әсәрләре белән «Яшь ленинчы» газетасында актив катнашып, яшь буынны коммунистик рухта тәрбияләргә булышлык иткәннәре өчен һәм газетаның 50 еллыгы уңае белән әдипләребездән Гариф Ахунов, Ләбибә Ихсанова, Равил Фәйзуллин, Ринат Харисов ВЛКСМ Үзәк Комитетының Почет грамотасы белән бүләкләнделәр. Күп кенә язучыларга «Яшь ленинчы»ның Юбилей грамотасы тапшырылды.

## ЯҢА КИТАПЛАР

Татарстан китап нәшриятында татар әдәбияты классигы Шәриф Камалның өч томлык сайланма әсәрләренең беренче томы басылып чыкты. Беренче томга язучының хикәяләре, «Акчарлаклар» повесте һәм «Таң атканда» романы кергән. Язучының популяр әсәрләреннән тыш, анда авторның «Хәйри — комсомол», «Адәм усә» һәм башка аз билгеле булган хикәяләре дә урын алган.

Сайланма әсәрләрне Гази Кашшаф һәм Ибраһим Нуруллин төзегән, Шәриф Камал турында кереш сүзне Ибраһим Нуруллин язган.

Тиздән Шәриф Камалның сайланма әсәрләренең икенче томы да басылып, укучыларга барып җитәчәк.

*

* *

Мәскәүнең «Советская Россия» нәшриятында Г. Тукайның «Шүрәле» поэмасы басылып чыкты. Поэманы шагыйрь С. Липкин тәрҗемә иткән. Рәсемнәрен Ленинград художнигы Фәйзерахман Әминов эшләгән.

## УҢЫШЛЫ ЧЫГЫШЛАР

ТАССР дәүләт җыр һәм бию ансамбле, Мәскәүдәге уңышлы концерттан соң Горький шәһәрендә булып, тамашачыларга өч концерт бирде. Программада илебез һәм татар совет композиторлары әсәрләре, халык җырлары һәм биюләре иде. Аларны 10 меңгә якын кеше тыңлады.

## КЫЗЫКСЫНЫП КАРАДЫЛАР

Башкорт дәүләт курчак театры республикабызның Бөгелмә, Әлмәт, Азнакай, Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрендә гастрольдә булып китте. Театр коллективы «Зәңгәр мәрҗәннәр» («Тормышка ашкан өметләр утравы») спектаклен алып килгән иде. Башкортстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Қ. Гаделшин тарафыннан сәхнәгә куелган ул спектакльне нәни тамашачылар яратып карады.

*

* *

Бөгелмәнең крайны өйрәнү музеенда художник Николай Осокин әсәрләренең күргәзмәсе булып үтте. Анда Н. Осокинның алтмышлап әсәре куелган булып, шулар арасында промышленность темасына ясалганнары да («Баулы калкулыклары», «Карьерда»), пейзажлар да («Кыр», «Март», «Якшәмбе көнне», «Каеннар»), портретлар һәм натюрмортлар да бар иде. Күргәзмә художникның якташлары — бөгелмәлеләрдә җылы тәэсир калдырды.

# БЕЗНЕҢ РӘХМӘТЕБЕЗ

«Казан утлары» журналын үз өйләренә алдырып укучылар саны гел арта килә. 1965 елда ул 24500 данә тираж белән басылган булса, быел аңа 90500 кеше язылды. Димәк, аның битләрендә басылган роман һәм повестьлар, хикәя, поэма һәм шигырьләр, очерклар һәм тәнкыйть мәкаләләре, культурабызга, тарихыбызга кагылышлы һәм күп төрле башка материаллар укучыларның күңеленә хуш килә дигән сүз. Шул ук вакытта бу факт халкыбызның материаль һәм культура дәрәҗәсе үсә баруы турында да сөйли.

Журналның һаман киңрәк тарала һәм популярлаша баруында «Союзпечать» бүлекләре һәм агентлыкларының, элемтә бүлекләре хезмәткәрләренең һәм, барыннан да бигрәк, җәмәгать тәртибендә газета-журнал таратучы иптәшләрнең дә өлеше зур. Алар, журналны үзләре уку белән генә чикләнмичә, аны үз хезмәттәшләренә, туганнарына һәм танышбелешләренә укырга тәкъдим итәләр, журналга язылырга практик рәвештә ярдәм күрсәтәләр.

Бу ел өчен газета-журналларга язылу чорында тагын бер гыйбрәт алырдай яңалык булды. Республикабызның күп кенә колхоз һәм совхоз идарәләре үз коллективларының алдынгы механизаторларын, ферма эшчеләрен һәм төзүчеләрен журналга еллык подписка белән бүләкләделәр. Нәтиҗәдә Татарстанда журналга язылучылар өч мең ярымга артты. Бу ел аны республикабызда 31629 кеше алдырачак.

Безнең укучыларыбыз Советлар Союзының бик күп шәһәр һәм авылларында яши. Үзбәкстан, Кыргызстан, Казагыстан, Таҗикстан, Төркмәнстан союздаш республикаларында, Оренбург, Пермь, Куйбышев, Чита, Чиләбе, Төмән, Свердловск, Горький, Ульяновск өлкәләрендә һәм башка якларда аны яздырып алып укучылар — меңнәрчә. Күбрәге, әлбәттә, һәр вакыттагыча, иң якын күршебез Башкортстанда була. Бу ел анда безнең журналга 24435 кеше язылды.

**Журналыбызны таратуда турыдан-туры актив катнашкан һәм шул эшкә булышлык иткән иптәшләрнең барысына да** редакция һәм редколлегия Татарстан язучылар союзы идарәсе һәм барлык татар әдипләре ис меннән **зур рәхмәт белдерәбез!**

Яңа елда аларга эштә яңа уңышлар һәм тормышта яңа куанычлар телибез!

Безнең журналга аны елның теләсә кайсы аенда ала башларлык итеп, илебезнең теләсә кайсы почта бүлегендә язылырга мөмкин. Бөтенсоюз каталогына ул 73210 номерлы индекс белән теркәлгән.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210